ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2005



## Хөрмәтле укучыларыбыз!

Киләсе елның февраль аенда “Казан утлары” журналының меңенче (1000!) саны чыгачак. Күңелләрдә горурлык уята торган вакыйга бу: сүз—халкыбыз рухи тарихының зур бер дәверен үз эченә алган мең томлык хәзинә турында бара. Журналыбызның чишмә башы булып 1922 елда чыга башлаган “Безнең юл” басмасы санала. Дөрес, совет чорына кадәр дә әдәби журналларыбыз булган безнең: “Әлгасрелҗәдит”, “Шура”, “Аң”... Әмма аларның гомерләре озын түгел, дөнья күргән саннары, төрле сәбәпләр аркасында, 200-250дән артмый.

“Казан утлары”—матбугатыбыз тарихында уникаль басма: афәтле репрессия, дәһшәтле сугыш елларында күп газет-журналлар ябылып, тукталып калганда да ул, язмыш тарафыннан нәселне саклап калу өчен сайланган таза күзәнәкле зат кебек, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклады, халык тарихы елъязмасы рәвешендә өзелмичә яшәвен дәвам итә алды.

Меңенче! Тарихта тирән эзле халык буларак, без мондый зур түгәрәк саннарга күнегеп барабыз шикелле. Казан шәһәренең мең еллыгы, мең елларга сузылган әдәбият, һәм ниһаять, журналыбызның меңенче саны... Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: быел басма матбугатыбыз барлыкка килүгә дә бер гасыр булды. Мөһим даталар, күркәм юбилейлар.

Журналыбызның меңенче саны чыгуны да, республикабыз җитәкчеләре һәм җәмәгатьчелек ярдәмендә, зур итеп, милли матбугатыбыз бәйрәме итеп уздырырга җыенабыз. Бу җәһәттән шактый оештыру эшләре алып барыла инде.

Әлеге бәйрәм, кадерле укучыларыбыз, бергә-бергә, уртак бәйрәмебез булып үтәр һәм араларны тагын да якынайта төшәр дип ышанабыз.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*“Казан утлары” журналының баш мөхәррире.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2005

# 10

(996)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Галимҗан Гыйльманов, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир— 292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары— 292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс** — (8432) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Зинһар, югалма... *Повесть.* ..... 5
Нур ӘХМӘДИЕВ. Безнең дөнья. *Шигырьләр.* ..... 52
Вахит ИМАМОВ. Казан дастаны. *Тарихи роман.* ..... 57
Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА. Ак сарайда серләр бар. *Поэма.* ..... 102
Риф БӘДРИ. Ярыктагы кояш. *Шук повесть.* ..... 113
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Көзнең нурлы нәкыше. *Шигырьләр.* ..... 138

**ҖӘУДӘТ ДӘРЗАМАНГА 60 ЯШЬ**

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Самими шагыйрь ..... 133
Җәүдәт ДӘРЗАМАН. *Шигырьләр* ..... 135

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Фәрит БӘШИР. Сүз кадере ..... 142

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге ..... 152

**ТАРИХ**

Тәлгат НАСЫЙРОВ. Октябрь һәм эзәрлекләнгән татар матбугаты ..... 157

"Татар энциклопедиясе" битләреннән ..... 176

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Равил ВӘЛИ. Башкала серләрен ача. ..... 178

Котлыйбыз! ..... 183
Безнең календарь. ..... 184
"Казан утлары" архивыннан. ..... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": исторический роман В. ИМАМОВА "Дастан о Казани" (окончание), повести Р. АБДУЛХАКОВОЙ "Пожалуйста, не пропадай...", Р. БАДРИ "Солнце в щели", стихи Н. АХМАДИЕВА, Х. МУДАРРИСОВОЙ.
"К 60-летию Дж. Дарзамана": статья Г. ГИЛЬМАНОВА и стихи поэта.
Дискуссия "Герой нашего времени": статья Ф. БАШИРОВА "Цена слова".
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"История": статья Т. НАСЫРОВА "Октябрь и татарская печать".
"Книжное обозрение": Р. ВАЛИЕВ рецензирует книгу "История Казани в документах и материалах. XX век".
Наши юбиляры: М. Насыбуллину 80 лет.
Наш календарь.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На обложках: Татарский государственный гуманитарно-педагогический университет. Фото С. Исхакова; писатель и актер Х. Залялов.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: historical novel by V. IMAMOV «Dastan about Kazan» (ending), stories by R. ABDULHAKOVA «Please, don't leave...», R. BADRI «Sun in crack», verses by N. AHMADIEV, H. MUDARRISOVA.
«To 60th anniversary of J. Darzaman»: article by G. GILMANOV and verses of poet.
Discussion «Hero of our time»: article by F. BASHIROV «Price of word».
«Science»: A. Timergalin «Dictionary of nation».
«History»: article by T. NASIROV «October and Tatar press».
«Book review»: R. Valiev reviews the book «History of Kazan in documents and materials. 20th century».
Our jubilees: M. Nasybullin is 80 years old.
Our calendar.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On covers: Kazan state humanitarian-pedagogical university. Photo by S. Ishakov; writer H. Zalalov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.09.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А–680. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



**Рәмзия Габделхакова**

# ЗИНҺАР, ЮГАЛМА...

ПОВЕСТЬ

Бу йортка нишләптер озак кагылмадылар. Югыйсә ул күптән буш иде. Буш һәм шыксыз иде. Штукатурлары кубып төшкән ала-кола диварлары, пыяласыз, караңгы тәрәзә уемнары урам йөзен бозып тора. Кичләрен кешеләр бу йортны урап-әйләнеп үтәргә тырышалар.

Ни өчен шундый иләмсез, тузган йортны карачкы урынына тоталардыр, шәһәр халкы моны аңламый һәм һәрвакыттагыча "нәчәлство"ны ду китереп сүгә. Берәүләре әлеге бинаны ремонтлап, кибет итмәкче булалар, дисә, икенчеләре бу урынны берәр "эшкуары" үзенә йорт салыр өчен саклап тора дип тә сөйләнәләр иде.

Әмма йортны буш дип уйлаучылар ялгыша иделәр. Әлеге ташландык йортның караңгы подвалында ике үсмер малай җан асрап ята. Аның берсе—чегәннеке кебек кара чәчле, каратут йөзле унөч яшьлек Рәмис, ә икенчесе—җирән Мишка. Ул Рәмистән яшьрәк тә, гәүдәгә дә кайтыш, әмма әрсезлеге, үткенлеге, җитезлеге белән татар малаен күпкә уздыра. Аның тагын бер өстенлеге бар: Мишка подвалдан кайчан тели—шунда чыга, кая тели, шунда бара. Аны монда этем дә белми. Ә Рәмис, теләсә-теләмәсә дә, көннәр буе караңгы оясында качып ятарга мәҗбүр. Чөнки аны эзлиләр. Ул—балалар йортыннан качты. Анда болай начар түгел үзе... Ашаталар да, киендерәләр дә... Тик яратмыйлар гына. Тәрбиячеләр кимсетә, зуррак малайлар да гел мыскыллап, чеметеп тора. Йодрык белән менеп төшәргә дә күп сорамыйлар. Рәмисне иң рәнҗеткән нәрсә шул булды: бүлмәдәшләре әнисенең хатларын урладылар да, күз алдында ерткалап та ташладылар. Имеш, "каля-баля", бернәрсә аңлашылмый. Татар телендә яза шул әнисе. Хаты саен: "Гафу ит, улым, гафу ит..." Төрмәдә утыра ул. Әтисен үтергән өчен утырттылар. Тик барыбер әнисен гаепләми Рәмис. Аларның өендә беркайчан да тынычлык

---

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА – *шагыйрә, прозаик; "Көзге яшен" һәм башка китаплар авторы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

булмады. Гел талаш-сугыш. Әтисе исереп кайта да, әнисен кыйный. Башта Рәмис куркып елый иде, аннары әнисен яклый башлады. Фаҗига булган көнне дә: "тимә әнигә", дип араларына кереп баскан иде. Әтисе кан баскан күзләрен акайтып: "Көчек, син дә миңа каршымыни?! Үтерәм, суям!"— дип акыра-бакыра Рәмиснең бугазына килеп ябышты. Тыны кысылды, хәле бетте малайның, күз аллары караңгыланды. Шулчак әтисе үзәк өзгеч тавыш белән акырып җибәрде дә, бармакларын Рәмиснең муеныннан ычкындырды. Икенче мизгелдә ул идәнгә капланган, аркасында пычак тырпаеп тора иде...

Әнисен төрмәгә утырткач, Рәмисне балалар йортына тапшырдылар. Өч ай да түзмәде анда Рәмис, качты. Башта бакчаларда кача-поса яшәде, шундагы җиләк-җимеш, бакчачылар калдырып киткән азык-төлек белән туенды. Көз җитеп, бакчалар бушап калгач, суык белән ачлык аны кешеләр янына, шәһәргә куып кайтарды.

Рәмис төннәрен чүп савытларында актарынды, көндезләрен исә подвалларга кереп яшеренде. Миша белән дә чүп савытын актарып маташканда танышты ул. Уртак язмышлы ике малай уртак телне тиз таптылар. Шулай итеп Рәмис иптәшле дә, оялы да булып куйды. Миша шәһәр кырыендагы ташландык йорт подвалында яхшы гына урнашкан, такта кисәкләре, чүплеккә чыгарып ташланган иске-москы җиһазлар, чүпрәк-чапраклар җыеп, караңгы подвалның бер кечкенә генә бүлмәсен җан асрарлык хәлгә китергән иде.

Мишка дөньяда әтисе бар икәнен белә, тик ул серле затны гомерендә бер тапкыр да күргәне юк. Әтисе үзенең дөньяда барлыгын айга бер тапкыр гына исенә төшерә. Бу көнне Мишкалар өендә бәйрәм була. Әнисе бер бүлмәле кысан фатирга үзенең дус-ишләрен җыеп кайта. Ул көнне Мишкага монда урын калмый. Хәер, бәйрәм көнен дә, төнен дә дәвам итә. Әтисе җибәргән алимент акчасы күпмегә җитә, бәйрәм дә шул чаклы дәвам итә. Мишканың ачлы-туклы йөрүендә исерек ананың эше юк, бары аяк астында чуалмасын, бары комачауламасын гына. Бар урамга! Ә урамның күңеле киң, колачы иркен. Ул барысын да сыйдыра. Урамда, ишегалларында без киноларда да күрмәгән гаҗәеп серле бер тормыш бара. Үзеннән олырак малайлар Мишканың авызына тәмәке кабызып тыктылар, аның буыла-буыла ютәлләвеннән кызык табып авыз ердылар. Икенче юлы аңа көчли-көчли аракы эчерделәр. Томан эчендә йөздә малай, дөнья дингезендә баткан кораб сыман чайкалды. Ахырда ул тәмәкегә дә, аракыга да ияләште. Урамда кызык иде, өйгә кайтып та керәсе килми башлады. Яңа иптәшләрен ошатты ул, аларга сокланды, шулар кебек бәйсез, кыю, үткен буласы килде. Кимсетсәләр дә, кыйнасалар да һаман шул компания тирәсендә чуалды, тегеләрнең йомышларына чапты. Тора-бара аны үз иттеләр, үзләре белән "төнге эш"ләргә дә ала башладылар. Ниһаять, Мишка туйганчы ашый алды. Элек күз генә кыздырып йөргән тәмле әйберләр бернинди акчасыз, җиңел генә аның кесәсенә күчте. Яңа дуслары: "Син әле кечкенә, синә берни булмый",—дип аны дәртләндереп тордылар. Алар авызыннан ишетелгән: "Молодец, болай булгач син безнеке",—дигән сүзләр Мишка өчен иң зур бүләкләрдән дә кыйммәтрәк иде.

Әмма дә бер киоскны басарга җыенганда, каршыларына каравылчы килеп чыкты. "Батыр"лар да куркып калмады, шалт тегенең башына тимер кисәге белән... Каравылчы карт шапылдап җиргә ауды, башыннан аккан кан асфальтка җәелде...

Шул төнне Мишка качты. Туп-туры вокзалга йөгерде. Товар поездына утырып, кая барганын да белмичә Казаннан чыгып качты. Поезд аны Яртау шәһәренә алып килде. Монда аны беркем дә белми, беркем танымый иде.

* * *

Иртәгә хакимияте яңа бинага күчте. Тавыш-тынсыз, ыгы-зыгысыз, тыныч кына күчте. Казаннан зур кунаклар килмәде, ал тасмалар киселмәде. Илленче елларда ук төзелгән ике катлы ак йорт та, машиналар өзелмәгән алгы мәйданчык та бушап калды. Тик мәйдан уртасында хуҗаларча киерелеп басып торучы Ленин бабай гына элеккечә кулын сузып: "Әйдәгез-әйдәгез" дип чакырган сыман тора иде.

Әле яңа гына ялдан кайтып төшкән Газинур Корбанов хакимиятнең күчүе хакында хәбәрдар булмыйча, элекке гадәт белән иске бинага килде. Ишектәге белдерүне укыса да, китәргә ашыкмады. Кырыйга китеп, байтак кына басып, нидер күзәтеп торды. Аннары икенче якка барып басты, элеккеге шәһәр комитеты бинасын хәтерендә ныграк калдырырга теләгәндәй, тагын карады—күзәтте. Ул да булмады, бина артына чыкты. Анда исә җанлылык сизелә. Арткы ишек янында ак "Газель" тора, зәңгәр халатлы ике егет эчтән төргәк-төргәк кәгазь ташыйлар, шуларны машинага төйиләр иде.

Газинур бина эченә үтте. Буш бүлмәләрне, утырышлар залын айкап чыкты. Сәер хәл, яңа төзелгән, әле тапшырылмаган буш йортка керсәң, ниндидер шатлыклы, тантаналы хис кичерәсең, менә бирегә бәхетле кешеләр килеп урнашыр, тормыш кайнар, шат авазлар яңгырар дип сөенәсең. Ә инде кеше яшәп киткән буш йортта, гәрчә ул әле бик иске булмаса да, күңелне ниндидер сагыш баса, йорт үзе дә моңсуланып калгандыр сыман тоела.

Шушы бинаны сатып алырга җыенган сыман һәр почмагын айкап чыккач, Газинур хакимиятнең яңа бинасына юнәлде.

Мәрмәр баскычларга басып, көзгеле ак ишекләрне ачып, ак якты коридорлар буйлап үтеп, шәһәр башлыгы урынбасарының кабул итү бүлмәсенә килеп керде. Бәхетенә, Ирек Бастамович урынында икән.

Кабул итү бүлмәсе үзенең зурлыгы, яктылыгы, затлылыгы белән күзен чагылдырган иде, Харисовның кабинеты аннан да шәбрәк булып чыкты. Яңа бинада барча җиһазлар да яңа, тик кабинетларда утыручы кешеләр генә һаман шул ук иде.

—О-о, с выходом, Газинур!—дип каршылады Корбановны социаль мәсьәләләр буенча урынбасар.—Ну, нәрсә, яңа көчләр туплап килдеңме? Ял итеп булдымы соң?

—Ял дип, бакча казып үтте инде. Авылга, әни янына кайттым. Ялгыз бит. Ярдәм итәргә кирәк.

—Яхшы, молодец!—Харисов житди тонга күчте.—Ни йомыш? Нинди мәсьәлә?

Газинур урынбасарның киң маңгаена, куе кашлар астына кереп яшеренгән нокта күзләренә, әйтергәме-әйтмәскәме, дигән сыман сынап карап торды да, тәвәккәлләп:

—Ирек Бастамович! Яшьләр комитеты ничә ел квартирант хәлендә, үз почмагы юк. Әле бер, әле икенче оешмадан арендага бүлмә алабыз. Безнеке кебек зур шәһәргә бер дә килешә торган эш түгел. Кунаклар алдында оят. Миндә мондый фикер бар: хакимияттән бушаган бинада Яшьләр үзәге оештырырга кирәк. Комитет та шунда була, спорт клублары, бию заллары да, ял итү бүлмәләре дә... Югыйсә яшьләргә кичләрен барыр урын да юк. Яшьләр, яшьләр, дибез. Барсы да сүздә генә. Эшкә килеп терәлсә, теге юк, бу юк.

Харисов башын артка ташлап көлеп җибәрде:

—Идеяң искиткеч шәп! Әмма соңардың, егеткәем. Бинага хуҗалар табылды инде. ЗАГС күчәчәк анда!

—ЗАГС? Сон, бик яхшы, аңа ике катның хаҗәте юк. Беренче кат аларга, ә икенчесе—безгә яки киресенчә. Шулай да була ич, Ирек Бастамович!

Харисов, юан бармакларын өстәл өстендә биетеп алды да:

—Уйлашырбыз. Тәкъдимеңне башлыкка җиткерермен. Синең баш кайнар, беләм. Яшь кешедә сабырлык чамалы була. Әлегә тыныч кына йөр. Ашыкма. Сөйләштекме?—диде.

Шуның белән сүз бетте дигәндәй, телефон трубкасына үрелде. Егеткә чыгып китүдән башка чара калмады.

Газинур авыл һавасы сулап, җәйләрен көтү көтеп, басуда эшләп үскән егет. Аның язмышы йөзләгән, меңләгән яшьтәшләренең язмышы белән уртак. Туды, үсте, яше җиткәч мәктәпкә барды, укыды, тәмамлады. Сабакташлары кайсы кая таралышты, байтагы укырга керде, кайсылары шәһәр тирәсендә эш тапты. Газинур авылда калды, тракторга утырды, җир сөрде. Аннан—армия хезмәте. Исәнлеге ташып торган, исеме җисеменә бик тә туры килеп торган егетне флотка алдылар. Диңгезләр кичте егет, дөнья күрде. Тагын да ныгып, шәбәеп кайтты авылга. Язмышын спорт белән бәйләргә карар кылып, Әлмәт физкультура техникумына укырга керде. Яртауга кайтып, мәктәптә эшли башлагач, көрәшчеләр түгәрәге ачып җибәрде. Сәләтле егетнең, аның булдыклы шәкертләренең абруе үсте. Газинур Корбановны таный-белә башладылар. Ике ел рәттән сабантуенда батыр да калгач, исеме телгә керде. “Яшьләр арасында авторитетың зур, кулыңнан эш килә”,—дип, аны район һәм шәһәрнең балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитетка рәис итеп билгеләделәр. Җитәкчелек эшендә бернинди тәҗрибәсе булмаган егет, сер бирмим, дия-дия ары чапты, бире чапты, әле моны оештырды, әле тегене оештырды. Эшләгән саен эше күбәя, үрчи барды, “тиеш”ләр, йөкләмәләр арта торды.

—Һи, дивана, карышмаган атка өеп төйиләр. Шуны белмисеңмени? Мондагы халык көн үтсенгә йөри, ә син чабасың. “Белмим” белән “булдыра алмыйм”ның башы авыртмый,—диде аңа бер “акыллы баш”.

—Синең дә үз тормышың булырга тиештер бит. Өйгә кайтып та күренмисең. Ни ял, ни бәйрәм юк,—дип сукранды яшь хатыны.

Әмма күңелендә намуслылык, җаваплылык хисе хәттин ашкан, һәр эшне ахырына, җиренә җиткереп башкарырга өйрәнгән Корбанов башкача булдыра алмый иде, үз эшендә “янып үләргә” тиешле кешеләрнең берсе иде ул.

Хакимият бинасы хакында сөйләшүдән соң Харисовтан хәбәр көтеп йөрде Газинур. Планеркаларга барган саен урынбасарның башлап сүз кузгатуын көтте. Тик Харисов дәшмәде. Әйтерсең, әлеге сөйләшү турында бөтенләй онытkан иде. Ахыр чиге үзе сүз кузгатырга җөрьәт итте.

—Ә-ә, хәтерлим, хәтерлим. Сон, ул мәсьәлә хәл ителгән ич инде. Бина ЗАГС балансына күчәчәк. Син, Корбанов проблемаларың һәм тәкъдимнәрең турында башлык белән президиум исеменә хат яз. Берәр җай килеп чыкмасмы,—диде Харисов. Аннары шаркылдап көлде дә:

—Әнә, безнең бизнесменнарыбыз, берсе артыннан берсе “шартлап” тора. Налог түләргә акчалары җитмәгәч, офисларын китереп салалар. Шуларның берсе артмасмы әле сиңа.

Үз эшләрен ачып җибәргән “яңа”лар арасында Корбановның якын дусты да бар. Алар бергә хезмәт иттеләр. Ике ел буе солдат боткасын ашаучылар яхшы белә, армиядә очраган якташ хәтта туганыңнан да якын була. Хезмәтләрен тутырып кайткач та, дуслык җепләре өзелмәде. Алар еш очрашалар. Табын артында бик күп серләр ачыла, җыелып килгән борчулар уртага салып сөйләнә. Ир-егетләрнең икесе дә хаклык өчен үләргә әзер кешеләр. Шуңа күрә бу болганчык заманда үзләрен кыйналап ташлагандай хис итәләр, илдәге тәртипсезлек, гаделсезлек өчен көяләнәләр.

Урынбасарның сүзләре Газинурның йөрәгенә барып кадалды.Юк, ул һич тә дустының ярык көймәдә утырып калуын теләми иде. Аның да, башкаларның да. Эшләсеннәр, яхшы яшәсеннәр, илне баетсыннар. Моннан беркемгә зыян юк, бары файда гына ич.

"Яшьләр һәм гаилә" темасына үткәрелгән семинарда Газинур шәһәр ЗАГС мөдире Куравлева белән бергә президиумда утырды. Семинар кунаклары өчен чәй табыны оештырылган иде, анда да урыннары янәшә туры килде, иркенләп сөйләшергә җай чыкты.

—Яңа йортыгыз белән котлыйм, Зинаида Павловна, шәп бинаны эләктергәнсез,—диде ул кыршесенә.

—Нинди бина? Нинди яңа йорт?

—Элеккеге хакимият бинасын әйтәм. Сезгә бирәләр дип ишеткән идем.

—Ә-ә, сез ул турыда икән. Булды андый сүз, булды. Тик, кызганыч, шулай сүз генә булып калды,—диде Куравлева уфтанып.—Алтын вәгъдәләр гел һавада асылынып кала шул, дускаем. Безгә насыйп булмады ул хан сарае.

—Харисов бик ышандырып әйткән иде. Имеш, башлык та раслаган,—Корбанов мөдир сүзләренә ышана алмыйча аптырады. Харисов олы башын кече итеп алдашты микәнни?

—Акча, дускаем, акча хәл итә барысын да. Бинаны Талиповка саталар. Беләсеңме шундый кешене?—Куравлева кинаяле елмаеп куйды. Талиповны кем белми, янәсе.

Моңа ышанырга була, Талипов—ул инде фигура. Ул инде башлык кабинетына да ишекләрне тибеп кенә ачып керә. Аның үзеннән дә алда акчасы йөри.

Талипов... Аның белән Газинурның юллары бер кисешкән иде инде. Үткән сайлауларда икесе дә бер округтан район советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелделәр.

Беркатлы егет бу вакыйгага сөенеп, горурланып йөргән иде. Бары тик демократик таләпләрнең үтәлүен күрсәтер өчен генә альтернатива булып исемлеккә кертелгән булган икән. Ә ул юк вакытын бар итеп сайлаучылар белән очрашуларга йөргән булды тагын. Һәр чыгышын ныклап әзерләде, Талипов исә озын-озак сөйләп йөрмәгән, сайлаучыларына бирәр кило шикәр комы белән он гына таратып чыккан. Ә халыкның миенә сеңгән: кемдә акча—шунда көч, кемдә байлык—шунда дөреслек, шунда власть. Күпер салыр өчен акча кирәк, газ кертер өчен акча кирәк. Мәктәпкә компьютерлар алыр өчен акча кирәк...

Әлбәттә, Талипов җиңде. Корбановны авыз ачып тыңлап утыручылар калын кесәле кандидатны кулайрак күрделәр шул. Сайлаулар үткәч, шикәр белән он ашалып беткәч, авыл агайлары төрле гозер белән депутатлары янына килә башлады, әмма тегесенең койрыгын тоту авыр иде.

Талиповның офисы шәһәрнең иң матур үзәк урамында урнашкан, өряңа заманча бина. Үзе яшәгән эче-тышы ап-ак йорт исә тыныч күл буенда. Күзгә-тәрәзәләре, көмеш түбәсе белән балкып утыра. Бүлмәләрне айкап чыгар өчен тәүлек кирәк, диләр.

Хакимият бинасына ник кызыга, ник кул суза? Аңа ул нигә кирәк? Бу сорауны Газинур Куравлевага бирде.

—Тәгаен белмим. Имеш, кунакханә ясамакчы була, ресторанлы, кафелы... Кайда да табыш эзли бит ул түгәрәк баш. Ул да ота, шәһәр казнасы да.

Кунакханә... Ресторан... Алары да кирәктер. Әйе, үсеп баручы яшь шәһәр өчен ресторан да, кунакханә дә кирәктер. Тик нигә күңел шул тиклем үртәлә, ник эчен кара мәче тырный әле? Бинаның ЗАГСка бирелүен бик тыныч кабул иткән иде югыйсә. Болай булгач, икесе дә коры калдылар инде. Бу юлы да акча җиңде.

* * *

Бирим дигән колына, чыгарып куя юлына диюләре хак икән. Кабинетта утыруның ни икәнен белмәгән Талиповны кайда тотыйм да, ничек сөйләшим икән дип йөргәндә, тегесе Ходайның бер бирмеш көнендә Корбановның каршына үзе килеп чыкты. Куравлеваның сүзе хакмы, хакимиятнең иске бинасы янында, чынлап та , Талиповныкылар чуаламы икән дип, Газинур эшенә, урап булса да шул тирәдән үтә иде. Бирeдә бернинди җанлылык сизелмәгәч, ишегендә элеккечә йозак эленеп торгач, күрәсең, бу хан сарае беркемгә дә тәтемәгәндер, Талипов ала дигәннәре буш сүз генәдер дип йөргәндә, эшмәкәрне нәкъ шунда очратты да куйды менә.

Халык депутаты, кулларын, төшеп китеп ватыла күрмәсен тагын дигәндәй, түгәрәк корсагы астына кушырып, көзге кебек ялтырап торган көмеш "Мерседес"е янында бик җитди кыяфәт белән басып тора иде. Өстендә төймәләре ычкындырылган күн куртка, ап-ак күлмәк, корсак өстенә ипле генә сузылып яткан кара галстук... Сумала кебек чәчләре шомартып таралган. Пөхтә йөри Талипов, ботинкасына да тузан кундырмый хәтта.

Кул биреп күрештеләр.

—Менә Симагинны көтәм әле. Сәгать бердә очрашырбыз дигән идек, чурт вазми, күренми. Симагин вакытында килсә, әйткән сүзен үтәсә, кешечә буламыни ул?!—дип сукранып алды Талипов.

Газинур исә үзен кызыксындырган мәсьәләгә күчәргә ашыкты.

—Бу,—диде ул, бинага ымлап,—сиңа эләккән диләр, дөресме?

Талипов канәгать елмайды:

—А как же! Алтын балык алтын җимгә эләгә ул, парин. Син дә күз кыздырып йөргәнсең, дип ишеттем.

—Бар иде шундый хыял, Яшьләр үзәге оештырырга иде исәп. Безгә тәтемәде, депутатлар өлгеррәк булып чыкты,—диде Газинур төрттереп.

—Причем монда депутатлык, парин?! Казна буш, ват в чем проблема! Синең ул Яшьләр үзәгең бюджет җилкәсенә менеп атлана да, давай-давай, дип акча суыра башлый.Ремонтка кирәкме? Кирәк! Мебельгә кирәкме? Кирәк! Инвентарь, чурт-мурты. Очы—кырые юк. Ә кем бирә акчаны? Бюджет! Ә акча юк! Юк, парин! Әллә телевизор карамыйсың? Укытучылар, врачлар айлар буе зарплата алмый. Кая монда Яшьләр үзәге ачу?!

—Мин үзем өчен йөрмим бит. Балалар, яшьләр турында сүз бара. Син уйлап кара менә: Совет чорында Пионерлар йорты бар иде, ә хәзер анда салым инспекциясе хуҗа булды. Акча юк дип, көрәшчеләр клубын яптылар. Ике балалар бакчасы банкка, ә пионер лагере ял йортына әйләнде. Киләчәк буын дибез, ә үзебез алардан барысын да тартып алдык та, үзләрен подвалларга куып төшердек.

Талипов сабырсызлана башлады:

—Туктале, парин, ник кызасың син? Причем монда мин, слушай?!

—Син депутат! Син сайлаучыларың, халык турында кайгыртырга тиеш!

—Ә мин кемне кайгыртам соң, чурт вазми?! Гостиница кем өчен? Ресторан кем өчен? Үзем өчен штули? Халык өчен, шәһәр өчен тырышам, лабаса! Вәт, парин, ни сөйләгәненне үзең дә чамаламыйсың, ахры.

Газинур кесәсеннән бер кап "Ява" чыгарып, сигарет алды. Талиповка да тәкъдим иткән иде, тегесе баш тартты. Эшмәкәр сәламәтлеге турында кайгырта, эчми-тартмый, кәефе-вакыты булганда спорт белән дә шөгыльләнә иде. Ул сәгатенә күз төшереп алды. Симагин килеп чыкса, бу бәйләнчек егеттән дә, эчпошыргыч сөйләшүдән дә котылыр иде, әмма көткән кешесе һаман күренми. Ә егерменче гасыр Дон Кихотының китәргә бер дә исәбе юк.

—Менә син гостиница, дисен. Берәү бар бит инде, житкән. Анысы да яртылаш буш әле анын.

—Буш, канишно. Ул таракан оясына кем килсен?! Общага бит ул! Хәтерлисенме, безнен шәһәргә Валерий Льеонтев килергә тиеш иде. Түлке концерты булмады. Беләсенме, ник? Кунарга урын булмаганга! Кергән Льеонтев безнен хәерче гостиницага, тьфу! дип бер төкергән дә, чыгып та киткән. Позор! Ә минем гостиница суперкласс, люкс булачак. Ельцин бабаң үзе килеп төшсә дә, "во!" диячәк. Беләсен килсә, культурный центр булачак монда! Ресторанда иң шәп жырчылар жырлаячак. Синен яшьләрең өерелеп киләчәк әле, культурно ял итәчәк. Ват шулай, парин! Минем акчалар банкта сасып ятмый, алар эшли. Эшли! Менә бу здание өчен түләнгән акча укытучыларга, врачларга китәчәк. Халыкка хезмәт итү шул инде ул, парин. Бугаз киереп акырып йөрү түгел. Сез авызыгызга алма төшкәнне көтеп ятканда, Талипов йокы күрмәде, көн-төн чапты. Беркем дә китереп бирмәде. Шырпы сатудан башлаган кеше бит мин!

Талипов кызганнан-кыза барды. Корбановнын сүзләренә үртәлгән-ярсыган иде ул. Әгәр шул чакта ремонт-төзелеш идарәсе башлыгы, Талиповнын көткән кешесе—Симагин килеп чыкмаса, бу ике кызган әтәч нишләп бетәрләр иде, билгесез. Әмма кеше алдында сер бирмәделәр, пока, диешеп матур гына хушлаштылар.

Каты бәрелде Талипов Газинурга. Улмы сон авызына алма төшкәнне көтеп ятучы? Ял диме, бәйрәм диме, чаба ич. Өенә дә төнсез кайтып керә алмый. Әмма нәрсәгә ирешште? Ярый әле бер бүлмәле булса да фатир алып калды. Анысы да баз кебек салкын, карангы. Хезмәт хакы ачка үлмәслек кенә. Талипов эшли, эшләгән саен байлыгын арттыра, эшләгән саен яхшырак яши. Ә Газинурга борыны белән жир сөрсә дә, юк. Ай саен бер "кәнфит". Карангыдан карангыга чапсан да—шул "кәнфит", өстәл артында йоклап утырсан да—шул "кәнфит"... Эшләп кем баеган?—дигән әйтем нәкъ менә анын кебекләр турындадыр, күрәсен.

"Мина гына кирәкме әллә? Барысын да ташлыйм да, шырпы сата башлыйм"—дип уйлады Газинур. Бу уй артыннан ук икенчесе килде: Юк, башта Яшьләр үзәге оештырам әле. Ичмасам, шәһәргә миннән бер истәлек калыр!

* * *

Хәмит өчен бу дөньяда бик кадерле һәм бик кирәкле кеше әнисе иде. Ул гомере буе улына яхшы, рәхәт булсын дип яшәде. Хәмит тора: чәй кайнаган, ашарга пешкән, юылган, үтүкләнгән киемнәре әзерләп куелган. Эштән кайта—табында тәмле ризыклар көтә. Аша, ял ит. Дөнья рәхәт, дөнья кин!

Хәмит өчен дөньяда тагын бер кадерле әйбер бар: ул да булса телевизор. Телевизор Хәмитсез тора ала, ә Хәмит телевизорсыз юк! Ни күрсәтәләр, шуны рәттән карый. Диванга сузылып ята да, рәхәтләнеп карый. Эче пошса, аш бүлмәсенә кереп, суыткычны ача. Әнисе гажәп унган, булган хатын. Кадерле улкаен тәмле ризыктан өзми. Ак күмәч өстенә мул итеп ак май ягып, анын да өстенә калын колбаса—сыр кисәге куя да, йомшак диванга сузылып ята, тагын телевизор карый.

Бик рәхәт яшәде Хәмит, мондый ваемсыз тук тормыш мәнге дәвам итәр төсле иде. Әмма көннәрдән беркөнне көтелмәгән хәл килеп чыкты. Хәмит эшкә сонга калды. Сонга калды, чөнки аны "Улым, тор" дип уятучы булмады. Хәмит берсе "9", икенчесе "3" саннары өстендәге сәгать телләренә ни уйларга белми шаккатып карап торды да, "Әни!" дип кычкырды.

Ана жавап бирүче булмады. Егет сикереп торып кухняга керде, анда бушлык иде. Өстәл дә буш, газ плитәсе өстендә дә кайнаган-пешкән әйбер

күренми, хәтта чәйнек тә сап-салкын. Аптыраган-куркынган егет әнисе бүлмәсенә юнәлде. Дөньяда утыз өч ел яшәп, әнисен йоклаган килеш күрмәгән егет шаккатты: ул әле һаман тормаган иде! Хәмит авызын турсайтып:

—Әни, син нигә ашарга әзерләмәдең? Нигә мине уятмадың? Синең аркада эшкә сонга калдым бит!—дип кычкырды.

Әнисе дәшмәде, хәтта кузгалмады да. Хәмит аның янына килде, юрган өстендә ятканябык беләгенә ачу белән төртте:

—Тор инде, тор!

Әмма ана аңсыз иде. Куркынган Хәмит күршеләренә йөгерде. Тегеләр "ашыгыч ярдәм" чакырттылар. Ак халатлы кешеләр әнисен носилкага салып үзләре белән алып китте.

Хәмитнең бәхетле, гамьсез дөньясы бер көндә ишелеп төште. "Әни терелмәсә, мин нишләрмен? Нишләрмен соң мин?!"—дигән сораулар җанын-тәнен өшетте. Үзенә чәй дә куеп эчәлмәгән егет чарасыз һәм мескен иде.

Улыма җил-янгыр тимәсен, ятимлекне тоймасын, башкалардан ким булмасын, теләгәнен ашасын, теләгәнен кисен дип, икешәр-өчәр эштә эшләп йөргән ананың исәнлеге картлык көннәренә артмаган иде шул. Инсульт кичергәннән соң, ул аякка басты, әмма үлемнең бүген-иртәгә ишек кагуын чамалый иде. Үз хәлен яхшы аңлаган бичара ана исән чакта газиз баласын ышанычлы, җылы кулларга тапшырып калдырырга ашыкты. Хәл белергә кергән һәр танышына да шул гозерен җиткерде.

—Әй, Мәкъбулә, әллә кайчан вакыт. Сакаллы сабыенны көйли-көйли шул хәлгә калдың да инде. Сине кызганмаган кеше юк,—диде берсе.

—Өйдә дә үзең, бакчада да үзең. Берданберем, дия-дия, атасы юк, дия-дия тәмам узындырдың. Ата каешы эләкмәгән шул ана. Үпкәләмә, улың харап иркә, кулыннан бер эш тә килми. Кем генә ризалашыр икән?—диде икенчесе.

—Минем белән бергә эшләгән Разияда бер кыз тора. Укый-укый яше утызга җиткән. Авыл кызы, бик сабыр күренә үзе. Мәктәптә укытып йөри. Сайлар-сайланыр вакыты үткән, бәлки ризалашып та куяр. Сөйләшеп карыйм булмаса,—дип өметләндерде өченчесе.

* * *

Шулай итеп Илдания дә кияүле булып куйды. Аны димләгән апа ялгышты. Беренчедән кызга әле утыз яшькә шактый ерак иде. Икенчедән акыл туплаган, сизгер кыз бер күрүдә үк егетнең нинди камырдан икәнен аңлап-чамалап алды. Дөньяда гаме булмаган буш карашлы, пошмас, ялкау икәнлеге йөзенә генә түгел, бөтен килеш-килбәтенә чыккан иде. Әмма да ләкин таза—нык гәүдәсенә, кызларныкыдай матур йөзенә, шул йөздә затлы бизәк булып утырган озын керфекле соры күзләренә баккач, Илдания болай уйлады: "Акыл минем үземдә дә җитәрлек. Бу чибәр егетне култыклап, авыл урамнарын бер узсам, "Ник һаман ялгыз йөрисең?" дигән бәйләнчек сораулардан мәңгегә котылачакмын. Кияүнең кәттәсен эләктергән, юкка гына шул гомер көтеп ятмаган икән, диячәкләр, валлаһи!"

Димче хатын ана әйтте:

—Иркәм, барысы да үзенә калачак. Кыр хәтле ике бүлмә, бөтен нәрсә җитеш. Мәкъбулә бик булдыклы, унган хатын. Ул озак яшәмәс инде, чире начар. Хәмит акчаны көрәп ала, тиененә хәтле анасына кайтарып бирә. Эчми, тартмый, тагы нәрсә кирәк?! Егетне кулга алалсаң, нужа күрмичә яшәячәксең. Әзергә бәзер булып барасың, чамала.

Кеше җаен җайлап, фатирдан-фатирга күчеп йөреп туйган иде кыз. Үз

оям, үз куышым булыр дип сөенде. Барысын да уйлап, исәпләгәч, Хәмит дигән бәндәнең тормыш юлдашы булырга ризалашып та куйды.

Кияү белән үткәргән беренче төн Илданиядә ифрат авыр тәэсир калдырды. "Мәхәббәт дигән нәрсә уйдырма. Без хайваннардан әлләни аерылмыйбыз икән",—дигән нәтиҗә ясады ул. Янына Хәмит килә башласа, бөтен тәне куырылып, өшеп китә, сулкылдап-сулкылдап наз-мәхәббәт көткән тән гүя салкын ташка әйләнә дә, ире белән кушылган минутлар бары тоташ газапка әверелә иде...

—Син Хәмитне ташлама инде, Илдания. Ялгыз яши алмый ул. Берүзе калса, харап булачак. Аның шундый булуына исерек атасы да гаепледер инде. Аерылып та котыла алмадым, ахры, аннан. Кара сакалын үзеннән калмый икән ул. Син аны, зинһар, ташлама, яме, балакаем. Хәмитемне ташласаң мәңге бәхил булмам, каберемдә рәнҗеп ятармын,—диде ана Мәкъбулә апа.

Ананың күзендә яшь иде. Аны кызганудан Илданиянең йөрәге кысылып куйды.

Мәкъбулә апаның тормышы үзе бер фаҗига. Гомере буе улы өчен яшәгән, тырышкан, булдырган. Әмма төзелгәне ахырда ком сарае гына булып чыккан. Әнә, аның тормышының мәгънәсе, нәтиҗәсе-сакаллы сабые—авыз ерып телевизордан мультфильм карап утыра... Әнисе авырып яткан бүлмәгә кереп: "Хәлең ничек?"—дип тә сорамый. Чөнки аның хәле Хәмитне беркайчан да кызыксындырмаган.

Икенче инсульттан соң Мәкъбулә апа мантый алмады, урында гына ятты. Аны карау-тәрбияләү өчен Илдания үз хисабына ял алды.

—И бала, ярый әле бәхетемә син булдың. Ходай исәнлегеңне бирсен,—дип рәхмәт укыды ана. Бик сабыр булды үзе, артыгын сорамады, йөдәтмәде, зарланмады. Карашын түшәмдәге ноктага төбәп, тыныч кына ятты. Ниләр генә уйлап бетергәндер көннәр-төннәр буена?!

Илдания аны кызгану хисе белән ярата, ярату хисе белән кызгана иде. Авыру кешене карап ялыкса да, кайнанасының үлүен теләмәде ул. Ир хакына да, фатир хакына да түгел, язмыш аны бу йортка гүя шушы хатын хакына, шул бичара гөнаһсыз бәндәнең соңгы көннәрен җиңеләйтү өчен гомере ахырында булса да кеше игътибары, күңел җылысы тойсын дип китергән иде. Соңгы сулышын алып, күзен йомганчы, Илдания кайнанасы кырында булды.

Ул көнне Хәмит эштән соңарып кайтты. Кешегә кайгылы хәбәр җиткерү гаять авыр эш. Илдания ире каршына чыгып, сүзне ничек башларга да белми торды.

—Чё?—диде Хәмит хатынының үзенә текәлеп басып торуын күреп.

—Хәмит... Әни үлде бит...

—У тебя что ли?

—Юк, безнең әни. Синең әни...

Хәмит курткасын эләргә дип үрелгән җирдән катып калды. Аптыраулы карашын Илданиягә төбәде:

—Нишләргә соң хәзер?

—Соң... янына кер. Хушлаш.

—Хәзер,—диде ир, тик йокы бүлмәсенә түгел, ваннага кереп китте, кулларын юып чыкты. Ә аннары:

—Ашарга бармы? Ашыйсы килә. Ике вагон такта бушаттык, арыттых,—дия-дия кухняга юнәлде. Әнисе турында гүя бөтенләй оныткан иде...

...Үз гаиләсендә аңлау, җылылык табалмаган хатын-кыз эшендә юаныч эзли, үзен җәмгыятьтә кирәкле итеп тоярга тели. Кайнанасы исән чакта, Илданиянең тормышы мәгънәле булган икән әле. Ул эшеннән ашыга-ашыга

кайта. Чөнки белә: өйдә аны тилмереп көтүче бар. Ул кемгәдер кирәк, берәү аның ярдәменә, күңел җылысына мохтаҗ. Аның пешергән ашын рәхмәт әйтеп ашыйлар, юган киемнәрен рәхмәт әйтеп кияләр.

Хәзер бу өйдә телевизор тавышы гына ишетелә. Андагы кешеләр нидер сөйлиләр, көләләр йә елыйлар. Телевизор каршында утыручы Хәмит көлми дә еламый да, сөйләшми дә. Көйләп җибәрелгән курчак кебек ул, тор дисәң тора, аша дисәң, ашый. Илдания күп мәртәбәләр аның белән сөйләшергә омтылып карады, тик берни барып чыкмый иде. Хәмит буш карашын телевизорга текәгән килеш: "аһа", "әһе", "ну-ну" дип җавап бирүдән узмады. Илданиянең эше дә, үзе дә, аның борчу-шатлыклары да ирне кызыксындырмады. Иң мөһиме: ашарга пешкән булсын!

Илданиянең ир белән яшәве бер фатирда көн күрүгә һәм өйдәшенә хезмәтче булуга кайтып калды. Дөрес, хезмәте өчен ир яхшы түли иде.

Өендә тапмаган ямьне Илдания эшендә эзләде. Атнасына утыз алты дәрес укыткан хатынның эче пошып утырырга вакыты да калмады...

* * *

Илдания бала чактан китап укырга яратты. Хәреф таный башлау белән китапханәгә юл ярды. Китапларны су урынына эчте. Әдәбият укытучысының шатлыгы, горурлыгы булып, иншаларны гел "5"легә яза, олимпиадаларда, төрле иҗади бәйгеләрдә катнаша, җинә иде. Соңгы сыйныфта укыганда әйтте укытучысы:

—Илдания сеңлем, иншаңда татар теле укытучысы булам, университетка керәм дип язгансың. Әгәр исәбең авылга кайтып эшләү икән, бер сүзем юк. Әмма авыл киләчәксез, шәһәрдә исә татар теле гел кирәксез булып калды. Кая барсаң да урыс теле кирәк, шуңа күрә сиңа рус теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә киңәш итәр идем,—диде.

—Татар теле бетсә, Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан исемнәре дә югалачак бит, Сания апа. Аларның шигырьләрен кем укыр?—дип җавап бирде кыз.

Гомере буе туган тел сагында торган чал чәчле укытучы рәхмәт хисе белән кызны кочып алды...

...1990 елның җәендә Илдания, Казан дәүләт университетын тәмамлап, кулына кызыл диплом алган иде. Шул елны республика халкы шау-гөр килеп бәйрәм итте. Күңелләрдә якты өметләр балкыды, милләтнең киләчәге алтын нурга күмелгәндәй булды. Әмма тормыш әкият түгел, "булсын!" дип әмер бирергә тылсымлы таяклар юк.

Яртауда әле ни татар балалар бакчасы, ни татар мәктәбе юк иде. Мәктәпләргә татар теле укытучыларын туплый башлагач, шатланып-канатланып мәгариф бүлегенә йөгерде кыз. Әйе, шатлыгы чиксез, өметхыяллары зурдан иде. Үзен нинди каршылыклар, күпме сынаулар көткәнен, күпме ут-ялкын кичәсен каян белсен, ничек сизсен? Мәгариф бүлеге җитәкчеләреннән, мәктәп директорыннан алып башлангыч сыйныф укучысына кадәр бер сүзне тукый: "Кемгә, нигә кирәк ул татар теле?" Өстән куштылар—ачтылар татар сыйныфларын, кирәкле җиргә кирәкле хисап бирелгән. Ә калганы сезнең эш, теләсә ни эшләгез!

Татар теле, бөек Тукай теле, аның яшәве, киләчәге әйтерсең лә татар теле укытучыларына гына кирәк иде. Телне урыс балаларына көчләп укытылуы да күпләрдә ризасызлык тудырды. Бигрәк тә ата-аналар шау итте: "Нигә кирәк? Кемгә кирәк?" Шушы сораулар татар белгечләренең башына таш булып яуды.

Татар телен һәр сыйныфта ике төркемгә бүлеп өйрәтәләр. Берсендә—урыс балалары һәм ана телләрендә бер кәлимә сүз белмәгән татарлар. Болар

белән дәрес үткәрү тоташ газап. Әллә чынлап та аңламыйлар, әллә аңларга теләмиләр? "Мин—кыз,"—ди бер малай. Икенчесе торып баса да, күзен шарландырып:

—Мин—урындык!—ди. Йөз кат кабатлаган, башларына сеңдерелгән сүзләрне юри бозып әйтәләр, биш хәрефле сүздә алты хата ясыйлар. Алар укытучы күзенә гуя мыскыллы елмаеп карыйлар: "Төкерәбез без синен теленә!" янәсе. Урыс баласын татар теленә өйрәткән укытучыга Ходай тимер йөрәк, корыч нервы, илаһи сабырлык бирсен!.

Илдания исә саф татар балаларын укыта. Болар арасында да төрлесе бар. Кайсы белем өчен тырышкан була. Кайсы, барыбер "3"ле куялар дип самолет очырып утыра...

* * *

—Татар теле укытучылары эшләми. Дәрес вакытында коридор буйлап әрле-бирле йөриләр,—диде директор педсовет утырышында.

Егерме елдан артык стажы булган өлкән укытучы Зәлия Гамировна Насыйрова, ни сабыр булса да, түзмәде, торып басты:

—Нина Ивановна, мәктәптә аерым татар теле кабинеты юк. Дәрес үткәрү өчен буш класс эзләп күпме вакытыбыз әрәм була. Мәсәлән, әле кичә генә мин әдәбият дәресен спортзалда үткәрергә мәҗбүр булдым.

Директор, бу турыда беренче тапкыр ишеткән сыман, йөзенә гаҗәпләнү кыяфәте чыгарып, нәзек кашларын җыерды:

—Ничек алай? Ник миңа әйтмәдегез?

Хәлбуки, ул барысын да бик яхшы белә, Зәлия Гамировна иң беренче нәүбәттә ана мөрәҗәгать иткән иде. Директорның коллектив каршында үзен пакь, гөнаһсыз итеп күрсәтәсе килә иде, күрәсең. Акланунын, аңлатуның файдасыз икәнен аңлаган Насыйрова, эченнән ни үртәлсә дә, кичерешләрен йөзенә чыгармый кала алды. Тыныч, басынкы тавыш белән:

—Инде белдегез, киләчәктә бу мәсьәлә хәл ителер дип ышанам,—диде.

Директор исә, аның сүзләренә мөһер сугарга ашыкмады, татар теле укытучыларына һөҗүмен дәвам итте:

—Мәктәптә татар телендә бер чара үткәрелми! Әнә ата-аналар район газетына жалоба язганнар. Бүген редактор шалтыратып әйтте. Ярый әле, Сафуанов үз кеше, сөйләштек, аңлаштык, хатны бастырмаска килеште. Менә шул, хөрмәтлеләрем. Хоть кровь из носа, әмма татарча бер мероприятие әзерлисез!

Кирсанованың сүзен хуплап, башкалар гөрелдәшеп алды: "Шулай, үткәрсеннәр.Эшләсеннәр. Югыйсә көненә ике-өч дәрес үткәрәләр дә, ычкыналар. Бик рәхәт яшиләр".

Хуҗаның артын яларга әзер торучы куштаннар һәр коллективта да бар. Җыелыш саен бер балык башы. Үз почмаклары, аерым кабинетлары да булмаган алты укытучы директорның кан дошманына әйләнде дә куйды. Ни өчен? Чөнки татар теле укыталар.

Хурланды Илдания. Аны мыскыл итәләр бит. Аны, иптәшләрен генә түгел, газиз телен, милләтен кимсетәләр. Һаман да үзләреннән түбән куймакчылар, аста калдырмакчылар. Дәшми калырга ярамый. Юк, ярамый!

—Нина Ивановна! Берне генә түгел, ун мероприятие үткәрергә дә әзер без. Менә озакламый Яңа ел бәйрәме житә. Әгәр бераз акча бүлеп бирсәгез, Чыршы бәйрәмен татарча үткәрер идек.

—Акча?! Нәрсәгә акча?!—диде директор сыек зәңгәр күзләрен түгәрәкләндереп.

—Соң, призлар, бүләкләр алырга кирәк булачак бит.

Кирсанованың йөзенә мыскыллы елмаю кунды.

—Аларсыз да бик яхшы үткәреп була. Җырласыннар, биесеннәр, Тукайны сөйләсеннәр. Гороноданкеше чакыртырбыз. Теләгән кешегә акчасыз да менә дигән бәйрәм оештырып була! Сметада татар елкасы өчен акча каралмаган. Бүләкләр аласыгыз килсә, әнә ата-аналардан сорагыз.

Тагы ата-аналар кесәсенә тыгылыргамы? Болай да мәктәп күпме акча суыра алардан: ремонт өчен, яңа җиһазлар, инвентарь өчен... Әмма директор белән бәхәсләшү, аны үз фикереннән чигенергә мәҗбүр итү таш стенаны борчак белән тишүдән дә авыррак эш.

Җыелыш тәмамлангач, бер йодрык булып укмашкан алты җан, аерылышырга теләмичә, урам чатына басып, күңел бушатты. Берәүнең дә авыр уйлар, күңелсез тәэсирләр белән ялгыз каласы килми иде шул.

—Юкка гына әйттең ул сүзне, Илдания. Берни барып чыкмаячак. Көлкегә генә калабыз,—дип төшенкелеккә бирелде Фәүзия Фатыйховна.

—Оештыруын оештырырбыз анысы. Бергәләп тотынсак. Кешесе килерме, диген. Ата-аналар да урыслашып беткән бит хәзер.

—Сер бирмик әле, кызлар. Монда бит милләт турында сүз бара. Без җиңсәк, милләт тә өскә чыгачак!—Татар иҗтимагый үзегенә йөреп, купшы, күтәренке рухта сөйләшергә өйрәнгән Разия Булатовна кечкенә генә шәһәрнең гап-гади мәктәбендә күтәрелгән вак кына проблеманы зурайтып, биегәйтеп җибәрде.

—Әллә соң, һич булмаса, үзебез бер илле мең сумнан булса да җыелышыйкмы? Акча бүген бар, иртәгә юк ул,—дип сүзгә кушылды моңарчы дәшми торган Зәлия Гамировна.

—И ул акчага хәзерге заманда нәрсә аласың? Кыш бабай капчыгының төбен капларга да җитми ич ул,—диеште башкалар.

—Нишлик соң?! Кирсанова барыбер бер тиен дә бирмиячәк.

—Әллә соң...Раил Мансуровичка барып карыйкмы?—бу сүзләрне X сыйныф җитәкчесе Наилә Туктаровна әйтте.

—Һаман-һаман аңа, туеп беткәндер инде без хәерчеләрдән. Язучыларның портретларын алганда, аннан сорадык, татарча китаплар кирәк булды, тагын аңа барып егылдык,—дип икеләнде Зәлия.

—Кем соң ул?—дип сорады Илдания.

—Бер укучымның әтисе. Гел ярдәм итеп тора.

—Шулай баймыни?

—Эш байлыктамыни? Байлар буа буарлык та анысы. Күбесеннән кыш көне бер көрәк кар да ала алмыйсың. Мәңгегә килгән кебек кыланалар. Ә Раил Мансурович... Ул бүтән.—Әлеге кеше турында сөйләгәндә Наиләнең йөзләре балкып, карашы җылынып китүен Илдания сизми калмады. Никтер шул Раил дигән ир-егетне күрәсе килеп китте. Башкаларның, куып чыгармас әле, барырга кирәк, дигән сүзләрен ишеткәч шатланып куйды.

—Үзең генә барма, әнә, Илданияне дә иярт. Яхшы кеше белән танышып калсын. Ул әле яшь, киләчәктә кирәк булыр,—диде Зәлия апалары.

Шулай килешеп аерылыштылар.

* * *

Раил дигәннәре бик төксе кеше булып чыкты. Аны башта ике сәгать көтәргә туры килде. Наилә белән Илдания инде китәргә дип торганда, ишек төбендә, нәкъ каршыларында озын буйлы, баһадир гәүдәле ир пәйда булды. Ул Наиләне танып исәнләште, укытучы ханымнарны кабинетына чакырды. Үзе исә курткасын да салып тормыйча, бүреген өстәл өстенә ташлады да, телефонга ябышты:

—Алло, бу "Камил"дән, Сөләйманов. Машинагызны кире җибәрдек, цемент бернигә яраксыз. Кабул итмәдек. Ә? Кабул итмәдек дим. Сыйфаты

начар, дым тарткан. Анысы сезнең эш. Башка җирдән табарбыз. Хуш иттек.

"Харап эшем иясе, утырырга урын да тәкъдим итмәде, әдәпсез. Шуны мактаган булалар тагын",—дип уйлап куйды Илдания.

—Гафу итегез,—диде "Камил" фирмасы хуҗасы, аның уйларын сизгән сыман.—Утырыгыз.

Үзе дә, куртка төймәләрен ычкындырып түр башына урнашты. Аннары "тынлыйм сезне" дигән сыман игътибарлы карашын каршыдагыларга юнәлтте.

Дөньяда аз сөйләүче, кирәклене генә сөйләүче кешеләр бар, телнең бар вазифасы көне-төне лыгырдау дип уйлаучылар да шактый. Әмма тынлый белүчеләр аз. Раил Мансурович шундыйларның берсе иде. Ул акыллы, уйчан күзләрен әле Илданиягә, әле Наиләгә төбәп кунакларын сабыр гына тыңлады. Хатыннар, бу ни әйтер диеп тынып калгач, бераз уйланып торды да:

—Мин каршы түгел,—диде.—Тик берничә шартым бар. Бәйрәм галочка өчен генә түгел, чын күңелдән, югары дәрәҗәдә үткәрелсен иде. Бу вакыйга район газетында яктыртылсын. Аннары, телевидениены чакырсагыз, әйбәт булыр иде. Тыйнаксызлык дип уйламагыз. Җыелыш, кинәшмә саен, үзегез өчен генә яшисез, шәһәр тормышында кайнашмыйсыз дип, сугәләр. Бераз эшебез күренсен иде диюем. Зинһар, дөрес аңлагыз.

Илданиянең күңеленә, әйтерсең, шайтан кереп утырган, котырта да котырта: "Харап икән! Мәскәү депутатларыннан бер дә ким түгел, өч тиенлек эшләре белән бөтен дөньяга шапырынмакчылар. Изгелекне яшереп эшлиләр аны, әтәч кебек кычкырып йөрмиләр".

Раил Мансурович ярдәмне акчалата күрсәтергә булды. "Үзегез теләгән әйберләрне алыгыз да, чекларны безгә тапшырырсыз. Хәер, Наилә Хисамовна, сез үзегез дә тәртибен беләсез инде",—диде. Аннары алар Наилә белән ниндидер Алсу исемле кыз турында сөйләшеп алдылар. Күрәсең, кызыдыр, дип уйлады Илдания. Саубуллашып чыгып киткәндә, Раил урыныннан торды, хатын-кызларны озата чыкты. Кул биреп хушлашты. Илданиянең кулын кысканда, күзләренә туры карап: "Сезнең белән танышуыма мин бик шат",—диде. Хатын, әдәплелек саклап: "Мин дә",—диган булды. Шат идеме, түгелме, гәрчә үзе дә аңламады, чөнки бик арыган иде.

... Бәйрәм көтелгәннән дә күңеллерәк килеп чыкты. Балаларының бәйрәмен уртаклашырга ата-аналар да килде. Алар читтән күзәтеп тормадылар, үзләре дә уен-биюләрдә рәхәтләнеп катнашып киттеләр. Берсе гармун уйнады, икенчесе җырлады, өченчесе биеде. Мәктәпнең иркен, биек спорт залында кич буе татар моңнары, татар җырлары яңгырап торды. Балаларны исә, җыр-биюдән бигрәк, Кыш бабай капчыгы ныграк кызыксындырды. Аның кулыннан бүләк алыр өчен әтәч булып та кычкырдылар, колын булып та чаптылар. Ә бүләкләр аллә дә шәп иде, күзләрне кыздырырлык иде шул!

Акчасыз берни булдыра алмаслар, тәнкыйтьләү өчен бер сәбәп булыр дип, үзенә җим эзләп йөргән директор шау-гөр килеп торган бәйрәмнән тәмам каралып чыкты. Нина Ивановна татарларны җаны-тәне белән сөйми, бу кара надан халыкка урыс халкы белем, культура биргән дип чын күңелдән ышана, үзенең бөек милләт вәкиле булуына чиксез горурлана иде.

Беркөнне тарих укытучысы Жанна Измайловна керәшеннәрнең килеп чыгышы хакында сөйләп утырды. Имеш, Иван Грозный Казанны алгач, чукындыру сәясәте башлаган. Шул чакта татарларны Иделгә куып кертә торган булганнар. Кем чукынган—исән калган, диненнән язарга теләмәгәннәрне батырганнар. Нина Ивановна бу күренешне бер тантана, ләззәт белән күз алдына китерде, уйларының тышка бәреп чыгуын үзе дә сизми калды хәтта:

—Всех надо было топить! Всех!

Директорның бетчәле йөзендә, тавышында шул тиклем ачу-нәфрәт чаткылары күреп, тарихчы сискәнеп китте, канына сеңгән курку-өркү хисенә бирелеп, ялт-йолт тирә-ягына карап алды. Ярый әле кабинетта икәү генә иделәр. Хәзер заман башка, татарлар үз җирләренә хуҗа булырга теләп, шау итәләр, Фәүзия дигән милләтчеләре урысларны куарга, катнаш никахтан туган балаларны юк итәргә дип лаф ора, имеш. Сыер дуласа аттан яман, сүзләреңне төйнәп, итәкләреңне җыйнап йөрмәсәң, урыныңнан да бәреп очырырлар.

...Бәйрәм барган олы залга килеп кергәч, Нина Ивановна, йөзенә фәрештә кыяфәте чыгарып, елмайган булды. Бар сабырлыгын җыеп, үзе аңламаган җырларны, шигырьләрне тыңлады. Әле бер, әле икенче укытучы янына килеп:

—Молодцы, әйбәт оештыргансыз. Тырышсагыз, булдырасыз бит,—дип хуплагандай, мактагандай итенде. Ары төртелеп, бире төртелеп йөрде дә, үзенә игътибар юклыкка үртәлеп, китәргә уйлады. Әмма китмәде. Чөнки видеокамера күтәреп, спортзалга кереп килүче телевидение хәбәрчеләрен күреп алды. Вак-вак басып, вәкарьлек белән алар каршына чыкты, үзенең монда хуҗа икәнен белдерергә ашыкты. Ә хуҗа һәрчак игътибар үзәгендә булырга тиеш! Шулай итеп мәктәптә үткәрелгән бәйрәм турында, нәзек иреннәрен бөрештерә-бөрештерә, чеп-чи марҗа сөйләп бирде:

—Безнең мәктәптә,—диде ул,—укучыларны милли рухта тәрбияләүгә зур игътибар бирелә. Татар мәдәнияте гаҗәеп бай, тирән тамырлы. Татар балалары гына түгел, шушы җирдә, Татарстан республикасында яшәүче һәр кеше төп халыкның телен, әдәбиятын, мәдәниятен яхшы белергә тиеш. Нәкъ шушы максаттан, безнең мәктәптә төрледән-төрле чаралар үткәрелә. Мәктәп администрациясе татарча чыршы бәйгесен үткәрүдә бик теләп ярдәм күрсәтте. Киләчәктә дә милли тәрбиягә зур игътибар биреләчәк.

Аның чыгышын мәш килеп бәйрәм үткәреп йөргән укытучылар ишетмәде. Әгәр ишетсәләр, бу кадәр икейөзлелектән хушсыз калып егылырлар иде. Шаккатулар әле алда, тапшыруны карагач, булачак. Әлегә алар үз эшләре белән мәшгуль. Әнә Шүрәле булып киенгән Илдания балаларны куркытып йөри: “Кая, кая кайсыгызны кытыклыйм? Кайсыгыз батыр, урман Шүрәлесенә кем каршы чыга?” Чү! Берәү “Мин!” ди түгелме соң? Аның каршына елмая-елмая Раил Мансурович килә ләбаса! Бу һич тә сценарий буенча түгел! Илдания коелып төште, ни әйтергә белми аптырады. “Йә әле, йә, көч сынашып карыйк булмаса”,—дия-дия, чыршы артына чигенде.

—Шүрәле! Нигә качасың? Качма, мин синең бармагыңны кысмыйм. Мин сине үзебезнең авылга алып кайтам!—дип кычкыра Раил.

Балалар рәхәтләнеп көлә. Бу бөтенләй башка әкият, бу Тукайча түгел.

Ак күлмәкле, галстуклы, кара кәстүмле абый Шүрәле артыннан йөгерсен, имеш! Сценарий буенча сәхнәгә чыгарга тиешле батыр малай нишләргә белми, аптырап басып тора. Менә Шүрәле киенү бүлмәсенә кереп югала.

—Мин сезне таныдым, Илдания!—ди аның эзенә басып кергән Раил.— Шундый шәп уйныйсыз.

—Сез... сез нигә... болай иттегез? Сез бөтен уенны боздыгыз!— Илданиянең бу кешегә инде чынлап ачуы килә.

—Шүрәлекәй, ачуланма инде. Бәйрәм бит. Шаярасы килеп китте.

—Зинһар башка комачауламагыз. Бу—мәктәп! Цирк аренасы түгел! Балалардан оят.

—Ник оят булсын! Әнә алар рәхәтләнеп көлә генә!

Раил үзе дә көлә. Бүген ул бөтенләй башка кеше. Кырыслыгының, житдилегенең әсәре дә калмаган. Ни булган аңа?

* * *

Сүз бирденме, үтә! “Камил” фирмасына, анын директорына ярдәмнәре өчен рәхмәт белдереп редакциягә хат язуны Илданиягә йөкләделәр. Алда тоташ бәйрәмнәр, хатны тизрәк бастырып чыгару кирәк иде. Кичен Хәмитне ашатып, савыт-сабаны юып куйгач, Илдания каләм, кәгазь алып өстәл артына утырды. Нидән башларга? Моңарчы мәкалә язганы юк иде, уй-фикерләрен туплый алмый газапланды, чөнки күз алдында һаман ул, елмая-елмая каршына килүче озын буйлы ир пәйда булды. “Мин сезне таныдым, Илдания!”. Бигрәк якын итеп, үз итеп дәште шул. Карашы шундый җылы, тавышы ягымлы. Менә шул кешегә рәхмәт әйтеп хат язарга кирәк. Рәхмәт сина, әй яхшы кеше! Чыршы тирәли Илданияне куып йөргән дивана... Юк, юк, дивана түгел, “Бәйрәм бит. Шаярасы килеп китте”. Әллә нинди аңлаешсыз, серле зат булып чыкты әле бу Раил Мансурович дигәннәре. Йә, ярар, язарга кирәк. Бәйрәм турында язарга кирәк. Ә нигә язмаска? Эшләре күренсен, башкаларга үрнәк булсын. Менә бит нинди заман килде, урыс мәктәбендә татарча бәйрәмнәр үткәреп яталар, дисеннәр. Шундый зур, матур бәйрәм үткәрергә ярдәм иткән дип, Раилне дә мактасыннар. Укыгач, шатланыр әле. Әйе, ул да укыячак бит! Бу күнелле ачыштан соң, әйтерсең, баш миендәге ниндидер киртә җимерелеп төште, уйлар үзеннән-үзе чишмәдәй агыла башлады, алар кәгазьгә җыр булып түгелде.

Мәкалә язылып беткәч, Илдания үзенә-үзе сокланып утырды: “Карале, нинди шәп язылган бит! Менә, ичмасам, талант! Моны һичшиксез басачаклар, җырлый-җырлый басачаклар. Һәм ул мәкаләне Раил дә укыячак. Тукта, укыса, укымаса, синен ни эшең бар анда? Кем ул сина? Син ана кем? Кызы булган кешенең хатыны да бардыр, ләбаса!”.

Әмма барыбер, барыбер... Ул бар! Дөньяда ул бар! Илдания ул төнне күкрәгенә ниндидер зур шатлык тулуын тоеп елмая-елмая, йокыга талды...

—Бүген бездә газет чыга торган көн, вакыт тыгыз,—дип каршы алды аны икенче көнне газет редакторы.

Бу кешене Илданиянең элек тә күргәне бар иде. Күргән саен гаҗәпләнә иде, шулкадәр арык гәүдә, шулкадәр нечкә муен бу кадәр олы башны ничек күтәреп йөртә икән, дип. Ай-һай авырдыр мондый олы башны көне буе күтәреп йөрү! Әле бу башка бүрек тә кигезеп куйсаң...

Илдания, йөзенә ифрат җитди чырай чыгарып:

—Мин сезне тоткарламам,—диде.

Әмма укытучы кеше кыска сөйли аламы? Балаларга дәрес аңлаткандай, эңәсеннән җебенә кадәр сөйләргә өйрәнгән ич инде алар. Редакторның Илданияне тыңлап бетерергә түземлеге җитмәде:

—Ханым, безнең газет “Мәгърифәт” түгел, укытучылар өчен генә чыкмый. Үзегезне мактап язган статьялар кирәкми безгә. Укымасам да белеп торам: сезнең мәкаләгез гап-гади отчет ул. Бездә материаллар болай да күп, тау хәтле язма чират тора. Сезнең мәкаләне бастыра алмыйбыз.

Ханымның ачуы килде:

—Татар телендә чыршы бәйрәме көн дә үткәрелми. Урыс мәктәбендә бит! Миңа калса, бу зур вакыйга!

—Ул бәйрәмнәр авыл саен, мәктәп саен үтә. Һәркайсы турында яза башласаң, ун битлек газет та җитмәс!—диде редактор дорфа гына.

Мондый мөнәсәбәтне көтмәгән Илдания ишекне шапылдатып чыгып китәргә уйлаган иде, бирелгән вәгъдә исенә төшеп сабыр итәргә булды.

—Бәйрәмне үткәрергә бик игелекле бер кеше ярдәм күрсәткән иде. Аңа газет аша рәхмәт белдерергә ярыйдыр бит? Ике-өч җөмлә белән генә булса да.

—Рәхим итегез, анысына каршы түгел. Кассага акча түләгез дә, хатыгызны калдырыгыз.

—Акча түләргә?—дип гаҗәпләнде Илдания. Бу хакта беренче ишетүе иде.

—Мин сезгә аңлаешлы итеп әйттем шикелле.

Илдания редакциядән үртәлеп чыкты. Күңелендә талпынган кошның канатлары салынган иде.

Атна-ун көн үттеме икән, Зәлия Гамировна Илданиягә нindидер газет сузды да:

—Күрдеңме, укыдыңмы?—дип сорады.

—Юк шул, укымадым. Быел район газетына языла алмый калган идем.

—Мә, алайса, укырсың.

Газетны алды Илдания, тик дәрескә ашыга иде, укып өлгерә алмады, ә аннары аның турында бөтенләй онытты да.

—Йә, ни әйтерсең?—дип сорады Зәлия мәктәптән кайтырга чыккач.

Сүзнең ни турыда баруын аңламаган Илдания:

—Ни әйтим? Менә тагы бер көн үтте. Язга тагы бер адым якынайдык,—дип куйды.

—Мин бит газеттагы мәкалә турында әйтәм. Язга ерак әле.

—И аллам, Зәлия апа, мин аны укымадым ич. Кайда икән инде ул?—Илдания сумкасында актарына башлады. Дәфтәрләр арасында кысылып калган газетны тартып чыгарды.—Шул бугай. Сез ни укырга кушкан идегез әле?

—Менә, өченче биттә. "Кыш бабай бүләге кемнәр өчен?" дигән мәкалә.

—Ярар, өйгә кайткач укырмын әле. Ул хәтле мөһим түгелдер бит?

—Мөһимдерме, юкмы, белмим. Укып чыккач, төне буе йоклый алмадым. Өстебезгә мичкәсе белән пычрак су түккәннәр. Белмим, кемгә комачаулаганбыздыр.—Зәлия Гамировна авыр гына көрсенеп куйды.—Син укы әле, укы башта.

Кая монда уку? Урамда карлар бөтерелә, җил аларга кунарга ирек бирми, җиргә төшеп ятканнарын да пыр туздыра. Кире мәктәпкә кереп, буш класска үттеләр. Илдания мәкаләне тыныч кына укый алмады, үртәлде, ярсыды: "Әстагы, бу ни дигән сүз?! Кайсы юньсезе язган моны?"

"Зур өметләр белән килгән идек без татар чыршысына. Бәйрәм урынына нindидер тәртипсез тамаша күреп кайттык. Кем нәрсә тели, шуны эшли. Бернинди оешканлык, әзерлек юк. Үткәрүчеләр әрле-бирле чабышып йөриләр.

Кыш бабай алдан билгеләнгән кешеләргә генә бүләк таратты. Минем баламны сөйләтмәделәр, бүләк тә бирмәделәр.

Газетта мәктәп укытучылары спонсорларына рәхмәт әйтеп хат язганнар. Язырлар да шул, бәйрәмне үзләре өчен үткәрделәр бит. Спонсор акчасы санамаган, кемнең күпме эләктергәне билгесез..."

Хат тулаем шушы рухта язылган иде. Мәкаләне укып бетергәндә Илданиянең йөзендә кан әсәре калмаган, иреннәре дерелди иде.

—Менә шулай, дустым,—диде Зәлия апасы.—Ит яхшылык, көт яманлык...

—Башыннан ахырына хәтле ялган ич бу! Кем язган моны? Кем ул Әхмәтшина?

—Мин исәпләдем, безнең мәктәптә Әхмәтшин фамилиясен йөртүче биш малай, сигез кыз бар. Кайсының анасыдыр.

Илданиянең күз алдына нәзек муенлы, олы башлы редактор килеп басты. Аның хатын-кызларныкына охшаш нечкә тавышы яңгырады:

—Сезнең мәкалә өчен урын юк, тау хәтле язма чират көтә.

Менә нинди язмалар чират көткән икән! Андыйларга урын түрдән. Әмма нигә, нинди максаттан эшләнгән бу?

—Татар газеты бит бу...—дип әрнеп әйтеп куйды Илдания. Ичмасам, бастырып чыгарганчы, безне күреп сөйләшкән, тикшергән булсалар! Ярдәм итәсе урында, аяк чалалар. Иһ!

—“Татар татарның башын ашар”,—шул була инде, дустым.

Урамга чыккач, Илдания кулындагы газетны вак-вак кисәкләргә турап, җилгә очырды. Алар кар бөртекләре белән буталып, һавада бөтерелә башлады. Әгәр кара язулары булмаса, ул кисәкләр ак кар бөртекләренә охшар иде.

* * *

—Әти, син нигә чыршы янына чыктың? Мин аптырап киттем, син... и вдруг такое. Не солидно, әти!

Нигә чыкты? Нигә Илдания артыннан йөгерде? Белсә икән Раил! Соңыннан үзе дә аптырады бит. Әллә нинди ашкыну булды ул. Акылсызлык, малайлык, җүләрлек... Кызына ни дип кенә җавап бирсен? Әмма дә сорауны җавапсыз калдыру килешми. Бигрәк тә Алсуныкын.

—Балачагым, яшьлегем искә төште. Гел олы, җитди булып йөрү туйдыра, кызым. Аңлыйсыңмы? Кайчагында үз яшеңне онытасы килә.

Кызы аны аңламады: чөнки ул яшьлек дигән әкияти гүзәл бакчаның ишекләрен ачып кына маташа. Әле ул аның сихри көчен, татлы тәмен белми. Яшьлек бакчасы белән хушлашкач, адәм балаларына мәңгелек сагыш ияргәнен уналты яшьлек кыз бала каян белсен?!

Кырык яшенә җитеп килсә дә, Раилнең хуштан язып гыйшык тотканы булмады. Ул кызлар көйләп йөрмәде. Чөнки кәләше кул астында гына иде. Тәпи йөри башлагач та, ишегалдындагы комлыкта очратты ул аны. Шуннан алар аерылмадылар. Коңгырт бөдрә чәчле, зәңгәр күзле, зур авызлы бу кызый Раилнең күләгәсенә әйләнде. Ландыш та алар йортында тора, хәтта подъездлары да бер үк. Ни гаҗәп, гел бергә йөрүче малай белән кызны “жених и невеста” дип үртәүче булмады. Үпкәли,кылана белмәгән, гел шаярып-көлеп йөргән Ландышны малайлар үз ишләре итеп күрәләр, аны кәләш ролендә күз алдына да китермиләр иде. Ландышның гел янәшәдә булуына Раил шул тиклем күнгән иде, армиягә киткәч, бер мәл югалып та калды хәтта. Бик ямансу икән ич ана бу кызыйдан башка! Гомерендә кызларга хат язганы булмаган Раил аптырап йөргәндә, аңа китап калынлыгы хат килеп төште. Ландыштан! Кызый егет кебек баш ватып тормаган, шәһәр яңалыкларын, иптәшләренең, үзенең хәлләрен бәйнә-бәйнә язып, егерме бит тутырган да, иң ахырдан, “карале, мин сине сагынам бит, чукынчык малай”, дип язып куйган. “Чукынчык малай” отпускыга кайтуга, Ландыш янына йөгерде, дус кызын беренче тапкыр кочып үпте. “Үбешә дә белмисең бит, әллә япун кызлары өйрәтмәде үзеңне?—дип көлде Ландыш. Раил Тын океан флотында хезмәт итә иде. Егет үртәлүдән кызарып чыкты. “Ә сине кем өйрәтте?”—диде ул көнләшүеннән шартларга җитешеп. “Үзем!—менә болай”—Ландыш кулын иренәнә китерде дә, шаян күзләрен Раилгә төбәп, беләген суырып үпте. Ап-ак беләктә кып-кызыл эзләр калды. Икесе дә шаркылдап көлделәр шулчак.

Шаян иде Ландыш, табигый, гади иде. Алар икесе бер җан, бер тән булып яшәделәр. Бик бәхетле буласылар иде. Әмма шатлык көткәндә, кайгы килде. Дөньяга аваз салырга да өлгермәгән улы белән хатынын бер кабергә салдылар... Раил өчен кояш сүнде. Туганнары, ялгыз яшәп бетә алмассың, өйлән, диеп әле берсенә, әле икенчесенә димләп маташты. Раил аптырады: “Ландыштан башка хатын-кызлар булуы мөмкинме? Аны алыштырырлык зат дөньяда бармы?”. Ир, берниндн үгетләүгә карамыйча, буйдак булып яши бирде. Янында кызы бар, җиткән!

Әйе, Раилнең һуштан язып гашыйк булганы юк иде. Әмма бу ялгыз, үзе чибәр, үзе бай иргә күз кыздырып, тирәсендә биеп йөрүче гүзәл затлар аз түгел иде. Күз генә кыс, берсүзсез кочагына керергә әзер тора. Әмма Раил

күз кысмады, үзенчә яшь бирде. Илданиянең исә бу хатын-кызлар алдында бердәнбер өстенлеге шул: ул Ландышка охшаган иде! Раилгә шул җитә калды, Ландышын хәтерләткән кеше табылуына, андый затның дөньяда булуына, һәм менә нәкъ үзләренең шәһәрендә яшәвенә, аның белән очраша алуына ул балаларча сөенде. Беренче очрашуда ир моны сиздермәскә тырышты. Әмма әледән-әле Илданиягә күз төшереп, эченнән генә сокланып, гаҗәпләнеп утырды. Башын читкә борып көлеп куюлары, ирен чите белән елмаюлары, каш астыннан сөзеп, сынап караулары, озынча аксыл йөзе, шул йөзнең яртысын диярлек биләп торган зур авызы—барысы, барысы Ландышны хәтерләтә иде. Охшаш чалымнарны күргән саен шатланды ир. Илданияне озатып калганда, ул инде карар чыгарып өлгергән иде: "Мин бу хатынга өйләнәм!".

Карар кабул ителгәч, аны кичекмәстән тормышка ашыру кирәк. Әгәр инде бу сөйкемле затны үз хатыны, кызының әнисе итеп күрергә тели икән, аның турында күбрәк белү зарур. Раил бу эшне сеңлесе Рәүфәгә йөкләде. Рәүфә йортлар идарәсендә эшли, шәһәр кешеләре турында теләсә нинди мәгълүматны табып бирә ала.

—Нигә соң үзеннән генә сорамыйсың? Әллә бик куркыныч кешеме?— дип көлсә дә, абыйсының йомышын үтәде, берничә көннән Илдания турында белешмәләр Раилнең өстәлендә ята иде инде.

Яртау шәһәрендә Илдания исемле бер укытучы ханым яши, һәр иртәне дәфтәр-китап тулы сумкасын күтәреп мәктәпкә ашыга. Үткәрәсе дәресләре, укучылары турында уйлый, ирен кайгырта, өй җыештыра, кер юа... Аның көне меңләгән хатын-кызларныкыннан берни белән дә аерылмый. Раил дигән берәүнең үзен гомерлек яр итеп сайлап маташуын ул башына да китерми, әлбәттә. Әмма бу шулай булачак. Чөнки моны Раил тели. Әгәр инде теләк-хыялларыңны тормышка ашырырлык та рәтең юк икән, ник яшәргә бу якты дөньяда? Һәрхәлдә Раил андыйлардан түгел.

Әмма сеңлесе генә кирегә сукалый:

—Сиңа кирәкле кеше түгел ул. Беткәнмени ялгыз хатыннар?

—Балалары юк дигәнсең ич.

—Балалары булмаса, ире бар! Аны кая куясың?

—Беркая да куймыйм. Анысы өендә калыр.

—Кызык син, абый! Бигрәк җинел уйлыйсың. Кеше язмышын ансат кына хәл иттең дә куйдың. Бәлки алар яратышып, яхшы яшиләрдер. Син бит әле ул хатын белән сөйләшеп тә карамаган!

—Ире ОРСта йөкче димәк... Ә хатыны—укытучы... Странный брак бу! Брак бу, чынлап та брак! Патша кызы белән көтүче арасында мәхәббәт әкиятләрдә генә була!

—Ну, абый! Гомергә шырдый-бырдый булдың инде. Акыл керергә вакыттыр югыйсә. Кырыкка җитәсең бит!

—Кырыкта акыл керми, Рәүфә, булганнары чыга башлый. Ну өйләнергә ярый әле.

—Өйлән! Кем сиңа өйләнмә ди?! Ирсез тилмерүче хатыннар муеннан! Ә сиңа нәкъ менә ирлесе кирәк.

Раил җитдиләнде, йөзенә сагышлы уйчанлык чыгарып әкрен генә:

—Әйе шул сеңлем, миңа Илдания кирәк! Никтер нәкъ менә ул кирәк. Йөрәгем шулай куша,—диде.

Теге чакта Яңа ел бәйрәменә дә Илданияне күрер өчен генә килде бит ул. Олы башын кече итеп бала-чага арасында йөрер идеме югыйсә?! Аның килүен Алсу да өнәмәде бугай, әтисен күрмәгән булып кыланды.

Ландышын хәтерләткән хатынга читтән генә туйганчы карап торасы килгән иде Раилнең. Тик Илдания күренмәгәч, кәефе төште, ник килүенә

үкенә башлады. Чыршы тирәли озын бармакларын уйнатып йөгереп, юк, йөгереп кенә түгел, очып йөрүче нечкә билле нәфис затның Илдания икәнен аңлагач, шатлыгыннан гүя акылын җуйды, "Мин!" дип аның каршысына йөгереп чыгуын үзе дә сизми калды.

* * *

Раил кичке ашка өйгә кайтырга тырыша. Эше ничек кенә тыгыз, вакыты ничек кенә кысан булмасын, кичке ашны ул үз өенә кайтып ашый.

Үз өенә... Ландышсыз калгач, ул өйдә җылылык, ямь бетте. Улларының үзенә урын тапмый өзгәләнеп йөрүен күреп, әнисе белән әтисе ул йортны сатып, якын-тирәдә берәр фатир алырга киңәш иткәннәр иде. Раил ризалашмады, бәхетле үткәргән уртак елларының шаһиты булган, үз куллары белән төзегән бу йорт аңа бик якын, бик кадерле иде. Ялгызы кайгырып утырмасын, ятим балага да юаныч булырмын дип баштагы мәлләрдә әнисе алар янында яшәде. Тик ике йорт арсында йөреп ул да арыды, ахыр чиге ата белән кыз икәүдән-икәү калдылар. Алсу балачак белән иртә саубуллашты, иптәшләре урамда куышлы уйнап йөргәндә, бу бала, кулына хуҗалык сумкасы күтәреп, учына акчасын кысып, кибеткә азык-төлек алырга бара иде. Пешерергә, җыярга-юарга да иртә өйрәнде кыз. Үзенең мөстәкыйльлеге белән ул горурлана иде. Әтисе әллә соң берәр хезмәтче алыйкмы дигәч, аяк тереп каршы килде: "Мин үзем!".

Ата белән кыз, гадәттә, кичен генә очрашалар. Алсу әтисен ашарга пешереп, табын әзерләп көтә. Ул кайтмыйча, үзе бер кабым да ризык капмаячак.

Кичке аштан соң Раил кабат эшенә, мөһим очрашуларга, хәтта күңел ачарга да чыгып китәргә мөмкин, әмма кичке ашны ул кызы белән ашый. Бу гаиләдә тәртип шундый. Табын артында ата белән кыз бер-берсенең хәлләрен белешәләр, борчу-шатлыкларын бүлешәләр, яңалыклар белән уртаклашалар.

—Синең укулар ничек?—дип сорый Раил.

—Бишле!—дип җавап бирә Алсу.

—Молодец! Минеке дә бишле. Иртәгә объектны тапшырабыз. Вакытына өлгерттек.

—Ремонтлап бетердегезме? Матур булгандыр, әйе бит, әтием.

—Әйе. Тәртип. Иң мөһиме—материаллар житте. Сметага сыештык. Иртәгә кереп кара. Кибетне танырлык түгел хәзер. Эче дә тышы да ялт итеп тора.

—Әйбәт булган,—дип сөенә Алсу.

"Камил" фирмасы төзү-ремонтлау эшләре белән шөгыльләнә. Хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларына караганда арзанрак булганга, заказларга мохтаҗлык юк, әмма табыш күбрәк булган саен, салымны да мулрак каералар.

Раилнең хыялы диңгезче булу иде. Диңгез флотына бары нык таза егетләрне алганнарын белгәнгә балачактан ук үзен шуңа әзерләде. Аның бүлмәсендә һәрвакыт төрле авырлыктагы гирләр, штанга, кул-беләк көчен арттыручы спорт әйберләре булды. Раилнең һәр иртәсе урамда йөгерү, күнегүләр белән башланып китә. Җәйләрен фотбол уйный, иртә яздан су керә, кышлары чаңгыда чабып, хоккей уйнап үтә. Чаңгы шуганда егылып кулын каймыктыруны санамаганда Раил авырып ятуның ни икәнен дә белмәде. Егет теләгенә иреште. Аны диңгез флотына алдылар. Нияте хезмәте тәмамлангач та диңгезче булып калу иде. Туган якка ялга кайткач, ул бу хакта әтисе белән дә киңәште. Тик сөйләшү барып чыкмады:

—Улым,—диде әтисе.—Тыныч заманда хәрбиләрдән халыкка бер тиенлек файда юк. Сугыш-фәлән чыкса да бер көтү солдатның кирәге булмаячак.

Хәзерге заманда бер атом бомбасы барыбызны да кырып-себереп юк итәргә житә. Хәрби булуыңа һич ризалыгым юк. Диңгездә жил куып йөргәнче, илгә кайт, монда файда китер.

—Әй, әти, аңламыйсың син. Диңгез күргәнең юк. Югыйсә башкача сөйләр идең,—дип каршы төште Раил.

—Адәм баласы балык түгел, улым, аның урыны жирдә. Алай бик диңгез дип шаккатсаң, әнә курортка барып йөрерсең. Диңгезче имеш... Шул да булдымы эш?! Дөньяда ожмахка илтә торган өч һөнәр бар: игенче, төзүче, укытучы. Үзем гомер буе йортлар салдым. Алар миннән соң да калачак, күпме кешегә жылы куыш булачак. Юкка яшәмәдем дип күкрәк киереп йөрерлегем бар!

Раил, әтисен күндерә алмаганын аңлап аңа каршы сүз дәшмәде. Әмма барыбер үз фикерендә калды. Төзүче эшенең ни икәнен ул яхшы белә иде. Чөнки мәктәпкә ремонт ясаганда өлкән сыйныф укучыларын да жиктеләр. Измә ясарга да, таш ташырга да туры килде. Куырып алырлык эсседә дә, үзәгенә үтәрлек суыкларда да, жил-яңгырларда да ачык һавада эшләп, әтисе ни гомер буыннары сызлау белән жәфалана, ә үзе горурланып шул авыр эшкә улын кодалап утыра тагын.

Әйе, Раил үз фикерендә калды, диңгезләр кичәсе, дөньялар гизәсе килде. Ләкин ул уйлаганча барып чыкмады, егет үз теләге белән яшьлек хыялларыннан ваз кичте. Беркем мәжбүр итмәсә дә, гәрчә аның тырышлыгын, кыюлыгын, намуслылыгын күреп, комадирлары хәрби хезмәттә калырга үгетләсә дә, ул барыбер туган якка әйләнеп кайтты. Әтисенең хаклы булуын аңлап кайтты. Айлар буе диңгез кочагында яшәү, андагы бертөрлелек, каты жиргә, жылы туфракка басып үскән егетне ахыр чиге барыбер ялыктырды. Ул ямьле туган ягын, шәһәр урамнарын сагынып кайтты. Күрше кызы да: "Кайт, сагынам, көтәм", дип хатлар яза иде.

Солдат хезмәтен тутырып кайткач, Раил Әлмәт төзелеш техникумына укырга кергән иде. Бик шәп укыттылар аларны. Жәй житте исә сылау-агарту, буяу эшләренә жигәләр иде. Практика дигән булып, бер тиен акча түләмичә эшләттеләр. Аның каравы күпме тәжрибә туплады Раил. Яртауга кайтып, төзелеш трестына урнашкач, мастер булып та, прораб булып та эшләргә туры килде аңа. Горбачев заманы килгәч, үз бригадасын туплады да, шабашкада йөри башлады. Заказлар күбәйде, бригада зурайды, "шабашчы"лардан кече предприятие оешты. Аны Раил житәкләде, белеме дә, тәжрибәсе дә житәрлек иде. Соңрак үз офисларын булдырдылар, оешмаларын "Камил" фирмасы дип рәсмиләштереп тә куйдылар.

Алсу, әле мәктәптә генә укып йөрсә дә, фирманың эшләре турында һәммәсен дә диярлек белеп тора. Үзе дә, мәктәпне тәмамлагач,Казан төзелеш институтына керәм, төзүче булам, дип хыяллана. "Камил" фирмасы, әтисенең эше яшәргә тиеш. Инде гаиләдә ир бала юк икән, әтисенең эшен Алсу дәвам итәчәк!

Өстәл янында сөйләшү дәвам итә.

—Ә безгә бүген яна укытучы керде. Шундый ягымлы апа,—ди Алсу.

—Нинди фәннән?

—Әдәбияттан.

—Сезне Наилә Хисамовна укыта иде түгелме соң?

—Ә ул авырый. Больницада ята.

—Начар...

—Беләсеңме, әти, Илдания Зөфәровна минем белән килеште. Ул да...

—Кем? Кем дисең?—таныш исемне ишетүгә Раил сискәнеп китте.

—Илдания Зөфәровна дим. Ә нәрсә?

—Юк, берни дә түгел. Сөйлә.

—Мин аннан сорадым: сезгә Йосыф ошыймы, әллә Зөләйхамы? Ә ул әйтте: Зөләйха! Чөнки ул ярата белә! Ә Йосыф мәхәббәттән баш тарта.

—Бу анын сүзләреме? Иллания Зөфәровна шулай дидеме?

—Юк, мин шулай дим.

—Каян исенә төште сон әле ул кыйсса?

—Әби аны яттан сөйли. Вәт хәтер! Ул әкият шундый зур, озын бит. Әби ничек исендә калдыргандыр. Мин гел Зөләйханы җәлли идем, гел газаплана ул. Ә Йосыфы шундый тәкәббер, шундый салкын. Яратмыйм гордый егетләрне. Кыланчыклар!

Раил елмаеп куйды:

—Нәрсә, синен йөрәкне дә берәр тәкәббер егет яндырып йөриме әллә?

Алсунын бите кып-кызыл булды:

—Әй лә инде, сина сөйләсән!

Раил исә кызы авызыннан Иллания турында күбрәк ишетәсе килә иде.

—Алайса, ошады дисен инде яна укытучы?—дип ялгап китте ул сүзне.

—Әй, сөйләмим. Сина барыбер кызык түгел.

—Нишләп кызык булмасын? Мин дә аны beләм бит.

—Алай булгач, ник сорыйсын?

Кинәт Алсунын йөзе яктырып китте, бүлтәйгән иреннәре язылды.

—Әһә,—диде ул, күзләрендә шаян очкыннар биетеп.—Исемә төште! Син Яна елда анын артыннан чаптын бит? Үзеннен йөрәген яна синен, мине үртәгән буласын тагын!

—Яна шул! Янса, ни ояты бар?—Раил кызы белән ачыктан-ачык сөйләшергә булды.

Алсу әтисенә гаҗәпләнеп карады:

—Синен яшьтәме?

—Минем яшьтә намаз укып утырырга гына кирәк димәкче буласынмы?

Кыз уңайсызланып китте, соравынын мәгънәсезлеген үзе дә аңлап алды. Әтисе аны тин күреп сөйләшә, ә ул...

Алсу житди тонга күчте:

—Син аны ошатасынмы?

—Әйе, кызым.

—Мин беләм, ник ошатканыңны. Ул әнигә охшаган, әйеме?

Менә ничек... Димәк, Раил ялгышмаган, кызы да анын фикерен хуплый түгелме сон?!

—Әйе,—диде ир ачыктан-ачык.

—Син ялгышасын, әти. Иллания апа башка кеше, ул әнине алмаштыра алмый.

—Син минем өйләнүемне теләмисен, шулай бит?

Алсу, иренен тешләп,уйга калды. Ни дисен? Әлбәттә, теләми. Ләкин әтисе гомер буе ялгыз яши алмас бит. Киләсе елга Алсу мәктәпне бетерер дә, Казанга китеп барыр. Шушы иркен, зур йортта әтисе ялгызы калырмы? Бик күнелсез булачак бит ана. Алсу моны аңламыймы? Аңлый, ләкин өйләренә чит кеше килүен теләми. Әтисен беркем белән дә бүлешергә теләми. Кирәк белән теләк икесе ике нәрсә. Әтисенә өйләнергә кирәк. Ә Алсу әтисенен үзенеке генә булуын тели. Дәшмәү ризалык билгесе, диләр. Раил аңлады: Алсунын дәшмәве нәкъ менә ризасызлык билгесе иде. Әмма аны Илланиядән баш тартырга мәҗбүр итәрлек көч дөньяда юк иде инде.

* * *

Әнә ул әкрен генә атлап килә. Өстендә тыйнак якалы яшел пәлтә, бөдрә чәчләре ак шәл астыннан тузгып чыккан. Шәленә, иннәренә ак кар кунган. Аларны кагып төшерү файдасыз, чөнки урамда ишеп-ишеп кар ява. Иллания

карлы сукмакта өр-яңа эзләр калдырып, авырлык белән генә атлый. Каршы искән жил, битенә бәреп яуган кар комачаулыймы, әллә бик арыганмы. Раилне күргәч, ни дияр? Аңлармы, әллә гаепләрме? Ирле хатынны кияүгә сорап килү үзе бер тилелектер инде ул.

Илдания якынлашкач, Раил машинасыннан чыгып, аңа каршы атлады.

—Исәнмесез, Илдания!—дип кул сузды.

Хатын башта аптырап калды, күрергә комачауламасын дигәндәй, йөзенә кунган меңләгән кар бөртекләрен сыпырып төшерде дә, каршында кинәт пәйда булган кешенең Раил икәнен танығач, елмаеп исәнләште. Шундый сөйкемле иде ул бу мизгелдә, аны кочаклап-үбеп алудан көчкә тыелып калды Раил.

—Илдания, кар астында тормыйк. Машинага утырып сөйләшик,—диде ул. “Кызык, ни турыда сөйләшмәкче була икән? Әллә кызы хакындамы икән? Кич белән, аулак урамдамы? Кызы турында сөйләшер өчен мәктәп бар. Ә нигә машинага утырырга? Нигә урамда гына түгел? Шул хәтле сүзе күпме? Гажәп, бик сәер”

—Утырыгыз, Илдания,—Раил машинаның алгы ишеген ачып, хатынга урын тәкъдим итте.

Өстендәге карны бераз каккалагач, Илдания жылы машина эченә чумды. Аның тәрәзәләрен шул арада кар каплап киткән, үткән-сүткән кешеләр, ни кызыксынсалар да, биредәгеләрне күрмәячәкләр. Шуңа күрә, танышбелешләр күрүеннән, гаепләвеннән курыкмыйча, иркенләп сөйләшеп утырырга була. Илдания ирнең сүз башлавын көтә. Тик Раил дәшми, чөнки... Чөнки аптырап, каушап калды. Югыйсә һәр жөмләсе алдан уйланган иде бит. Менә сиңа, Илданияне янәшәсенә утырткач кына, жебеде дә төште. Әмма болай дәшмичә утырып та булмый бит. Әһем-әһем...

—Илдания, сез минем кызымны укытасыз икән. Алсу сезне бик мактый.

—Ул үзе дә бик тырыш кыз.(“Алай... Димәк, бу кеше кызы турында сөйләшергә килгән...”)

—Алсу сезне бик ошата.

—Рәхмәт.

—Моңа хәтле аның бер хатын-кызны да болай мактаганы юк иде.

—Шулаймыни?

—Кызым сезне бик ярата, Илдания.

—Рәхмәт, бәхете булсын. Гафу итегез, әгәр башка сүзегез булмаса, мин китим.

—Бар!

Шундый кинәт һәм кычкырып әйтелгән бу сүзне ишеткәч, Илдания коелып төште. Нинди тупаслык! Әмма, үртәлергә ашыккан икән, ул “кит!” дип аңлаган “бар” сүзенә бөтенләй башка мәгънәдәге жөмлә ялганып китте:

—Башка сүзем дә бар, Илдания. Зинһар, китмә. Зинһар, югалма!

Хатынның аптыраулы-сораулы, шул ук вакытта жылы, назлы, өметле дә карашы ирнең ялварулы күзләре белән очрашты.

“Янсам-янам, батсам-батам, бер чумуым, чыгуым, уф!”—Раил йөрәктәге утын бер сулыштан чыгарып ташлавын сизми дә калды:

—Илдания, хатыным бул! Бергә яшик.

Үз дөньясын кайгыртып, уйларына чумып тыныч кына атлап барган кешенең, арттан килеп, башына суксыннар әле, ни кичерер иде микән бичара? Илдания дә нәкъ шул хәлдә иде, тәмам зиһене чуалды. Раил исә, аңа анга килергә дә мөмкинлек бирмичә, дәвам итте:

—Мин ялгыз, кызымнан башка беркемем дә юк. Син миңа кирәк, Илдания! Чык миңа кияүгә.

Илдания мондый сөйләшүгә әзер түгел иде. Раилнең сүзләре колагыннан

кирә, әмма аңына барып житә алмыйча кайдадыр адашып йөри.

—Тик мин... Минем бит... ирем бар.

Әмма Раил сүзеннән чигенергә ашыкмый, Илданиягә таба ава төшеп, күзләренә туп-туры карап:

—Бармы соң ул? Чынлап та, бармы?—диде.

Бу сорауга жавап эзләгәндәй, хатын уң кулын йөзенә якын китерде дә, бармагын кысып торган тар балдакка, беренче тапкыр күргәндәй, озак кына карап торды: “Чынлап та, бармы соң ул?!”

Шулчак аны кочаклап алдылар, бармакларын үптеләр, йөзенә кайнар тамчылар тамды. Илдания аларны шәленнән эреп төшкән кар тамчылары дип уйлады. Тик ялгышты. Ул яшьләр Раил күзләреннән тамды. Ир тавышсыз—тынсыз гына елый иде. Яшьлек ярын артык иртә югалткан, парсыз аккоштай ялгызлыктан тилмереп, хатын-кыз жылысына сусап яшәгән тол ир ничә еллар буе бәгырен көйдереп яткан иң яшерен хисләренә ирек бирде. Ничә еллар буе жыелган сагыш Илданиянең мамык шәленә түгелде, ир күз яшьләрен аңа күрсәтергә теләми иде. Иреннәре, дымлы чәчләрне үбә-үбә, әкрен генә пышылдады: “Бәгърем... Зинһар, югалма, югала гына күрмә. Өметемне өзмә...”

Чит ир белән кочаклашып утыруына унайсызланып, Илдания йөзен читкә борды. Шулчак әллә ялгыш, әллә Раил шулай теләдеме, иреннәре ирнең кайнар иреннәре белән кушылды. Аны болай назлы итеп, бөтен тәнен, жанын, йөрәген оетырлык итеп гомерендә беренче тапкыр үбүләре иде...

* * *

Казан малайлары өйрәткән кәсебен Миша Яртауда да ташламады, тәмле-томлы ашарга өйрәнгән карак малай чүплек ризыгыннан тиз туйды. Урлашып йөри-йөри кулы шактый шомарган елгыр үсмер базар тирәсен үз итте. Ял көннәрендә базар кырмыска оясыдай мыжлап тора, ата улны, ана кызны белми, товар сайлый-сайлый, күзләре тонган кешеләр берсен-берсе таптап үтәргә әзер булып кыбырсыйлар. Ә Мишага шул гына кирәк тә, халык арасында елан кебек бөтерелә. Аны тоту түгел, күрергә дә өлгерми калалар.

Карангы оясына харап горурланып, вәкарьлек белән кайтып керә, тапканын дусты белән бүлешә, әмма төрттереп куярга да онытмый:

—Мә, аша абзаң тапканны! Тәмлеме? То-то! Минем белән югалмассың!—дип масая.

Подвалда яшәгәндә генә түгел, ни балалар йортында, ни әти-әнисе янында туйганчы ашый алмаган Рәмис комсызланып алма-әфлисунга ябыша, тартып алмагайлары дигән сыман, ашыга-ашыга ашый.

—Эшләп ашарга кирәк, Ромка!—дип төрттерә Миша.

—Мин куркам. Тотсалар, тагы детдомга ябып куячаклар. Минем детдомга барасым килми.

—Ха! Тоттырмаска кирәк! Тотсалар, мине төрмәгә ябалар әле, чөнки мин кеше үтердем. Вот так!—Мишканың үзен харап батыр итеп, текә итеп күрсәтәсе, бу йомыкый малай алдында мактанасы килә.—Минем башлар күрде инде, братан! Минем рәсем чат саен эленгән, һәр көнне теликтан күрсәтеп торалар. Разыскивается опасный преступник! Вот так! Ә мин,—Миша кулын өскә күтәреп кукиш күрсәтә,—менә аларга! Тоттырмыйм. Ха! Хәзер!

Рәмиснең күзе мангаена менә:

—Син... Син, чынлап та, кеше үтердеңме?

—А как же!—Миша инде үз ялганына үзе ышанып, тәмам рольгә кереп беткән.

Рәмис авызына капканын чәйнәргә дә онытып:

—Мин синнән куркам,—ди.

—Курыкма! Сине үтереп миңа ни файда?! Сәләмәннән башка ниең бар?! Син, Ромка, авыз ачып утырма, блин. Миша сине гомер буе ашатмас, давай, эшлә. Мин сине үзем өйрәтәм. Без синең белән базарның өстен аска әйләндерәбез, каракүтләрне үрле-кырлы сикертәбез әле, да, братан?! Без, Ромка, тарихка кереп калачакбыз. Сине дә теликтан күрсәтәчәкләр. Детдом хәерчеләре асларына җибәрәчәк. Ха!

Мишаның кәефе шәп, тамак тук, өс бөтен, урыннары җылыда, артлары корыда. Аның җилдән җитез йөгерә торган аяклары, елгыр, җитез куллары бар. Алар булганда Миша ачтан үлмәячәк. Шуңа күрә ул иртәгәге көн өчен кайгырмый, тук корсагын кочаклап, бер гаме булмаган кешедәй, башын төртүгә йоклап та китә.

Ә Рәмисне йокы алмый. Мишаның сүзләре күңеленә шикле уйлар, борчулар сала. Миша кеше үтергән... Миша Рәмисне урлашырга чакыра, үзем өйрәтәм, ди. Ә Рәмис моны күз алдына да китерә алмый. Булмас ла, булдыра алмас, гомерендә кеше әйберсенә кул сузганы юк. Югын юк та... Әмма алып кайтып биргәч, баш тартмый, рәхәтләнеп ашый бит әле. Урлау—гөнаһ, ә урлаганны ашау гөнаһ түгелме? Аннары алар бит аз-азлап кына алачаклар, үзләренең тамакларын туйдырырлык кына. Ачтан үлмәс өчен урлашу алай зур гөнаһ та түгелдер әле. "Миша ашата, Миша киендерә... Алай да ярамыйдыр инде. Үз тамагыңны үзең кайгыртырга кирәк. Гел-гел Миша булмас. Шулай итәр, Рәмис тә тәвәккәлләр, дусты белән базарга чыгар. Күп алмас, әз генә... Тегеннән берне, моннан берне. Әллә ни зыян булмас әле. Аларның күп бит, күлдән бер чиләк су алганнан күл кимиме? Юк ич. Базарда сату итүчеләр—байлар. Аларда күп, алардан алсаң да ярар. Әйе, шулай итәр, Рәмис тә Мишага иярер, урлашырга өйрәнер. Бәлки әле баеп та китәр. Баегач, әнисе янына барыр, бик күп күчтәнәчләр алып барыр. И әнисе сөенер иде! Әнисе янына барыр өчен акча күп кирәк. Бәлки Миша акча урларга да өйрәтер? Күлдән бер чиләк алганнан ни була? Байлардан урлыйлар ич. Мишаны тынларга кирәк. Киләсе ялда Рәмис тә аңа ияреп, базарга чыгар. Танысалар, качар, аяклар ни өчен? Миша әнә Казаннан ук чыгып качкан. Әле ул кеше дә үтергән...

Шулай уйланып ята-ята, Рәмис бер карарга килә: ул да Миша кебек оста карак булачак! Аңа ияреп урлашырга чыгачак.

Әмма аның гөнаһлы хыялларына тормышка ашу насыйп булмады. Чөнки икенче көнне Миша кайтмады.

* * *

Илдания Раил белән саубуллашканын томанлы гына хәтерли. Бернинди каршылык күрсәтмичә, үзен үптерүенә, алай гына да түгел, беренче күрешкән ир ихтыярына тәмам буйсынуына оялды, уңайсызланды ул. Иреннәре аерылгач, Раилгә күтәрелеп карарга да кыенсынып: "Хушыгыз",—диде дә, машинадан атылып чыгып, карга бата-чума йортларына таба йөгерде. Раил аны куып җитте, кулларын тотып:

—Мин җавап көтәм. Зинһар, өметемне өзмәгез, Илдания,—диде.

Шулай диде бугай... Ә Илдания саташкан, зиһенен җуйган кеше сыман үзләренекенә түгел, бөтенләй башка подъездга кереп киткән.

Икенче катның караңгы тәрәзәсеннән карый-карый озатып калды ул Раилне. Аның машинасы күздән югалгач та, өенә керергә ашыкмады, Хәмитне күрергә теләми иде. Әле генә булган вакыйгаларны хәтерендә яңарта-яңарта, урамда уйланып йөрде. Күңелендә Раил тавышы кат-кат яңгырады: "Җавап көтәм... Өметемне өзмә... Бергә яшик... Зинһар, югалма..."

Илдания ул төнне йоклый алмады, ничә еллар буе, бернинди ашкыну, тетрәнүләр кичермичә, тыныч кына тибеп яткан йөрәге ул төнне әллә нишләде, күкрәгеннән чыгып китәрдәй булып, дулап-дулап типте. Илдания ул төнне шигырь язды:

Син бар!
Көттем сине
Ничә айлар,
Ничә еллар.
Өмет уты сүнгәндә,
Караңгыга күмелгәндә,
Инде, ул юк, дигәндә,
Син табылдың!
Рәхмәт укыйм бар дөньяга,
Син булганга, табылганга.
Чыккан өчен юлларыма,
Инде югалма,
Зинһар, югалма!

Илдания элек тә шигырьләр язгалый иде. Нургаязга багышлап яза иде ул аларны. Тик беркайчан да егеткә күрсәткәне, укыганы булмады. Унҗиде яшьтә күкрәгендә йөрәге булган һәркем шигырь яза бит, һәм алар, гадәттә, сөю турында була. Нургаяз үзе дә шигырьләр чыгара, аларны көйгә салып, җырлый да иде әле.

Нургаяз...

Илданиянең тормышында кайчандыр шундый егет тә бар иде. Кечкенә буйлы, арык гәүдәле, ифрат аз сүзле бу малайны хәлсез Нургаяз дип йөртәләр иде. Ул иптәшләреннән читтә йөрде, гел ялгыз булды. Ни укуы, ни тәртибе, ни көче, ни матурлыгы белән алдыра алмаган бу малай үзен читләтүләрен, үртәү-кимсетүләрне бернинди каршылыксыз, шундый битараф, шундый тыныч (гүя шулай булырга тиеш дип) кабул итә иде. Ахыр чиге, аны күрми, барлыгын да белми башладылар. Әйтерсең ул дөньяда юк та иде. Тугыз ел бергә, бер класста укып йөргән менә шул мокыт малай белән көннәрдән бер көнне Илдания өр-яңадан танышты.

Сорыяр авылында көтүне чиратлап көтәләр. Илданиянең әтисе инвалид, протез аяк белән йөри, һәм, әлбәттә көтүгә чыгу турында уйлыйсы да юк. Шуңа күрә, чиратлары житкәч, бу йорттан, тәмле йокыларыннан мең газап белән аерылып, озын чыбыркыларын өстерәп, ике кыз—Илдания белән Зөһрә чыга. Көтү зур, ике йөздән артык хуҗалыктан җыелган мал. Ә Сорыяр халкы унган халык, һәркайсы икешәр-өчәр баш терлек асрый.

Ул көнне сыер көтүен түбән очтан Сәгыйть абый белән Гөлфәния апа, ә югары очтан Илданияләр һәм Нургаяз көттеләр. Өлкәннәр үз дәрәҗәләрен белеп кенә йөрде, артларын болгый-болгый авыл ягына сыптырган сыерлар артыннан әле Нургаяз, әле Илдания, әле Зөһрә чапты. Малларны тау астына, елга буена төшергәч кенә тын алырга җай чыкты. Өлкәннәр, бераз тамак ялгап алгач, эсседән әлсерәгән тәннәрен чирәмгә сузып салдылар. Зөһрә дә тал ышыгына барып ятты, Нургаяз каядыр югалды. Ә Илдания яланаяк калып суда йөрде, рәхәтләнеп юынды. Аннары яр кырындагы олы гына ташка менеп утырды да, хыялга бирелде. Менә бу елга бик ераклардан агадыр. Ниләр генә күрмәгәндер ул, ниләр генә белмидер. Елга суы тоташ булып ага, ә ул суда кешеләр күрә алмаган миллионнарча тереклек бардыр, һәм ул кечкенә, бик кечкенә затларның Сорыяр авылы янынннан тәүге тапкыр үтүләредер. Елга тавышы бәлки шул серле затларның челдер-челдер

сөйләшүләре, көлешүләре, бәлки җырлауларыдыр. Ниләр сөйли икән алар? Елга телен ташлар аңлыймы икән? Менә Илдания янынннан гына бер шаян дулкын үтеп китте. Ул дулкын башка беркайчан да Илдания исемле кызны күрмәячәк, һәм Илдания дә аны күрмәячәк...

Ул дулкын бик яшьтер, бик чаядыр, ташлар өстеннән җитез генә сикерә-сикерә үтте дә китте. Бу елга юлны үзенә үзе сайлагандыр, беркем дә аңа әйдә, менә моннан үт, димәгәндер. Кызык, кайдан гына акса да, ничек кенә акса да, көннәрдән беркөнне ул барыбер диңгезгә барып чыгачак, димәк, елга кешеләрдән акыллырак, зирәгрәк. Адәм баласы кечкенә генә урманга кереп тә, өч көн адашып йөри әле. Ә аккан су юлны барыбер таба.

Шулай уйланып, хыялланып утырганда, шылдыр-шылдыр итеп аккан елга тавышына башка тавыш килеп кушылды. Кемдер үтә дә моңлы итеп җырлый, бар йөрәге белән сагышлана иде:

Сулар ага, сулар ага,
Текә ярлар ишелә,
Зинһар, авыр сүз әйтмәгез
Миндәй ятим кешегә.
Башкайларым бигрәк зарлы,
Ничек юаныйм икән?
Авыр да соң яшәүләре,
Әллә югалыйм микән?!

Кем җырлый? Шул чаклы тирән, моңлы тавышның иясе кем? Су буенда алардан башка тагын кем йөрер? Илдания урыныннан торды да, сак кына басып тавыш килгән якка китте. Суга иелеп утырган яшь талларны әйләнеп үткәч, яр кырыенда тезләрен кочаклап утырган Нургаязны күрде. Аңа якынайган саен, тавыш та көчәйде. Җырлаучы, һичшиксез, ул—Нургаяз иде. Классташының шундый илаһи тавышка ия булуын башына китермәгән Илдания таң калды. Шул көннән соң Нургаязга бөтенләй башкача карый башлады, аны бер изге, серле зат итеп күрде. Үзе активист, үзе отличник булган, зифа буйлы, үткен Илданиянең үзеннән бер башка түбән, кәкре аяклы Нургаяз янында бөтерелүен классташлары берничек аңлый да, аңлата да алмадылар. Әйтерсең лә Нургаязның исәнлеге, бәхете, тормышы өчен бөтен җаваплылык Илдания өстенә төшкән иде, кыз аның тән һәм җан сакчысына әверелде. Әмма моңлы егет моңа тамчы да сөенмәде, әле борынына кызлар исе кермәгән иде. Илданиянең мәхәббәте болай да авырткан башына тимер таяк булып төште. Нургаяз кыздан ераграк йөрергә тырыша, юллары бер якка булса да, юри артка кала, йә, киресенчә, алдан йөгерә иде.

Мәхәббәт турында китаплар укыган, бихисап шигырьләр белгән хыялый кыз, егетнең моңлы тавышына гашыйк булып аны артык идеаллаштырды. Бу малай, чынлап та, башкаларга охшамаган иде шул. Аралары якынаеп киткәч, Илдания аны сорап-сорап җырлата иде. "Баягы җырыңны тагы җырла әле",—дисә, Нургаяз, гаепле кеше сыман башын иеп: "Оныттым инде мин аны",—дип җавап бирә. Сүзләрен дә, көен дә чыгара тора, җырлый тора, әмма аны исендә калдырмый, шундук оныта да.

Мәктәпне тәмамлагач, Илдания егетне укырга керергә үгетли башлады:

—Синең урының шәһәрдә, зур сәхнәләрдә. Синдә—Ходай биргән талант, сиңа укырга гына кирәк.

Әмма егет аяк терәп каршы торды:

—Мин авылдан беркая да китмим. Яратмыйм шул шәһәрне. Үзләренә булсын,—дип ниндидер ачу, нәфрәт белән әйтеп куя иде.

Шәһәрдә ярты ел да тормады бит, югыйсә. Шул арада да канына байтак

тоз салганнар, күрәсең. Нургаяз бишенчедә укыганда, әнисе кияүгә чыгып, шәһәргә киткән, улын да үзе белән алган иде. Әмма малай яна гаиләгә сыймаган, әбисенә кире кайтардылар. Газиз әнкәсе белән аерылышуны ул бик авыр кичергән, шуңа күрә җырлары да искиткеч сагышлы, моң-зарлы.

Яраттымы Нургаязны, аллә бары кызганды гынамы, Илдания үзе дә анларга өлгерми калды. "Әллә югалыйм микән?"—дип җырлауларьы фәрештәләрнең "амин" дигән чагына туры килгән күрәсең: югалды егет... Илданиянең тормышыннан да, авылдан да, бәлки әле якты дөньядан да югалды. Сорыярда тора салып кеше югалу гомердә булмаган хәл иде, яшәве дә, китүе дә кешечә булмады егетнең. Һавада эрегәндәй, җир астына төшеп киткәндәй, ап-ияз, тып-тыныч көндә гаип булды да куйды. Күпме эзләделәр, милициядән килеп тикшерделәр, әмма ни үле, ни тере гәүдәсен тапмадылар. Адәм балаларын, оча торган тәлинкәләргә утырып килеп, чит планета вәкилләре урлап китә икән дип, газет-журнал тутырып яза, телевизордан әллә нинди әкәмәтләр күрсәтә, сөйли торган заман иде. Халык Нургаязны да күктәгеләр урлагандыр дип, үзенчә нәтиҗә ясады да тынды. Егетне, зәңгәр капкачлы тәрәзәсеннән карый-карый, әбисе көтте дә, моңлы дустының шулай кинәт югалуына ышанырга теләмәгән Илдания көтте. Әмма ай артыннан ай, ел артыннан ел үтә торды, җырчы егет кайтмады, табылмады. Шул чакта әллә аны сагынып, әллә кызганып, шигырьләр яза башлаган иде кыз, әмма шагыйрьлек тумыштан бирелмәгән булгандыр, күрәсең, бу шөгыльне тиз ташлады. Ничә еллар күнел дәфтәренә бер юл язылмаган иде, бүген әллә нинди могҗиза булды, күнеле әллә нишләде, бер җанга сыялмыйча бөтерелгән хисләр дөньяга әнә шундый сәер сүзтезмә булып бәреп чыкты. Раилнең сүзләре Илданиянең шигырендә кайтаваз булып яңгырады: "Зинһар, югалма!".

* * *

... Аны базардан чыгып барганда туктаттылар.

—Үскәнем, булыш әле. Буш итмәм, түләрмен. Сумкаларым бик авыр,—дип дәште берәү.

Дәшүче мөлаем гына юантык яшь хатын, аның кулында, чынлап та, азык-төлек белән шыплап тулган ике сумка. Хатынның елмаеп, якын итеп каравы, иркәм, дип йомшак итеп дәшүе күптән җылы сүз ишетмәгән малайны гүя сихерләде, уяулыкны онытып, хатын кулындагы сумкага үрелүен үзе дә сизми калды. Җитмәсә, аның кулына өр-яңа унлык та тоттырдылар: "Бусы үскәнем, аванс булыр".

Хатын ерак тормый икән, ике квартал үтеп, биш катлы йортның соңгы подъездына керделәр дә өченче катка күтәрелделәр. "Менә сезгә күчтәнәч алып килдем!"—дип дәште хатын кемгәдер. Алгы бүлмәдән өстенә "адидас" фирмасының кара-зәңгәр төстәге спорт костюмын кигән алагаем зур гәүдәле, итләч битле бер ир килеп чыкты. Аның куе кара мыегы иягенә хәтле сузылып төшеп, болай да ямьсез йөзен тагы да килбәтсезләтә иде. Бу бәндә Мишага бер дә ошамады. Ул куркып артка чигенде, тик ишеккә түгел, хатынга килеп төртелде. Хатын исә аны ике кулы белән эләктереп алды да җиңелчә генә иргә таба этте:

—Мә, Федук, кабул ит товарны. Гел базар тирәсендә чуала. Сиңа файдасы тияр.

Ир мыекларын колагына таба шудырып елмайгандай итте:

—Фу, бу чыпчыктан ни файда? Ни ите, ни сөяге. Үләксә!

—Алай димә. Мин бу йолкышны күптән күзәтәм. Бик елгыр малай.

—Шулаймы, чыпчык?—дип сорады ир. Бу юлы тавышы җылырак чыкты. Үзенең кая килеп эләгүен аңлый алмый аптыраган малай җавап бирергә

теләмичә, башын иде дә, юеш борынын керләнүдән күзгә кебек ялтырап торган куртка якасына төртте.

—Бу чыпчыкның теле юкмы әллә?

—Кая карыйк, ач әле авызынны, үскәнем,—диде хатын.

Ул йомшак куллары белән малайның йөзен үзенә таба борды. Мишаның борыны хатынның йомшак түшенә килеп төртелде, аннан сирин чәчәге һәм тозлы балык исләре килә иде.

—Тимә миңа!—дип кычкырды Миша читкә ыргылып.

Хатын кычкырып көлде:

—Ишеттенме, аның теле бар! Товар брак түгел.

—Калсын, күрербез.

—Алайса, хуш. Саграк кылан инде, тавыш чыгарлык булмасын.

Аның китәргә җыенуын, үзен шушы куркыныч иләмсез ир янында ялгызын калдырырга теләвен аңлап, Миша куркуга төште. Ул мәче җитезлеге белән ачык ишеккә ыргылды, әмма олы гәүдәле көчле ир көрәктәй куллары белән аны йолкып алып, түргә өстерәде.

—Мин монда калмыйм!—Миша бар көче белән карышты, тыпырчынды, бу куркыныч җирдән аңлаешсыз кешеләрдән котылырга азапланды. Әмма бүре авызына эләккән куян ерткычка ничек каршы тора алсын? Аны ишетүче дә, кызганучы да булмады. Ир, малайны бер кулы белән җилтерәтеп диванга китереп сылады да, гайрәтле, ачулы тавыш белән:

—Ә синнән кем сораган соң әле, көчек?! Тыпырчынма, утыр шунда тыныч кына!—дип кычкырды.

—Нишләтмәкче буласыз мине?

—Пешереп ашарга җыенабыз. Сөяк тансыклаган идек, ха-ха,—дип көлде ир. Малайның куркуы, үзен шул кечкенә җан иясенең хуҗасы итеп тою иргә зур канәгатьлек хисе бирә иде. Гомеренең яртысын диярлек төрмәдә үткәргән Федя Дранчук башкаларда курку хисе уятудан, үзен барсыннан да көчле, өстен итеп тоюдан тәм таба торган бәндә иде. Бу йолкыш малайның тормышы да, язмышы да бүгеннән Федя кулында. Тели икән, прәнник бирер, тели икән, каеш... Федя үзенең корбаны белән бераз мәчелетычканлы уйнап алырга булды.

—Исемең ничек синең?—дип сорады ул малайдан.

—Миша.

—Михаил Батькович инде, димәк. Ә мин Федор абзаң булам. Спортчы, боксчы. Киреләнмәсәң, акыллы булсаң, сине дә өйрәтермен. Килештекме, Михаил Батькович?

Малай эченә бераз җылы йөгерде. Бу абый алай ук куркыныч түгел бугай. Спортчыларны хөрмәт итә Миша, Казанда чакта малайлар белән стадионга, футбол карарга йөриләр иде.

—Ашыйсың киләме?—дип сорады Федя.

Миша уңайсызланып куйды, подвалда калган дусты исенә төште. Рәмиснең дә ашыйсы киләдер, ул дүрт күз белән Мишаны көтәдер.

—Федя абый, җибәрегез мине, ә?! Әнием кайгырадыр. Ул авырый, аңа кайгырырга ярамый.—Миша бу сүзләрне еламсырап әйтте, үзен кызгандыру өчен, яшьсез күзләрен дә сөртеп алгандай итенде.

Мыекбай аптырап китте, чөнки Талибә аңа ата-анасыз сукбай балаларны гына китерергә тиеш иде.Әйтте бит, күптән күзәттем, диде. Димәк, малай алдаша, бер дә әниле балага охшамаган. Анасы, булса да, бер исерек хатындыр. Федя белә: андыйларда бала кайгысы юк. Шулай да ул ышангандай кыланды:

—Чыпчык, синең анаң бармыни?! Алай булгач, бернинди бәхәс юк, братан. Әниләрне борчырга ярамый,әлбәттә. Әйдә танышу-очрашу

хөрмәтенә сыйлыйм әле үзенне. Аннары дүрт ягын кыйбла, Михаил Батькович.

Миша жинел сулап куйды. Болай булгач, котыла икән. Инде башка вакытта анлырак булыр, теләсә кемгә ияреп китмәс. Ул тыныч күнел белән Федя абыйсы корган табынга утырды.

* * *

—Мин жавап көтәм,—диде Раил. Ә жавап күптән әзер...

Илданиянен тыныч кына аккан бер төрле тормышына бигрәк кинәт, кисәк килеп керде ул, беренчи рөхсәт сорап тормыйча килеп керде. Кояш та синен өенә шулай килеп керә, телисенме син юкмы, ул ишек-тәрәзәнне шакып та тормый, өй түренә үтә, бүлмәнне жылыга, якты нурга күмә. Раил Илданиянен тормышына үтеп керде дә, тулаем аны биләп алды, күнеленә, йөрәгенә хужа булды. Чөнки бу күнел, бу йөрәк буш иде. Бигрәк буш иде шул!

Ә киләчәккә илтер юллар озын бит әле. Гомер булса, күпме еллар, күпме айлар, күпме көннәр, күпме төннәр кичәсе бар... Ул юлларны Хәмит белән үтәрме Илдания? Йә Хода, нинди күнелсез сәфәр булачак ул! Нинди озын һәм нинди мәгънәсез сәфәр.

Менә алар тормыш юлы буйлап икәү атлап киләләр, имеш. Хәмит бер якка, ә Илдания икенче якка караган. Бу икәүнен сөйләшер сүзләре, бүлешер серләре юк. Ике жанны тоташтырып, кулларын тотып барырдай уртак сабыйлары юк. Болар очраклы юлчылар. Сонгы тукталышка кадәр бергә янәшә атларга хөкем ителгән бер-берсенә ят ике жан... Ничек түзмәк кирәк, ничек бу озын гомерне яшәп бетмәк кирәк?

Аһ, ник ашыкты Илдания? Ник үз насыйбын, үз тинен көтмәде? Кем белгән, кем уйлаган бит, бердәнберен шулай сонлап очратыр дип!

Кеше өстендә яшәгәндә дә бу тиклем ялгыз түгел иде әле Илдания. Разия апасы: "Кызым, мәктәптә ни хәлләр бар? Балалар бик борчымадымы үзенне?"—дип каршы алыр, табын корыр, каршысына килеп утырып, рәхәтләнеп сөйләшер иде.

Ир белән түгел, эт, мәче белән яшәүчеләр дә бу тиклем ялгыз түгелдер. Ул жанваркайлар, хужалары кайткач, аларнын каршыларына йөгереп чыгалар, үзләренчә сәламлиләр, шатлыкларын белдереп сырпаланалар, мыраулап, өреп сөйләшкән булалар...

Фатир да бар, акчага да мохтажлык юк, өрлек кебек ире дә янында. Ни житми сон Илданиягә? Мәхәббәт житми, жан жылысы житми!

Жаны-күнеле белән бүгеннән үк Раилгә ияреп китәргә, язмышын анын белән бәйләргә риза ул. Әмма акылы теше-тырнагы белән каршы килә: "Жүләр! Чакырган бер кеше артыннан, алдын-артын исәпләмичә, корган оянны жимереп, иләсләнеп чабарсынмы? Кем ул Раил? Син аны беләсенме? Ана ышанасынмы? Акыллы, төпле ир-ат, гомерендә ике тапкыр күргән хатынга тәкъдим белән киләме? Сина таяныр терәк була алырмы сон ул? Ике көймәгә берьюлы утырмакчы булып, суга мәтәлеп төшмәссенме, батмассынмы? Ашыкма, Илдания, ашыкма!".

Акыл тирги тора, күнел исә һаман иләсләнә: "Язмыш синен юлына шундый асыл ирне—яратып—сөеп туймаслык мәхәббәтле, сөйкемле кешене чыгарды. Аннан баш тартсан, жүләр булырсын. Гомер буе мәхәббәтсез яшәрсенме? Ошый бит ул сина, тәвәккәллә, Илдания! Язмыш бүләк иткән бәхетенне ычкындырма!".

Уйлый, икеләнә Илдания. Бер фикергә киләлмичә аптырый. Ай, авыр да мәсьәлә булды бу. Алу.. кушу... Хәмитне алабыз, Раилне кушабыз...

Утыз яшенә житеп, беркемне болай яратканы, сагынганы булмады, бугай. Әллә онытылган гынамы? Юк, юк, булмады.

Институтта укыганда Рифкать белән очрашалар иде. Каникулга кайтканда, поездда таныштылар. Күрше авыл егете булып чыкты. Башта якташлар буларак аралаштылар, аннары дуслашып киттеләр. Бер җәйдә Рифкать Илданияне авылларына озата кайтты. Һәм... һәм чем кара күзле, калын толымлы Зөһрәгә гашыйк булды да куйды. Бакчада, алмагач төбендә кияве белән сеңлесенең кочаклашып-көлешеп торуын күргәч, Илдания барысын да аңлады. Зөһрәнең әле иләс-миләс чагы, ул җәйне яңа унҗидесен тутырган иде, аңа ныгытып әйтте: " Ялгышма, сеңлем бу ышанычсыз кеше. Мине саткан, сине дә сатачак",—диде. Үзе исә Рифкать дигән кешене күңеленнән бөтенләйгә сызып ташлады...

Нургаяз югалды, Рифкатьне үзе куды... Әллә ничек кенә уңмады Илдания мәхәббәттән... Юк ул, дип өметен өзгән, шуңа да бернинди хиссез, гыйшыксыз Хәмит белән кушылырга ризалашкан иде. Кем уйлаган йөрәгендә сөю хисе кабыныр дип. Шулай кинәт, шулай соңлап...

"Җавап көтәм",—диде Раил. Шул сүзләре белән Илданияне ут-ялкынга салып китте, бөтен тынычлыгын урлады. Шул көннән соң Илданиянең тынычлыгы югалды. Ул күзгә күренеп үзгәрде, йөзенә нур кунды, нинди эшкә тотынса да, җырлап башкарды. Хатынның эче-тышы яңа чәчәк аткан гөлдәй балкый иде.

—Сиңа ни булды?—диделәр аңа. Илдания көлә-көлә җавап бирде:

—Гашыйк булдым!

Әмма гаҗәп хәл, күп очракта кешеләр дөрес сүзгә ышанмыйлар. Әгәр Илдания "акча оттым" дисә, шикләнерләр ышанмаслар иде, мөгаен, яшерә, гашыйк булган дип гаепләрләр иде. Билгеле, яшь хатынның шарран ярып, гашыйк булдым, диюен чынга алучы да булмады. Чөнки Илдания үзен һәрчак житди, сабыр тота. Хәтта кияүгә чыкканда да болай балкып, сөенеп, йөрмәгән иде. Аның кинәт яшәреп, дәртләнеп китүен аңлату өчен башка сәбәп таптылар.

—Авырга узгандыр, шуңа шатланадыр,—диештеләр.

Чынлап та Раил белән очрашкач, Илдания үзе дә нәкъ шул турыда уйлый башлаган иде. Шул гомер яшәп Хәмиттән балага узмаган икән, димәк аны Ходай үзе саклаган! Хәмиттән сау-сәламәт, тулы акыллы бала тууы бик икеле, ә Раил бөтенләй башка. Әйтәләр бит, кыз бала кияүгә чыкканчы ук дөньяга тудырасы баласы турында уйларга тиеш. Ә Илданиянең ана буласы, камил, сәламәт баланың әнисе буласы килә. Алсу кебек чибәр, зиһенле, ипле баланың әнисе буласы килә. Илдания бу кызны бик ярата, чөнки ул Раилнең кызы, әтисенә охшаган. Шул ук очкынлы күмер күзләр, киң маңгай, дулкынланып торган дегет чәчләр, барыбер үземнекен итәм дигән сыман үҗәтләнеп кысылган иреннәр.

Илдания Раилне сагына. 10 нчыларга кергәч үзе дә сизмичә әтисенә ике тамчы судай охшаган Алсуны яшерен генә күзәтә. Аның карашын сизеп, кыз да аңа төбәлә, ялкынланып торган үткен күзләре укытучысының күңелендә бөтерелгән мәхәббәт давылын үтәли күрә, сизә кебек. Алсуның карашы да, елмаюы да ниндидер мәгънәле сыман. Бәлки элек тә шулай булгандыр, ләкин ул чакта аңа кем игътибар иткән. Үткен кыю карашлы бу кызга егет кенә булып туасы калган, әтисе кебек тешләгән җиреннән өзеп алачак бу. Раил белән кушылган очракта шул усал, үҗәт кызның әнисе булырга да туры киләчәк бит...

Раил үз сүзен өздереп әйтте дә югалды. Ә Илдания аны көтә. Һич булмаса шалтыратуын. Ике атнаның шулай озак буласын, шул кадәр әкрен узасын кем уйлаган. Элек сизелми дә үтеп китә иде югыйсә. Урамда да үзләренең ишек алдында да Илдания карашы белән таныш машинаны эзли. Ишеп-ишеп кар яуган тылсымлы, бәхетле теге кичне сагына. Раилнең ягымлы

карашын, жылы кулларын, кайнар иреннәрен сагына. Ярый әле, Хәмиттә аның кайгысы юк. Кайта, ашый, телевизор карый. Дөньяда хатынының барлыгын да онытып, изрәп рәхәтләнеп йоклый. Шуның өчен булса да рәхмәт әйтерсең үзенә. Илдания аны кызгана, ярдәмгә мохтаж, яклаусыз-саклаусыз калган яшь баланы кызгангандай кызгана. Ләкин бергә яшәү өчен бу гына җитми икән. Үзен кемгәдер кирәкле, кадерле зат итеп тоясы, хатын-кыз булып, сөеп-сөелеп яшисе, назланасы килә.

Раилнең дә түземлеге ике атнага җитмәде. Дүшәмбе көнне Илданиянең эшенә шалтыратты, дәресләрдән кайчан бушавын белешеп, каршыларга киләм, диде. Ул көнне Илданиянең алты сәгате иде, һәм алар гомердә булмаганча озак үтте. Дәрес үткәрүенең рәте-чираты булмады, буталды, ялгышты, дәрес турында түгел, Раилне күрәсен, кичен үзен кетәсе шатлыклы очрашу турында уйлады. Алай ярамый иде, әлбәттә, үзен кулга алырга, тынычрак булырга кирәк иде. Әмма ул Раилнең килмәвеннән, алдавыннан курыкты. Шул курку күңеленә тынычлык бирмәде. Шикләнүе юкка булмаган икән, ашыга-кабалана чыкса да, мәктәп капкасы төбендә аны көтүче юк иде. Раил чынлап та килмәде.

Ул төнне ничек үткәргәнен Илдания үзе генә белә. Үртәлү-әрнүенең чиге булмады. Бер ачуланды Раилне, бер akларга тырышты. Әмма ничек булса да болай алдашырга, кеше хисләре белән уйнарга кирәкмәс иде. Алар бала-чага түгел ич. Төн йокысыз, төрле борчулы, икеле-микеле уйлар белән үтсә дә, хатын таңны ныклы бер фикер белән каршы алды: “Җитте! Иләс-миләс уйларга бүтән ирек бирмәскә. Үз ирем белән тыныч кына яшәргә! Мәхәббәт бары газап кына китерә торган нәрсә, ансыз да бик яхшы яшәп була! Җитте, шуның белән гыйшык-мыйшык уеннары тәмам!” Карар нык иде, аннан баш тартырга мәҗбүр итәрлек сәбәп булмаска тиеш иде кебек...

Әмма икенче көнне әкрен генә атлап эшкә барганда ана исеме белән дәштеләр. Борылып карамаса да таныды Илдания: дәшүче Раил иде. Бу тавышны ишетүгә дулкынланудан, каушаудан адымнары ялгыша башласа да, ул туктамады, ишетмәмешкә салышып атлавында булды.

—Илдания!

“Түз, йөрәгем, түз. Безгә беркем дә кирәкми. Шулай тыныч, шулай кирәк!” Ләкин адымнар якыная, менә инде ул янәшә атлап бара, еш-еш сулаганы ишетелә. Инде күрмәмешкә, ишетмәскә салышу мөмкин дә түгел. Илдания кинәт туктады да, Раилгә таба борылды. Бер сүз эндәшмәсә дә, әйтергә теләгән сүзләре, үпкә-рәнҗүләре йөзенә язылган иде.

—Илдания, гафу итегез. Сезнең алда алдакчы булып калдым. Акланырга теләмим, әмма сәбәп чынлап та, җитди. Эштә күңелсезлек килеп чыкты. Сварщик егетебезнең саксызлыгы аркасында, янгын чыга язды, җитмәсә үзе дә бик нык пеште. Бик үкенечле, мин сүземдә тора алмадым. Вәгъдәсез кешеләрне үзем дә яратмыйм югыйсә. Зинһар, кичерегез.

Бөтен ачу-үпкә җилгә очты. Раилгә түгел, үзенә ачуы килде Илданиянең. Шушы яшьтә көйсез, үпкәчән бала сыман кыланмаса соң. Ә Раил егет икән, эше, вакыты никадәр тыгыз булса да, телефон аша гына түгел, аның үзен күреп аңлашуны кирәк тапкан. Хатын күңелендә иргә карата рәхмәт, соклану хисләре генә калды. Аның карашы җылынды, Раилнең хәленә кереп:

—Инде барысы да җайландымы соң? Пешкән егет бик авыр хәлдә түгелме?—дип сорады.

—Җиңел түгел. Әмма үзе гаепле булса да, кешене авыр хәлдә ташларга ярамый. Гаиләсенә дә ярдәм итәргә кирәк. Хәзер яхшы дарулар кыйммәт.

—Рәхмәт, бик кешелекле икәнсез.

—Мин шалтыратырмын. Әлегә сау булыгыз, Илдания. Хәбәрләшербез, ярыймы?

Раил кызу-кызу атлап машинасына таба юнәлде, ә Илдания күнеленнән генә: "Исән-имин йөре, кадерлем, бәла-казаларга юлыкма. Юлларың да, эшләрең дә хәерле булсын",—дип теләп калды.

* * *

Илдания белән хушлашкач, Раил хастаханәгә юнәлде. Николай хирургия бүлегендә ята икән. Кабул итү сәгате булмаса да, бик үтенгәч, аңа биш кенә минутка кереп чыгарга рөхсәт иттеләр. Хастаханәдә иртәнге ыгы-зыгы вакыт иде. Ак халатлы шәфкать туташлары җил-җил атлап палатадан палатага чаба, авырулар үз мәшәкатьләре белән мәшгуль, кайсы юынып, кайсы ашау-эчү эшләрен кайгыртып, өй башмакларын чаштор-чаштыр өстерәп, хастәханәнең дару исләре сеңгән тар коридорында арлы-бирле йөренәләр. Алар арасында Николай юк, әлбәттә. Һәм тиз генә була да алмас.. Хәле хәлме...

Палатага килеп керүгә, Раил карашы белән таныш йөзне эзләде. Хәер, эзләп тору кирәк тә түгел иде, чөнки бүлмәдәге биш авыруның бары берсе генә урында ята, һәм урында яткан кеше бары Николай гына була ала. Егетнең күзләре йомык, йөзенә кызганмый карау да мөмкин түгел, сазлык мүген хәтерләткән кара яшел төстәге мазьне бармак калынлыгы итеп сылап куйганнар.

Раил сак кына басып караватъ янына килде, авыруга таба иелеп, әкрен генә эндәште:

—Николай...

Шулчак аның янында әллә каян ифрат ябык, кечкенә хатын пәйда булды, теш арасыннан пычкы чыжылдаган тавыш чыгарып, кырыс кына:

—Ул йоклый. Аңа көчле укол кададылар,—диде.

—Ә сез аның кеме буласыз?

—Хатыны.

Раил аптыраулы карашын әле кибән хәтле булып бөтен караватны инләп яткан таза иргә, әле кесәгә салып йөртешле кечкенә хатынга төбәп, ышанмаган кешедәй кабатлап сорады:

—Сез чынлап та, аның хатынымы?

Ризасызлык белдереп иреннәрен бүлтәйткән хатын ни дә булса җавап бирергә өлгергәнче, түрдә чәй шөпереп утыручы пеләш башлы агайның карлыккан көр тавышы ишетелде:

—Хатыны инде, хатыны! Башкаларга рәте юк бит әле мужикның.

—Алайса, менә... Бу сезгә...—Раил кесәсеннән төргәк чыгарып хатынга сузды.—Ирегез эшләгән оешмадан бераз ярдәм. Даруга, башкасына... Үзегез карагыз. Егетне ташламабыз, тизрәк терелсен генә.

Хатынның йөзе яктырып китте, нечкә иреннәрен елмаю йотты, хәтта тавышы да бу юлы күпкә ягымлы тоелды:

—И-и-и, рәхмәт инде, рәхмәт...

Раил хушлашып чыгып китте. Аста аны тагын бер очрашу көтә иде. Кабаланып чыгып барганда берәү: "Кияү!" дип дәште. Бу сүз белән аңа бары бер генә кеше дәшә ала, һәм ул кеше әлбәттә, аның әбисе, Ландышның әнисе Гөлчирә апа. Дөрес, Раил аңа беркайчан да "әби" дип эндәшмәде, балачактан өйрәнгән гадәт буенча "Гөлчирә апа" гына дия иде. Аның каравы Гөлчирә апа ике сүзнең берендә төчеләнеп "кияү, кияү балакай" дияргә яратты, хәтта Ландыш белән өйләнешкәнче үк Раил аннан бу сүзне еш ишетә иде.

—Исәнмесез, Гөлчирә апа,—Раил ишек кырындагы эскәмиядә сумка кочаклап утыручы илле яшьләр чамасындагы юантык хатын белән ике кул биреп күреште.

—Авырып киттегезме әллә?

—Юк, кияү, буламы сон?! Минем исәнлек әлһәмделилләһи шөкер әле! Менә бабаң гына бераз хәлсезләнеп тора. Зыянлы түгел, озак яткырмаслар, Аллаһ боерса. Дөнья жимертеп йөри торган достуй кеше ул.

Әйе, бу нәкъ анынча, Гөлчирә апача. Авызы тулы кан булыр, әмма сирәк тешләрен кысып булса да елмаер. Сер бирәсе килми. Унга бар унганчы бар, дигән кагыйдә белән яшәде Гөлчирә апа. Ана ышансаң, уннын һәркайсы дөнья бәясе ир иде. Гомере буена кеше арасында, сатуда эшләгән, жинел холыклы хатын өчен танышу кавышулар әллә ни кыен эш булмагандыр, күрәсен. Анын бу холкы, яшәү рәвеше аркасында Ландыш жан газаплары кичерә, әнисе өчен ояла, унайсызлана иде, әмма үзе әнисен беркайчан беркемнән гаепләтмәде, гел яклады.

Раилнекеләр анын Ландышка өйләнергә жыенуын белгәч, тәмам куркуга төштеләр: "Анасы кебек жилбәзәк булмасмы?" янәсе. Югыйсә Ландышка әнисенен язмышы үрнәк түгел, гыйбрәт иде. Бервакыт Раилгә очраклы гына аларнын бәхәсләшүен ишетергә туры килде.

—Әни! Нәрсәгә сина бу адәм?! Кешеләр көлә бит үзеннән. Минем турында уйла бераз.

—Синен үз тормышын, минем үземнеке. Син кияүгә китәрсен дә, ә мина нәрсә, гомер буе ялгыз яшәргәме?

—Әни! Ялгыз яшә, димим, тик зинһар теләсә кемне алып кайтма! Бу исерекнен иптәшлеге инде. Синен өстә яшәп ятучы әрәмтамак бит ул!

—Әтиен турында алай әйтмә.

—Нинди әти булсын ул мина ?! Минем бер генә әтием. Үлгән кешене рәнжетмә, ичмасам.

Ландыш бик иртә әтисез калган, ул аны хәтта хәтерләми дә. "Ичмасам истәлеккә бер фотосы булса икән!" дип үртәлә иде. Гөлчирә апанын сөйләвенә караганда, Зөфәр абый машинасы белән авариягә очрап һәлак булган. Ландыш төс-биткә дә, холкы белән дә әнисенә охшамаган, бөтенләй башка иде. Күрәсен, анарда әтисенен каны өстенлек иткәндер. Шулай итеп Раилгә чын бабасын күрергә насыйп булмады, әмма бабайларга мохтажлык кичермәде. Алар берсен-берсе алыштырып кына тордылар. Хәзерге бабайны исә Раилнен гомерендә дә күргәне юк. Чөнки Гөлчирә апа, фатирына бер яшь гаилә кертеп, Боеклы авылындагы тол иргә кияүгә чыккан, соңгы араларда анын шәһәрдә күренгәне юк иде. Шуна күрә бу Раил өчен һич көтелмәгән очрашу булды. Гөлчирә апа исә аны күрүенә чиксез шатланган сыман, йөзенә елмаю кундырып, жырлы тавышын сузды:

—Кияү балакай, ни эшләр бетереп ятасыз? Өйләнмәденме әле?

—Юк.

—Дөрес иткәнсен! Юньле хатын табып буламыни хәзер?! Өйләнмә, өйләнмә!

Раил мыек астыннан гына елмаеп куйды:

—Ялгыз яшәү дә яхшы нәрсә түгел инде.

—Нишләп ялгыз?! Кызын бар ич. Ул да алай үги ана тансыклап тормыйдыр әле! Алсу балакай ни хәлдә сон?

—Гөлчирә апа, анын хәлен миннән сораганчы, бер килеп күрер идегез. Оныгыгыз ләбаса.

—И кияү бәбкәм, вакытын бармы диген. Көнем тавыктыр, сарыктыр саклап үтә. Тын алырга да вакыт юк. Әле менә көч-хәл белән бабаннын хәлен белергә килгән идем, кертмиләр. Абхуд, ди. Синен знакумнарын юкмы сон?

—Бик жайсыз вакытта килгәнсез шул. Тәрәзәдән дәшсәгез генә инде,— дип Раил хушлашырга ашыкты. Чөнки Гөлчирә апанын сүзе тиз генә бетмәячәген ул яхшы белә иде.

* * *

Мишанын чалбар, күлмәк, куртка кесәләреннән өстәлгә шактый байлык коелды: ике алма, ике кап Мәскәү печеньесы, ике "марс" конфеты, ике пәрәмәч... Барысы да икешәр, бөтен нәрсәне пардан чәлдергән малай. Әллә авыру анасы булуы хакмы икән? Федя күңеленә шик үрмәләде. Болай булса малайны эзләүләре мөмкин ич. Әмма чигенергә соң инде, эшләнәсе эш эшләнгән, малайга кирәкле "дару" бирелгән. Ул хәзер ике тәүлек буе йокы симертәчәк. Ник анда дөнья җимерелми, берни сизмәячәк. Бичара шикләнмәде дә, йотлыга-йотлыга эчте дә куйды порошоклы суны. Үзен ни көтәсен белми һәм соңыннан да белмәчәк. Ике көннән аны Талибә апасы килеп алыр, көчле дарудан әле айнып та бетмәгән аңгы-миңге малай үзенең кайда булуын, ни эшләгәнен дә онытыр. Федяның беренче кунагы түгел ул, Талибә аңа сукбай балаларны байтак ташыды. Чөнки, алар монда булганда, үзе ял итә. Талибә ни кушсаң, шуны үтәргә әзер. Ул мескен үзен Федя алдында бурычлы дип саный, коткаручысы да, муеннан бурычка батыручысы да бер үк бәндә икәнен каян белсен. Тәмам Федяның колына әйләнде, хәтта наркотиклар сатарга да ризалашты. Талибә белән Федя икесе бер арбада, бер юлда хәзер, беркая китә алмый ул хатын.

Федя малайның тир исе килеп торган, пычрак киемнәрен бәдрәфкә кертеп бәрде. Аннары бүлмәгә чыкты да, малай йоклап яткан диван янына килде. Мишаның кечкенә арык гәүдәсенә комсыз караш ташлап, үзе генә белгән пычрак уйларына мыскыллы елмайды да, чишенә башлады...

...Миша төнлә уянды. Әгәр Федя биргән порошокны гомерендә беренче татуы булса, ул әле уянмаска тиеш иде. Әмма малайның мондый "дару"ларны татып караганы бар иде инде. Уянды, үзен Казандагы фатирларында дип белеп, исерек кешедәй алпан-тилпән атлап бәдрәфкә юнәлде. Шунда гына үзенең анадан тума шәрә икәнлеген күреп алды. Бу аны гаҗәпләндерде, чөнки болай чишенеп йоклау гадәте малайда гомумән юк иде. Житмәсә бөтен тәне авырта, әрни, гуя аны эчке әгъзаларына хәтле ботарлап, кыйнап ташлаганнар. Миша ыңгыраша-ыңгыраша йомышларга иелде, шулчак идәндә таралып яткан үз киемнәрен күреп алды. Димәк, аны әнисе чишендергән, пычрак киемнәрен юарга куйган. Тукта, ә бу нәрсә? Ванна кырындагы урындыкта өч Миша сыярлык ирләр чалбары ята, ә аның өстендә бер кап затлы сигарет һәм пистолет формасындагы зажигалка. Әнисе янына чираттагы кунак килгәндер мөгаен. Миша авырту-әрнүләрен онытып, сигаретка үрелде, аны кабызырга ниятләп, кулына пистолет-зажигалканы алды. Матур әйбер, моны урларга кирәк, вәт мактаныр малайларга. Кеше куркытыр өчен менә дигән уенчык! Миша пистолет көпшәсен сигаретка авызына туры китереп, чакмага басты. Ин башта аны колак төбендә яңгыраган коточкыч тавыш гаҗәпкә калдырды, әлегә тикле кабызгычлардан мондый куркыныч тавыш чыкканы юк иде. Икенчедән, ни өчендер каршы стенадагы кафель плитәләр коелып төшеп, чәлперәмә килде. Ә өченчедән, ванна бүлмәсенең ишеге кинәт каерылып ачылды да, анда шкаф кадәрле бер кеше пәйда булды. Ул йонлач зур кулларын Мишага сузып:

—Бир пистолетны! Хәзер үк бир!—дип кычкырды.

Малай ирдән дә, аның ямьсез тавышыннан да курыкты. Шул курку аны кабат чакмага басарга мәҗбүр итте. Ир өстендәге зәңгәр майканың корсак турысы нишләптер кинәт алланып китте, ул тап зурайганнан зурайды. Әмма ир аңа игътибар да итмичә, һаман Мишага үрелде. Кабат мылтык тавышы яңгырады, бу юлы инде кызыл тап ирнең күкрәгендә иде...

—Әни! Әни!

Миша, әнисен эзләп-чакырып, атыла-бәрелә бүлмә буйлап чапты. Әмма әнисе беркайда да юк иде, ул гына да түгел бу бөтенләй алар фатиры түгел иде. Аптыраган-йөдәгән малай ни эшләргә, кая барып бәрелергә белмәде, аның башы тәмам каткан, мингерәгән, уйлау сәләтен югалткан иде. Ул йөгереп ишеккә килде, тик аны ачалмады. Аннары тәрәзәгә чапты, балконга чыкты, салкын тоеп, үзенең ялангач икәнен искә төшерде. Кире юыну бүлмәсенә кереп, канга буялган киемнәрен алды. Бөтен бүлмәне тутырып кан эчендә яткан зур гәүдәгә карамаска тырышты. Мишаның куркуы житкән иде, ул хәтта киенеп тә тормады. Диван япмасын тартып алып, шуна уранды да, сәләмәләрен кочагына жыеп, балконнан сикерде. Малай үзенен өченче катта икәнен дә оныткан иде, бәхетенә кар өеменә килеп төште. Карга бата-чума сукмакка чыгуга, кая баруын да аңламыйча йөгерде дә йөгерде, аңа бары моннан китәргә, бу куркыныч урыннан тизрәк ерагаерга гына кирәк иде. Курку, ашкыну шул кадәр көчле иде ки, ул хәтта аягындагы коточкыч авыртуны да яраланган ерткыч кебек оясына кайтып егылгач кына сизде. Әмма аягындагы әрнү аны борчымый, иң мөһиме ул үз куышында, дусты янында һәм аларга башка бернинди куркыныч та янамый. Чөнки Мишаның куенында әллә нинди дошманнарны да юк итәрлек, үзен дә, дустын да якларлык чын корал бар! Малай бу табышка чиксез шат иде.

* * *

Шимбә көнне үз подъездлары төбендә таныш машинаны күргәч, Илданиянең сөенечтән Раил каршына йөгерәсе, анын кочагына атыласы килде, тик йөгермәде, атылмады, бик сагынган булса да, үзен тыеп калырга көч тапты. Унжиде яшьлек кыз түгел, сабыррак житдиерәк булу кирәк.

Ир исә яше белән дә, "кирәк"ләр белән дә исәпләшеп тормады, Илданияне күрү белән, каршысына ашыкты, күзләренә туп-туры карап: "Мин сине алырга килдем"—диде.

—Унбиш минут вакыт бирәм. Иң кирәкле әйберләренне генә ал. Вакланма. Мин сине мохтажлыкта яшәтмәм, Илдания.

Шушы акыллы, күркәм ирнең үзенеке булачагына әле һаман ышана алмаган хатын анын күзләренә: "Син мине алдамыйсыңмы, шаяртмыйсыңмы?"—дигән сыман гажәпләнеп карап торды.

—Йә, бар инде, Илдания. Мин сине көтәм,—дип кабатлады Раил.

Хәмит өйдә булганда, аларның фатирына карак керү янамый. Фатирны гына түгел, подъездны ук бер чакрымнан әйләнеп үтәчәкләр, чөнки телевизор тавышы беренче каттан ук ишетелә башлый, менгән саен ул көчәя. Телевизоры булмаган кеше өченче катка менеп яки төшеп, рәхәтләнеп яңалыклар тыңлый ала. Сөймәгән кешеннең бар гамәле дә сөйкемсез тоела шул.

Илдания томанлы, буш карашын экранга төбәп дөньясын оныткан Хәмит каршына килеп утырды. Ире битараф карашын иренеп кенә аңа күчерде:

—Нигә миңа болай карыйсын?

Боргаланып маташу урынсыз иде, Илдания сүзен мангайга бәреп әйтте:

—Хәмит, мин синнән китәм.

Ир башта бу сүзләрнең мәгънәсен аңламады әле, аннары кинәт йөзе үзгәрде, күзләре түгәрәкләнде, иреннәре дерелди башлады.

—Китәсен? Ә мин?

Бичара бала, дөньяның бер бәхетсез имгәге... Илданиядән башка яши алмаячак бит ул. Әнә бит күзләре ничек мөлдерәп карый. Кемне хәтерләтә соң бу күзләр, бу караш? Кемнедер хәтерләтә бит, ә-ә, әйе, исенә төште. Илданияләрнең Сарбаен хәтерләтә ич. Ул да күзгә шулай карый иде: "Мин синең тәпиеңне яларга риза, тик ташлама, ач итмә мине",—дигән сыман

ялварып, мескенләнеп карый иде. Хәмиттә дә—шул караш, хуҗасына тугры булган эт карашы, буйсынучан, ялварулы караш. Хатынның күнелен кызгану хисе биләп алды. Бу мизгелдә ул гаҗиз иде. Нишләргә? Аста, урамда аны Раил көтә... Ә монда Хәмит еларга әзерләнгән бала сыман күзгә мөлдерәп карый.. Бер йөрәкне ничек бүләргә?

Шул чак Илданиянең карашы китап киштәсендәге фоторәсемгә төште. Анда кайнанасы Хәмитне кочаклап төшкән. Хәмитнең беренче сыйныфка барган чагы. Колаклары тырпайган, авызы ерык, аркасына ранец аскан, кулында—чәчәкләр. Мәкъбулә апа да елмая. Мәңгелектә югалган үткәннәрнең бер мизгеле.

Илдания рәсем каршында басып тукталып калды. Кинәт кенә кайнанасы күз алдына килеп басты, колагында аның сүзләре яңгырагандай булды: “Син Хәмитне ташлама инде. Ул ялгыз яши алмый. Зинһар, ташлама...”. Илдания анага вәгъдә бирде, ташламам, диде. Теге дөнья белән бу дөнья арасында бернинди элемтә юк, әгәр кайнанасы исән булса, каршысына тезләнер иде дә: “Кичер, әни, мин китәм”,—дияр иде. Ә үлгән кешегә бирелгән вәгъдә ул инде мәңгелек, аны үзгәртеп тә, кире алып та булмый. Мәкъбулә апаның күзләре әйтерсең лә, ялварып, инәлеп сорыйлар: “Ташлама, ташлама...”.

...Ул урамга буш кул белән чыкты. Раил аны көтә иде, каршына йөгереп килде: “Сиңа булышыргамы?”. Илдания гаепле кеше сыман башын иде: “Гафу ит, мин...”. Раил сүзсез дә аңлады, барысын да аңлады. Бар йөрәге белән ачынып: “И-их!”—диде дә, кисәк борылып, кызу-кызу атлап машинасына таба китте...

Елыйсы килә иде, кычкырып-кычкырып, илереп елыйсы килә иде. Их, бу шәһәр, кеше күзеннән качып рәхәтләнеп елар өчен бер аулак урын да юк, ичмасам! Кайсы якка барсаң да, кешеләргә килеп төртеләсең. Күкрәгенә, йөрәгенә тулышкан бәгырь яшьләрен көчкә тыеп, Илдания ишек алларындагы ташландык йортка таба йөгерде, атыла-бәрелә бер бүлмәгә кереп, песи баласыдай почмакка сыенды да, күз яшьләренә ирек бирде: “Кичер мине, Раил, кичер, бәгърем. Мин сине яратам, яратам!”.

Күпме вакыт үткәндер, шулчак яшь пәрдәсе аша ниндидер шәүлә чалынды. Илдания күзләрен сөртте, тик шәүлә югалмады. Каршысында әллә шайтан баласы, әллә кабереннән кузгалып чыккан мәет басып тора. Чәчләре укмашып каткан, күзләре эчкә баткан, яңаклар суырылган, борын төбе пешкән кебек кызарган, өстендәге сәләмә киемнәре карачкыга кигереп куйгандай эленке-салынкы тора. Хәер сорашучы чегән балаларының да кыяфәтләре моныкыннан бишкә артык, аларның йөзләре туп кебек, таза шоп-шома, ә бу бичара бигрәк бетерешкән...

—Апа, дару бир әле,—диде “шайтан баласы”.

—Дару?! Кай җирең авырта соң, балакай?

—Бөтен җирем авырта, апа.

—Ни булды? Егылдыңмы әллә?

Малай дәшмәде, пычрак җиңе белән борынын гына сөртеп куйды.

—Син кайда яшисең соң?

Бу сорау да җавапсыз калды.

—Соң, әйдә. Берәр нәрсә табылыр. Ашатып та чыгарырмын үзеңне,—Илдания урыныннан кузгалып, өстен какты.

—Юк, апа. Мин монда калам. Син үзең алып кил, апа,—диде малай.

—Әй, балакай, дару гына басса икән әрнүләрне! Тән ярасын гына дәвалый шул ул. Җан ярасына дәва юк. Йә, ярар, көт, алып чыгармын.

Шулай итеп, ни ташландык буш йортта да Илданиягә рәхәтләнеп еларга ирек бирмәделәр. Әллә каян гына килеп чыкты бу шайтан баласы?

Рәмис, ә бу ул иде, мәрхәмәтле апасы биргән ризык белән даруларны алып үзе генә белгән тычкан юлы аша подвалга, авыртудан сызланып, ыңгырашып ятучы дусты янына ашыкты.

* * *

Ашыкты Раил. Үзе дә ашыкты, Илданияне дә ашыктырды. Сабыр итәргә, ашыкмаска кирәк иде. Ул үзен артык җавапсыз, артык малайларча тотты бугай. Илдания, әлбәттә, аны җиңел акыллыга санагандыр, шуңа баш тарткандыр, Раилнең чакыруын кабул итмәгәндер. Ашыккан ашка пешкән дип юкка гына әйтмиләр икән картлар.

Пеште Раил. Ландышын югалтканнан соң беренче тапкыр чит хатын-кызга күзе, күңеле төшкән иде, анда да буш кул белән калды. Раилдән баш тарттылар. Ничек әле алай булды? Төс-кыяфәте кешедән кимме? Юк! Булдыксызмы? Юк! Беркемнән дә ким түгел Раил! Менә дигән йорты бар, эше—дәрәҗәсе бар, акчасы, байлыгы да җитәрлек.

Үз-үзе белән бәхәсләшеп, Чистай аракысын эчеп утыра Раил. Менә шулай тик томалга, япа-ялгыз эчкәне юк иде. Соңгы вакытта никтер шуңа тартыла башлады. Үртәлгән, кимсенгән күңелен ничек булса да юатасы килә.

—Әти, зинһар, эчмә!—дип ялвара кызы.

—Соңгысы, соңгысы кызым,—ди Раил, үзе исә рюмкасына һаман аракы агыза.

—Утыр әле, утыр яныма. Кызым, Алсукаем минем! Әйт әле миңа, дөресен әйт! Синең әтиең начармы? Бик начармы?

Алсу кулы белән рюмканы каплый.

—Юк, әти, син дөньяда иң яхшы кеше. Тик эчмә, зинһар, эчмә, әтием!

—Ник ул мине ташлады? Ник ташлады?

Кем турында сүз баруын Алсу яхшы аңлый. Әтисен шундый газапларга салуы өчен Илдания апасына бер яктан ачуы килә, ә икенче яклап әтисенә ияреп өйләренә килмәвенә шатлана да. Шул гына җитмәгән иде, укытучысы ана үги ана булсын, бирелә хуҗа булып йөрсен, имеш.

Әмма кызның әтисен юатасы килә.

—Әтием, аның ире бар бит. Ире булмаса, ул сине ташламас иде. Алай борчылма инде, әтием. Син һич тә начар түгел. Мин сине бик яратам.

—Әй, кызым, әле дә син бар, күбәләгем! Кил әле, бер кочаклыйм үзеңне.

Әмма Алсу килми. Кечкенә вакытында әтисенең тезләренә менеп утырып, аның кытыршы яңакларын сыйпарга ярата иде. Хәзер ояла, бала-чага түгел бит инде. Шулай да, әтисенең каршысына килеп тезләнә, аның зур кулларын үзенең нәфис, кечкенә учына салып, бармакларын үбә. Әтисен юатасы, аны тынычландырасы килә аның. Әмма әтисе кинәт елап җибәрә:

—Кызым, нигә яратам икән мин ул юньсез хатынны? Юньсез бит ул, әйеме?

—Әйе, әтием. Ул юньсез.

—Алсу! Кызым! Нигә алай дисең?! Илдания апаң юньсез түгел!

—Ярар, әтием, синеңчә булсын, юньсез түгел. Башка эчмә инде, яме. Әйдә, мин сиңа урын җәям, ят, әтием, ял ит,—Алсу, эчә-эчә тәмам йомшарган әтисен, торгызмакчы була:

—Ашыкма, кызым. Әле сөйләшеп бетермәдек бит. Мин, кызым тотам да өйләнәм. Хет иртәгә өйләнәм. Матур хатыннар күп бит дөньяда, әйе бит, кызым. Вәт, тотам да берсен алып кайтам.

—Кирәкми, әти! Безгә беркем дә кирәкми.

Әтисе Алсу белән килешә:

—Дөрес әйтәсең, кызым! Безгә беркем дә кирәкми! Бетте, точка! Алып ат бу әшәке Чистай малаен! Безгә беркем дә кирәкми!

Кызы белән кочаклашып икенче катка, йокы бүлмәсенә күтәрелә.

—Тыныч йокы, әтием,—ди Алсу. Инде менә ничә көннәр анның күңеле тыныч түгел, кыз борчулы. Әгәр әтисе эчә башласа? Бу бит коточкыч фаҗига булачак! Әллә соң Илдания Зөфәровна белән сөйләшеп карарга мы? Шулай итәр, әгәр әтисе үзен кулга алмаса, Алсу шулай итәр, мин-минлеген, горурлыгын читкә куяр да, Илдания апасы янына килеп: “Әтиемне коткарыгыз, югыйсә ул харап була”,—диячәк.

Раилнең дә җаны тыныч түгел, ул йокыга китә алмый газаплана. Нидер җитми, кемдер җитми ана... Күзләре дивар рәсемгә—Ландышының сурәтенә төшә, һәм үзе дә сизми сыкранып әйтеп куя: “Их, Илдания, өздең лә үзәгемне!”. Ничә еллар буе Раилнең йөрәген, күңелен биләп торган Ландыш сурәте әкрен-әкрен гүя эри, артка чигенә, томан эченә кереп югала, анның урынына Илдания пәйдә була, ул һаман алга чыга, Раил тормышында һаман күбрәк урын били бара...

Алсуга укытучысы каршына барып, баш иярргә туры килмәде. Анның бәхетенә, хәер, үзенекенә дә, Раил сүзендә торды, “акбаш”ларны күз алдыннан алып-җыеп куйды. Ир яхшы белә: утырган арбаңнан бер төштеңме, аңа шундук башкалар хуҗа була, ә сине таптап кына китәчәкләр. Заман кырыс, рәхимсез.

Фирманың биш бригадасы берьюлы берничә объектта эш алып бара. Һәркайсын күз уңында тотарга кирәк. Кирәкле материаллар белән тәэмин итү, акча, транспорт мәсьәләләрен хәл итү, килешүләр төзү, яңа заказлар табу... Кыскасы, эшлим, булдырыйм, дигән кешегә тәүлекнең егерме дүрт сәгате дә җитә торган түгел. Чаба Раил, әмма Илдания дә аннан калмый, күңеленә кереп утырган да, китәргә исәбе юк. Хәер, Раил моны теләми дә. Җанына якын булган шул сөйкемле затның дөньяда барлыгына, тормышына яңа ямь, җылы нур өстәп торуына сөенә генә. Юк, өметен өзми әле ир, өзми. Ике арадагы җепләр мәңгегә өзелмәгән бит.

Хатын-кызлар бәйрәме якынлашкан саен Раил күңелендәге өмет тә үсә, ныгый барды. Бәйрәм белән котлауны сәбәп итеп, Илданиягә сукмакны яңартырга теләгән иде ул. Әмма барып чыкмады, мәктәпкә шалтыраткач:

—Яруллина административ ял алды. Әнисе бик каты авырый, авылына кайтып китте ул,—дигән җавап ишетте.

* * *

Сеңелесе “әни авырый” дип шалтыраткач, Илдания хәлнең ни дәрәҗәдә җитди икәнен әле аңламаган иде. Бәйрәм бүләге булыр дип, базарга чыгып, әнисенә яулык эзләде. Ак төсләрне яратуын белә иде, кырыйлары сырлап-сырлап эшләнгән, уртасына ефәк җепләр белән чәчкә-бизәкләр чигелгән тәүге кар кебек ак, мәк чәчәгедәй нәфис яулыкны сайлап алды. Әнисен бик шатландырасы килгән иде Илданиянең.

Кызын күргәч, талпынып куйды ана, нидер әйтмәкче булып иреннәрен кыймылдатты, тик ыңгырашудан башка аваз чыкмады. Хәрәкәтсез, телсез ята иде ул. Илдания бу хәлне күреп тетрәнеп китте, ни кылырга белмәде. “Бәйрәм белән”,—дигән булып, сумкасыннан яулыкны чыгарды. Аны күргәч, әнисе тагы талпынып куйды, кызына мөлдерәп төбәлгән күзләреннән яшь тамчылары тәгәрәде.

Зөһрә кичкенә баласы белән кайткан иде, улы төне буе елады, беркемгә тынгы бирмәде. Әллә шул тавыштан, әллә сызланудан әнисе дә борсаланды, ыңгырашты. Урамда март бураны котырды. Әллә нинди шомлы, бәгырьләрне өзәрлек авыр төн булды ул.

Таң аткач, бар да тынды. Елый-елый арып беткән малай, ниһаять, йокыга китте, буран да басылды, әнисе дә тынып калды, мәңгегә тынычланды...

Иртән кайгылы йортка туган-тумача, күршеләр җыелды. Йола-гадәтләрне

яхшы белгән өлкәнрәкләр үлем кирәк-яракларын хастәрләргә керештеләр. Әнисе барысын алдан әзерләп куйган икән, сандык тулы чүпрәк-чапрак, хәер итеп таратырга дигән вак акчалар да яулыкка төйнәп куелган. Шулчак кабер казучыларга дигән тастымаллар арасыннан бер конверт килеп чыкты. Тышына "балаларга" дип язылган иде. Олы кыз булгач хатны Илданиягә бирделәр. "И-и, әнием, и-и, бәгърем!"—дип елый-елый конвертны ачты, күзен томалаган яшьләр укырга комачаулый, хаттагы хәрефләр биешә иде. Әмма аны укырга кирәк, бәлки әнисе соңгы васыятен шунда язып калдыргандыр.

"Балалар! Бу арада бик ямьсез төшләр күрәм. Әтиегез чакыра. Әҗәлем якындыр, ахры. Шуна исән чагымда язып калдырыйм дидем. Өстемдә бер бурыч йөри. Аны үтәмәсәм, әтиегез рәнҗеп каршылар. Исән чагымда, әйтәсем, сезгә белгертәсем килмәде. Әтиегез, балалар бер-берсен белеп, аралашып үссеннәр, туганнар бит алар, дисә дә, гел каршы килдем, бер дә күнелем тартмады.

Хәлләр болай, балалар. Әтиегезнен читтә тагы бер баласы бар. Әлмәттә шофер булып эшләгәндә, бер хатын белән кушылган булган. Загссыз гына яшәгәннәр. Әтиен авариягә очрап, аяксыз калгач, ул хатын, гарип кеше тәрбиялисе килмичә, баласын алып качкан, бүтәнгә кияүгә чыккан. Имеш, алар хәзер Яртауда яши, әтиегез үзе күреп кайтып, мина сөйләгән иде. Йөрмә, кеше семьясын бозма, оныт дигән идем. Минем кан, минем бала, үз атасын ул белергә тиеш, диде. Кызы белән сөйләшергә өлгерми калды, анын васыяте сезне туганлаштыру иде.

Инде әйттем, хәлне белдегез. Калганын үзегез карагыз. Теге баланын исеме Ландыш, 1960 елда туган, әнисе Гөлчирә исемле.

Балалар, бу хатны сез мин үлгәч кенә укырсыз инде, бәхил булыгыз, тату яшәгез, туган оягызны туздырмагыз.

Мине әтиегез янына жирләгез.

Балаларым, бәхетле булып, озак яшәгез. Миннән теләк шул. Әниегез. Язылды 10 нчы гыйнварда"

"Ике ай элек... Күнеле сизгән икән бәгырькәемнен. Их, әни!"—сулкылдап-сулкылдап елап утырган апасы янына Зөһрә килде, анын кулындагы хатка үрелде. Әмма Илдания бирмәде, хатны бөкләп, халат кесәсенә тыгып куйды.

—Кирәкми, укыма... Аннары... Барысы беткәч, бу хәсрәттән бераз айныгач... Әлегә барыбер баш эшләми, анлап бетерә торган түгел, сенлем.

Әнисе белән хушлашу, аны мәңгелек йортка озату мәшәкатьләре белән хат турында бөтенләй онытылды да.

Соныннан, әнисенен жидесен үткәргәч, ике кыз туган кара-каршы утырып, йорт язмышын хәл иттеләр.

—Апа, әгәр син каршы булмасан, мин кайтам. Инсаф белән сөйләштек, ул риза. Барыбер общагада этләнәбез,—диде Зөһрә.

Илдания аны кочып алды, бу анын сенлесенә рәхмәт белдерүе иде.

Хат турында Зөһрә онытмаган икән, апасынын исенә төшерде:"Мина укырга ярыйдыр бит?".

—Йә, ни диярсен?-дип сорады Илдания, хатны укыганнан сон, хисләнеп, тәэсирләнеп уйга калган сенлесенә карап.

—Әтинен кызы... Безнен апа... Барыбер, чит кеше инде ул безгә, якынлашып, туганлашып булмастыр кебек. Белмим тагы... Син ни уйлыйсындыр.

—Әтинен үтенече бит, Зөһрә. Безнен өстә бурыч булып калмасын. Эзләргә, табарга, анлашырга кирәктер.

—Мина синнән башка бернинди туган да кирәкми. Семьябызга чит

кеше кертәсем килми. Яшьтән бергә үсмәгәч, әллә кайда йөргән ул Ландышның ни якынлыгы булсын?!

—Сүз туганлашу турында бармый бит, сеңлем. Әти васыятен үтәргә кирәк. Әни дә шулай теләгән. Безгә рәнҗеп ятмасыннар. Яртауга кайту белән эзли башлыйм мин ул Ландышны,—диде Илдания бәхәскә нокта куеп.

Теләсә ни эшлә, бигайбә, дигән сыман, Зөһрә иреннәрен бүлтәйтеп, иңнәрен генә сикертте.

Әнисенә бер тапкыр да бәйләргә насыйп булмаган ак яулыкны Нургаязның әбисенә илтеп бирде Илдания.

Егерменче гасыр Җиһан әбинең өенә кереп тормыйча гына үтеп бара. Эче-тышы балчык белән сыланып, ел саен агартылып торган мондый кечкенә, җыйнак йорт авылда бер генә. Өй каршындагы бакчада рәт-рәт тезелеп үсеп утырган тәз, биек наратлар да башка беркемдә юк, Җиһан әбидә генә. Сорыяр авылын аркылыга-буйга йөреп чыксагыз да, бу йорт каршындагы кебек сиртмәле кое табалмассыз. Ул коены Җиһан әбинең карты Әгъзам бабай казыган, бурасын да үзе бураган, шуңа күрә, үзе дөнья куйгач та, карчыгы бу коега күз-колак булып тора, кое янына бала-чага китерми, чиләге тишелсә, аны алыштыра, кое тирәсен чистартып тора.

Җиһан әбинең йорты урамнан эчкәрәк урнашкан, аның җиләк-җимеш бакчасы башкаларныкы кебек артта түгел, ә алда, урам ягында. Җәй җитте исә, карчык тирә-күрше балаларын алмадыр, карлыган-шомырттыр белән сыйлый, тегеләрнең бакча басарга теләге дә калмый аннары. Җиһан әбинең ишегалды да, капка турысы да яз-җәй ямь-яшел булып тора, әйтерсең келәм җәйгәннәр. Хәзер ул мал-туар асрамый, моңа көче җитми, әмма сыеры булганда да шулай иде, йорт тирәсе ямь-яшел чирәм иде.

Һәрчак пөхтә йөрүче, йөзеннән ягымлы нур сирпелеп торган Җиһан карчыкны Илдания балачактан ук үз әбиседәй якын күрә. Нургаяз белән очрашканда да, нәкъ менә шул йорт турысында, алмагач төбендә сөйләшеп утыралар иде.

“Ул чакта әни бар иде, исән иде... Нинди бәхетле, бер кайгысыз көннәр булган”,—дип ямансулап куйды Илдания. Хатирәләр сагышын, йөрәк әрнүен тирәнәйтте.

Ул кергәндә, Җиһан әби өй түренә басып намаз укый иде. Андый чакта кешене бүлдерергә ярамый. Илдания артык тавыш чыгармаска тырышып, әкрен генә басып керде, ишек төбендәге сандыкка килеп утырды. Бу йортта берни үзгәрмәгән икән, вакыт бирердә гүя туктап калган да, рәхәтләнеп ял итә. Алай дисәң, стенадагы чылбырлы кара сәгать һаман келт-келт йөри әле, бичара күке инде ничә еллар ишеген ачып кычкырадыр, бәлки әле еллар гына түгел гасырлардыр, бик борынгы сәгать бит инде бу.

Илдания баш-башлары сырлап эшләнгән киң караватка, аның өстендәге колач җитмәслек мул мендәрләргә, хан заманыннан калган, инде саргая-карала башлаган дүрт почмаклы көзгегә, идәндә сузылып яткан чуар паласка күз салып чыкты. Барысы да шул, хәтта намазлык өстенә баскан Җиһан әби дә шул, барысы да элеккечә, тик аркасын җылы мичкә терәп сандык өстендә утыручы Илдания генә башка...

Соңгы көннәрдә ул бик арыды, йончыды. Бу җылы, фәрештәле йортка килеп кергәч, тәнендә, күнелендә ниндидер җинеллек тойды, ничә төн юньләп йокламаган иде, кинәт кенә күзенә йокы төште, оеп киткәнен сизми дә калды. Аны:

—И-и, Илдания кызым килгән икән,—дигән тавыш айнытып җибәрде. Ул урыныннан торып:

—Исәнме, Җиһан әби,—дип, карчыкка кулларын сузды.

—Аллага шөкер, кызым, әлһамделлаһи шөкер. Менә сезнен йортка гына

кайгы килде. Ахыры хәерле булсын инде. Иртәрәк китте шул Рәйханә. Ярый әле, озак интегеп ятмаган мескенкәем. Кем карап бетерер иде?

—Карар идек әле, Жиһан әби. Гүрдә ятканчы, өйдә, яныбызда ятсын иде! Дәшмәсә, сөйләшмәсә дә, әни булыр иде,—Илданиянең күзләренә кабат яшь тулды.

—И-и, кызым, бик олы шул хәсрәтегез, адәм баласы ничек түзәдер. Әнине югалту бик авыр, кайсыбыз кичермәгән. Үзәкләр өзелә инде, кояш сүнгәндәй була. Син, кызым, елыйсың килгәндә, тырнакларына кара. Аннары су да хәсрәтне юа, мунча керергә кирәк, һәр көнне булса да артык түгел. Хәсрәтенне кешегә түккәнче, суга түк, дия иде минем әни.

Жиһан әби дә кайчандыр бала булган, яшь кыз булган, кемнеңдер кызы булган... Аның да әнисе булган... Ышанасы да килми хәтта, ул гомере буе шулай әби булып кына яшәгәндер төсле. Илдания бирегә ни өчен килгәнен искә төшереп, алып килгән яулыгын сузды:

—Менә, Жиһан әби, әнигә... бәйрәм бүләге итеп алган идем... Үзенә бәйләргә насыйп булмады... Әнинең төсе итеп син бәйләрсең, Жиһан әби.

Карчык бисмилла әйтеп, яулыкны алды да, аны тиз өстенә куеп, шәмәхә төскә кергән нечкә кәкре бармаклары белән берничә тапкыр сыпырып алды.

—И-и, рәхмәт инде, кызым. Бигрәк зурлагансың. Харап затлы яулык бит бу! Кыйммәттер?

—Бүләкнең бәясен сорамыйлар,—дип котылды Илдания.

Жиһан әби озак итеп дога кылды, тыйнак кына ачылган иреннәреннән берсеннән-берсе күркәм теләкләр коелды. Илдания догалар белми, шуна күрә "амин, амин" дип кенә утырды.

—Каяле, самавыр гөжләтеп жибәрик. Чөкердәшеп чәй эчәрбез,—дип Жиһан әби өстәл өстендәге күмер самаварын күтәреп почмак якка кереп китте. Илдания ярдәм итәргә теләгән иде, якын да китермәде.

"Житте, азапланма!",—диеп кызлары Жиһан карчыкка житмеш яшенә электр самавыры бүләк иткән булганнар. Имеш, Жиһан әби моңа бик шатланган, балаларына рәхмәтләр укый-укый, күмер самавырын келәткә үк чыгарып куйган. Әмма кызлар китү белән иске самавыр кабат үз урынына, өстәл башына менеп тә кунаклаган, имеш...

Илдания Нургаяз хакында сүз кузгатырга кыймаган иде, Жиһан әби чәй янында үзе бу хакта сөйли башлады.

—Безнең имансыз малай да табылды бит әле, кызым. Анасы беркемгә әйтмәскә кушкан ие дә... Бик дуслар идегез бит, әллә ятрашып та йөрдегез инде... Сиңа гына сөйлим, ишет тә оныт: исән бит безнең Нургаязыбыз!

Илдания иренәнә китергән чынаягын куеп, түземселәнеп сүзнең ахырын көтте. Кайда йөргән Нургаяз? Ник беркемгә белгермәгән?

—Ничә еллар буе бездән ут йоттырды. Анасы йөрәк чирлегә әйләнде тәмам. Нәселдә булмаганны, ни кыланды бит!—Жиһан әби кулларын кая куярга белмәгәндәй, әле бер, әле икенче савытны урыннан-урынга күчерә, йә калтыранган бармаклары белән ашъяулыкны сыпырып ала.

—Авыр булса, сөйләмә Жиһан әби.

—Юк, сөйлим әле, кызым. Эчемдә жыелып ятмасын. Безнең Нургаяз нишләгән? Кыз-хатын киеме киеп, телсез-чукрак булып кыланып Мәскәү жир астында хәер теләнеп йөргән. Имансыз малай!

Менә сиңа Нургаяз! Башка сыймаслык хәл бит бу!

—Хәзер әнә ристоранда жырлап йөри икән. Акчасы да күп, ди. Бер маржага йортка кергән. И-и, кызым, картайган көнебездә мыскыл итте ул безне.

—Жиһан әби, ник алай иткән соң ул? Исәнлеген ник беркемгә белгермәгән?

—Солдатка бармас өчен. Әрмиядән качып йөргән. Элек өтермән белән

куркыталар иде кешеләрне, хәзер Әрмия дип кот очыралар. Нургаяз сугыштан бик курка иде бит ул, и-и җебегән малай иде дә соң мескенкәем. Тач атасы инде!

—Исән булгач, табылгач, яхшы инде. Авылга кайтырга исәбе юкмы соң? Сагынмады микәнни?

—Сагынам, дигән. Әбине күрәсем килә, дигән. Кайтырга куркып ята. Хәзер солдатка барыбер алмыйлар, яше үткән инде. Оялганга кайтмый. Ояты булгач, иманы да бар инде, димәк. И Ходаем, иманнан гына яздырмасын. Үлгәнче, шул Нургаязны бер генә күреп калсам иде. Баланың баласы балдан татлы, үз кулымда үсте бит.

Беркемнең дә казаны буш түгел шул. Җиһан әби башта бер ут эчендә янды, инде икенчесенә илтеп тыкканнар. Их, Нургаяз, нишләдең син?! Фәрештәдәй изге кешегә ник шул хәтле хәсрәтләр китердең, акылсыз малай?!

* * *

Еламаган балага ими бирмиләр. Хакимият бусагасын таптый торгач, ниһаять, Газинур да теләгенә иреште: "Яшьләр үзәге" өчен Дала урамындагы ике подъездлы буш йортны бирделәр. Тугыз катлы биек, яңа йортлар арасында ничек адашып калгандыр ул, анысын бер Ходай белә, әмма нәкъ менә шул яңа йортлар янында булганга да, кыяфәте яман иләмсез, коточкыч булып күренә. Көчсез, мескен кешеләр үзләрен башкалардан ким күрсәтмәс өчен, йөзләренә ничек тәккәбберлек, гайрәтлелек кыяфәте чыгарсалар, бу иске, котсыз кечкенә йорт та караңгы тәрәзәләрен акайтып, "тиеп кенә карагыз!"—дигән сыман, кәпрәеп утыра иде.

Газинурның бу тирәгә килгәне дә, бу йортны күргәне дә юк иде. Кулына адрес тоттыргач, ул шатлыгыннан очардай булып, бирегә йөгереп килде, һәм, тәмам хәрәбәгә әйләнгән иске бинаны күргәч чак кына аңын югалтмады. Эченә кереп тормыйча да аңлады, бу сәләмәне рәткә китергәнче, бүген урамда футбол тубын тибеп йөрүче малайлар бабайга әйләнәчәк!

Йортның тышкы кыяфәте бер имәндерсә, эчендәге хәлләр аннан да яманрак булып чыкты. Стеналар умырылып беткән, буй-буй ертык обойлар убырлы карчык чәчләре кебек тузып тора,ишек-тәрәзәләрне төбе белән каерып алганнар, идәннәрдән җилләр искән, су, җылыткыч торбалары, ванна, кульюгыч—бернәрсә калмаган. Алына-сүтелә торган бөтен нәрсә юкка чыккан. Карактан соң әйбер кала, уттан берни калмый дип, әйткән булалар тагын. Юк, ут та болай рәхимсез кыланмас. Үзе юкның күзе юк шул, иясез малга хуҗа тиз табыла.

—Яшьләреңне җыеп, өмә үткәр. Ремонт өчен бераз акча бирербез,—дигәннәр иде, кеше көлдерерлек сан булып чыкты, әле анысына да рәхмәт әйтергә куштылар.

Әгәр кирәк икән, Газинур спартакиадалар, әллә нинди конкурслар, семинарлар, фестивальләр үткәрә ала (һәм үткәрә дә), берүзе ун кешегә каршы тора ала, йөзәр килолы штанганы эһ тә итмичә күтәрә ала, тагы бик күп, бик күп эшләр башкара ала, өмәсен дә үткәрер, тик төзелеш эшләрендә "незнамо", теше үтми. "Бомбежка"дан калгандай бу ярым җимерек йортны кайсы баштан төзәтә башларга икәнен хәтта күз алдына да китерә алмый. Чит планетага килеп төшкән заттай бүлмәдән-бүлмәгә, этаждан этажга аптырап, каңгырап йөрде йөрде дә, Газинур, киңәш-табыш итәргә дип, дусты-хезмәттәше янына "Камил" фирмасына юнәлде.

"Камил" фирмасы биш катлы йортның өч бүлмәле фатирына урнашкан. Элек кемнәргәдер йокы бүлмәсе булып торган бүлмәдә—бухгалтерия, икенчесендә—директор кабинеты, ә зал—кабул итү бүлмәсе булып тора. "Аерым бина тотуга караганда, болай арзанга төшә, чыгымнар азрак",—

дигән иде шул фирманы оештыручы һәм житәкләүче дусты—Раил Сөләйманов. Газинур килеп кергәндә, ул каядыр китәргә жыенган, ишек төбендәге шкаф янына басып, киенеп маташа иде.

—Биш минут вакытым бар, сөйлә, ни йомыш?—диде ул, күрешкәч. Газинурның юкны бушка аударып йөрмәгәнен яхшы белә иде, дустының нәрсәгәдер борчулы икәнен йөзенә карау белән сизде. Тегесе булдыра алганча кыска тотып, хәлне аңлатты. Раил аны игътибар белән тыңлады. Газинур сөйләүдән туктагач:

—Киңәшем шул: РСУлар белән бәйләнмә. Акыртып талыйлар. Бер айлык эшне елга сузалар, аның каравы бәяне кабарта белә үзләре. Син, Газинур, частниклар белән эш ит. Бердән, арзанга төшәчәк, икенчедән, алар сыйфатлырак та, тизрәк тә эшли,—дип киңәш бирде.

—Шуңа күрә, сиңа килдем дә бит инде, Раил. Син ул мәсьәләдә намуслы, ышанычлы кеше, бәлки алынырсың.

—Андый эшне кабинетта утырып хәл итеп булмый, туган. Барып күрергә кирәк.—Раил өстәлдәге календарьга күз салды,—әйдә... тәк... берсекөнгә сәгать өчтә очрашыйк. Шунда иркенләп сөйләшербез.

—Берсекөнгә ял көне бит.

—Шулаймыни?!—дип гаҗәпләнде Раил.—Вәт, малай, чынлап та! Дөньяда ял көннәре дә бар бит әле, онытылган, валлаһи! Алайса, кайчан?

—Миңа барыбер, Раил. Ял көне белән исәпләшеп торган юк. Үземнең дә әле бер, әле икенче мероприятие. Безнең эш тә сәгатьле түгел бит,—диде Газинур.—Ял көне тәк, ял көне...

—Нинди адрес диден әле?

—Дала урамы, 96 нчы йорт.

“Дала урамы? Соң Илдания яшәгән урам ич бу!” Илданияне көтеп торганда ул йортка игътибар иткән иде Раил. Ник сүтеп атмыйлар икән, дип уйлап та куйган иде шул чак. Бигрәк урамны ямьсезли бит, яшь, гүзәл, зифа кызлар арасына ялгыш килеп эләккән тешсез, шөкәтсез карчык кебек утыра. Дустына, әлбәттә, ярдәм итәчәк ул. Тик ремонт эшләре өчен бүлеп бирелгән акчага сыешмаячакларын санап тормасаң да көн кебек ачык. Алдагысын күз күрер, диде дә, килешкәнне беллереп Газинурга кул сузды. Раил өчен вәгъдә иман икәнен Корбанов яхшы белә иде.

* * *

“-Син аны үтерергә тиеш, Джек!

—Кемне?

—Минем мөгезле идиотны.

—Эмми, нигә? Без болай да бәхетле.

—Майклның счетында миллионнар ята. Барысы да безгә булачак, Джек! Егет бул, үтер аны!”.

Әлбәттә, үтерәчәк. Үтермәсә, америка киносы буламыни?! Джек Майклны үтерәчәк, аннары Эммиена да чират житәчәк. Соңыннан, миллионнары барлыгын белгәч, Джекның да башына житәчәкләр! Хәмит телевизор эченә кереп китәрдәй булып әнә шул тамашаларны карап утыра.

Илданияне беркем үтермәде, әмма ул тереләр арасында юк инде. Тәне исән, ә җаны үлгән.

Хәер, алай дип әйтергә ярамыйдыр. Исән ул жан, исән, бары яралы гына. Теге чакта, Раил каршына буш кул белән чыгып, язмыш гомерендә бер тапкыр бүләк иткән мәхәббәтеннән, бәхетеннән баш тарткач, бәгыренә салкын ук кадалгандай булган иде, шул ничә көннәр, төннәр сулкылдап-сулкылдап сызлады, әрнүдән җаны ыңгырашты. Шул яралы җанга янасы—әнисен югалту хәсрәте килеп өстәлде. Үзен кая куярга белми бәргәләнә

Илдания, бернинди ямь, шатлык таба алмый. Ландышны эзләве дә нәтиҗәсез булды. Фамилиясен дә белмәгән кешене ничек тапмак кирәк?! Эскерттән энә эзләү белән бер ич ул.

Ландышның әнисе исәнме икән? Әтисенең беренче хатыны... Бәлки ул алай ук начар да кеше түгелдер, бәлки яшьлегендә кылган гөнаһы—авыру ирен, баласының атасын ташлап китүенә үкенә дә торгандыр? Бәлки ул анада Илдания өчен дә йөрәк җылысы табылыр иде...

Яртауга беренче тапкыр әтисе белән килгән иде ул. Биек тауларга, ярга сыенып утырган яшел каланы күргәч тә, аһ итте кыз, шул гүзәл шәһәргә гашыйк булды. Яз иде, урам буйлап тезелеп утырган алмагач-шомыртлар шау чәчәктә иде. Карап-күреп туймады бу каланы Илдания. Гөлбакча эчендә утырган әкият иле кебек күңеленә кереп калды ул. Казанда укып йөргәндә үк, "мин Яртауга кайтам",—дип хыялланды, гел шунда ашкынды. Кайда без юк, шунда яхшы, диләр. Хәзер менә, Яртаудан, җимерелгән өмет-хыялларыннан качып, Сорыярына гына кайтыр иде. Әтисенең, әнисенең кабере шунда, туган йорты шунда, Җиһан әбисе шунда... Яшисе иде ак карларга күмелеп утырган, эче-тышы балчык белән сыланган ак, кечкенә йортта, арканы җылы мичкә терәп, дисбе тартып утырасы иде. Берни турында уйламыйча, кайгырмыйча... Янында йомгак кебек йомры гына йомшак кына бер песи мыраулап йөрер иде. Ә урамда тыныч кына ап-ак кар явар иде...

Зөһрә шунда бит. Бәхетле җан, ирен, улын ияртте дә, туган йортка кайтып урнашты. Авыл егетенә чыгып дөрес эшләде ул. Бәхетенне читтән эзләргә түгел икән. Авылда бит кеше бер-берсенең ничек тын алуына хәтле белеп тора: бу нәсел мондый, ә бусы болайрак... Хәмит кебекләр Сорыярда картаеп беткәнче үзләренә хатын таба алмыйлар. Читтән алып кайтып карыйлар, әмма тегеләре булдыксыз ир янында озак юанмыйча, бик тиз сыпырта...

Ялгышты Илдания. Мәкъбүлә апа каршында бернинди бурычы да юк аның. Ул аны тапканмы, бакканмы, тәрбияләгән-укытканмы? Ник әле Илдания гомере буе аның улын саклап ятарга тиеш? Бернигә карамый, ияреп китәсе калган Раилгә! Аһ, ялгышты шул. Ә хәзер соң, соң инде. Поезд китте. Китте... Илданиянең бәхетен еракка, бик еракка алып китте. Эзләп, табып булмый торган җиргә.

Раилдән бер хәбәр юк. Ике сөйләшә торган кеше түгел шул ул.

Бүген ял көне. Илданиянең иң яратмаган көне. Бик озак үтә ул, һәм бик күңелсез үтә. Эч пошканнан юк эшне бар итеп, өйләр җыештырган, керләр юган булды, өчпочмаклар пешерде. Сәгатькә караса, әле өч тә тулмаган икән. Ял көне бигрәк озын шул.

Илдания йокы бүлмәсенә керде, башын мендәргә салды, әмма көпә-көндез нинди йокы булсын? Йоклаганда ичмасам, баштан авыр уйлар китеп тора, беразга булса да, хәсрәт онытыла. Йокласан, көн дә тиз үтә... Әмма йокы ялындыра, килергә ашыкмый. Аптырагач кулына китап алды Илдания, күз алдында хәрефләр сикереште, әмма укыганының мәгънәсенә төшенмәде.

Уф!!! Нинди тормыш соң бу?! Ник шулай буш, салкын соң ул?! Илдания тәрәзә каршына килеп басты. Быел апрель язга да охшамаган. Карлы яңгырлар ява. Юеш, салкын, ямансу... Бик ямансу... Тәрәзәдән күпме караса да, күңел юатырлык, җанын тынычландырырлык берни тапмады Илдания. Карашы һаман биек, таш йортларга гына килеп төртелде. Авылдагы кебек чиксез, киң офыклар юк шул монда...

...Чү,чү! Аларның ишегалдына ак "Нива" кереп бара түгелме соң? Ул! Ул! Номеры анык, Раил килә! Айдан артык аннан бер хәбәр булмады ич. Килә... Илданиянең фатирын беләме икән соң ул? Табармы икән? Әллә каршысына йөгереп чыгаргамы? Ай, килешмәс лә... Ак "Нива" ташландык йорт турысында туктады. Машинадан ике баһадир ир төште. Берсе—Раил!

Икенчесен дә таныды Илдания, ул кешенен мәктәпкә килгәне бар иде, Яшьләр комитеты рәисе Корбанов. Болар буш йорт янына килеп, куллары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, сөйләшеп тордылар. Күрде Илдания: Раил әледән-әле алар йортына таба борылып карый, берәүнен челтәр артына посып үзен күзәтеп торуын башына да китерми, әлбәттә. Илданиянен кәефе төште, Раил анын янына килмәгән...

Ирләр сөйләшә-сөйләшә, ташландык йорт эченә кереп киттеләр. Ә Илдания тәрәзә яныннан кузгалмады. Ярты сәгать, бер сәгать үтте... Хатыннын күнеле шомлана башлады: ник чыкмыйлар алар, бу шайтан оясында ни эшлиләр? Күз алдына теге сәләмә киемле, өрәккә охшаган ябык малай килеп басты. Бәлки ул беркая китмәгәндер, һаман шунда ятадыр, бәлки үзе генә дә түгелдер, бәлки анда тулы бер шайкадыр. Караусыз калган урам яшүсмерләрен бик кансыз, диләр бит. Күнеленә шик бер үрелсә, аннан тиз генә котылам димә инде. Илдания дә сабырсызлана башлады, ахырда түзмәде, киенде дә урамга чыкты. Ишек төбендә ике хатын сөйләшеп тора иде, әллә шуна батырайдымы, буш йортка ялгызы гына кереп китте. Әле бер, әле икенче подъездга кереп, шыксыз бүлмәләрне айкап чыкты. Тик беркемне очратмады. "Кайда алар?"—дип аптырады хатын, ни уйларга белмәде. Шулчак гүя шар шартлаттылар, ниндидер ят, куркыныч тавыш ишетелде. Аннары тагы, тагы. Әллә аталар инде?! Илдания бәрелә-сугыла урамга атылып чыкты. Ә анда берни булмагандай тыныч кына кар ява, баягы хатыннар да әле һаман авызга-авыз куеп гәпләшеп торалар. Ни булды сон? Бу сәер тавыш кайдан ишетелде?

Илдания кабат подъездга керде, шунда гына сул яктагы кара бушлыкны күреп алды. Димәк, монда подвал да бар, Раил белән Газинур шунда! Кемгә аттылар? Йә, Алла! Курку турында онытып Илдания, абына сөртенә карангы бушлыкка таба атлады.

Шулчак ниндидер зур әйбергә килеп төртелде, ана кемнендер куллары кагылды. Хатын, бар көченә акырып, баскычларга абына-сөртенә, өскә атылды. Теге бәндә дә, аннан калышмый, дөп-дөп атлап, эзенә басып килә.

—Женщина, вызовите скорую! Скорее!—дигән сүзләрне ишеткәч, газиздән-газиз, кадерледән-кадерле тавышны таныгач кына, Илдания туктап калды, артына борылып карады. Анын каршында бите-кулы, киемнәре канга баткан Раил басып тора иде. Коты очкан, куркудан тәмам йөрәге алынган хатын үзен-үзе белештермичә ирне кочып алды.

—Раил, бәгърем! Ни булды? Раил!!!

—Илдания, анда—Газинур... Тизрәк скорый, милиция чакыр! Ана аттылар. Илдания, вакытны сузма, йөгер!

Раил шулай диде дә, Илданияне үзеннән аерып, кабат карангылыкка кереп югалды.

Анын тәнендәге, киемендәге кан, чынлап та, Газинурныкы иде. Чөнки сукбай малайлар поскан бүлмәгә ул беренче булып керде, фонарен яктыртып, алдан атлады. Алар подвалга җылылык челтәрен, су үткәргеч торбаларны тикшерергә төшкәннәр иде. Баскычтан төшеп, унга борылулары булды, кемдер бик ямьсез итеп кычкырып җибәрде:

—Убью! Не подходи! Гады!

Аннары ату тавышы янгырады... Теге бәхетсез бала, Мишка, боларны үзен эзләп килүчеләр дип. Әгәр пистолетында патроннары бетмәсә, Раилне дә Газинур язмышы көтә иде. Чөнки ул, ни булганын да, ни булачагын да исәпләп тормыйча, дустына ярдәмгә ашыкты.

Раил фонарь утынын һавада чайкалып алуын күрде, нидер гөпелдәп төшүен ишетте, икенче мизгелдә фонарь җирдә ята һәм әле һаман яна иде. Раил аны кулына алды. Ин башта Газинурнын җир идәндә чалкан яткан

канлы гәүдәсен күрде. Аннары фонарь яктысы бер-берсенә сыенып почмакка елышкан ике малайга төште. Берсенең кулында пистолет иде. Раил малай кулындагы коралны тартып алды да, Газинур өстенә иелде. Дусты, авырлык белән булса да, сулый иде әле...

* * *

Канга баткан Газинурны "Ашыгыч ярдәм", ә куркышып бер-берсенә сыенышкан ике үсмерне милиция машинасы алып китте. Ишегалдындагы ыгы-зыгыны тәрәзәдән күзәтүгә генә риза булмыйча, бар нәрсәне үз күзләре белән күреп, белеп калырга омтылып, кызык күрергә, гайбәт өчен җим җыярга дип җыелган карт-коры, әби-апалар да ах-вах итешеп берәм-берәм үз ояларына таралышты.

Ташландык йорт янында Раил белән Илдания генә басып калды. Раил дустын хастаханәгә озата барырга теләсә дә, "Ашыгыч ярдәм" машинасының табибы аның үтенеченә ни өчендер катгый рәвештә каршы килде, рөхсәт итмәде. Санаулы минутлар эчендә булган бу коточкыч көтелмәгән фаҗиганең чынлыгына Раил әле һаман ышанып бетә алмый, дусты белән сөйләшә-кинәшә җитәкләшеп диярлек кереп киткән караңгы ишек уемына нинди дер могҗиза көткәндәй тилмереп карап тора. Менә-менә башын бераз ия төшеп, кызу-кызу атлап Газинур килеп чыгар төсле. Ләкин аннан дусты түгел, бүрек кадәр кап-кара йомгак атылып чыкты, аның артыннан ук сорысы күренде. Ике йолкыш мәче бер-берсен куышып, ап-ак кар өстеннән тәгәрәп узды. Караңгы ишектән кинәт килеп чыккан шул мәчеләр Раилне сискәндереп-айнытып җибәргәндәй булды, күңелендә бу йортка карата үзе дә аңламаган ниндидер ачу-нәфрәт хисе калкып чыкты. Гүя дә дустының үлемендә, кешеләрдән куркыр дәрәҗәгә җиткән, якты дөньяның караңгылыгыннан җир астына качкан ике бичара баланың бәхетсез язмышына нәкъ менә шул черек нигезле, котсыз йорт кына гаеплеләр сыман тоелды. Үзе дә сизмичә йодрыкларын кысып, ярсып, нәфрәтләнеп әйтеп куйды:

—Җир белән тигезләргә кирәк моны. Юк итәргә! Бөтенләй юк итәргә! Искене күпме генә ямасаң да, яңармый ул. Чөнки аның нигезе черек. Ә яшьләргә яңа, өр-яңа бина кирәк!

Аның янәшәсендә, ташландык йортка карап, үз уйларына чумган Илдания аптыраулы карашын иргә төбәде. Кешеләргә бары мәхәббәт сирпеп караучы якты күзләренә олы хәсрәт оялаган иде. Әйе, бу күзләрдә шатлык нуры сүнгән, бүген алар дөньяга бәгырь яше аша карый. Үзе өчен бик тә кадерле, якын булган бу иргә карата чиксез кызгану, ярату хисләре, аңа ярдәм итү, юату теләге бергә кушылды да, Илдания, шул хисләрне берьюлы күтәрә алмыйча, сак кына Раилнең кулларына кагылды: "Мин синең яныңда, мин сине аңлыйм, кайгыңны бүлешәм". Бу орыну күпне аңлата иде, ир моны тойды, рәхмәт белдергәндәй, Илданиянең җылы бармакларын йомшак кына кысып куйды.

—Мин иң якын кешеләремне югалттым, Илдания. Хатынымны, улымны, инде дустымны.

Алар бер-берсенә артык якын торалар, Илдания хәтта йөзендә Раилнең кайнар сулышын тоя, тыгыз дымлы иреннәре шундый якын, шундый якын. Аларга кагыласы, үбәсе килә. Хатын бу теләгенең чиңга ашуыннан курыккандай йөзен читкә борды. Өстенә гади халат кигән килеш, бернәрсәсез, хәтта яланаяк кадерлесе артыннан китәргә риза бит Илдания. Тик чакырсын гына. Чакырсын гына! Ләкин Раилдә аның кайгысымы?! Илданиядән аерылмас өчен түгел, ә якын дустын югалту кайгысыннан ни кылырга белми аптырап басып тора ич ул бирелә. Йөзендә, күзләрендә бары хәсрәт тирбәлә. Раилне авыр уйларыннан араларга, аның ярлы җанын юатырга теләп, күңеленә тулган наз-мәхәббәт хисләрен сүзләренә, тавышына салып, хатын әкрен генә әйтеп куйды:

—Аны коткарырлар. Ул үлмәс.

Ир дәшмәде, ул могҗизага ышанмый иде.

Болай басып тору унайсыз иде. Йә китәргә, йә нидер эшләргә кирәк. Ә Илданиянен китәсе килми, Раилдән аерыласы, аны ялгыз калдырасы килми иде. Назлы карашы белән ирнең борчулы йөзен сыйпап үтте дә:

—Сезнең йөзегез канлы,—диде.

Аннары кесәсеннән кульяулык чыгарып, Раил битендәге кан тапларын сөртә башлады. Ир каршылык күрсәтмәде, йөзен аңа ия төшеп күндәм генә басып торды. Бу мизгелдә ул әнисе янындагы баланы хәтерләтә иде. Күмер күзләрен Илданиягә төбәп, нидер уйланып торды да:

—Сез минем хатыныма, Ландышка охшагансыз. Бәлки шуңа сезне үз иткәнмендер. Теге чактагы әрсезлегем өчен гафу итегез,зинһар,—диде.

Илдания сискәнеп китте, кулындагы канлы кульяулыкны җиргә төшереп җибәрде.

—Ландыш?!—дип кабатлап сорады ул.—Ландыш сезнең хатыныгыз идеме?

—Әйе. Ә нигә шулай гаҗәпләнәсез?

—Анын әнисенең исеме Гөлчирә түгелме, Раил?—Бу сорауны монын шулай булуын теләмичә, бары тискәре җавапка өметләнеп биргән иде Илдания. Әмма ир "юк" димәде, гаҗәпләнеп:

—Ә сез каян беләсез?—дип сорады.

—Алайса,—Илдания нидер әйтергә теләгән иде, тик кире уйлады.

Хатын күңелендә нинди уйлар бөтерелгәнен Раил аңламады, әчке кичерешләреннән гаять дулкынланган хатынның болай да ут янган битенә кайнар сулышын бөркеп, соравын кабатлады:

—Илдания, ник җавап бирмисез? Сез Ландышны белә идегезме?

"Әйтергәме, әйтмәскәме? Бәлки мин ялгышамдыр? Ялгышсам, яхшырактыр. Тапмаган да килеш, югалтканчы. Бер тапкыр да күрмичә". Барсын да ачыклыйсы, күңелендәге икеләнүләргә нокта куясы иде, әмма урыны, вакыты ул түгел. Ләкин әле тагын кайчан Раил белән күз-күз карап сөйләшү өчен мондый мөмкинлек була, бәлки алар башка очрашмас та. Уңайсызланса да, Илдания тәвәккәлләп сорарга җөрьәт итте:

—Раил, ә Ландыш... Ул ничәнче елгы иде?

—Әгәр исән булса... Исән булса, аңа быел утыз җиде тулыр иде.

Инде берниндu шиккә дә урын калмады кебек. Барысы да туры килә. Раилнең хатыны Ландыш Илданиягә апа тиешле кеше булып чыга, ләбаса! Раил моны белергә тиеш! Алсуда анын әтисенен—Зөфәр абыйның да каны да бар. Алсу—Илданиянең сеңлесе! Димәк, Раилнен гаиләсе—Илданиянен дә гаиләсе. Алар бергә булырга тиеш: Алсу, Илдания һәм Раил.

—Алайса. Минем сиңа әйтер сүзләрем бик күп икән, Раил.

—Минем дә,—диде ир.—Син миңа кирәк, Илдания. Сиңа әйткән һәр сүзем, тәкъдимем үз көчендә кала. Мин сине күпме көтәргә дә риза, тик өметемне өзмә. Бу дөньяда ялгыз яшәү бик авыр. Сине дә югалтасым килми.

Раилнең әрнү, сагыш тулы күзләре җавап көтеп хатынга төбәлде.

Илдания бер тын дәшми торды да, аннары кинәт кенә үрелеп Раилнен янагыннан үбеп алды.

—Мин хәзер. Син китмә. Көт мине, Раил! Мин синең белән.

Ул ашыга-ашыга өенә таба атлады. Берни аңламаган Раил анын сүзләренә ышанырга да ышамаска да белми, көтелмәгән һәм инде өметләнмәгән бу шатлыклы хәбәрдән хәтта бераз башы әйләнеп, аптырап басып калды.



## Нур Әхмәдиев

# БЕЗНЕҢ ДӨНЬЯ

### Татар яшәр

Ерактагы кояш җылы диеп,
Шул кояшка табан омтылдык.
Карурманнар кичтек кара төндә,
Дәрья чоңгылында йотылдык.

Каршы җилләр исте — туктамадык,
Бирешмәдек бозлы яңгырга.
Язмыш һаман селкеп торгангадыр,
Сынгалады кайчак кабырга.

Җил уйнады такыр кесәләрдә,
Сатылмадык ләкин алтынга.
Татар башың белән ничек мескен
Күренәсең дөнья халкына!

Мең гарасат кичеп тарихында,
Зилзиләдән татар котылган.
Белсен дөнья: татар мескен түгел,
Алып батыр — Татар токымыннан.

Әле тагын күпме сыналырбыз,
Сыналырбыз, ләкин сынмабыз.
Өметләрнең һич тә сүнәсе юк,
Ирек өчен изге юлда без.

Татар бетә, татар бетә диеп
Йөргәннәрдән Тарих көләчәк.
Татар бетмәс, татар чәчәк атар,
Татар яшәр, ишет, Киләчәк!

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, прозаик; дистәләгән китап, шул исәптән дүрт томлык "Сайланма әсәрләр" авторы. Әлмәттә яши.*

## "Идегәй"нең дәвамы

Кыз алган да кыз биргән,
Кунакка да еш йөргән
Алтын Урда алысмы?
Күп сыйланып кикергән,
Симезлектән сикергән;
Еллар буе аш җыйган
Табагына төкергән —
Кем икәне танышмы?

Монгол диеп тормаган,
Татар диеп тормаган, —
Мактаган да хурлаган;
Җай чыкканда Урдадан
Хәер-шәфкать сораган,
Урлый алса урлаган —
Кем икәне танышмы?

Дуслык сүзе — телендә,
Һәрчак ызгыш илендә.
Аның белән дус булсаң,
Балтаң булсын билеңдә —
Кем икәне танышмы?

Куенында җылыткан
Агулы елан үзен
Чагачагын оныткан
Гамьсез дәүләт кем булыр?
Урда артын ялаган,
Аркасына сиздерми
Азак пычак кадаган —
Яман эткә тиң булыр, —
Кем икәне танышмы?

Күрми агын, әйбәтен,
Сату дөнья гайбәтен
Кай халыкка хас икән?
Иле-җире бай көйгә
Шушы халык ач икән.
Чәйнәгәнен йоталмый —
Тамагында таш икән.
Иле кан һәм яшь икән,
Илгә җәллад баш икән. —
Кем икәне танышмы?

Иленең төп шөгыле —
Ертыкларын ямаудыр,
Куркытудыр, янаудыр;
Көнбатыштан әләккән
Сөякләрне ялаудыр.—
Кем икәне танышмы?

Җанга тигән гамәле —
Катлы-катлы ясактыр;
Туган-үскән илендә
Үз кешесе качактыр;

Дөнья тулы эшсезе,
Халыкны кем ашатыр? —
Кем икәне танышмы?

Бу нинди соң тамаша:
Уйлап уйлар адаша;
Ил башында торганнар
Урлаша да алдаша,
Аңлашалар кан аша...—
Кем икәне танышмы?

## Ак бураннар

Ак дөньяның ап-ак бураннары
Ак пәрдәләр аша елмая.
Таулар һаман, һаман урынында,
Тауларыма илтер юл кайда?

Ак дөньяның ап-ак бураннары
Ап-ак юлларымны себерә.
Ап-ак бураннарда җитәкләшеп
Ник йөрмибез хәзер без бергә?

Ак дөньяның ап-ак буранында
Адашмаган берәр кем бармы?
Ак бураннар — сукмакларны түгел,
Күмә безнең узган елларны.

Ак дөньяның ап-ак бураннары
Ап-ак урманнарга сарыла.
Кешеләр дә буран булыр иде,
Түзә күңелләре сабырга...

***

*Мөхәммәт Мәһдиевкә*

Торналарның төшкән җире кайда? —
Син күргәнсең аны, күргәнсең.
Күргәнсең дә, торна тавышларын
Моңга төреп, безгә биргәнсең.

Шуңадырмы күңел ерак калган
Торна тавышларын сагына.
Гөберчәктә торна кая төшкән?
Бездә — төште Торна тавына.

Без ишетеп үстек торна моңын,
Онытылмас гамьле балачак:
Шул чакларның торна тавышлары
Сагындырып сеңеп калачак.

Ә хәзер бит кырга төшми торна,
Кайдан күрсен аны балалар...
Күренмичә генә кайталар да,
Күзләр җитсә, китеп баралар.

Кайда яши, кайда оя кора,
Беләсеңдер, бәлки, Гөберчәк?
Тапмый калмас идек кайдалыгын,
Балачакка табан йөгерсәк...

Балачак шул узган инде, узган,
Калган бары, калган сагышы.
Дөньяны да әллә карга басты? —
Бөтен җирдә алар тавышы...

## Картаймыйбыз

Олыгая барабыз шул,
Сүрәнләнә таңнар.
Сер бирәсе килми ләкин, —
Яшьтәшләрем аңлар.

Мең ямаулы йөрәктә дә
Ята Сөю көйрәп.
Әй йөрәгем, һәркемне дә
Сөяргә син өйрәт!

Сөя белү, аны саклау —
Батырлыкка тиңдер, —
Кызганма, Раббым, җаннарга
Син Мәхәббәт иңдер.

Калмасын җирдә бәхетсез,
Сызланмасын бәгырь.
Ятим җаннар җир йөзендә
Чиктән ашты хәзер.

Ятимнәргә һичкайчан да
Җиткәне юк җылы.
Җирдәшләремнең һәммәсе
Булсын Сөю колы!

Шул чагында мин үзем дә
Тыныч була алам.
Ягыгыз Сөю учагын —
Йөрәгемне салам!

Янсыннар шушы ялкында
Яшькә карамыйча.
Үкенеч бит: үлеп китсәң
Шуны аңламыйча!

...Җетелеген җуя төсләр,
Колак катылана.
Белмим ләкин, ни сәбәптер,
Дөнья матурлана.

Канатына алса Сөю,
Бирешми ул йөрәк:
Алтмыш яшькә җитеп килям,
Ә картлыкка — ерак...

## Безнең дөнья

Көлә-көлә гөнаһ кылабыз да,
Әмер, дибез аны күкләрдән.
Ә чынлыкта язмыш такталары
Язылып та, бәлки, бетмәгән.

Хак тәгалә безне гел сыныйдыр,
Артык катлаулы шул бу тормыш.
Савап урынына каргыш ява,
Ә син рәхмәт көтеп утырмыш.

Без өйрәнгән: үз-үзеңне, ятны
Алдый-алдый гомер кичәргә.
Ялган тостлар әйтеп кул чабарга,
Аягүрә басып... эчәргә.

Без алдыйбыз һәм дә алданабыз,
Дөнья тора тоташ алдаудан.
Хыял белән катгый чынбарлыкны
Уйдырмалар аша ялгаудан.

Бик яшисе килә алданмыйча,
Алданмас та идек — эш куша.
Алдамасаң һәм дә алданмасаң,
Әллә ничек шунда: эч поша...

**Вахит Имамов**

# КАЗАН ДАСТАНЫ

ТАРИХИ РОМАН

## 52

Кәрван Кабан күлләре янына житәрәк, ике-өч фәрсах кына ара калгач, Болгар каласыннан чапкын килеп төште.

—Тимер-Мөэмин пайтәхетне калдырып, Чулман буйлап килә. Аның кул астында төмәньярым гаскәр. Сине мәмләкәтнең үзәгенә аяк бастырмыйм, ди. Иделнең унъяк ярында ук турап ташламакчы...

Ибраһимның алдан уйлап куйган нияте булган икән, шундук әмер бирде.

—Сал-Сал сәрдәр! Булган бөтен көчне жый да артына ут капкан шикелле алга сыптыр! Өч Кабан күле янында кыядай Елантау бар. Шуны Тимер-Мөэминнән алда эләктерергә кирәк.

Сал-Сал Айзирәк утырган бөркәвечле арба ягына күз ташлап, кыяркыймас кына авыз ачты.

—Ә карт-корыны, бала-чагаларны, э-э... мал-туарны нишләтәбез соң? Аларны дала уртасында каравылсыз көе ташлау ару түгел...

—Нинди карт-коры ди? Нинди мал-туар кайгысы ул тагын?—дип, үзүзен белештермичә, яшелле-зәңгәрле тавышлар белән кычкырып жибәрде әмир.—Өскә Тимер-Мөэмин ябырылып килә. Аңлыйсыңмы, унбиш меңлек гаскәр! Әгәр Елантауны үз кулыбызга төшереп өлгермәсәк, Тимер-Мөэмин безне йон төргәге урынына тетеп ата. Ә без оттырсак, ул карт-корылар, ул мал кемгә кала?

Ибраһим иң беренче булып ияргә сикереп менде. Кәрван шул мизгелдә үк таяк тыгып болгатылган дәү кырмыска оясына охшап калды. Берничә минуттан соң инде барча жайдак жан-фәрман Кабан күлләре ягына оча иде.

Иң әүвәл, Елантау өстенә менеп тезелделәр. Сал-Сал сәрдәр шулчагында гына тирә-юньне күзләп, бәяләп чыкты. Ибраһим дөрес сайлаган, урын искитмәле отышлы һәм унайлы икән. Елантау—кыр уртасына бастырып куйган печән кибәне шикелле биек, озынча, текә. Бер ягыннан Идел, икенче яклап исеме юк елга, өченче яктан эреле-ваклы күлләр муенсасы каплап

*Ахыры. Башы 8 санда.*

тора. Тау, кыйблага табынган диндар шикелле, көньяк тарафына гына йөзен ачып, туры төбәп баскан. Ләкин әле ул яклап та Елантау сөяркәсен күкрәк-итәкләрен ачып каршылаучы фахишә хатын кебек көтеп тормый. Аста шактый текә булып сузылган тау итәге, аның алдында гына тигез, зур мәйдан бар. Тик аны да бер очтан сазлык китереп кыскан, икенче очта гаҗәеп зур, тирән чокыр ята.

Ибраһим өчен күптән таныш, якын урын булгач, ул инде йөзләрне-меңнәрне үзе тау өстенә урнаштырып йөри. Әнә, җор-канәгать дәшкән әмер авазлары яңгырап ишетелә.

—Әй, меңбаш Бәхтегәрәй! Елантауны ул Мунчала күлләр ягыннан саклауның кирәге юк. Алапа хакына ялланган аймык вә угызлар ул черек күлләргә Тимер-Мөэмин арттан камчы илә куса да барып кермәячәк.

—Меңбаш Сәүбан! Тимер-Мөэмин колларының әнә теге казан эченнән күтәрелеп яисә сазлык аша килеп һөҗүм ясавыннан сакланырга кирәк!..

Тавышлар тынган кебек булган бер арада Сал-Сал үзе Ибраһим янына барып житте.

—Сигез меңгә якын җайдакны бердәнбер тау түбәсенә туплап яту бик отышлы түгел. Өстәвенә, кәрванда калган сугымчыларның, малчы-торгакларның янә бирегә килеп җитүе бар. Тимер-Мөэмин олы чиру белән һөҗүм итә алырдай җир бераү генә. Әнә, теге казандай чокыр белән сазлык арасында яткан сукмак. Ул сукмакка бүген үк яшерен тозак корып калдырырга мөмкин.

Ибраһимның күз алмаларында утлы очкын биеп-биеп алды.

—Ничек итеп? Нинди яшерен тозак?

—Ике-өч мең җайдакны аерып алып, әнә теге, Идел буендагы таллыклар, өрәңгеләр арасына яшереп куеп була,—дип Сал-Сал бик җинел генә бәян итә башлаган иде.

Әмма Ибраһим карашындагы очкыннарның шайтан уты сыман шашына башлавын, уртларының яман кысылуын күргәч телен тешләгәндәй туктап калды. Аның каравы, Ибраһим үзе усал ысылдады.

—Миндә әле Тимер-Мөэминдәге хәтле ярты гаскәр дә юк. Ә син инде аны да Мөэминнең авызына калҗа-калҗа итеп бүлгәләп тыкмакчымы?

Сал-Сал соңгы шартка барып үз фикерен якларга мәҗбүр булды.

—Ярар соң, алайса, ярар! Синең кул астында йөргән җайдакларны алмыйм! Әнә, үзем белән алып килгән бер мең яугирем бар, шуны бир дә чыгар. Ә нинди тозак корырбыз, ул үзен акләрмы-юкмы, яуда күрсәтербез.

Ибраһимның әле һаман ныклы бер карарга килә алмый интегүен күргәч, янә дәште.

—Сайлаган корбанынны, кирәк чакта, ике яклап кысып та аулыйлар ул. Бераү аягыннан килеп тешли, корбан абынып егылса яисә кирегә борылса, икенчесе күкрәгенә, йә сыртына кадый.

—Мин бит ауга чыккан сунарчы түгел. Мин тәхет өчен яуга чыккан әмир. Алда бугазга-бугаз килеп җан кыешу көтә. Миңа һәрбер тешнең кадерле булуы бар.

Ибраһим шул рәвешчә тартышты-тартышты да ахырда барыбер кул изәде.

—Ярар, бер мең җайдагынны ал да далага чык. Арткы яктан һөҗүм итеп, бәлки, чыннан да, аны тоткарларсың.

Сал-Сал үзенең карлукъларь, мангытлары белән кичекмәстән Идел буендагы таллыкка күченде, шул кичтә үк күнекмәләр ясый башладылар. Дала ирләренең бер өлеше тал чыбыгыннан каз оясы йә читәннәр үрде, икенчесе яр астындагы балчыкта казынып көн үткәрде. Болгарныкылар белән бәҗәнәкләр Елантау өстенә баскан килеш тә, таллык янына килеп-килеп тә кат-кат күзәттеләр, тик бер сергә дә төшенә алмадылар...

Тимер-Мөэмин чирүе Кабан күлләре янында дүртенче көнне, инде төш вакыты үтеп киткәннән соң гына пәйда булды. Әлеге гаскәрнең килеш-килбәтен, кыйланышын күзәтеп яту үзе үк бер әкәмәт, олы сабак иде.

Хан чатырын биш үрәчә кушып ясагандай галәмәт озын арба өстенә көйләп утырткаканнар. Аның артында тагын зур-зур тирмәләр корылган үнлап арба, бөркәвечләр япкан утыз-кырыклап олау. Кайбер тирмәләрдән чыр-чу килгән кыз-кыркын тавышлары, кайсыларыннан чән яисә кубыз авазлары янгырап ишетелә. Ике якта озын дилбегә булып тезелгән җайдаклар шул ваемсыз аһәң тәэсирендәияр өстендә килеш оеганнар. Хан кәрваны үзенең яу кәрваны икәнлеген бөтенләй оныткан, ахры. Ул йә яшь килен алып кайтучы, йә яна кодалар төшерүче моң-хәсрәтсез олауны хәтерләтә. Сан ягыннан күплек сукырайткканмы соң боларны, әллә җиргә хуҗа булып басып йөрү тойгысы шулай исерткәнме?—берни аңламассың.

Казандай зур чокыр белән сазлык арасында яткан мәйдан уртасына килеп керүгә үк олаулар, бер-берсенең өстенә өелешеп, капылт тыгылдылар. Арттан килгән ташкын басымына түзмичә, бер яклап сузылган дилбегә сазлык эченә барып керде, икенчесе тирән чокыр төбенә шуышып төште. Ике-өч минут эчендә Елантау итәген туфан сыман тавыш күмеп китте.

—Ханның иравыл алайлары юкмыни ул? Безне нинди тәмугъ сазлыгына кертеп батырдылар?

—Җаек хәтле Җаек аръягыннан шушы казан эчендә сытылып үләргә дип килдек микәнни соң?!.

Тимер-Мөэминнең курсыбай җайдаклары хан кәрванын ике яклап кысрыклый-кысрыклый, дөмбәсли-дөмбәсли ипкә-сапка кертә генә башлаганнар иде, Идел буендагы таллыклар эченнән шайтан туен хәтерләткән ташкын килеп чыкты. Нинди җанварлар өстенә менеп алганнар да, кайсы төрдәге корал белән коралланган болар? Дию пәрие, гыйфрит шикелле җир астыннан калыккан нинди коточкыч дәһшәтле көч бу?

Тип-тигез диварны хәтерләткән тере ташкын юлда очраган һәрнәрсәне сытып үтәрдәй булып болгарлар өстенә килә. Дивар талдан үреп ясалган, арба зурлыгындагы калкан-читәннәрдән хасил. Ул калканнар артыннан җайдаклар үзләре дә юньләп күренмиләр, өстәвенә, чаптар-аргамаклар да тезләренә тикле капланганнар. Хан сакчылары сафындагы берничә мәргәннең сәрпи уклар очырып каравы да файда китермәде, алар шул читәннәрдәге талчыбыклар арасына кереп кысылды да калды.

Ә Сал-Сал җайдаклары берзаманны капылт туктады да тоташ дивар корды. Икенче мизгелдә инде читәннәр артыннан аймыклар, угызлар өстенә ук янгыры очты. Бер көтү йомран-әрлән сыман сызгырып, селәүсен кебек чинап килгән укларны күрүгә үк хан гаскәрендәге йөзәрләгән җайдак ияреннән җиргә сикереп төште, хуҗасыз калган аргамаклар дулый-дулый әле дала якка, әле кеше өстенә чапты. Сазлык арасына исән-имин килеп төшкән укларның очында балчыктан ясалган тишек башаклар күреп алгач кына беркадәр тәшенделәр, ләкин саксыз кычкырган яналыклары хан җайдакларына хәвеф кенә өстәгәндәй булды.

—Сызгыра торган уклар! Безнең өнне алу өчен ясалган махсус уклар!

Дала яугирләре Тимер-Мөэмин гаскәре өстенә ук янгыры яудырып бетерүгә җиде-сигез кисәккә бүленделәр. Аралыкларда кулларына сагызланып беткән тал казоялары белән ут кисәве тоткан өр-яңа җайдаклар төркеме пәйда булды. Бераздан соң инде хан гаскәренә таба дала яктан тоташ ут көлтәсеннән хасил тәгәрмәчләр чылбыры сызгырып оча башлады. Бу дәһшәттән өннәре алынган аймык, угыз аргамаклары җан ачысы белән кешнәп бер-берсенең өстенә сикерделәр. Җайдаклар арасында да кылыч белән тураш, суеш купты.

Ул арада Ибраһим әмир дә Елантауга тезелгән ике мең бәҗәнәк яугирен Тимер-Мөэмин гаскәре өстенә ташлаган иде инде. Текә тау башыннан чүл бүреседәй улап, карчыгадай канат җәеп төшкән өр-яңа ташкынны күргәч, хан ялчылары чокыр-сазлыкларны аралап тормыйча як-якка сибелделәр. Ә берничә минуттан соң курсыбай йөзбашлары кичәге ханнарын Ибраһим әмирнең аргамак аяклары астына китереп атты.

—Ул тәхеткә әтисен үтереп, хыянәт белән менде. Шул нисбәттән ул беркайчан да безнең өчен хак хан, лаеклы хан булып саналмады,—дип Тимер-Мөэминнең сыртына аягын куйган килеш сөйләп китте араларыннан берсе—йөзбаш Атлаш.

Ибраһим аны әле Янкалага килгән чагында ук ятлап калган иде, хәзер инде, әлбәттә, бүлдермәде. Йөзбаш дәвам итте.

—Безнең өчен, бөтен Болгар өчен бер генә инсан—хак хан. Ул син, Ибраһим... хан! Без сина гомер буе бил бөгәргә әзер!

Ибраһим янә йөзбашның кыяфәтенә өстән генә, бөркет сыман итеп күз ташлады. "Мине хан итеп күтәрү синең генә кодрәтеңнән килми". Ләкин Ибраһимның бәхет белән мөлдерәмә тулы күңеле бу минутта кытаклап тора иде, ул йөзбашның ялагайлануына каршы елмаймый булдыра алмады. Атлаш исә тагын батырланды.

—Ә моны хәзер нишләтәбез инде, Ибраһим... хан?—диде ул корбанының сыртына аягы белән төртеп.

Тузанга, күз яшенә баткан Тимер-Мөэминнең йөзе җирдән күтәрелде. Тик бер үтенечә генә сыкрап ишетелде.

—Бу көе калдырма, үтер мине, эн-не-к-кәш?

Ибраһим аннан каһкаһә белән кычкырып көлде.

—Чокырга егылып төшкәч, бер бүре баласы да кәҗә тәкәсенә "жизнәкәй" дип назлап эндәшкән, ди. Син дә минем энең икәнлегемне җиде ел үткәчтен искә төшерденме?

Аннары әтисенең: "дөньяда таянырга әле дә син бар, улым",—дигән сүзләре, Ука елгасы буенда үткән еллар аҗаган шикелле уйнап Ибраһимның хәтереннән үтте. Йөрәк әрнүләренә түзмичә, ул тешләрен, уртларын шыгырдатып, нәфрәт белән дәште.

—Юк, сине мин хөкем итмим. Әле Болгарга чаклы исән-сау көенчә алып кайтачакбыз. Анда син зинданга ташлаттырган вәзир, меңбашлар бар. Анда син кулларын чабып өздергән тимерчеләр, көмешчеләр исән. Ул гарипләрнең мескен хатыннары, балалары да, бәлки, ачтан кырылып, үлеп бетмәгәндер. Менә шуларның күзләренә кайтып кара әле. Шул мескеннәр сине хөкем итсен.

Җан ачысы белән Атлаш өстәп куйды.

—Минем әткәй белән ике абыем кулларына кашык та тота алмыйча, кеше күзләренә текәлеп, мөлдерәп яши. Канга—кан! Тимер-Мөэминне дә шулар көненә калдырырга кирәк.

—Шулай итсән, бәлки, дөресрәктер,—дип ваемсыз гына җавап кайтарды да Ибраһим аргамагының касыгына типте. Ярымборылып Атлашка кычкырган сүзләре яндагы ботак-яфракларга сарылып-йотылып калды.

—Мәгәр кайткач, Болгарга әйләнеп кайткач!

Ибраһим инде Елантау итәгенең яртысынча менеп житкән иде, Атлаш аның сүзләрен тәгәл ишетмәде. Аның һавада яшен кебек ялтырап алган кылычы икенче минутта Тимер-Мөэминнең ике кулын да терсәктән тиң өзеп аткан иде.

## 53

Елантау өстенә менеп житкәч тә, Сал-Сал сәрдәрне, якыннарын жыеп, Ибраһим сабан тургае сыман очына-очына әйтте.

—Мин бу урынга әле Янкалага чыгып киткәнче үк үлеп гашыйк идем. Бүген ул минем өчен инде иң истәлекле, иң кадерле жиргә әверелде. Без монда бүген жиңү яуладык, Болгар тәхетенең иминлеген, бәхетен саклап калдык. Мондый урынны мәңгеләштерми булмый. Кичекмәстән яна кирмән корып куярга кирәк монда, яна кирмән кирәк! Кем белә, бәлки, әле пайтәхет үзе дә тора-бара монда күчеп килер...

Ибраһим яраннары табын корып күңел ача, бөек жиңүне билгели башладылар. Янә сөеклесе белән кушылудан учак кебек кабынган, дәртләнгән Айзирәк Сал-Салны житәкләп, сикергәли-сикергәли, Елантау итәгеннән аска алып төште. Монда, исемсез елгага таба сузылган киң ерымнар эчендә, әллә ничә мәгарә бар икән. Мәгарәләргә йөзәрләгән жайдак белән кереп югалырга була; аларның ахыры елан койрыгыдай боргаланып Елантауга кереп югала.

Шул мәгарәләрнең берсендә сабый күз яшедәй чиста чишмә челтерәп ята. Чишмә ерактӑн, Елантау астыннан ук тибеп чыккан бугай, мәгарә авызына килеп житкән урында ул гөжелдәп, гөрләп ага. Чишмәнең нәни генә күл хасил итеп жыелган урынында матур жиз улаклар, кечкенә тирмәләр дә ясап куйганнар. Димәк, Елантау үзе дә, әлеге чишмә дә болгарлылар өчен чит-ят түгел, бирегә кемнәрдер бик еш килеп йөри икән.

—Нургали чишмәсе бу,—дип таныштырды Айзирәк, аның кәүсәр суын учларына алып.—Нургали дигән бәхетсез яугир хөрмәтенә шулай атаганнар. Күрше-тирәдә көн күрүче чирмеш авыллары да, узгынчы болгарлар да бу чишмәне һаман изге саный.

Ашъяулык чаклы гына нәни күл янына тезләнеп Сал-Сал сорап куйды.

—Нургали баһадир булганмы соң? Вәзир-мазармы, берәр хан туганымы?

Моңсу, талгын тавыш белән Айзирәк тезеп китте.

—Юк, аны кеп-кечкенә болгар авылыннан чыккан гап-гадәти егет булган, диләр. Туган, үскән, егет булып житкән. Жаек елгасы ягыннан дошман бәреп кергәч, аны Болгар мәмләкәтенең данын якларга дип яуга чакырганнар. Бер орыш барышында дошман пәһлеваны моның баш түбәсенә гөрзи белән китереп орган да, Нургали, аңын югалтып, менә шушы исеме дә юк елга ярына ауган. Иптәшләре, яудашлары аны инде вафат булган шәһиткә санаганнар, шушы елга ярында япа-ялгыз көе ташлап калдырганнар. Егет аңына килсә, аның ике күзе дә сукырайган булган. Ул хәзер инде үзен беркемгә дә кирәксезгә санап, шушы яр буенда япа-ялгыз көе яшәп калган...

— Бәрәкалла, бәрәч! Әллә аның исәнлеген тикшерүче кеше дә булмаганмы? Теге егетләр нишләп алны-артны карап тормыйча да качкан?— дип ярсып купты Сал-Сал.

Айзирәк аңа игътибар да биреп маташмады.

—...Ә Нургалинең авылда Сөмбел атлы бик тә сылу сөйгән яры торып калган икән. Юлдашлары егетнең вафаты хакында кайтып әйткәч, Сөмбел ачыргаланып, өзелеп елаган, ди. Башка яугирләр "үлгән артыннан үлеп булмый, болай бетеренмә", дип үгетләп караганнар, чынлап гашыйк булып кызның кулын да сораганнар. Беркемне дә якын жибәрмәгән Сөмбел, барча яучыларны кире куган. Аннары менә шушы елганың чишмә башын эзләп тапкан да, якындагы тугайлыкта үскән аллы-гөлле чәчәкләрдән такыялар үреп, аларны елый-елый агымсу буенча озатып кала икән. "Такыялар гади

генә түгел. Мин аларга йөрәгемне, сөюемне куштым. Бер дә туктамыйча, сөйгәнемне эзләп тапканчы агыгыз, такыялар. Егетем сезне танымыйча калмас",—дип бәгырен теләтелә озаткан, ди Сөмбел аларны. Такыяларның берсе нәкъ менә шушы урынга, Нургали яраланып ауган яр читенә агып килеп җиткән. Көтмәгәндә такыяга җан ингән, ди. "Сөйгәнеңнән сәлам алып килдек, ә син безне таныйсыңмы, егет?"—дип, кеше кебек назлап эндәшкән ул. Дөм-сукыр булса да, Нургали яр буена йөгереп төшеп җиткән, такыяны кулларына алган. Ул такыяны үбәргә дип иреннәрен тидерүгә булган, ике күзе дә шундук ачылган, ди. Мондый бәхет белән канатланган егет аргамагына сикереп атланган да, сөйгәнен күрергә ашкынып, авылына очкан...

Сал-Сал, учларын бер-берсенә ышкып, очынгандай итте. Авызы ерык иде.

—Һе! Болай булгач, кавышканнар инде ул бәхетле ярлар.

Айзирәк егетнең хыялларын бик тиз җимереп атты.

—Ю-у-ук шу-ул, батыр, кавыша алмаганнар.

Иреннәрен әрем капкан төсле бөрештергән Сал-Салның күзләрендә ялкын сүнгәч кенә Айзирәк дәвам итте.

—...Сөмбел аны бик-би-и-ик озак итеп, атналар вә айлар буе көткән. Ә аннары инде кыздагы түземлек тә язгы кар шикелле барыбер эреп беткән. Көннәрдән-беркөнне ул ирләр киеменә киенеп алган да, чаптар атка атланып сөйгән ярын эзләргә чыгып киткән. Язмыш шаяртуы, димичә, тагын ни әйтәсең? Нәкъ менә шушы урында үзенең такыялары җыелып торганны күреп тукталган ул. Сукыр Нургали яшеренеп яткан шушы мәгарәне дә эзләп тапкан. Ләкин көтмәгәндә бер дошман мәргәне килеп чыккан да, ир-ат кешегә санап, бичара кызны ук очына алган. Мондый бәхетсезлек илә мондый гаделсезлекне күреп, өстәвенә әле гөнаһ та күтәрә алмыйча, Елантауның хуҗасы ярсыган, ди. Кинәт кенә бөтен тау өстендә котчыкмалы гарасат, туфан купкан. Ә менә шушы мәгарә эчендә, Сөмбел егылган төштә җир-ананың күз яшьләре булып чишмә бәреп чыккан...

Айзирәк үзе дә хискә чумган иде. Күз яшьләрен Сал-Салга күрсәтмәс өчен ул яңагын бармак очлары белән сөртеп-сыйпап алды.

—...Нургали Сөмбелнең гәүдәсен шушында эзләп тапкан. Каядыр мәгарә эченә алып кереп, сөеклесен яшереп җирләгән, ди. Кабер янында Сөмбел хөрмәтенә Елантау өстенә менеп яңа кирмән, яңа кала төзиячәге турында нәзер әйткән егет. Тик Нургалинең гыйсъяндай тәкәббер сүзләре Елантау хуҗасына бер дә ошамаган. Ул егетне шул минутта ук янә сукырайткан. Ахырда бичара егет шушы урынга әйләнеп кайтырга мәҗбүр булган. Әнә, теге улак куелган урынга башын бәрә-бәрә өзгәләнгән. Сөеклесенең җырларын, күз яшьләрен, гыйшкын хәтерләткән бу чишмәне соңыннан да ташлап китмәгән ул. Менә шушы тирмә эчендә яшәгән, шунда җан биргән, ди. Чишмәне хәзер "Сөмбел күз яшьләре" дип телгә алучылар сирәгәйде. Аны күбесенчә йә "Елантау җаны", йә "Нургали чишмәсе" дип искә төшерәләр...

Айзирәк сөйләүдән туктагач, Сал-Сал батыр басынкы, боек тавыш белән йомгак ясап куйды.

—Синең хикәятләреннең һәрчак ахырлары сәер. Йә ике яр да берьюлы һәлак була, йә бер яры ялгыз торып кала. Табышып кавышкан бәхетле ярлар турында син бер хикәят тә сөйләмәдең әле... Нигә шулай? Әллә безгә дә аерылу юрыйсыңмы?

—Авызыңнан җил алсын!—дип ярсып кычкырды да Айзирәк Сал-Салның муенына килеп сарылды. Нәни йодрыклары белән батырның күкрәген дөп-дөп төя-төя тагын кабатлады.

—Юк, юк! Без аерылмыйбыз, жаным, аерылмыйбыз! Әткәй Болгар каласына гына кайтып житсен, тәхеткә менсен. Аннары, аннары без синен белән мәнге-мәнге бергә булачакбыз...

Болгарга кайтып керүгә Айзирәкнең әнисе яман сырхаулап түшәк өстенә ауды. Яңа яз борынлаган чакта аны жирләделәр. Аннан соң да атналар, айлар узды, бәхетле йомгак очы һаман табылмады.

## 54

—Уока елгасы ягыннан дошман якынлаша!—дигән уттай хәбәр Болгарга язгы карлар тәмам эреп беткәч кенә килеп житте. Янкала—урыс кенәзлекләренең борын төбенә китереп торгызылган кирмән, дошман өчен анын бөергә утырган таш шикелле тәэсир итүе болгарларга ят сер түгел иде. Беренче хәвефне нәкъ шул кала тарафыннан көтеп яшәделәр. Кайгылы, шомлы хәбәрне атна-ун көннән соң ак күбеккә баткан чапкын алып кайтты.

—Янкала урыслар кулында. Һәрбер каралтыны тишек комганнарга хәтле талап бетерделәр.

Эскәк белән жыйган төсле төкләп-бөртекләп тупланган башка төр хәбәрләрне Ибраһим хан алдында вәзир булып алган Насыйр бәян итте.

—Дошман чирүендә егерме биш мең яугир. Яу сәфәрен Кияү каласының олугбәге Владимир үзе житәкләгән. Ул элегрәк безнең өскә килгән Святославның уйнаштан туган бер малае икән. Кияү каласындагы боярлардан шикләнгәнгә күрә үзенә сәрдәр итеп әнисенең энекәше Добрыняны алган. Әтисе белән әнисеннән йоккан чир калгандыр инде, эссесен басар өчен Владимир үзе белән бергә өч йөз жариясен ияртеп йөри икән.

—Һе, уйнашлыкта әтисен уздырган бу,—дип әүвәл Ибраһим да каһкаһәләп көлде, әмма икенче минутта ук кискен житдиләнде.—Хәер, уйнашлыкта гына түгел икән. Святослав безгә унбиш меңлек чиру белән килеп кергән иде, монысы егерме биш менне жыйган. Димәк, тегеләрнең өнен тыгар өчен күбрәк калаларны кулга төшерергә, күбрәк байлык таларга өметләнә. Теге чакта әтисенең арт сабагын укытып озата белмәдек, шуна күрә комсыз, азгын болар.

Ибраһим тешләре сызлаган шикелле йөзен сытып, ярсый-ярсый кабынып ук китте.

—Әй-яй, ачыгавызлар без, әх, үшәннәр! Моннан өч элек үк Елантау өстенә яна кирмән төзеп куярга нияг иткән идек. Бүгенгәчә кыл да селкеткән юк. Авызга су тулмыйча торып, йөзәргә дә өйрәнә белмибез бит! Нигә дошман килеп артка типкәнче болай йоклап яттык? Әгәр Елантау өстендә хәзер ныклы кирмән, яңа кала балкып утырса, дошман Болгар иленең йөрәгенә таба аяк та атлый алмас иде бит, атлый алмас иде! Әй, үшән без!

Шул рәвешчә берникадәр бушангандай булгач, вакытны озакка сузмыйнитмичә, Ибраһим тәүге әмерләрен дә әйтеп ирештерде.

—Барча олысларга, калаларга иртә таңнан мөнадиләр вә чапкыннар китсен. Калаларның һәркайсыннан өчәр меңлек чиру. Һәрбер олыстагы авыллардан берәр меңлек нөгәр тупласыннар. Күнелемә хуш килгән урын сиңа яхшы мәгълүм. Алайларның һәммәсен дә Елантау өстенә илтеп тупласыннар.

Тәхет залыннан вәзир Насыйр чыгып югалуга, Ибраһим хан шыгавыллар башлыгы Гаянны чакырып алды.

—Миңа курсыбайдагы йөзбашы Атлашны табып китер. Кара аны, кеше шәйләмәсен.

Карангы зал ишегендә кап-кара башлыкка төренгән Атлаш пәйда булгач, теш арасыннан сытып сүз ыргытты.

—Тимер-Мөэминнең кулларын өзгән өчен мин сине инде әллә кайчан йә дар агачына астыра, йә кисәкләргә чаптырып ташлый ала идем. Син ханнар каны бәһасе торырдай алтын тавы түгел. Әмма теге чакта кисәкләргә өзгәләтеп ташламаганмын икән, димәк, кирәк чакта сиңа таянырдай исәпләрем булган. Менә, сиңа да гөнаһларыңны юу өчен уңай форсат чыкты. Безнең өскә олы дошман килә. Иң ышанычлы биш-алты гына иптәш сайлап ал да, шуңа каршы юнәл. Владимир кенәзнең ыстанына үтеп керми калма. Кенәз нинди адым кыла, ниләр ният итә—энәсеннән җебенә чаклы миңа җиткерерсең...

Атлаш төркеме таң аткач та юлга чыккан иде, унбиш-егерме көннән соң гына "Шәһитләр убасы" дигән йомрытау янында дошман гаскәренә килеп кушылдылар. Бу тирәдә яр читендәге бакакайлар кебек сирәк-мирәк кенә сибелгәләп ар йә чирмеш авыллары яшәп ята иде. Шул авылларның берсеннән чәчәкле-чуклы киемнәргә төренеп, билләренә дөмбер һәм кыңгырау асып чыккан җиде-сигез ир-атка юньле-рәтле игътибар биреп торучы да табылмады. Арадан берсен—бил каешына көмеш аел эләктергән Атлашны гына ике сакчы ыстан үзәгендәге зур чатырга таба җилтерәтеп-йолкып алып китте.

—Нинди кыргый исемнәр бу сезнең якта? Каян килгән "Шәһитләр убасы" бу?—дип өстән янгыраган ят тавышны ишеткәч тоткын юлчы сынып төшкән иде, тылмач тәрҗемәсеннән соң гына аңа җан кергәндәй булды.

Күтәрелеп караса, алмачуар ат өстендә иңнәренә җете-кызыл төстәге озын җилән япкан мәһабәт ир утыра. Олугбәк Владимир дигәннәре шушы була икән. Әче бал яисә хәмер капкан бугай, авызы ерык, аскы ирене иягенә чаклы салынып төшкән. Атлаш тилемсә кеше сыман башын чайкый-чайкый шундук тезеп китте.

—Каян килгән диеп, гомер буе шушында утыра инде бу йомрытау. Ни өчен исеме "Шәһитләр убасы"мы? Чөнки монда яу кырында башын салган шәһитләрне, ягъни илен, халкын яклап вафат булганнарны җыеп җирләгәннәр. Исеме дә шуннан торып калган. Ә "уба" дигәне сезнеңчә "курган" була.

Атлаш аңлатмасын тынлап бетерүгә үк Владимир кенәз кулларын үз астындагы алмачуар атны да күккә алып менеп китәрдәй булып болгый-болгый тузынды, котырынды.

—Япа-ялан дала уртасында нинди ил булсын ди? Каян килгән дәүләт, нинди дәүләт? Барысы да уйдырма, һәммәсе дә ялган! Бу— әле төрән йөзе дә күрмәгән, кызлыгы да алынмаган дала, хуҗасыз җир! Монда бернинди дә шәһитләр була алмый. Әлеге тау астына сихерчеләрне, кыргыйларны җыеп җирләгәннәр. Аның изге курган булып саналырга хокукы юк. Хәзер үк, күз ачып йомганчы җимереп бетерегез!

Ялгыз бәрән тапкан ач бүреләр сыман барысы да йомрытауга барып ябырылды. Кич җиткәндә аның урынында яшел кәс калдыклары, кызыл балчык өемнәре генә сибелеп ята иде...

Владимир кенәздәге чит-ят гадәтләрне, аның җансыз потларга табынуын да күргәч, Атлаш торган саен ныграк сәерсенде. Кенәз яу сәфәре, юл михнәте дип тормаган, зур-зур чатыр арбаларга утыртып, кайсысы балчыктан, кайсысы агачтан юнып ясалган әллә нинди сыннар алып чыккан. Берсе маллар алласы Волос икән боларның, икенчесе уңыш алласы Ярило, ди. Тагын җиләк-җимешләр алласы Купала үзе аеры көе бар, уйнаганда-биегәндә Колядага табыналар икән. Гыйшык тотучылар Ладо дигән потны үбеп-кочып яши, гөнаһлары өчен гадел хөкем өмет итүчеләр Прове атлы сын каршына барып

тезләнәләр. Аннары бер-бер артлы тезелешеп киткән эреле-ваклы потларның иясе— Подага, Живаго, Хорс, Дажебог, Припекала, Мокош, Стрибог, Похвист, Яр, Пик, Давор... Боларның исемнәрен дә ятлап бетереп булмый, ә алар тормыш итү, бала табу, тимер кою, кояшлы көн, жил... тагын кырыкмаса-кырык төр буенча илаһи көч иясе дип саналалар икән. Ерып чыккысыз чытырманлык, куып таратып булмас шайтан туе белән бер бит бу, валлаһи!

Әле ярый, кенәз чатыры корылган арба янәшәсендә боларның Перун атлы төп Алласын сурәтләгән пот ияреп йөри. Гәүдәсе агачтан ясалган, йөзен—көмеш, иягенә төшкән мыекларын алтын калай белән каплаганнар. Ул элегрәк яшен, ут Алласы булып исәпләнгән, хәзер вак-төяк потлар арасында баш хужа, ди. Владимир аны бастырык шикелле озын, биек итеп ясаттырган, үз чатырыннан бер адым да читкә калдырмыйча, гел ияртеп йөри. Кара сугышчылар "кенәзнең бу агач түмәрен түшәккә салып ятасы гына калды инде", дип чыш-пыш килеп көләргә генә тора. Ләкин Владимирның күләгәсе пәйда булуга, шундук сагаялар. Кенәз әлеге потка тел тидергәннәрен бер дә сөйми икән. Озакламый Атлаш мона үзе шаһит булды.

Жилем шикелле тартыла-сузыла бара торгач, "Өрәкләр үзәнлеге" дип аталган уйсулыкка да килеп житте алар. Үзәнлекнең сәер кушаматын ишетүгә үк, һаман да шул Атлашны чакырып алды кенәз.

—Каян килгән исем? Нинди уйдырма?—дип күк күкрәгәндәй акыруын белә.

Атлаш тавышын басып кына аңлатырга маташкандай итте.

—Бу үзәнлектә кычкырып сөйләшергә һич ярамый, кенәз. Элек бу урында бик олы яу булган. Меңәрләгән ирләр кырылышкан. Атлап йөрерлек тә урын беткәч, исән калган ирләр яна далага күчеп орышканнар. Ә шаһит булганнарны соңыннан бер кеше дә килеп жирләмәгән. Менә шушында, ачык далада череп кенә юкка чыкканнар, ди. Кайсын ач бүреләр килеп ботарлаган, кайсын карга-козгын. Адәм балаларындагы мондый гамьсезлекне, кансызлыкны күреп, Ходай тәгалә үтә рәнжегән дә әлеге үзәнлекне бик нык каргаган, ди. Хәзер монда юлаучылар килеп керә калса, атлары һич тыңламый. Чыбыркы шартлатсаң, козгын-карга көтүе жыелыша. Сызгырып йә сүгенеп куйсаң, барча арба үрәчәләренә тикле кереп бата. Юлаучылар мал бүлешә йә сугыша башлады исә, жир убыла. Менә шундый, бик тә хәвефле, сихерле һәм яман үзәнлек бу. Аны хәзер күпчелек кешеләр урап кына үтә. Ә төннәрен монда фәкать өрәкләр генә чыгып йөри икән.

Тылмач хикәятне бәян итеп чыккач, якын-тирәгә жыелышкан барча ирләр утка пешкән тире кебек куырылып, кечерәеп калды. Владимир гына авызын күккә чөеп, буш чиләк шикелле дан-дон килеп шаркылдавын белде.

—Ниткән өрәкләр ди? Нинди яман үзән? Уйдырма, әкият, тоташы белән ялган! Бернинди дә сихер-михерләр юк. Бу урынга чаклы ни рәвешле килеп житкән булсак, шул көенчә алга атлыйбыз да "эһ!" тә итми үтеп китәчәкбез!..

Юкка гына һаваланды кенәз. Беренче меңдәге атлар үзәнлек эченә аяк басуга ук шабыр тиргә батты. Кайберләре авызлыкларын зеңгелдәтә-зеңгелдәтә, усал пошкыра-пошкыра алга таба атлаудан бөтенләй баш тартты. Жайдаклары аңлап һәм бәяләп житкермәде. Дуамаллар малкайларның касыгына типте, камчы белән ярды. Өннәре алынган атлар, чарасызлыктан-көчсезлектән ярсып дулый-дулый, үзәнлекнең читенә сибелделәр. Дистәләгән жайдак әллә каян гына хасил булган сазлыклар эченә кереп батты, дистәләгән атның сыйраклары, умырткасы сынды. Ирләрнең аякларына киелгән катлы-катлы чабаталар сазлык эчендә жәфаланучы хужаларын таш аскандай аска өстерәде. Бичаралар өстенә арттан килгән

ташкын килеп өелеште. Үзәнлекне ачыргаланып кычкырган ирләр белән атлар тавышы күмеп китте.

Ахырда, уйсулыкны урап узгач кына, санап карадылар. "Өрәкләр үзәнлеге" төп-төгәл бер мең атны, йөзәрләгән җайдакны үзенә йоткан иде.

Владимир кенәзгә каршы, иң беренче булып, аталы-уллы Федор белән Иван гау куптарды. Боларның аякларында хәтта чабаталары да юк, алар карап торышка ук Алла мескеннәре иде.

—Икебезгә бер чаптарсыз калдык. Хәзер Болгарны таларга да барып булмый, кайтып китик дисәк тә бер терәк юк. Синең, әнә, йөзәрләгән чаптарларың балчык потлар, агач сыннар төялгән олауларны тартып йөри. Ул җансыз потларны сөйрәп бушка тыгынганчы, ике атны безгә кайтарып бир һәм вәссәлам, кенәз!

Владимирга әле генә кылган гөнаһларын юар өчен корбан кирәк иде. Шулар табылган сөенечтән, ләгънәт ора-ора, алга чәчрәп чыкты.

—Аһ, безнең изге Аллаларга тел тидерәсезме әле, ике бәдбәхет җан?! Алар җансыз агач сын да, яу сәфәренә чыккан кешеләргә җиңү сорап табынырга потлар кирәкмиме? Йөзләренә ялган битлек киеп алган дошман икән болар! Безгә җиңелү һәм хурлык теләп йөрүче кабих җаннар! Тураклап ташлагыз бу имансызларны, тураклагыз!

"Өрәкләр үзәнлеге"ндә зур югалту кичереп исәңгерәгән ирләр кенәзнең шашынулы әмеренә каршы тора алмады. Бер төркем җәяүле ир үзләренең гыйсъян юлдашларын күз ачып йомган арада өзгәләп тә атты.*

## 55

Урыс гаскәренең икегә бүленеп килүен төгәл белә иде, Ибраһим да аларны болгар көчләреннән ике ятьмә корып каршылады. Елантау өстенә алданрак килеп җитешкән алайларның берсе дә тик ятмаган, дилбегә чаклы озын бүрәнәләрдән урыны-урыны белән ерым читләрендә, итәкләрдә тоташ койма-дивар бастырып куярга да өлгергәннәр икән. Ибраһим төп чирүне, әлбәттә, шул диварлар артына яшереп, туплап куйды. Сал-Сал сәрдәр өчен дә фәрман-бурыч күптән әзер иде.

—Син мөгез чыгаруны бик тә яратасың. Әйдә инде, бу юлы да Идел буендагы таллыклар ышыгында посып утыр. Саллар, каеклар өстендә агып килүче сигез мең урысны Владимирның агасы Добрыня үзе җитәкләгән, диләр. Менә, ике сәрдәр ике кәҗә тәкәсе шикелле маңгайга-маңгай килеп орышырсыз. Кайсыгыз остарак икән, сынап карыйк әле...

Канлы яулар, зур сынаулар үткәреп торырга насыйп булмаган шул. Авызларына камыш сабагы, көпшә капкан карлукъ, мангыт ирләре төүге саллар белән Кабан күлләре турысына килеп җиткәнче үк, су астыннан гына чумып барып, барча арканнарны кисеп бетерделәр. Бүрәнәләр елга буйлап таралды, йоклап баручылар су төбенә китте, уянганнарын аякларындагы чүлмәк кадәрле чабаталары аска өстерәде, Идел өстен тоташ мәхшәр, тәшвиш каплап алды. Елгырраклар янда аккан каекларга ташланганнар иде, өстәгеләр сөнге-кылыч кадап, ишкәк белән сугып аларны янә Идел дулкыннары эченә чумдырдылар. Дистәләгән каекларның астыөскә килде, елга суы янадан-яна корбан белән тулды. Җил тузгыткан салам кебек таралышып яткан бүрәнәләр, үле балык сыман янтаеп йөзгән каеклар өстенә арттарак сузылган яна саллар, күбесенчә ризык, мал-туар һәм җарияләр төягән олырак көймә-баркаслар килеп менде. Мондый

*Аталы-уллы Федор белән Иван—мәҗүси Киев Русендә бер генә Аллалыкны яклап чыккан өчен кенәз Владимир корбан иткән һәм соңыннан чиркәү тарафыннан изгеләштерелгән җаннар.

башбаштаклык тагын күз күрмәгән, колак ишетмәгән гарасат китереп чыгарды. Бер-берсенең өсләренә яткан көймә-саллар язгы ташкын вакытында тар бугазга килеп тыгылган боз катламнары сыман ухылдады. Өнсез калган кәҗә-сарыклар, тимер көбә белән ук-җәясен дә эләктерергә өлгермәгән ирләр күз-башларын тондырып суга сикереште. Йөзә белгәннәр Кабан күлләре ягына якынайса, алар өстенә таллык, әрәмәләр эченнән ук яңгыры очты. Каек-салларга төялгән урыс ирләренең күпчелеге, ахыр чиктә чабаталарына хәтле салып ташлап, Иделнең икенче як ярына чыгып ауды.

Добрыня үзе егерме ишкәкле зур корабта су кәрваны уртасында йөзеп бара иде. Яңагына китереп суккан сыман искә-анга килеп, дилбегәне үз кулына эләктерергә бик сонарып кына өлгерде ул. Идел өстен аның жиз торба чыны шикелле усал, мәгърур тавышы каплап китте.

—Саллар, каеклар читенә калкан күтәрегез! Смоленск белән Галич укчылары, алга, кәрван борынына! Радимичлар, вятичлар, кривичлар! Яр өстенә чыгып ябышу өчен каплан алайлары әзерләгез!

Барча кәрван астына ут ягылган олы казан сыман айкалды, гөбердәде. Сал-каекларның як-ягын агач яки тимер калканнар дивары төреп алды. Калканнар арасыннан дәһшәт бөркеп сузылган ук һәм сөңге очлары энәләрен усал тырпайткан мәһабәт керпеләрне хәтерләтте. Әле Галич, әле вятич укчыларыннан торган йөзлекләр, кәлтә еланнары кебек тавыш-тынсыз гына шуып төшеп, Кабан күлләренә таба йөзеп китте. Үгез тиреләреннән катлы-катлы итеп һәм сумала белән катырып ясалган җиңел калканнар астына ышыкланган укчылар төркеменең һәркайсы, чыннан да, посып кына корбанын ауларга баручы кара капланнар шикелле дәһшәт бөрки иде.

Тора-бара яр өстенә чыгып ныгыдылар. Идел белән Кабан күлләре арасында яткан инкүлектә өч меңнән артык сөңгесен як-якка тырпайткан беренче рус гаскәре хасил булды. Яр өстеннән килүче төп көч белән ике арадагы элемтә өзелгән иде инде, Добрыня итәгенә ут капкандай ашыгып бер дистә чапкын куды.

—Кенәзгә җиткерегез! Болгар ханының төп гаскәре безне әнә теге тау башында көтә. Даладагы иң отышлы, иң шәп биеклекне мин эләктердем, дип шунда посып яту, дивар артына кереп качкан көе шәрә йодрык селтәп кәпрәю-һавалану—ул әле безне ярык тагарак тоттырып калдырдым, дигән сүз түгел. Ибраһим ханның печән кибәненә менеп яткан эт шикелле үз-үзенә кабер казуы бар. Бәлки, ул кибәнне без озак вакыт буе кимерә дә йолыккалый да алмабыз. Әгәр инде төрле яктан килеп ут төртмәсәк. Ә иң мөһиме—ханның әнә шул кибән төбәсендә, печән ашый алмаган эт хәленә калып, ачтан үлүе бар. Монысы инде фәкать безнең нинди камалыш боҗрасы төзеп куюыбызга гына бәйле. Шуңа күрә олугкенәз үзенең җайдакларын әнә теге, олы казан шикелле, чокыр буйлап тезеп куйсын иде.

Баскын җайдаклар гаскәре берәр сәгать чамасы вакыт үткәннән соң пәйда булды. Владимир Елантау буендагы хәлне үзе өчен тагын да отышлырак, хәвефсезрәк дип бәяләде, ахрысы, ул җайдакларын янә кыл урталай бүлде.

Владимир үзе белән бергә яу сәфәренә ике яшь хатынын, әтиләренең җиңүен күреп горурланырдый зуррак балаларын, шулар арасында ундүрт яшьлек Святополкны да алып чыккан иде. Святополк—кенәз Владимир ятагына көмәнле килеш канизәк сыйфатында килеп эләккән киленкәе Ангелина тапкан-баккан бала. Аның әтисе мәкерле Ярополкны Киев тәхете өчен суеш барышында Владимир үзе үтерттерде. Дөрес, Ярополктан соң тол калган юнан сылуын хатын итеп алды ул алуын. Святополкны да какмый-сукмый үстергәндәй итте. Ләкин картлар "ятим бала асрасаң,

авызын-борынын кан булыр", дип юкка-барга гына кисәтмидер. Бишектәге бала кырыкка төрләнә, ди. Святополк үсеп житсә ни булыр бит әле? Әтисенең үлеме өчен үчкә сусамасмы? Андый хәвефләрдән котылыйм дисәң, көндәшеңне янган учак янында йөртү хәерлерәк. Хәтта син төртеп төшермәсәң дә, аның үзенең ачыгавызланып утка пешүе бар. Менә шушы уйлар аны үги улы Святополк белән юлдаш, яудаш итте...

Әтисе ым каккач та, хуҗасы мәрхәмәт күрсәтеп ыргыткан сөякне тугрылык һәм рәхмәт хисе белән эләктерергә ташланган эт баласы кебек, канатланып килеп житте егет. Авызын колакларына тикле ерган, йөзендә үч-мәкер чалымы юк, әмма... әмма ул, барыбер, сөзешергә әзерләнгән усал үгез кебек, каш астыннан текәп, сынап карый. "Ятим бала һәрчак үчле була", дигәннәре хакмы соң ул әллә?

—Бер нөгәрне синең кулга бирәм,—дип башлады Владимир.—Әнә теге инеш буена бар да Ибраһим хан оялаган тауны шул тарафтан биклә. Мине жыен юк-бар мәшәкать өчен дә чапкын куып бимазалыйсы булма. Үзең баш, үзең түш. Һәммәсен ялгыз көе хәл итәргә өйрән.

—Итәм, итәм, әткәй! Үзем, үзем!—дип учак кебек дөрләп кабынды яп-яшь егет.

Икенче мизгелдә җайдаклар өстенә гайрәтләнеп кычкырган әмер яңгырады.

—Киевлылар, Осколлылар, алга! Куркак хан менеп качкан тауны кече инеш ягыннан өчәр катлы чылбырга утыртабыз!..

Юк, тагын ашыкты, хаталанды кенәз. Яшүсмер Святополк үзенең алайларын Нургали чишмәсе тирәли тезеп тә өлгермәде, ә Елантау түбәсеннән баскыннар өстенә туфан куптарып улаган, дөбердәгән бүрәнәләр очты. Гади бүрәнәләр генә булса бер хәл, андыйлары урыс җайдаклары өчен зур яңалык түгел. Мәгәр болар! Һәрберсе җиде башлы дию, гыйфрит, аждаһа, буар елан!

Елантау өстеннән алдан ук сагызланып куелган һәм хәзер инде ут элеп очырган юан-юан бүрәнәләр тәгәри. Һәркайсы да озын, колач җитмәслек юан. Чүл бүресе сыман улап, яман ут көлтәләре бөркеп тәгәриләр. Алар килеп төртелгән һәр урыннан чүлмәк-чүлмәк кәс кантарлары, олы-олы ташлар кубарылып оча. Бүрәнәләр атларны-җайдакларны йә тау урынына сыта, йә мәһабәт кылыч айкап үткән кебек дистәсе-дистәсе белән кыеп сала. Тау белән инеш арасында тасма рәвешендә сузылган тар, ачык җир ята. Анда ышыкланып калырдай бер түмгәк, бер чокыр юк. Аждаһадай ажгырып һәм дулап төшкән бүрәнәләр җайдакларны инеш суына кадәр алып очыралар. Аяклары чабаталы, иярләре өзәңгесез булгач, җайдаклар атларын хәвефсезрәк якка борып та кача алмый. Тау астында чуалыш, үлем, җан ачысы белән кычкырган хушлашу авазлары, өннәре алынган ат кешнәве, тәшвиш, өметсезлек, гарасат һәм мәхшәр!..

Баскын җайдаклар исемсез елга суына ташланып, вак-вак төркемнәргә бүленеп кача-кача, чак-чак котылдылар. Тау астында, инеш ярларында чабаталарына чаклы изелеп һәм сытылып беткән йөзәрләгән мәет аунап калды. Святополк үзе инеш аша чыгып качкан иде. Җайдакларны кабат жыеп, аларны яңа яуга күтәрү аның кодрәтеннән киләчәк эш түгел. Шуны уйлап, Святополк алайларны туплау өчен ымсыну да ясап карамады. Кызган күл астына эләгүдән шүрләп, әтисе янына кайтырга ашыкмады. Качаклар кич белән, караңгы төшкәч кенә, койрыклары көйгән бүре көтүе сыман шыпан-шыпан кайтып, янә кенәз казаны янына тупландылар.

## 56

Төнлә Владимир кенәз ыстанына Добрыня үзе килде. Чатыр ишеген ачып эчкә инүгә, башын җиргә орды.

—Салда килгән җәяүле укчыларны тоташ тәшвиш, бердәм курку басты. Аларны өр-яңадан яуга ташлау өчен дәртләндерми булмый. Болгар ханыннан батырлар алышын таләп ит. Әйдә, теге чакта болгар баһадирының җанын кыйган Алешаны чыгар...

Батырлар орышын үткәрү турында тәкъдим килеп җиткәч, Сал-Сал әле керфек тә селкетеп карамаган иде. "Аның ни даны бар? Сәрдәр чаклы сәрдәр башың белән юеш борынлы малай-шалай кебек сугышып йөреп булмас",—дип кенә кул селтәде ул. Ләкин берзаманны Олы Кабан күле ягыннан бик тә таныш, әмма аның өчен дөньядагы иң җирәнгеч исем ишетелгәч, куырылып калды.

—Алеша? Алеша дигән пәһлеванны янә алышка чыгаралар? Тукта, бу минем атайның гомерен кыйган җанвар түгелме соң? Әнкәй мина аның исемен юкка гына ятлатмады бугай. Бәлки... бәлки мина атай өчен үч кайтарырга җай чыгадыр?..

Ибраһим хан янына атылып барып җиткәч, тегесе әүвәл өрәк күргән сыман аптырап торды.

—Нинди Алеша ул? Каян килгән нәүбәт? Нинди үч кайтару?

Тынычрак тавышка күчкәч җиңел анлаштылар.

—Ә-ә, синең элегрәк тә әйткәнең бар иде шул, мин бөтенләй онытканмын,—дип, йокыдан айныгандай тезде Ибраһим хан.—Ә югыйсә, синең әтиеңнең орышына мин үзем дә шаһит булган кеше. Әйе, моннан утыз-кырык фәрсах чамасы арада утырган Кашкатау янында әрәм булды атаң. Хәрәмләшеп җиңде аны урыс пәһлеваны, күзенә ком сипте. Теге имгәк шулай хәрәмләшмәсә, мөгаен дә, орышта синең әтиең җиңгән булыр иде. Язмыштан узмыш юк шул, юк шул. Мин ул алышка үзем чыгарга да ният иткән идем. Син кысылма, диделәр, ирек бирмәделәр...

Ибраһимның һаман урап-кырыйлатып сөйләнүенә түзмичә, Сал-Сал янә каен тузы сыман кабынып китте.

—Атай өчен үч алырга бу юлы үзем чыгам. Минем нәүбәт! Мондый форсатны кулдан ычкындырсам үз-үземне гафу итәсем юк!

Сүз мең сарыклы көтүдән аерылып калган сынар бәрән турында бара, диярсең, Ибраһим чебен куган кебек итеп кул селтәде.

—Ярар, кулың бик кыҗрап тора икән, чыгарсың, алайса...

Гаскәрләрне моннан егерме ел элек, Кашкатау янындагы шикелле, капма-каршы тезеп бастыру насыйп булмады. Елантау тирәсендә мәйдан чикле: йә чокыр, йә сазлык, өстәвенә борчак төсле чәчелгән күлләр сибелеп ята. Ибраһим хан үзенең җайдакларын Елантау итәгенә бастырып куйды, Владимир кенәз яртылаш төстә яланаяк калган укчыларын Кабан күлләре буендагы куе таллык ышыгына тезде. Рәвешен китереп, сорнай-дөмберләрне уйнатканнан соң гына, ике арадагы үзәнлеккә Алеша белән Сал-Сални чыгардылар.

Урыс баһадирына күз салгач та ошатмады Сал-Сал. Ит йә балык тозлау өчен әзерләп куелган агач мичкәдән дә юанрак гәүдә. Күкрәгенә салынып төшкән җирән, куе сакал. Кашлары алагаем аска бөтәрләнгән. Яңаклары әле яңа гына табадан сикереп төшкән беленмени?! Борыны бәрәңгедәй. Йодрыклары саллы. Ирнен тәнендәге тазалыкны челтәр көбә дә каплап бетерә алмый. Беләкләре дәһшәт бөркеп тора. Ләкин шактый олыгайган шул инде бу баһадир. Ул бия-тай күрмичә, кап-караңгы аранда япа-ялгыз көе тотылган хиссез айгыр сыман.

—Атың кем синең, әй, селәгәй егет?—дип көтмәгәндә аваз салды урыс

пәһлеваны.—Ичмаса, тукмак белән сугып жиргә индергәнче шуны белеп калыйм. Аннары соң була.

Сал-Сал котырудан күмер төсле кара янып чыкты. Аңкавына без белән кадаган шикелле ябышып калган телен көчкә әйләндереп, жавап сүзен әйтте.

—Байдар минем атым. Ишеттеңме, көзән?!

Алеша шундук куырылып калды, күзе акаеп чыкты.

—Нинди Байдар тагын? Мин сезнең андый исемдәге бер мәхлукъ батырыгызны моннан егерме ел элек үк дөмектергән идем. Нәрсә, әллә сездә Байдардан тыш бүтән исем юкмы?

—Синең өчен юк, мәкерле көзән. Син шушы исемне генә кабатлап үләчәксен!..

Аргамакларының касыгына тибеп, икесе дә берьюлы урыннан кузгалдылар. Алеша унъкулына сыер боты чаклы гөрзи тоткан иде, бер сугуда чәрдәкләрдәй булып, үкереп якынайды. Сал-Сал качышлы уйнаган балаише ары качты аннан, бире качты. Урыс баһадиры ярсудан, шашынудан тиргә батып бетте, түземлеген жуйды.

—Качма, куркак чебеш! Барыбер тураклыйм мин сине, барыбер он итәм!

Сал-Сал торган саен аны ныграк үчекләде.

—Мин бит мәрхәмәтле. Әйдә, әйдә, йөгереп кал, сыер! Телeнне аркылы тешләгәч кенә чалып ташлыйм сине...

Гөрзиен ажгыртып төшергән бер вакытта Алеша иярендә утырып кала алмады. Баскын пәһлеван жир өстенә капланып төште дә утын түмәре кебек тәгәрәп китте. Ул аягына басарга ымсынган бер минутта Сал-Сал аны кисәкләргә өзгәләп аткан иде инде.

Елантау өстенә тезелгән болгарлар күк капусын күтәрердәй итеп дәррәү кычкырдылар.

—Безнең сәрдәр жиңде! Сал-Сал жиңде!

—Урысларга безнең каршыга килеп тезләнергә вакыт!

Сал-Сал баскын укчылар ягына күз ташлады. Һәммәсе дә яңгыр астында калып жебегән тавык-чебеш кебек сөмсерләрен коеп тезелгәннәр. Күзләрендә өметсезлек, кайгы, тоташ тәшвиш. Сал-Сал ыргыткан үчекле, өр-яңа шарт бөтенесен тораташтай итте.

—Сезнең һәрбер батырыгыз белән аеры-аеры көе орышып булмас. Сәрдәрегез чыксын!

Болгар батырынын шушы шарты баскыннарның бар гаскәрен, әйтерсең лә, пычаксыз-нисез суеп салды. Һәммәсе дә тере елан йоткандай тын тордылар. Фәкать кенәз чатыры ягыннан гына чышан-пышан килгән тавыш ишетелде.

—Чыгара күрмә мине, туганкаем, и-и, чыгара күрмә. Мин газиз ананның бертуган энесе бит. Бар гомерен эт типкесендә, читкә кагылып үткәргән Малушаның хатирәсе хакына ялыныплар сорыйм, мине харап итмә. Мин картайдым бит инде, мин гайрәтсез. Син болгар сәрдәренең безнең Алешаны ничек өзгәләвен үзең карап тордың. Алеша хәтле Алешаны жиңгәч, мине бетле чебеш урынына ботарлап атачак бу. Юк, мин чыкмыйм! Солых сора, кенәз...

Ниһаять, гаскәр алдында Владимир үзе пәйда булды.

—Ханыңа житкер, батыр,—дип, әле һаман элеккечә вәкарьләнеп, Сал-Салга эндәште ул.—Безгә уйлау, үлчәү, әзерләнү өчен бер төн вакыт кирәк. Кичкә караганда иртәнге эш, калдык ашка караганда яңа пешеп чыккан ризык хәерлерәк, диләр. Үз карарыбызны сезгә иртәгә тан аткач житкерербез...

Ике як гаскәр дә күк йөзеннән убылып төшкән, көтелмәгән ялга таралышты.

## 57

Бу төнне ике ыстанда да яубашлары керфек какмадылар. Бер яктагы хәлне дә өметле, хәвефсез дип бәяләрлек түгел, шулай да Владимир кенәз чатыры эссе салмый мунча кирәрлек булып кызып житкән иде. Аеруча иртәгә үзенә үлем афәте янаган сәрдәр өзгәләнде. Анын янагында көндез үк ялтырый башлаган күз яшьләре кипмәде дә сыман. Кортлы агач эзләп тапкан тукран шикелле, ул бер үк сүзне тукуын гына белде.

—Болай да шушы тау янында алты меңгә якын ир югалттык. "Өрәкләр үзәнлеге"ндә юкка чыкканнарны, юлларда егылып әрәм булганнарны да кушып исәпләсәк, жиде меннән арта. Әгәр дә иртәгә мине орышка чыгарсаң, тагын бер корбан килеп өстәләчәк, моны бик белеп тор. Ярар, синең анан белән минем төсле ятимнәрнең башы алтын бәһасе дә тормасын, ди. Ләкин чатыр тышында мондагы болгар капкынына килеп эләккән тагын унсигез меңгә якын ир-ат бар бит әле. Алар болай да аю чокырына егылып төшкән бичаралар хәлендә. Ә иртәгә болгар сәрдәре мине дә турап аткач, син аларны яңа орышларга ничек күтәрерсең?

Владимир авызына ямау салган сыман әүвәл бер сүз эндәшмәде. Уянгандай итсә, бер генә зары ишетелеп торды.

—Ибраһим безгә ясак түләргә риза булмасмы икән?

Добрыня яңа яктан килеп үгетләргә ашыкты.

—Мин чамалыйм, син Киевка әптәрләнеп ташланган хәлдә әйләнеп кайтудан хурланасың инде. Шуңа күрә һаман "ясак, ясак" дисең. Тик син алданасың, туган. Ибраһим үзенең жайдакларын тезеп куйган чакта шәйләмәдеңмени? Болгар гаскәрендәге һәрбер ир-ат аягына йә күн итек, йә күн читекләр кигән. Без тоташы белән диярлек тишек чабатадан. Чабатадан, кенәз, ча-ба-та-дан! Ә итекле-читекле ил безнең сыман чабаталы һәм яланаяклы мескенгә ясак түләмә! Шулай икән, туганкай, болардан ясак талап итү турында хыялланма. Башны исән-сау көенчә алып качу хакында уйлау хәерлерәк.

Ниһаять, түземлеген җуеп, Владимир катгый сорау бирде.

—Нәрсә, хәзер инде үзебез ясак түләп яисә коллар калдырып кайтып китикмени?

—Нигә ясак түләп? Нигә коллар биреп?—дип кабатлый-кабатлый җанланып куйды сәрдәр.—Бернинди мескенлеккә дә төшмичә, көчләре-дәрәҗәләре тип-тигез агай-эне сыйфатында да аерылышып була.

Владимирның күзләре жилдә уйнаклаган очкын сыман ял-йолт килде.

—Ничек инде, ничек? Ибраһим капкыныннан кан коймыйча да котылу мөмкинмени?

—Мөмкин, мөмкин, туганкаем! Ибраһимга ике ил арасында солых төзү турында тәкъдим ясарга кирәк. Ике туган, ике дус үзара сугышмаска, кан коймаска сүз беркеткән кебек.

Владимир янә аптырашка калды.

—Соң, Киев тәхетендә миңа хәтле утырган бер генә кенәзнең дә моның ише солых төзегәне юк иде бит әле.

—Ике ил арасында дуслык солыхы төзегән беренче кенәз менә син булырсың! Аның каравы, атың һәм гамәлең тарихларга керер!

Мондый мәртәбәле, шөһрәтле сүзләрне ишетүгә Владимир бер карышка үскән кебек булды, ул хәтта иңбашларын калкытып күркә сыман кабарынып алды. Моны күреп батырайган сәрдәр борчак сипкән кебек бертуктамый тезде.

—Безгә дуслык солыхы әле тагын яңа калкан кору, өстәмә терәк булдыру өчен дә кирәк, туганкаем. Бәла дигәннәре ялгыз гына йөрми. Болгарлардан җинелгәннән соң ук хәзәр каханына коллыкка төшүебез бар. Болгарларны аркадашлар итеп, дуслар итеп, алар белән бергә каханга каршы яу күтәрү күпкә отышлырак. Болгарлар белән яу кырына кереп, дошман артыннан дошман җыеп йөрмик. Йөз дус та аз, бер дошман да күп, дигән бабайлар. Безне елан сыман сагалап, йотарга әзер торучы күндәшләр болай да күп. Бәҗәнәкләрне күз алдыңа китер, әнә, яисә мадьярларны. Үз кардәшебез сыман кыйланып күзгә төтен җибәреп яткан ростовныкыларны, Смоленск, Новгородны да шул ук сафка бастыр. Ә иң беренче дошманыбыз—хәзәр каханы безнең. Ул безнең вятич, радимич кабиләләреннән талап ясак җыя. Нәкъ менә шул хәзәр каханы безнең сылу кызларыбызны, яп-яшь егетләрне үзенең харәмханәсенә алып китә. Аманат итә, имеш, шулай алдый. Ә чынлыкта җария итә бит аларны, сөяркәләр ясый. Менә, менә ни өчен болгарлар белән дуслык солыхы төзергә тиешле без.

—Тик ул солых хакында Ибраһимның үзенә ни рәвешле тәкъдим итәргә соң? Ялынып барсаң, мескенлек. Байлык белән сатып алыр идең, төяп алып килгән хәзинә юк. Мондый чакта "коры кашык авызны ерта", диләр. Нинди генә ысул, сукмак уйлап табыйк?—дип Владимир баш чүмечен кашырга керешкәч, Добрыня, әлбәттә, чәчрәп алга чыкты.

—Ибраһим хан янына үзем барам, кенәз, үзем барам! Сәрдәр хәтле сәрдәрне кулга төшерү хәтәр ымсындыргыч булып тоелса да, алар миңа барыбер тимәячәк. Уен-муен түгел, аларның сәрдәре мине орышка чакырды. Миңа кул тидерсәләр, бик тә изге йола бозыла, алар үзләренә гөнаһ алмаячак. Ә Ибраһим янына барып кергәч, үлсәм—үләм, әмма солых турында аның ризалыгын алмыйча кире кайтмыйм!

## 58

Ибраһим хан чатырындагы иминлек бизмәнен дөм-караңгы төн уртасында Сал-Сал сәрдәр генә әйләндереп атты. Бер минутта алар чатыр эчендә тик икесе генә торып калган иде.

—Мин сиңа өч елдан артык гомер хезмәт итәм,—дип башлады ул һич тә көтелмәгән, әрнүле һәм ярсу зар белән.—Өч ел буена бернинди мал да, алтын-көмеш таулары да сораганым булмады. Әрсезлеккә барсам, мин инде әллә кайчан синнән берәр кала йә олыс таләп итә алган булыр идем. Без чит-ят кешеләр түгел, яшереп торасы юк бит. Әле Янкалада чагында ук мин сиңа канат бирдем. Менә шушы тау буена кайткач, Тимер-Мөэмин гаскәрен мин җимердем. Чынлап баксаң, сине тәхеткә утыртып куючы кеше дә асылда мин. Шулай түгелме, хан?..

Ибраһим баш түбәсенә күсәк белән китереп орган шикелле гел миңгерәп калды. Юк, ике арада кайчан да булса йә мунча ташыдай кайнар, йә кылыч очыдай кискен һәм хәлиткеч әңгәмә килеп туачагын ул чамалый, көтеп йөри иде. Әмма нәкъ менә бүген, ил язмышы хәл ителгән көндә, сәрдәр кеше ханны бугазыннан эләктереп алыр, дип кем уйлаган?..

Ибраһим көч-хәл белән телен әйләндереп сорау бирде.

—Ниләр таләп итмәкче буласың? Әйдә, сана.

Сал-Сал элеккечә, үзен-үзе тыя алмыйча, ярсып дәвам итте.

—Кызың Айзирәккә гыйшык тотып йөрүем сиңа яхшы мәгълүм. Инде өч ел буе, Янкаладагы Ана сөте чишмәсеннән бирле гыйшык тотышабыз. Мин синнән Айзирәкнең кулын сорыйм.

Ибраһим бу сорауны да күптән көткән иде. Хәзер уенга борып җибәрмәкче булды.

—Кызның кулын әтисеннән түгел, үзеннән сорыйлар бит.

—Айзирәк риза, без анын белән әллә ничә тапкыр вәгъдәләштек инде,—дип җавап кайтарырга ашыкты Сал-Сал, яна-пешә.

—Ә ни өчен нәкъ менә бүген сорыйсын син? Чатыр тышында дошман басып тора, иртәгә безне янә яу көтә. Кәләш сорау өчен һич кенә дә кулай вакыт түгел.

Сал-Салнын карашында янә усал ут кабынды.

—Яу бетсә, йә дошман кайтып китсә, синен мине тишек кәвеш төсле чыгарып атуын бар. Мин чамалыйм моны.

—Ә бүген хан беркая чигенә алмый, чөнки ул сәрдәреннән башка беркем түгел, дигән нәтиҗә ясадынмы? Әй-яй! Ашыгасын, Сал-Сал.

—Нигә, ник ашыгам? Мина калса, ин-ин кулай вакыт.

Ибраһим хан инде көлемсерәп кенә йомгак ясап куйды.

—Айзирәк минем өчен берәү генә, Сал-Сал. Ә сәрдәрләрне мин көн саен алыштыра алам. Монысы бер. Аннан икенчесе. Сине танда канлы орыш көтә. Менә шул орыштан исән-сау чык башта.

—Исән чыксам, Айзирәкне мина бирәсенме?..

Ибраһим авыз ачарга да өлгермәде, чатыр ишеген дөбер-шатыр китереп, каравылбаш Көбәк килеп керде. Артыннан юлбарыс йә бүре куганмыни, сулышы-тыны капкан. Күз кабаклары шырпы кыстырып куйгандай акайганнар.

—Ибраһим хан! Көтелмәгән кунак... олуг түрә...

Чатыр почмагында кыя читенә китереп бастыргандай шик-шөбһәгә калган Сал-Салны күрүгә, каравылбаш авызына шундук йозак элде. Әмма Ибраһим хан колагына иелеп чыш-пыш килгән чакта бер-ике җөмләсе барыбер дә ишетелеп калды.

—Ханнын үзе белән генә сөйләшәм, беркем булмасын, ди.

Мизгел эчендә җитдиләнеп калган Ибраһим хан Сал-Сал ягына борылып әмер бирде.

—Арадашчы килгән, берүземне калдыр. Чамалыйм, иртәгә сина орышырга язганмы икән, юкмы—менә хәзер булачак сөйләшүдән тора...

Добрыня сәрдәр берьялгызы булып чыкмады, ул эт кебек иснәнеп юл күрсәтердәй кешене күптән тапкан икән. Чатыр эчендә элек курсыбайда йөзбашы булып йөргән Атлашны да күргәч, Ибраһим шактый тирән аптырашка калды. Әллә бу шымчы-йөзбашы ике якка да ярый, ике якны да имә белә торган йомшак иренле, юха еланмы сон?

Атлаш Добрыня өчен эзтабар гына түгел, әле тылмач та икән. Беренче җөмләләрне тәрҗемә кылуга ук, идәнгә төбәлеп утырган көенчә, ул гел үзенчә тезде.

—Алар синнән дуслык солыхы төзеп, үзләрен кыйнамыйча җибәрүне үтенәләр, хуҗам. Боларнын сине сатып алырдай юньле байлыгы юк. Алар йорты-каралтысы янып беткәч хәер эстәп чыккан сукбайга тин. Иллә мәгәр боларнын бик тә йомшак, элпә сыман юка бер ягы бар. Бу хакта мин сина элек тә хәбәр иткән идем. Болар мәҗүсиләр, Аллаһы тәгаләне бөтенләй танымыйлар. Алар кырыкмаса-кырык төрле потларга табыналар. Солых төзисе булсан, син кенәзгә шарт куй. Әйдә, изге ислам диненә күч, шәригать йолаларына өйрәтү өчен мин сезгә имам-хатыйблар да тагып җибәрәм, диген. Менә шушы җинү ин зур җинү булыр. Безнен дингә күндерүгә ирешсәк, болар берчакта да яу белән Болгар өстенә килмәс...

Иртәнгә чаклы сузылачак бәхәс-килешүләр шулай канат ярды.

## 59

Елантауның өстен бүген һич танырлык түгел. Тауның түбәсенә, куна тактасыдай тигез булып яткан мәйдан уртасына акшардай пакь киезләрдән генә корылган өр-яңа чатыр күтәреп өлгергәннәр. Бер як читтә, уйсурак урында, иң чиста киемнәргә төренгән сугымчылар сарык бәрәннәрен, яп-яшь колыннарны корбан итеп чала, кулларына комган-сөлге тоткан акъяулыклы кызлар тыз-быз килеп ярдәмләшеп йөри, янда гына дистәләгән олы казан кайный. Учаклардан күтәрелгән сыекзәңгәр төтен әрфиядәй җинел, нәни болыт ясап өскә күтәрелә. Күк йөзе чалт аяз. Анда җир өстендә әле азгынлык, хыянәт барлыгын да белмичә су коенган гөнаһсыз кызларны күзәтергә чыккан шук егет шикелле туктаусыз елмаеп, эчкерсез һәм мәңге уяу кояш сакта тора. Җиһанның шау-шу, гөнаһ, хыянәт, яу кабул итмәс чагы.

Ибраһим хан әлегә үзе күренми, ул һаман да иске чатырында. Яңа кәләш янына кереп зөфәф төне уздырачак кияү егете диярсең, аны яп-яшь кызлар олы-олы ләгәннәрдә коендырып, сакал-мыекларын пөхтәләп, зәйтүн мае, гөләп-җәсмин төнәтмәләре белән хушландырып изге очрашуга әзерлиләр. Шушында ук ялтырап торган аел, садак тоткан һәм тычкан койрыгыдай нечкә мыекларын туктаусыз бөдрәләүче курсыбай йөзбашлары бөтерелеп йөри.

Бай кодалар көткән табын төсле бизәлгән зур мәйданга әлегә вәзир Насыйр хуҗа. Итек эченә ут салганнармыни, ул бер урында басып тора алмый. Тәрәзәдән яучы күзәтүче сазаган кыз сыман, вәзир әле пешекчесугымчыларга килеп бәйләнә, әле меңбашлар белән олугбәкләр эшеннән гаеп эзли.

—Әмир Шуран, Мөслим! Чәңчеләр белән танбурчыларны чакырдыгызмы соң сез?

—Имам Мәрдән, Локман хәзрәт! Бүген Мөхәммәт галәйһиссәлам рухына багышлап шәриф догалар кыласы да бар бит. Нигә инде вакытлыча мәчет манарасы күтәреп куймадыгыз?

—Сәркатибләр белән битекчеләргә эндәшергә оныттыгызмыни, эх, Алла коллары!..

Тауга, төрле яклап, өсләренә өр-яңа көбәләр, баш түбәләренә җиз самавыр сыман ялтырап торучы очлым элеп алган, көмеш җепләр белән бизәлгән кынлы кылыч һәм садаклар таккан яугирләрнең, укчыларның унлыклары, йөзлекләре күтәрелә тора. Су эчеп күбенгәннән соң тоз яларга атлыккан маллармыни, берән-сәрән булып аларга төнлә белән ат саклаучы торгаклар, әмир-бәк шикелле аксөякләрнең колчуралары, тимерчеләр, салчылар ияргәннәр. Һәркем җиңү тантанасына шаһит булырга ашкына, һәрбер Алла бәндәсе бүген үзен ил алдында эш күрсәткән фидакарьгә саный...

Тау итәге астыннан, алтын каурыйлы кош тоткандай тантаналы, рисвай аваз ишетелде.

—Киләләр, ки-лә-ләр! Балтимер кенәз белән Дәүборын сәрдәр икесе дә килә!

Мәйдан өстендәге ирләрнең күпчелеге әүвәл май сибелгән учактай кабынып дәррәү көлештеләр.

—Урыс түрәләренә вәт шәп кушаматлар чәпәп куйды бу, чукынмыш!

—Балтимер, Дәүборын! Менә сезгә ике яңа исем!..

Аннары Елантау читенә тезелеп бастылар да кибет киштәләрен күзәтүче ярлыдай тын калдылар. Юк, тар-мар ителгән йә тез чүгәргә килгән йолкыш

гаскәр башлыклары кебек борын салындырып, сугым малы сыман күндәм кыяфәттә атламыйлар болар. Кенәзләре алтын-көмеш жепләр белән нәкышьләнгән кызыл җилән кигән. Алтын аеллы кин каешы астында озын хәнҗәр, очы жиргә чак-чак тими калган саллы кылыч. Добрыня сәрдәр өстендә уч төбе чаклы шакмаклардан ясалган тирән көбә, билендә кәрәк кинлегедәй, ике йөзле кылычы бар. Аларга ияргән боярлар-менбашлар да көбә-кылычтан, шайман-коралсыз атлаучы бер кеше юк. Шулай да, мал төге шикелле, чит-ят күзгә ияреп китәрдәй кимчелекләре бар боларның. Берсенең дә сакал-мыеклары ипләп таралмаган-кырылмаган икән, сөнгекалкан тотып атлаучы сакчылар арасында чабатадан гына килгән ярлылар бар.

Болгар ирләре өчен иң тансыгы һәм үтә кыйммәтлесе, балбалдай таш иткәне—иң азакта аккош чылбыры сыман тип-тигез сафларга тезелешкән чит хатыннар, сәлектәй сузылган зифа буйлы кызлар. Үләннәргә тиеп баручы озын итәкле ап-ак күлмәкләр-җиләннәр кигәнгәдер, ахры, аларның аяк атлаулары да күренми. Кызлар күл өстендәге каз-үрдәкләр шикелле тавыш-тынсыз, ымсыз-хәрәкәтсез генә йөзеп килә. Маңгай өсләренә асылташлар белән бизәлгән кәктүшләр* кигәннәр, иннәрендә аллы-гөлле чәчәкләр төшерелгән, чаклы-чуклы, матур башъяулыклар. Күбесенең муенсалары, беләзекләре ялтыр-йолтыр килә.

Чибәркәйләрнең һәммәсе дә керфекләренә сөрмә тарткан, битләренә иннек ябынган, ә чәйнек чаклы булып тулган мул һәм тыгыз күкрәкләре өстендәге саргылт толымнары кызлар атлаган саен елан сыман уйнап егетләрне ымсындырып тора. Болгар яугирләре җансыз түгел, авыз суларын корытып үзара сөйләшәләр.

—Әнә тегесен, зәңгәр калфак кигәнен кара, Хәмзә. Бер кашык су белән кабып йотарлык бит, малайкаем!

—Ә тегесенә, сары муенса тakканына күз сал. Моның белән бер мәртәбә булса да мунча керү бәхетенә ирешсәң иде ул! Аннары үлсән дә үкенерлек түгел.

—Болар Алланы танымый, болар мәҗүси бит. Аларның кызлары алга юмарт, диләр...

Урыс яубашлары Елантауга менә башлагач та Ибраһим ханга хәбәр индерделәр. Урысларның коралланган хәлдә килүен ишетүгә, Болгар ханы кылычын болгап атты.

—Кылычны кул таягы итеп солых төземиләр. Елантау өстенә менгән угъланнарга, газиләргә, укчыларга фәрман житкерегез. Һәммә яугир салаккылычларын яшереп куйсын! Баскынлык белән генә көн күрергә ният иткән халык Болгар иленнән ачы гыйбрәт алып китсен әле.

Ибраһим хан бәйге көткән ярсу чаптар кебек чатырыннан тышка ашкына иде. Каравылбаш Көбәк кереп кенә, ил хакимендәге көрпәлек укасын бераз коя алды.

—Син сыеры кысыр калгач капкасын шар ачып, теләсә нинди узгынчы үгезне дә ихатасына кертергә әзер торган жүнсез хужа түгел лә инде, тажлар. Жебегән кенәз, солых төзегән булып, синең кармагыңнан исән-имин ычкынырга ниятлиме? Шулай икән, әүвәл үзе маэмай сыман мүкәләп каршыңа килеп житсен. Ә син ияреннән соңрак, болыт өстендәге алиһәләр кебек итеп кенә төшсәң дә бик килешә. Табынга көттеребрәк китерелгән ризык һәрчак тәмле була...

Ниһаять, вәзир Насыйр үзе кереп житте.

*Кәктүш – кокошник; бнек, текә калфак.

—Килделәр, Ибраһим хан. Кенәз үзе дә, яраннары да монда. Кояш кебек чыгып күрен, әйдә.

Ибраһим чатырның ишек төбендә кылыч-хәнҗәр аскан Сал-Салны күргәч, елан чаккан төсле агарынып калды.

—Мин һәр болгар яугиренә коралларын яшерергә, дигән әмер бирдем. Ә син фәрманны ишетмәдеңмени?—дип теш арасыннан сытып чыгарды ул сүзләрен, атаказ шикелле ысылдап.

Сал-Салның йөзе-кыяфәте болай да кара янган иде. Сүзләрен бизмәндә үлчәгән шикелле тартып-сузып кына җавап бирде.

—Андый фәрман сәрдәр кешегә кагылмый, дип беләм. Бер аягы белән элмәккә утыртылган булса да, лачын кошлар һәрчак чукышырга әзер булып тора.

Ибраһим янә яшен чатырдаган төсле коры тавыш белән дәшәргә мәҗбүр булды.

—Син урыс сәрдәре белән орышка чыгарга насыйп булмады дип, ялан-кырда җил куалап йөрмә. Алатауда үскән качак булсаң да, сиңа Болгар иминлеге турында кайгыртуны өйрәнергә вакыт. Ә хәзер, бар, Елантау астына төш тә, Олы Кабан күле белән ике араны бикләә. Юньсез кешене ипкә-сапка кертү—кәкрәйгән кадакны төзәтү генә түгел. Баскын кенәз, әнә, тагын корал тагып килгән. Иелгән башка төкерүләре дә, аны хәтта кыеп төшерүләре дә мөмкин. Сәрдәр икәнсен, син сакта тор...

Сал-Сал кар астына чумган ерганак шикелле тавыш-тынсыз гына эреп юкка чыккач, һәммәсе дә яңа чатыр янына юнәлделәр. Чатыр тирәләп, яланда йөреп аргач капка төбенә кайткан йорт казлары сыман, алтын-көмеш җепле акъяулыклар япкан, мәрҗән ташлы калфак, көмеш тәңкәле хәситәләр, аллы-гөлле бизәкле ак вә кызыл читекләр кигән кызлар тезелешкән. Шуларның нәкъ уртасына, йөзек кашы сыман булып, җиләктәй пешеп җиткән Айзирәк чыгып баскан. И-и, озынкөн буена керфек тә какмый кыздырган кояш шикелле эчкерсез, самими нур бөркегән карашлары аның! И-и, куе яфраклар арасыннан масаеп сузылган чияләрдәй кызарып янулары! И-и, аның тәти курчак көткән сабый кебек нәүмиз елмаюы! Ибраһим хан Айзирәкне күреп шулай сокланды да, бар зар-хәсрәте җил себереп алгандай шундук юкка чыкты.

Кылыч-сөңге тотып керпедәй кабарса да, урыс илчелеге барыбер Елантауның читенә, сөзәк итәк тирәсенәрәк тезелешеп баскан. Владимир кенәз, әлбәттә, уртада, жансакчылар ышыгында тора. Добрыня сәрдәр, әнә, сугыш әтәче шикелле, кем якынайса шуның өстенә очып кунарга әзер. Башкалар да бер кулларын кын өстенә салган. Карашлары авыл уртасындагы ихатага барып кергән бүренекедәй уяу. Боларның хәтта борын яфракларына тикле киерелгән.

Ибраһим хан арткы рәттә торган бер укчы ир кулында кечерәк кенә казан шәйләп өлгерде дә мизгел эчендә шабыр тиргә батты. Әстәгыфирулла! Ибраһим хан үзе урысларның яу башлыгы булган Святославка бүләк итеп биргән алтын казан бит бу! Моннан егерме ел элек, Ашлы каласында. Ибраһим ул вакытта урыс кенәзенә әлеге казанны "бу безнең уртак дуслык чагылышы булсын, безнең өскә яу йөрүне туктат", дип тәкърарлый-тәкърарлый әйтеп биргән иде. Нигә Ибраһим хан гозерен тыңламаган кенәз? Бу гозерне нишләп үз балаларына нәзер итеп әйтеп калдырмаган? Кыркымыш сарык йоныдай нинди кыска, сай хәтерле кавемнән соң болар?..

Шулай да, Владимир кенәз батыр кеше икән. Яраннарына ым гына какты да Ибраһим ханга каршы япа-ялгыз китте. Кул сузымы ара калуга ук, кан дошманын иң беренче булып кочагына алды. Сүз башлаганчы әллә ничә тапкыр тамак кырды. Ул учак өстенә куелган казан кебек, чыннан да, дулкынланып-кызып чыккан иде бугай.

—Кулга кылыч күтәреп орышучы пәһлеваннарга караганда да куәтлерәк жаннар бар икән бу дөньяда,—дип, ниһаять, бар мәйданга ишетелерлек куәт белән сөйли башлады ул.—Кирәк чакта ярсуын авызлыклап, яу кылычын кабат үз кынына тыгып куя белгән илтабарлар да бар икән жир өстендә. Без Болгар жиренә килгәч менә шундый кешене эзләп таптык. Андый олы жаннар, ил мәнфәгатен уйлап һәм дан-шөһрәткә күмеп яшәүчеләр кылыч тотып баскан мең яугиргә караганда да куәтлерәк икән. Болгар туфрагында әнә шундый көчле, туганнардан да якынрак булырдай дусны очраттык без. Ул син, Ибраһим хан! Ул сез, болгар дуслар! Менә шуна күрә орышны-яуны туктатып, дуслык солыхы төзергә карар кылдык та без. Моннан ары Киев белән Болгар арасында һичбер дошманлык юк! Бер-беребез өстенә яуга йөрешмибез! Ике олуг мәмләкәт арасында сәүдә кәрваннары гына йөреп торсын. Бер-беребезне талау-рәнжетү юк. Без мәңгелек дуслар!

Мәйдан читендә, алдан котыртып куйган шикелле, Добрыня сәрдәр дә капылт эләктереп алды.

—Дуслык солыхы төзибез, дуслык солыхы! Урыс белән болгар моннан ары мәңге-мәңге дуслар!

Арттa, көттереп кенә, боярлар да дәррәү кычкырдылар.

—Дуслык кына насыйп булсын безгә! Дуслык, дуслык!

Күзләренә яшь бөртеге бәреп чыккан Ибраһим хан үз колакларына үзе ышанмагандай кат-кат сорау бирде.

—Ә безнең бу солых без икенче мәртәбә очрашканчы гына булмасмы соң, кенәз? Кабат кырда-далаларда бер-беребезгә тап булырга туры килгән чакта без янә юньсез тәкәләр шикелле сөзешмәбез микән?

Владимир кайнар мунчадан соң саф һавага чыккан яшь кияүләр сыман изүләрен ачып җавап тотты.

—Юк, без солыхны гомерлек, мәңгелек итеп ныгытабыз, туган. Без төзегән солых гасырлардан-гасырларга, оныклардан-оныкларга күчеп барырдай булсын! Киләсе буыннар үрнәк итеп, ядкарь итеп искә алсын аны.

Ибраһим ханга да тулысынча жан кергәндәй булды, учактагы ялкын сыман кабынып, кайнар хисләр сипте.

—Алайса, безнең халыкта мондый очракларда әйтелә торган бик тә матур сүз бар. Таш су өстенә калкып йөзә башласа яисә колмак үләне таш шикелле су төбенә китсә генә бозылыр безнең дуслык.

Таждар авызыннан ишетелгән хикмәтле сүзләрне янга килеп тезелешкән олугбәкләр, меңбашлар һәм тылмачлар сокланып кабатлады.

—Аһ, ничек маж китереп, шәп әйтелгән сүзләр!

—Аһ, никадәр тирән мәгънәле фикер бу әйтемдә!

Тылмачларның катлы-катлы, бормалы-сырмалы аңлатмаларыннан соң Владимир кенәз дә шаккатып баш чайкады.

—Таш суда йөзә башласа йә колмак су төбенә китсә генә бозыла, диген. Мәзәк, сәер. Таш бервакытта да су өстендә йөзеп йөрми бит инде ул. Колмак үләне дә су төбенә китми. Вәт, әкәмәт!

Язгы тургай төсле очына башлаган хан ак чатыр янында уклау йотып торган битекчеләргә карап әмер бирде.

—Әй, кәгазь кортлары, җыен әрәмтамак! Сәркатибләр белән бергә уйлагыз да тантаналы шартнамә тудырыгыз. Мондый солых, андый шартнамәләр бездән соң киләчәк яңа буыннарга үрнәк булып калсын! Болгар тарихында мондый хәлнең әле булганы юк. Моннан ары урыслар белән мәңгелек дуслар, якын туганнар без!*

*985 елда булып узган мәгълүм вакыйгалар.

Тантана шаукымы исерткеч шәраб сыман, һәр кешегә бик тиз канат куя. Владимир кенәз дә тышауларын өзде.

—Юк, без ике дәүләт тарихындагы беренче солых төзүне болай гына очламыйбыз әле, Ибраһим хан. Дуслык, туганлык дигән сүзләр, буш вәгъдәләр булып, кәгазьләргә язылып кына калмасын ул. Тарихи солых төзү бәхетенә ирешкәнбез икән, бер-берсенә ярдәмгә ашкынып торырдай һәм мәңге өзелмәстәй чын туганлык җепләре белән беркетик без аны. Әйдә, мин сиңа үземнең кызым Василисаны хатынлыкка бирәм!

Болгарлылар үрә катып калды, урыс укчылары капкын-тозакка таба җанвар куа килгән сунарчылар төсле дәррәү кычкырдылар.

—Әй, Василиса чибәркәй, Василиса! Хан хатыны булачаксың, уртага чык!

Владимир кенәз ап-ак күлмәк, зәңгәр кәктүш кигән, саргылт чәчле, зәңгәр күзле, тыгыз тәнле сылуны бармак очларыннан тотып кына мәйдан уртасына чыгарып бастыргач, Ибраһим хан фәрештәнең үзен күргән сыман бөтенләй коелып төште.

—К-һм, ни, эһем-эһем, ни бит,—дип авыз эченнән генә ботка пешерде ул.—Инде ничә айлар буе хатын-кызга якын барган юк бит. Мин, ни, Айзирәкнең әнисен бик ярата идем. Шуны оныта алмыйм. Иллә мәгәр бу кыз... эх-ма, ничек каршы торыйм!

Ибраһим хан батырая башлап яшь кәләшнең билләреннән алгач, болгарлылар оясыннан куркытылган кош шикелле пырхылдап көлештеләр.

—Безнең хания күрше ихатадагы танага ияргән яшь үгез шикелле сырпалана, әттә генәсе лә!

—Чыбыркысы шәп шартлыйдыр әле, шундыйга охшаган бу!..

Бераздан Ибраһим хан акылына килде. Бармак белән изәп кенә вакыт сорады да, чибәр кызлар уртасында гөләп чәчәге кебек балкып-аерылып торган Айзирәк каршына китте.

—Кунак ашы кара-каршы булырга тиеш, кызым,—дип талгын, иплә тавыш белән сүзен башлады ул, Айзирәкне кочагына алып.—Без ике ил арасында зур солых төзедек, урыс кенәзе үзенең кызын миңа хатынлыкка бирде. Синең башка чараң юк, кызым. Син туган илеңнең иминлеге хакына миңа шушы кенәзгә хатынлыкка чыгарга тиеш булачаксың.

—Минем Сал-Салым бар бит, без аның белән үзара вәгъдәләшкән ярлар,—дип күз яшьләре аша калтыранды, өзгәләнде бала.

Ибраһим элеккечә иплә, әмма инде торган саен корычлана барган җитди тавыш белән үгетләвен белде.

—Ярлы-ябагай кызлары, әле хәтта олугбәк кызлары да әллә кемнәр белән гыйшык уйнап, миңа димәгәе, дию пәриенең үзенә дә кияүгә чыгарга хаклы, балакаем. Әмма синдәй ханәкәләр түгел. Син илең хакына, әтиең сайлаган отышлы гамәл хакына үз җаныңны, гыйшык утларыңны корбан итү өчен яралгансың, кызым. Миңа шуны анла да күз яшеннә сөрт. Авызың тулы кан булса да, чит кешеләр алдында төкерергә ярамый шул безгә, ярамый. Түз, ризалаш, балам.

Айзирәкнең дә язгы ерганак челтерәве шикелле генә тонык, зәгыйфь тавышы ишетелде.

—Әле булса Сал-Салны күрмәдем бит. Ичмаса, аның күзенә бер багасы иде.

—Кирәкми, балакаем,—дип ашыга-кабалана янә тезде ата.—Сал-Сал батырны мин кисәткән идем. Ул ризалашты, шуңа моннан сине калдырып китте.

Айзирәкнең куллары кыйнап ташланган аккош канатларыдай салынып төште, ул күз яшьләрен йотып үз карарын әйтте.

—Мин анладым, әти. Ил хакына шулай кирәк икән, мин карышмыйм.

Син кушканга күрә генә мин кенәзгә чыгам. Сал-Сал да баш тарткач, мина барыбер инде.

—Син акыллы, балакаем, рәхмәт, рәхмәт,—дия-дия кызын мәйдан уртасына таба этте ата.—Сине анда булачак ирен көтә, әйдә, горур атла.

Әле Ибраһим белән Айзирәк мәйдан уртасына килеп житкәнче үк Владимир кенәз күзләрендә шайтан уты яна иде инде.

—Бездә дә чит-ят дәүләтләргә, хәтта кахан илә кайсарларның үзенә дә хатынлыкка бирердәй кызлар юк түгел ул. Владимир кенәз! Менә сина бүләккә минем кызыкаем, Айзирәгем,—дип яшь кәләшнең кулларын да тоттыргач, баскын кенәз тәмам эреп китте.

—Новгородка, Ростов, Галичларга барып чыкканым бар. Мадьярлар, бәҗәнәкләр янына да кат-кат эләккәләдем. Инде мин лаек кәләш сорап юнан кайсары янына барырга йөри идем. Бактын исә, кайсар кызларынын йөзен, менен берүзе алыштыра алырдай чибәркәйләр сездә үсә икән. Рәхмәт сина, рәхмәт, Ибраһим хан!

Владимир кенәз күзләрен мут уйнатып Айзирәкнен билләрен дә кымтырыклый башлагач, мәйдан читендә янә Добрыня шәрран ярды.

—Һе! Сез бер-берегез белән үзара кияүләр дә булыштыгыз инде. Ә моның туй дигәннәрен кайчан, ничек билгеләп үтәбез сон? Туйсыз гына кәләш алышмыйлар ла инде ул, кит, әкәмәт!

Владимир кенәз хужа сыман кыйланып сүз ыргытты.

—Калган эшкә кар ява, ди, сузу-сонарту юк. Хәзер үк туй итәбез! Урыны шәп. Олауларда байлык, нигъмәт житәрлек. Туйны менә шушы төштә үткәрәбез.

Кулыннан дилбегә ычкына башлавын сизеп алып, Ибраһим хан гаярь аваз салды.

—Кунакларның, дусларның сый-ризыгы әле кайтыр юлда үзләренә бик күп кирәк булыр. Сез минем кызымны юлда ачлыктан интектерергә ниятләмисездер лә инде?—Анда-санда көлешү авазлары янгырап алды, хаким дәвам итте.—Ә кунакларны сыйлар-көйләр өчен безнен үзебездә дә ризык олы күл кадәрле. Әнә, күрәсезме?

Урыс укчылары зәнгәр төтен бөркеп утырган дистәләгән учакларга таба борылып авыз суларын корытты, ә Ибраһим хан дилбегәне янә каккалады.

—Урынын шәп, диден, Владимир кенәз. Менә шушы Елантау өстендә туй итәбез. Хәзер үк туй!

Йөзәрләгән ир-ат шундук эләктереп алды.

—Туй, туй! Ике кияү, ике хаким туе!

Күк күкрәвенә тиң тавыш басылуга Ибраһим хан яна тәкъдиме белән һәммәсен шаккаттырды.

—Әле моның белән генә эш бетмәде. Безнең бабаларыбыз элек заманда үк изге гамәл кылган урыннарында яна нигез кора торган булганнар. Мин дә шушы олуг жиңү, мәнгелек солых хөрмәтенә ошбу тау башында өр-яңа бер кала кордыртам. Без инде элек үк монда яна кирмән корырга кыжрап йөргән идек, кул житмәде. Менә, син булса да чеметеп уяттың безне. Калган эшкә кар ява, ди. Яңа каланың беренче казыкларын бүген үк кагып куям! Еллар, гасырлар үткәч, синең оныкларың да, бәлки, шушы солых хөрмәтенә нигезләнгән бу каланы яндырып юк итмәсләр.

—Ну инде, ну инде! Солых төзедек лә, нинди яндыру ди?—дип сөйләнә-сөйләнә Владимир кенәз борча талагандай бөтерелде.

Курсыбай газиләре "ә" дигәнче тап-таза имән казык табып китерделәр. Ибраһим хан аны кулларына алды.

—Аллага тапшырдык,—дип уч төпләренә төкеренгәләп куйды.

—Кая, мин дә кагышыйм,—дип Владимир кенәз дә имән казык янынарак

елыша башлаган иде, Ибраһим хан терсәге белән төртеп читкә арындырды.

—Һәрбер яңа кала—яңа бала сыман. Ә җир йөзендә бер генә баланың да атасы икәү-өчәү булганы юк әле. Бу безнең җир, казыгын да ялгызым кагачакмын!

Ниһаять, гайрәтле кизәнеп, Ибраһим хан казык башына чукмар белән орды.

—Меньяшәр кала булырга язсын инде, берук!

—Уртак кала булсын!—дип чак-чак кына ишетелерлек итеп пышылдады бер як читтә турсаеп торган кенәз.

Имам Мәрдән белән Локман хәзрәт читкә китеп кенә дога багышлады. Гади яугир белән ярлы-ябагайлар кыйбла якка карап намаз укыдылар. Беренче йолалар шул рәвешчә үткән генә иде, яна сорау белән кенәз аваз салды.

—Җиһан бездән онықларга кала. Бу җирләргә дә, бәлки, тора-бара яңа хуҗалар табылыр, каланың туган елы да әллә ничә тапкыр үзгәрер әле... Ә исемен, исемен ничек дип кушасың, Ибраһим хан? Җир йөзендә кушаматсыз мал да сирәк ләса.

—Исеменме? Исемен...—дип кабатлап торды таҗдар, аннары һичкем көтмәгәнчә капылт әйтеп салды.—Ә исеме Казан булыр, кенәз. Әйе, Казан! Бөтен ил белән бергә килеп аскан күмәк казан. Ахыр читтә, егерме ел үткәч үз иленә әйләнеп кайткан әнә теге казан. Алтын казан!

Ибраһим хан куллары белән төртеп күрсәткәч кенә, читтә янтаеп утырган ялгыз казанны шәйләп, һәммәсе "аһ" иттеләр. Хуҗа хаким тиз-тиз генә аңлатмалар бирде.

—Моннан егерме ел элек безнең өскә килгәч атаң Святославка нәкъ мин бүләк итеп биргән идем аны. Моннан бер йөз чакрым чамасы ераклыкта, Ашлы каласында. Бу безнең уртак казаныбыз булсын, яна яулар белән безнең өскә килмә, дип олы, изге хисләр кушып биргән идем. Атаң кабат килмәде-килүен, ә менә син барыбер дә килдең. Димәк, атаң сабак бирмәгән бит сиңа, нәзер калдырмаган. Менә, бүләк ителгән казанны да кулыңнан ычкындырган. Ул казанны өстерәп монда син килгәнсең. Яман фал бу. Мондый савыт юлда йөри башласа, сез үзегезнең аерым кала-олысыгызда аңа салырдай ризык таба алмыйсыз, ул ризыкны күршеләргә кереп кенә юнәтергә җыенасыз икән, дигән шик уяна. Ә кулдан-кулга күчеп йөргән казан гел уртак мал җыя...

Мондый юраудан соң ирләр арасында монсу-сагышлырак тынлык сарган иде, каравылбаш Көбәк аны йомры сүзе белән таратты да куйды.

—Кенәз, кенәз! Сез үзегез белмисез дә әле, ә безнекеләр сәрдәр белән икегезгә өр-яңа исемнәр уйлап тапканнар бит.

—Нинди исем тагын?—дип кенәз күз акайткач, Көбәк ярты ялан ишетерлек итеп шәрран ярды.

—Син Владимир түгел, Балтимерсен хәзер. Ә сәрдәреңнең яңа аты-наме төп-төгәл Дәүборындыр.

Сүзләрнең мәгънәсен тылмачлар аңлатып бетергәч, Владимир кенәз эченә кату төшкәнче туктаусыз шаркылдады.

—Балтимер, Балтимер, минеке ярый әле. Ну, менә синекен, туган агайкаем, ай-яй, туры китергәннәр дә инде. Дәүборын! Суйган да каплаган бит, бигрәк килешеп тора...

Йөзбашлар һәм вак түрәләр генә түгел, хәтта олугбәкләр дә казаннар белән ак чатыр арасында инде күптән тыз-быз килеп йөгерешә башлаганнар иде. Ниһаять, вәзир Насыйрның тантаналы, дәртле чакыру авазлары яңгырады.

—Туйга рәхим итегез, дустанә яшәргә ант беркеткән мәмләкәт таҗдарлары! Туй табыны сезне көтә, яшь кияүләр белән яшь кәләшләр!

Чәнчеләр һәм танбурчыларның дәртле аһәненә кушылып, Елантау өстен

янә йөзәрләгән яугирнең шатланып кычкырган тавышлары күмде.

—Туй итәбез, туй! Ике туган туе!

## 60

Кабан күлләре тирәли урнашкан баскыннар ыстанында жанланыш, хәрәкәт чаткылары өч көн үткәннән соң, әче таңда ук тоемланган иде. Бу хактагы хәбәрне ишетүгә Ибраһим хан кияү чатырыннан шундук чәчрәп чыкты.

—Хәзер үк аргамакны китерегез миңа!—дип каравылбаш Көбәк тарафына әмер ыргытты ул.—Бөтен гаскәр яу хәленә килсен! Аннан... аннан Сал-Сал сәрдәрне дә табып китерегез!

—Сал-Сал юк, Ибраһим хан. Сәрдәрне инде ике көн буе эзләп тә таба алмыйбыз.

Ибраһим шөпшә тешләгән шикелле боргаланып, ярсып жикеренде.

—Кайда соң ул, кайда? Ике көн буе да табылмагач, нинди сәрдәр ди ул?

—Берни белүче, күрүче кешеләр юк,—дип, Көбәк элеккечә гаепле төс белән аклануын белде.—Качып китмәгән булса ярый инде тагын.

Ибраһим хан янә котырынды.

—Качкан икән, качкан. Төкерәм мин аңа! Болгар илендә сәрдәр итеп куярдай ирләр беткәнмени? Менә, син булырсың!

—Әй-яй, Ибраһим хан! Сәрдәр—канизәк тә, сөяркә дә түгел. Чәчбиләрне ятакта көнсаен да алыштырып була, әмма язгы боз шикелле ышанычсыз, яки тимерче миченддәге булат хәленә китереп сыналмаган, чүкелмәгән сәрдәр белән тәхет тоту кыен. Син әмер бирәсең икән, сәрдәр булырмын мин анысы. Тик хәзер үк кисәтеп куям, мин Сал-Салны алыштыра алмыйм!

—Син алыштыра алмасаң, янасын куярбыз!—дип элеккечә жикерде Ибраһим хан.—Түрә урынына кызыкмаган кеше буламыни? Майлы калжа һәрчак ымсындыра.

—Анысы шулайдыр да, әмма ул калжаның зәһәр капкын эченә көйләп куелган булуы да мөмкин...

Тагын да дәгъваләшергә ирек бирмәделәр. Елантау өстенә янып-пешкән яна чапкын егет менеп житте.

—Кенәз белән сәрдәр бу тарафка килә. Бик житдиләр. Олы гозерләре бар ахрысы...

Бу юлы инде коралсыз гына килгән яубашларның сүзе асылда житди булып чыкты.

—Миңа Киевка коры кул белән әйләнеп кайтырга ярамый, моны аңлыйсыңдыр,—диде Владимир.—Аннары илдәгеләр миннән бот чабып көләчәкләр. Мин атай юлы буйлап китәргә карар кылдым.

—Һаман бер үк балык башы, тагын Йосыф кахан өстенә барырга жыенасыңмыни?—дип Ибраһим хан сүз кыстырып куярга мәжбүр булды.

Владимир кырт кистереп, катгый жавап тотты.

—Барам, Ибраһим хан! Хәзәр каханы безнең икебезне дә нык имде, күп сауды. Аны кан белән костырырга вакыт. Син каханга каршы кылыч күтәрергә жөрьәт итмисең икән, мин аның йортына япа-ялгыз кое бәреп керәм! Сукыр тычкан кебек качып-посып кына жан асраудан, кәрван-кәрван ясак озатып ятулардан менә болай гарык! Йә кырылып бетәбез, йә жинәбез! Башка юл юк!

Мин-минлегенә балта чабылган Ибраһим хан йөзен чытып аның сүзен бүлде.

—Ә син мине кай нисбәттән куркаклыкта гаеплисең әле? Кахан каршында куянтә шикелле бөгелеп яшәүләрдән мин дә туйдым. Йосыф

каханны тәхетеннән чәнчелдереп төшерү Болгар иленә дә хөрлек, мөстәкыйльлек алып килә. Шуңа күрә мин дә синең яу сәфәреңә кушылырга риза! Бар нечкәлек фәкать синдә генә. Сиңа ничә мең яугирлек гаскәр бүлеп бирим?

Бу юлы кенәз урынына Добрыня сүз тотты.

—Жиде мең, Ибраһим хан, төп-төгәл жиде мең баш җайдак. Без синең иленә сәфәр чыгып, шулчаклы ир югалттык.

—Ярар, һичбер төрле тоткарлык та булмас,—диде Болгар ханы, бик тә ансат күнеп. Әмма яңа җөмләсе белән баскын яубашларны кайнар суга салды.—Иллә мәгәр олы бер шартым бар. Сез Елантау эргәсенә килеп урнашканнан бирле гаҗәпләнеп йөрдек. Сезнең һаман һичбер аллагыз юк, сез чирмеш, ар һәм мукшы кабиләләре сыман кырыкмаса-кырык төрле потларга, җансыз сыннарга табынып көн күрәсез икән. Сезгә дә фәкать бер аллага гына табынырга, изге дин юлына күчәргә вакыт. Мин бүген үк, кичекмәстән безнең дингә күчегез, дип әйтмим. Динне кабул итү өчен аңа җаның-тәнең белән инанырга, аның бар канун-йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кирәк. Менә шуңа күрә синең даирәңә безнең муллабызны, ислам диненең барча нечкәлеген белгән имам-хатыйбны кушып җибәрәм мин.

Ибраһим хан мәйдан уртасында хасил булган тагын бер яңа чатыр ягына борылып оран салды.

—Әһ-һәй, имам Якуб Ногман! Монда чыгып күрен!

Борын астына тычкан койрыгыдай нечкә мыек җибәргән япь-яшь егет пәйда булды. Кенәз белән сәрдәрнең гаҗәпләнеп текәлүен күргәч, Ибраһим хан үзе аңлатмалар бирде.

—Яшь икәнлегенә карамагыз. Ул Коръәнне су урынына эчә. Андыйларны бездә Коръән-хафиз, диләр. Юлда чагында да, сараеңа кайтып җиткәч тә сиңа аның үгет-нәсихәтләрен, вәгазьләрен тыңлау комачауламас, кенәз. Мин ышанам, син үзең дә, урыс милләте дә без сайлаган изге динне якын итәчәксез. Ә дәүләтең белән ислам диненә күчсәң, без бер ана балаларыдай газиз туганнар булып та көн күрербез әле.

Владимир кенәз Ибраһим ханның һәммә мәшәкатен уен сыман кабул итте бугай, кулын селтәп кенә җавап бирде.

—Киев, чыннан да, бер асыл дин сайларга тиеш инде. Бу яшь егет безне ислам ягына борып куя алса, әйдә, сихерләсен. Үзенең кыйбласына инандыра икән, без сезнең динне кабул итәргә риза...

Елантау өстендә инде икенче көн буе балта тавышлары ишетелә иде, Владимир тирә-юньгә күз ташлады. Чыннан да, гаҗәеп хәл хөкем сөрә икән. Әнә, дистәләгән ирләр җилән-күлмәкләрен салып ташлаганнар да, икешәр дилбегә буе бүрәнәләрне яланнын бер башыннан икенчесенә мамык каурый шудырган шикелле генә итеп сөйрәп күчерәләр. Бүрәнәләрнең күбесе инде каезланган, алар ап-ак сөяктәй ялтырап, күзләрне камаштырып тора. Һәр агачның баш-башларында матур уентыклар, буеннан-буена тигез итеп алынган улакчыклар. Оста куллар һәркем көнләшерлек итеп башкарган бу эшләрне. Бүрәнәләрнең бер-берсенә сумаладай берегеп ятасына шикләнерлек түгел. Балта осталары үзләре дә канәгать, күрәсең, ара-тирә тел шартлатып дәшкән авазлары ишетелеп куя.

—Их, бүрәнәсе дә бүрәнәсе! Валлаһи, җанлы кебек! Менә мондый бүрәнәләрдән салынган сарайларда яшәсәң дә була!

Җор телле сүзләр һәр җирдә табыла, өстәп-төрттереп куючылар бик аз түгел.

—Йортың моннан кайтыш агачлардан салынган булса да ярый ла ул. Иң мөһиме, култыгында кайнар җанаш булсын!

—Иелгән саен ирлегеңне искә төшереп торырдай җанашың янда булмаса, алтын сарайларда яшәүдән ни хикмәт?

Ирләр нәсел айгырлары сыман кубып дәррәү көлешәләр, хәтта күк капусы кинәйгәндәй була. Шулай, дәрт белән, килешеп һәм көлешеп үткәргән өмәләрдән дә татлырак мизгелләр юк инде ул ир-атка. Мондый чаклар бик аз тәти шул ул.

—Көнләшәм мин сездән,—дип куйды Владимир кенәз чын күнелдән.—Без Киев жирендә бер-беребезнең калаларын үзара яу йөреп яндырабыз, ә сез кирмән артыннан кирмән тергезәсез. Безгә менә мондый тәртип кайчан керер инде?

Ибраһимның: "Яу йөрүдән туктагыз",—дип төрттерәсе килеп китте. Теле бик тә кычытып тора иде, дәшми калды.

Владимир кенәз белән Ибраһим хан бер-берсен кочакларына алып саубуллашты.

—Кунакның гомере өч көн, юл кешесенең юлда булуы хәерле, ди, без кузгалыйк,—дип хушлашты кенәз.—Инде шушы Елантау өстендә, өр-яңа кала нигезендә төзегән солыхыбыз җимерелмәсен дә яу сәфәрләребезнең юллары кисешмәсә генә ярар иде.

Яубашларны түгәрәкләп алган болгарлылар бердәм кабатлады.

—Шулай була күрсен, кенәз, амин, амин!

## 61

Болгарлар белән урысларның күмәк гаскәр төзеп сәфәр чыгуына бер атналап вакыт үтте инде, ә Ибраһим хан һаман яшь кәләше белән кереп бикләнгән чатырыннан ерак китә алмый. Дөрес, кияү чатырын Елантау өстеннән төшереп, исемсез елга буена, нәкъ Нургали чишмәсе каршына күчереп кордыртты ул. Чөнки табигатьнең холкы соңгы көннәрдә керәле-чыгалырак, яшь киленнәр төсле көйсезләнә, иртәгә кайсы яклап терсәк күрсәтәсен һич тә аңламассың. Әле озын, кара итәкләрен Елантауның түбәсенә сөйрәп авыр болыт уза, әле тауны йөз кисәккә бүлгәләп һәм тетеп ташларга җыенгандай яшен кылычы чытырдап-айкап ала. Күк йөзеннән фәрештәдәй ингән Василисаны әнә шул яшен утлары куркытты да инде.

—Тау түбәсе түгел, утлы таба бит бу. Ирем куенында онытылып үбешә дә алмыйм. Чытырдаган һәрбер яшен кылычы астында дер калтырап бишкә бөгелгәнче, әйдә, тизрәк тау астына төшик. Ичмаса, шунда рәхәтләнеп назга күмелербез.

Яшь хатын сүзе олыгая башлаган һәр ир өчен тайпылышсыз канун. Монда хан яки әмир булуның аермасы һич юк. Ибраһим да муенчакка утыртылган көчек кебек уйнаклап шундук Нургали чишмәсе янына төшеп житте. Юкка түгел, каһәр! Василиса хәзер аны куеныннан бер дә ычкындырмый. Ул әле үзе Ибраһимның өстенә менеп атлана да ими башларын аның мыекларына тидереп уйната-сикертә рәхәтләнә, әле юрган астына чума да яшь кияүне ожмах бакчасына кертеп адаштыра. Ибраһим шәраб эчеп исергән сәрхүш сыман тәүлек буе иләсләнеп ята. Ул мескен дә элек үзен иркәлек-наз татыган ир урынына санап яшәгән икән бит, и-и, томана!..

Менә шуңа күрә әледән-әле кереп, үзен бимазалап йөргән вәзир белән олугбәкләрнең сүзенә бик үк ыжламый ул. Тик шулай да, ил хуҗасы булгач, колак салмыйча мөмкин түгел. Ә тегеләр, сукбай тәненнән бет эзләгән шикелле, җыен вак-төякне табып кына тора. "Яшь кәләшең безнең дингә индерелмәгән бит, никах укыту фарыз булыр", диделәр. Таҗдар шундук күнде. Менә, биш көн буе аның яшь хатыны Вәсиләкәй хәзер, Василиса түгел. Аңа карап кына кәләшнең иреннәре-тәне суынмады, ул утлы күмер шикелле элеккечә кайнар.

Аннары якындагы бер авылдан тапкан чирмеш камын тотып китерделәр. Чәче мич пумаласы шикелле тузгып, катып беткән. Биленә һәм муенына аскан кыл бауларга кипкән чуртан башлары, бүре һәм аю тешләре, тавык тәпиләре тезеп чыккан. Өстенә аллы-гөлле төскә манылган, катлы-катлы киндер күлмәк кигән, ләкин һәммәсе дә эт талагандай кылка. Әлеге кам аламасының хәтта зәһәр исенә чыдамалы түгел, әмма аның сәер хорафатын, барыбер, тешләрне кысып тыңларга туры килде.

—Син яңа кала урыны итеп сайлаган бу тауның олуг хуҗасы бар. Ул яркант шикелле итеп канатларын җәйгән зур аждаһа. Ул монда көн дә кунмый, сирәк кенә килә. Аждаһа юк чагында тауга хуҗа булып вак еланнар кала. Вак дисәң дә, алар арасында дилбегәдәй озыннары, бүрәнәдәй юаннары ысылдап-ыҗлап йөри. Алар синең монда аждаһа рөхсәтеннән башка килеп утыруыңа бик нык рәнҗегәннәр. Ул еланнарның көтмәгәндә килеп сине чагуы бар. Мондый бәладән исән калыйм дисәң, иң әүвәле, Елантау түбәсенә меңәрләгән учак кабызып, аның хуҗасы булган аждаһаны да, вак-төяк еланнарны да куып җибәрергә, ә аннары аларны бәхилләтер өчен корбанын да китерергә кирәк. Аждаһаны күп очракта менә шушы Нургали чишмәсе агып чыккан мәгарә авызына килеп куна, диләр. Корбанны да, мөгаен, шуннан эзләр.

—Әллә нинди сәер һәм бормалы бу синең хорафат-юрауларын,—дип Ибраһим хан кул селтәмәкче булган иде дә, чирмеш камы усаллана барып таләп итте.

—Юк, берничек тә сәер йә бормалы түгел, хан. Син асылын аңламадыңмыни? Әлеге тауга тик бер генә җан иясе, аждаһа гына хуҗа. Тау түбәсе—вәкарь чаптар сыман, ул үзен дистәләгән кеше иярләүне сөйми. Икенең берсе: йә аждаһа хуҗа булып кала тау башына, йә син булачаксың. Йөзәрләгән учак тергезеп, тоташ ут кабызып, мөгаен, син ялгыз аждаһаны куып та җибәрерсең. Мәгәр үзең аның өстендә гомер буена, гасырлар буена бердәнбер һәм азат хуҗа булып тора алырсыңмы? Елантау кулдан-кулга күчеп йөрүләргә лаек түгел. Башкалар аңа хуҗа булырга ымсынмасын өчен Елантау буена чит-ятларны китермәскә кирәк. Әгәр читләр камалышка алып ут төртсәләр, сиңа да нәкъ аждаһа шикелле чыгып качу юлы гына кала... Тизрәк корбан китер!..

Чирмеш камы китте, ләкин аның хикәяте белән тәэсирләнгән таҗдар Елантау өстенә тоташ ут ягарга барыбер әмер бирде. Тау башында йөзәрләгән учак дөрли башлауга ук, хан чатыры тышында әллә ничә ирнең саташулы тавышы яңгырап ишетелде.

—Әнә, әнә, кыйбла якка кара! Ике канатын җилпеп аждаһа күтәрелде. Әнә, инешнең икенче ярына таба очып бара!

—Китче, китче! Пыскый-пыскый очкан салам көлтәләре генә түгелме соң?

—Юк ла инде, юк ла, үзем күреп тордым. Канатларын җилпи-җилпи аждаһа очып китте. Без Елантауга хуҗа булып калдык!..

Икенче танда имам Мәрдән белән Локман хәзрәт килде. Үзләре сөенеч китергән төсле, үзләре калтырыйлар. Чатыр тышына күлмәкчән генә чыккан Ибраһим хан аларның гозерен көчкә аңлый алды.

—Нургали чишмәсе янында бер-бер хәл булмасмы дип сакка төшкән идек. Мәгарә эчендә әүвәл ниндидер карачкы шәүләсе ялтырап алды да капылт гаип булды, аннан коры сөяккә калган карт эт чыкты. Ипи сыныгы ыргытып мөритләр теге этне кулга эләктерделәр. Әллә... яңа кала астына корбан итеп... шул хуҗасыз этне суйыйкмы соң әллә?

Ибраһим хан, үкчәләре белән җиргә тибеп, давыл сыман дулап җикеренде.

—Нинди эт сую ди?! Кая сездә гакыл? Корбан итеп эт чаласын икән, димәк, бездән соң этләр кулына калачак бит Казан! Чирмеш камы бик тә хак сүз ычкындырды. Казан каласы гомер буе, мәнге-мәнге тик безнеке генә булырга тиеш! Аны эт каны белән буяу, ана эт аягы бастыру да хәрәм!..

Имам Мәрдән белән Локман хәзрәт капкын авызыннан чак качып котылган бүреләр шикелле койрыкларын кысып, тавыш-тынсыз гына китсәләр дә, өйлә намазыннан соң янә килеп тә життеләр. Бу юлы инде үзләре генә түгел, яннарында бер сукыр сукбай бар. Сәләмә киемнәреннән, тоташ жыерчыктан хасил төс-кыяфәтеннән үк сизелеп тора: урау, озын юллар үткән дәрвиштер бу.

—Жаек аръягыннан, Жидесу иленнән үк килгән,—дип таныштырды имам Мәрдән.—Үзе чичән, үзе күрәзәче. Яна кала язмышы хакында берәр гыйбрәт ачып салмас микән? Бергә-бергә сорап карыйк әле.

—Казан каласын нинди язмыш көтә?—дип эндәшкән хан ягына таба йөзен дә бормады бу сукбай чичән. Яна кирмән нигезләнү хакында әле юлда ук ишеткәндер инде, солы биштәренә төртелгән ат шикелле, иреннәрен чапыр-чопыр ялмап тезеп китте.

—Озын гомерле булачак бу кала. Мең кат егылып, мең кат тереләчәк. Кай елларда ут-янгын да ялмап алыр аны, әмма даладагы кылган төсле янә уяныр, янә күтәрелер. Көтү-көтү булып әллә ничә дошман килер аның өстенә, әмма күп гасырлар буе бер гаскәр дә аны тез астына егып сала алмас. Тик берзаманны каланың үз эчендә үләтләрдән хәтәр яман бер чир котырып кузгалыр да ошбу кирмән дошман кулына төшәр. Аннан ары Казан шул дошманнар каласы булып исәпләнер, ана шөһрәт һәм дан китерер...

—Нишләп дошман кулына төшәр соң ул?—дип хәзрәтләр бердәм чәчрәп купканнар иде дә, сукыр чичән һаман үз жаена, салмак дәвам итте.

—Дошман умарта күче кебек өерелеп килсә, дәүләтләрнең язмышын ике юл хәл итәр. Берсе—каланы бирмибез, дип киребеткән, мүкләк кәжә сыман үжәтләнү. Бу очракта гаскәрең белән илбашынны капчыкка салган бүре урынына кыйнап үтерәләр. Икенче юл—гаскәренне һәм халкынны саклап калу бәрабәренә кирмәнне ташлап чыгу.

—Соң, кирмәнне дошман кулына ташлап китү—ул жинелү ләбаса!—дип янә Ибраһим хан ярсый-ярсый чичәнне бүлгән иде, тегесе аның сүзен чебен куган кебек кире какты.

—Көя кисә, көя талый, дип үз күлмәген баш астына салып йоклаган тилене күргәнең бармы, таждар? Яки, нәкъ киресе. Умарта күче килеп ябырылса, бер бәндә дә үз күлмәгенең итәк астына качып котыла алмый. Мең кат сынаган бар: мондый чакта кеше күлмәген сала да аны селтәп-болгап кортлар талавыннан котылырга тели, ахыр чиктә, читкә-янга качып, якын-тирәдәге күл эченә чума. Менә шушы ике мисалдан соң нинди нәтижә килеп чыга, таждар? Димәк, һәр ике очракта да адәм баласына күлмәгеннән бигрәк башы кадерлерәк. Күкрәк баласы гына әнисенең имчәгеннән башка берни белми, ә акылы бар илбашы камалышта калган кирмәнгә ябышып ятарга тиеш түгел. Буш калдырылган кирмәнгә барып кергән дошман үзе капкынга эләгә ул. Аннары аның үзен ничек кирәк шулай ябырыл да тала. Алай итсәң, дошман үзе күлмәк-ыштаннарын сала-сала чыгып йөгерәчәк. Менә шуны аңламыйча, тар маңгайлы булганга оттыралар ханнар...

Ибраһимның аркасы буйлап кайнар сумала йөгергәндәй булды, сукыр дәрвишкә каршы саллы дәлил китерә алмаганы өчен бөтен тәне янды, янә кәефе кырылды.

—Алып китегез моны,—дип ысылдады ул имам Мәрдәнгә, ишетелер-ишетелмәслек кенә итеп.—Жыен сукбайны минем янга ташып йөдәтмәгез.

Сукыр кеше колакка сак була. Дәрвишнең бик әрнеп-үртәлеп мыгырдаган тавышы ишетелде.

—Шәп сандугачның башына анын шәп сайравы җитә, ди. Йөзгә бәреп әйтә торган хакыйкать—ул һәрчакта да артык кашык кебек. Андыйларны бер хуҗа да сөйми...

Хәзрәтләр "баш өсте, хуҗабыз", дигән төсле иелә-бөгелә китеп барсалар да, ахшам намазы алдыннан икесе дә янә күренделәр. Икесенең тиң йөзе акшар сөрткән төсле агарынган иде.

—Мәгарә эчендә эт белән бергә йөргән карачкыны тагын күргәннәр бит. Чәче-башы ап-ак, сакалы биленә җиткән, теләсә нинди ертык-мыртык, кылка киемнәргә киенгән, ди. Иң сәере: анын ике кулы да терсәктән тиң кисеп ташланган, җиң эчләрендә ике зәгыйфь ботак кына тырпаеп тора икән. Болгарга теге чакта "йөзбаш Атлаш Тимер-Мөэминнең ике кулын чабып ташлаган", дигән имеш-мимеш хәбәр кайткан иде. Бәла табан астында йөри, ди. Бу карачкы Тимер-Мөэмин урыслар калдырып киткән катил-мазар булып чыкмагае! Илбашларны читтән килгән утыз меңле, илле меңле дошман гаскәреннән саклап калып була ул. Мәгәр бер хыянәтче соранның пычак йөзеннән аралап калу өчен бөтен халкынның да, дәүләтнең дә көч-гайрәте җитми.

Ибраһим ихахайлап көлде.

—Куркак җанга урмандагы һәрбер агач төбе бүре башы булып күренә, ди. Мең кат әйттем инде, җыен юк-бар ташып, саруымны кайнатып йөрмәгез әле монда!

Хәзрәтләр шыпан-шыпан гына юкка чыкты. Елантау итәкләре өстенә иплән кенә караңгылык ятты. Хан чатырыннан күгәрченнәр кебек гөрләшүче сөекле ярлар тавышы ишетелә иде, аны тынлап торуны арусынмыйча, шыгавыллар читкә китеп басты. Томан төшкән кебек сиздермичә генә төн уртасы җитте, җиһан кышкы урман йокысына талды.

Нургали чишмәсе агып чыккан мәгарә ягыннан сыңар таш кисәге тәгәрәгән тавыш ишетелде, игътибар итмәделәр. Чатыр янына бикле ишекне тырмалаучы песи баласы шикелле кыштырдап шуышкан шәүлә якынлашты. Чатыр эчендә фәкать балавыз шәм яктысы гына җемелдәп тора иде. Менә шәүлә чатыр авызына килеп җитте, эчкә башын тыкты. Чәче-сакаллары яңа явып үткән ак кар сыман, авызына каен кайрыларыннан ясалган олы тырыс капкан. Шәүлә шул тырысны чатыр эченәрәк кертеп куйды, борыны белән төртеп аны бер янга аударды. Эчке якта йомран сызгырган кебегрәк тавыш яңгырауга, шәүлә чатыр авызыннан шундук юкка чыкты...

Икенче көнне өйлә вакыты җиткән чакта гына чатыр эченә аяк басарга җөрьәт иттеләр. Ибраһим хан белән Васила-Василиса шәп-шәрә көенчә, ике елан янәшәсендә җансыз ята иде.

## 62

Сал-Сал Елантауны ташлап киткән беренче тәүлектә генә көне буе чапты. Югыйсә, артыннан куа чыкмасларын да, үзенең бер йөз аучыга тоттырмас җайдак икәнлеген дә анлый, белә иде. Тик, барыбер, тәнендәге бар ярсуын, үчен, рәнҗүләрен дала өстенә каурый урынына коеп калдырырга җыенгандай, Акбуранны кызганып тормыйнитми алга куалады да алга куалады. Әйтерсең лә, күк күкрәгән төсле дөбердәп, аны арттан үртәп-мыскыллап кычкырган ачы авазлар янаклый-янаклый куа, ә ул, шулардан колакларын томалап котылырга ашыккандай, һаман ераклаша, алга кача иде.

Каршында сазлыкка эләккән олау шикелле менә жимерелә м, менә авам,

дип торган иске йорт аламасы урнашкан кеп-кечкенә бер аланлыкка килеп кергәч кенә сәерсенеп, сискәнеп туктады ул. Нинди таныш чалымнар бар соң монда, күнелгә якын нинди ызаннар бу? Хәтер сандыгында, чатнап беткән көзге кисәкләре кебек ялт-йолт килеп, дистәләгән мизгел ялтырап үтте. И-и, син икәнсең лә бу, киндек каным тамган газиз нигез! Очарга, талпынырга дип, әткәм-әнкәм канат биргән ызан! Яшәргә, аумаска тырышып синең камылларыңа ябышкан һәм беренче мәртәбә иннәренә таянып аягурә баскан газиз туфраккаем! Ничәмә-ничә ил-далалар, утлар-сулар, канлы яулар үтеп, никадәрле хаким-түрәләр каршында бил бөгеп тә бер уч бакыр акча, яна киндер күлмәк, ярты кабым икмәк тә юнәтә алмаган мескен, ятим улың гап-гади, ялангач кол хәлендә синең каршыңда башын иеп тора. Илен-халкын түгел, хәтта үз нигезен дә данлый алмаган игелексез, сукбай улыңны кабул итәрсеңме? Бу җиһанда аның бер бәндәгә, сынар байбәтчә түрә-хакимнәргә тишек кәвеш чаклы да кадере, кирәге юк.

Сал-Сал газиз тупса туфрагына ятып озак өзгәләнде.

—Ярар, яр-р-р-ар,—дип, саташкан кешедәй, үз-үзенә кычкырып эндәште ул.—Һавадагы иң гүзәл аккошны, күк йөзендәге иң якты йолдызны кулларыңа эләктермәкче идең. Битенә "лач" иттереп төкерделәрме, туган? Шул-лай. Җир йөзендә һәркемнең үз урыны. Шайтан таягы икән, ул әрекмәннәр, алабута, кычыткан янәшәсендә. Күкчәчкәләр, лалә, гөләпләрнең үз түтәле, кишәрлекләре бар. Алабута, саташып, канәферләр ышыгына барып борын төртсә, аны төбе-тамыры белән йолкып ыргыталар. Син күк йөзендәге иң матур, иң алсу йолдызны күрергә маташкан сукыр кеше кебек хыялланма. Атаң Байдар менә шушы яланлыкта Сания исемле бер ялгызны, үзенә язган лаек парны очраткан бит әле. Җиһан чиксез, тәкъдир дигәннәре йөгәнсез ат сыман. Үпкә-сагышларыңа кул селтә дә үз тиеңне көт син!.. Аннары... аннары тәхет хакына, ил хакына дип бил бөгеп һәм җан түгеп йөргәннәрең өчен мәрхәмәт һәм рәхмәт сүзләре дә көтеп азапланма. "Изгелек эшлә дә суга сал, халык күрмәсә, балык күрер", дигән аксакаллар сүзе тиктомалдан гына туар идемени? Шулай, изге гамәлләрне, корбан бирүләрне бәяли белердәй хакимнәр юк бездә. Халык яклы яисә ватан җанлы кешеләр бездә гомер буе ятим. Шул, ел-гасырлар үткәч, оныклар күреп бәяләсә генә. Кичәге мәшәкатьләреңне, йөрәк яраларыңны оныт, Сал-Сал. Иске бишмәт бүре талаганда булса да ярап тора, диләр. Бәлки, сиңа да берәр кайчан иске бишмәт, иске балта төсле искә төшерерләр, сагынырлар әле...

Йорт янарту, ризык, утын, савыт-саба табу кебек вак-төякләр белән мәшәкатьләнеп, бер ай чамасы вакыт үтеп китте. Төннәрен гел тезмәдә, хәтфә печән кочагында аунап уздыра торган иде. Беркөн таңда Акбуранның ярсып, дулап пошкырган тавышына сискәнеп уянды ул. Түбә ярыгыннан сузылып аска бакса, арпа-солы сибелгән колаша янында ике аяклы бер карачкы бөтерелеп йөри. Ни адәм, ни җанвар түгел бу җан иясе. Иңнәреннән ике якка кисек күлтәпиләр чыгып тырпаешкан. Өстендә сагызланып каткан, кылка-ертык чүпрәк аламасы. Биленә чаклы житкән чәче-сакаллары ап-ак, алар елан күче сыман үзара укмашып, буталышып беткән. Тәлен иягенә салындырган йөзе котчыкмалы кыргый, шакшы һәм җирәнгеч. Акбуран булып Акбуран да укшый бугай, малкай. Ул бер тибүдә сытарга чамалап, шушы карачкыны агач колаша тирәли ду китереп куа.

Сал-Сал кылычын янына кыскан көенчә аска сикереп төште. Шашкын Акбураннан аралаучы кеше табылуга сөенгән шикелле, җанвар аламасы аның каршына мүкәләп килеп җитте. Ул инде аягурә басу, бил турайту гадәтен дә гел оныткан бугай. Күзләре белән Сал-Салга төбәлсә дә, тездә

торган көе, бияләй чаклы теле белән сакал-мыекларын ялмый-ялмый, капылт сүз башлады.

—Ә мин Ибраһимнан барыбер үч алдым бит. Мине узып яши алмады ул җиһанда. Мин ташлаган еланнар чакты ул кабихне, буа-буа чакты! Аларны тиккә генә ике атна буе ач тотмадым ла мин. Шул еланнарга чактырдым, чактырдым Ибраһимны! Менә шулай кирәк ана, шулай кирәк! Ибраһим дигән имгәк хан юк хәзер җир йөзендә, Ибраһим юк! Мин җинүче хәзер бу җиһанда, йә Аллаһ, мин җинүче!..

Бу шакшы җанвар үзе дә Сал-Салга зәһәр елан булып күренә башлады, аркасы буйлап меңәрләгән кырмыскалар, тараканнар чабышып-биеп узды. Кылыч сабына салган кулын тыеп, тешләре арасыннан тик бер генә сорау сытып чыгарды ул.

—Ә син эттән туган Тимер-Мөэмин атлы үләт чире инде, алай булгач?

Карачкы аягына күтәрелә башлап, ярсый-ярсый, котырына-котырына аваз салды.

—Үләт түгел, Тимер-Мөэмин хан мин! Хан мин!

Карачкы тураеп басарга өлгермәде, аның түмгәк сыман тырпаеп торган башы агач колаша астына таба тәгәрәп китте. Кылычын үләнгә сөрткәч, Акбуранның йөгәненә кулын салды Сал-Сал. Күңеле яман шештән, зәһәр чуаннан котылган кеше тәне кебек җиңеләеп, бушап калган иде. Рәхәтләнеп аргамакка дәште.

—Тәхет тирәсендә тагын мәхшәр башлангандыр инде тугры дустым. Сарай әргәсендәге түрәләрнең күбесендә баш урынына җиде тишекле түмәр утырса да, аларның һәркайсы фәкать үзен генә алтын таҗ кияргә лаек асылзат, дип саный. Айзирәккәй үзе безгә тәтемәде инде. Ичмаса, аның энекәше Хәсәнне булса да тәхеткә күтәрү өчен кире кайтыйк, туган.

## 63

Владимир кенәз юл буе Айзирәкне учыннан төшермәде. Иң тәмле ризыклар—аңа, татлы-төче сүзләр—аңа һәм, әлбәттә инде, яшь, кайнар тән сусавына иркә-наз да—аңа. Айзирәк үзе генә бу хисләргә җавап кайтара алмыйча һаман-һаман тоташ ут эчендә барды. Беренче атналарда аңа хәтта иң якты көн дә караңгы төн булып күренде, кенәзнең кирәкмәс назыннан кереп качар урын эзләп изаланды. Чатыр тышында чит-ят ирләрнең аяк тавышлары ишетелсә дә, кылыч таккан каешлары яисә кытыршы куллары чагылып китсә дә, шул мизгелдә үк аның күз алдына Сал-Сал газизе килеп баса һәм, әйтерсең лә, адым саен тик бер сорауны гына кабатлап бетмәс-төкәнмәс ут эченә сала да куя иде:

“Табышып кавышкан бәхетле ярлар турында син бер хикәят тә сөйләмәдең әле... Әллә безгә дә аерылу юрыйсыңмы?”

Айзирәк хыялында ана нәкъ Нургали чишмәсе янындагыча өзгәләнә-өзгәләнә җавап кайтарырга ашыга:

“Юк, юк! Без аерылмыйбыз, җаным, аерылмыйбыз!.. Без синең белән мәңге-мәңге бергә булачакбыз!”

Ләкин менә шушы хыялыннан аерылып ул чынбарлыкка кайтып төшә дә никахлы иренең карашыннан-назыннан ничек котылырга белмичә, ялгыз калган аккош сыман һаман бәргәләнә, һаман җаны сыкрый. Кенәз ире—яу сәфәренә чыккан сәрдәр, меңәрләгән кешеләр гомере өчен җаваплы кеше бит, аңа бик еш кына яшь кәләше яныннан юк булып торырга да туры килә. Бер уйласаң, сөйкемсез кочактан аерылып тору дәва булыр сыман. Ләкин ялгыз калуның да шифасы юк, мондый вакытларда Сал-

Салының томан аша эндәшкән һаман да бер соравы эзәрлекли башлый һәм ул Айзирәкне икеләтә көйдерә, бәгырен телә икән. Сөйкемсез ир кочагына кереп назлануның ялгызлык газапларыннан мең мәртәбә өстен икәнлеген менә шушы чакта аңлады ул.

Владимир да аның ниндидер сәер хисләр өермәсе эчендә януын тоясызә бугай, ул яңадан-яңа юаткычлар табып, ике арадагы бозны эретмәкче була. Бер төнне, хәтфә печән түшәлгән зур арбада чалкан яткан көе иләсләнеп-хозурланып барган чакта, һавадагы Киек Каз Юлына төртеп, кенәз сәер риваять сөйләп бирде.

—Минем кебек бер кенәз синең төсле үк бик тә чибәр сылуны очратып, аны үзенә хатынлыкка алган. Чөкердәшә-чөкердәшә бер ай чамасы да яшәп өлгермәгәннәр, кенәз үзенең дружинасы белән байлык тупларга дип яуга чыгып киткән. Ә кәләше япа-ялгыз көе, әмма инде буйга узган хәлдә яшәп калган. Кенәз яуда йөри-йөри бик күп дошманнарын җиңгән, тау-тау байлык җыйган. Ләкин ерак-ерак илдә, җиде башлы бер гыйфриткә очрап, шуның кулына әсирлеккә төшкән. Бу вакытта инде аның туган нигезендә калган яшь хатыны игезәк балалар да табып өлгергән. Шул хакта ишетеп, гыйфрит кенәзгә мондый таләп куйган. "Йә шул балаларыңны үземә тартып алам, йә башыңны өзәм!" Уйлаган-уйлаган дә, балаларын корбан итәргә ниятләгән кенәз. "Ярар, мин әле яшь, хатыным белән балаларым да соңгылары булмас", дип үзен юата икән. Ул арада гыйфритнең өчәр башлы эне-сенелләре—аждаһалар—очып килгәннәр дә, яшь ана кулындагы балаларны алып киткәннәр, ди. "Сабыйларыма тимәгез, мин алардан башка яши алмыйм", дип ялварып та караган ул ана. Аждаһалар кычкырып көлгән генә. "Ирең риза булды бит, ә ирнe узарга ярамый", дип җавап кайтарганнар. "Алайса, мин иремне дә каргыйм!"—дип бар йөрәге белән кычкырган, ди ана. Аның өзгәләнүләрен, елауларын күк йөзендәге фәрештәләр күзәтеп торган, имеш. Шулар ялгыз ананы канатларына утыртып күккә алып менеп киткән. Ә ананың күкрәкләре югарырак менгән саен ныграк тулылана, ныграк шешә икән. Чөнки балаларын имезә алмау сәбәпле һаман саен сөт җыела икән дә сөт җыела икән. Менә шушы төшкә менеп житкәч, күкрәкләренең сызлавына-талавына түзмичә, бәхетсез ана күкрәк очларын тырнап җибәргән, ди. Ана имиеннән бәреп чыккан сөт тамчылары күк йөзенә әнә шулай, мең йолдызлар булып сибелгәннәр. Алар күктә ана сагышы да, хатын каргышы да булып һаман яналар, ди. Менә шулай хасил булган ул Киек Каз Юлы.

—И-и, бигрәк сагышлы, аяныч икән бит сездәге хикәятләр, гел безнеңчә түгел,—дип Айзирәк гаҗәпләнә-гаҗәпләнә баш чайкады. Ахырда, барыбер, тел очына килгән иң олы теләген әйтми түзә алмады.

—Андый язмышлардан минем балаларымны аралый күр, Ходам!..

Җидеколак дигән сай сулы елгачык ярында алар ап-ак чәчле, күзләре чокылган картка тап булдылар. Тирә-юньдә һичбер юлдашы юк, кулында сөяк сыман кибеп беткән шома таяк кына. Мондый диңгездәй зур дала уртасында ничек исән-сау килеш яши ала да, ничек адашмый бу?

Шул хакта үзенә киная ташлагач, сукыр сукбай болай да җеп шикелле булып калган ирennәрен усал кыса-кыса җавап тотты.

—Мина бу килеш кенә үлеп китәргә һич тә ярамый бит. Җир йөзендә мине әҗәт йөртә. Иосиф кахан дигән бер җәлладка әҗәтем кайтарылмаган. Шул вәхши җан ике күземне чокып алды минем. Үз күзләрем өчен әлләни үкенмим мин. Аларны иртәрәк чокып алса, яхшырак булыр иде. Ә ул мине тоташ елга булып аккан туганнарымның канын карап торырга мәҗбүр итте. Минем күз алдымда бер мең юлдашымны, мина ышанып чыккан бер мең

урыс ирен суеп чыкты бит ул, эттән туган имгәк! Мине җир йөзендә әнә шул бер мең илдәшем алдындагы бурычларым йөртә. Мин аларның каны, аларның гомере өчен үч алмыйча китәргә тиеш түгел.

Меңбашлар белән йөзбашлар яу сәфәрен Владимир кенәз җитәкләп баруы турында да әйтеп салгач, сукыр карт катгый кистереп дәште.

—Иң яшерен юллар белән кахан өстенә мин сезне үзем алып барам. Савилий дөм-сукыр, пычагым да күрми, дип юкка кайгырмагыз. Ике күзле көе сукыр булып яшәгән туңйөрәкле, агач бүкәннәргә караганда дөм-сукыр көе уттай янып йөргән кешеләр күпкә кыйммәтрәк ул...

Каханат уртасында аерым утрау булып утырган Итил каласының тоткавыллары бу юлы да берни сизмәделәр. Болгар белән урыс угъланнары бар урамны чәчәк түтәле урынына сытып-таптап узды. Капчык кебек юанайган Иосиф кылычын болгый-болгый атылып чыккан чакта болгар җайдаклары кахан сараеның диварларын тулысынча чолгап алган иде. Тоташ көбәләргә төренгән болгарларны шәйләп өлгерүгә, утка пешкән төсле ачыргаланып һәм ярсый-ярсый, вәзир-бәкләренә үкерде яһүд кахан.

—Болгар илен саклагыз, алар белән дуслыкны өзмәгез, аларга тимәгез, дип әйттем бит мин сезгә! Урыс кенәзләре Болгар илен аяк астына салса, аннан безнең чират, дидем. Менә, күрдегезме? Болгар иле черек койма төсле урыс ягына ауган. Болгарларны калкан итеп алгач, бу кыргый баскыннар Хәзәр илен дә таптап үтәр инде...

Иосиф каханны үз сараеның баскычлары өстендә турап үтерделәр. Идел ярындагы иң биек кыя түбәсенә менеп баскан Владимир пайтәхетнең барча урамнарын күк күкрәгәндәй көчле, күркәнекедәй тәкәббер һәм масаюлы тавыш белән күмеп гөрелдәде.

—Хәзәр каханы юк ителде, Иосиф атлы юха яһүдине җир йөзеннән тәмугъ төпкеленә себереп аттык! Моннан ары "кахан" дигән шанлы дәрәҗәне мин үз өстемә алам! Белеп торыгыз, җиһанга хәзер Владимир кахан атлы урыс хакиме башлык!..

Итил каласын тоташ талап чыккач, Владимир шул ук кыя өстенә басып яңа әмер бирде.

—Кибән төсле, төрле яклап ут төртегез моңа! Хәзәрләрнең пайтәхет урынында көл катламы гына ятып калсын! Каханат далалары өстендә хәзер урыс мәмләкәте канат җәяр!

## 64

Балаларын Айзирәк бик интегеп тапты. Түшәк өстендә ике тәүлек буе газап чиккәч, җиһанга мичтән чыккан күмәч кебек кып-кызыл, орчык чаклы гына бәп-бәләкәй сабый пәйда булган иде дә, михнәтләр бетмәгән, Айзирәккә игезәк бала яратырга насыйп иткән икән. Якты дөньяга анысы да чыгып аваз салгач, кенәзбикә янында бөтерелеп йөргән кендек карчыгының һәм бояр хатыннарының барчасы да тулган ай шикелле елмаеп, бердәм сөенделәр.

—И-и, әле ни юнан килененең, ни варяг хатынының игез бала тапканы юк иде. Кенәз Идел буеннан ияртеп кайткан болгар кызы бигрәк уңган икән!..

Бояр хатыннары аның көндәшләрен санаганда Айзирәк ярсаланып беткән иреннәрен усал кысып, үрсәләнеп ятты. Ни хәл итмәк кирәк, урыс хакименең бердәнбер хатыны булып яшәү бәхете тәтемәгән аңа. Кенәзнең менә шушы сараенда түбә бүлешүче хатыннары гына да тугыз. Аларның һәркайсына "җанкисәгем", дип эндәшкән чагында кенәз, чыннан да, үзенең хатыннарын аның җанын һәм түшәген яңартып-кайнарлап торучы

сөяркәләр генә итеп саный кебек. Кенәз туймас, дуамал, шашкын. Аның нәфесе көтүче чыбыркысы сыман озын бугай. Аңа тугыз хатын гына да житми. Ул әле Аккалада, Өскалада, кул сузымында яткан Берестовта янә сигез йөз жария кыз тупланган харәмханәләр тота. Сарайга ул атнага-айга бер генә, анда да кайнап торган казанга чумдырылган чөгендер төсле кызарып пешкән хәлдә кайтып керә. Үзен ел буена күрмичә тилмергән картрак хатыннары Владимирга чәнечкеле-төртмәле кушамат та тагып өлгерделәр.

—И-и, безнең кенәзебез болытлар арасыннан чыккан Кызыл Кояш кебек күзебезгә кайтып күренде бит!

—И-и, безнең Кызыл Кояшыбыз, Кояшыбыз кайткан!..

Айзирәк балалар тапкач та кенәз анын бүлмәсенә кереп карамады. Яшь ананың ашъяулыктай керсез, пакь күңеле ачыну-гарьләнүдән көзге болыт сыман тулып ташкан иде. Биләүләрен тибеп елаган сабыйларына кушылып, түшәк-ястыкларны төя-төя әллә нича төннәр буе яшь түкте ул, нинди генә сүзләр әйтеп бетермәде?!

—Синең сөюләрең дә шул, өй кыегындагы язгы боз сөңгесе белән бер икән бит. Башка сөяркәләр бераз гына елмаеп карадымы, синең миңа булган мәхәббәтең шундук эреп бетә, юкка чыга икән. Далада яндырып калдырган учак кебек онытырлык булгач, нигә, нигә дип кенә алып килдең соң син мине шушы чит-ят жиргә? Табаны ике яклап кыздырган чагында гына андагы ризык тәмле-татлы булып пешеп өлгерә ул. Ә мин сабыйларыма күчерерлек ут-жылыны берьялгызым гына каян табыйм?..

Әле ярый аның күңелендәге болытларны куып таратырдай бер кеше бар. Һәрбер таңда чәчәк тажы сыман елмаеп һәм ачылып каршылый ул аны. Тупсаны атлап керүгә үк Якуб Ногман барын да күреп ала, һич ялгышмый. Аның сүзләрен тыңлап утыру да ләйсән яңгыр астында йөргән кебек рәхәт.

—Картайган кәккүк шикелле монаеп утырма әле. Аллага шөкер, яныңда балаларың бар, син япа-ялгыз түгел. Кенәзнең сирәк күренгәнe өчен дә чәч агартма. Хакимнәрнең гыйшыклары кышкы учак сыман. Терәлеп утырган чакта жылысы бәреп тора, бер-ике адым ара калды исә, туңдыра ук башлый. Андый бәндәләрнең мәрткә киткән намусы—йокыга чумган авыл гына түгел. Аны тәрәзәгә шакып кына уятып булмый, наный...

Айзирәк сабыйлар белән юанган беренче көннәрдә үк кояш кебек иртә таңнан килеп елмайды ул. Балаларга исем кушарга кирәклеге хакында да нәкъ шул Якуб башлап сүз кузгатты.

—Кенәз күрергә керми дип йөгән-дилбегәсез көе елап ятып булмас. Беткә үч итеп тунны утка ягу—таза акыллы кешеләр эше түгел. Кенәз үз ярына таба йөзә тормыш дәрьясында, ә безнең үз кыйблабыз бар. Аталары килеп эт кушаматлары таккачы, сабыйларны мөселман исемнәре белән тәгаенләү күпкә хәерлерәк.

—Соң, ни, килешеп бетәр микән?—дип Айзирәк әүвәл каушабрак сузып караса да, тора-бара язгы урман төсле уянып китте.—Уйлап куйган исемнәр бар инде ул. Беренче сабыйны мин Киевка килгәч, дүрт дивар уртасына бикләнеп калганга күрә, "иптәш китер миңа, сердәш жибәр миңа", дип ялына-ялвара көтеп йөргән идем. Ходай тәгаләгә барып житте зарым. Шуңа күрә беренче сабыйга "Аллазар" дигән исем кую урынлы булыр сыман. Ә икенчесен көтми идем дә, белми идем дә бит. Анысы Ходай тәгалә хозурына үзе аяк басты. Аңа "Аллахозур" дигән исем кушсак, игезәк туганы белән пардан булыр иде.

Якуб хәзрәт авыз ера-ера шундук эләктереп алды.

—Бик әйбәт, бик урынлы. Йә, килештек, наный. Берсен Аллазар дип

тәгаенләп куйыйк. Икенчесе, әйдә, Алхозур булсын. Шулай ипле, алай килешләрәк. Аллазар, Алхозур! Икесе дә безненчә, мөселманча! Икесе дә озын гомерле була гына күрсен!..

Ни үкенеч, Якуб Ногманның янгыравык, дәртле тавышы Айзирәк бүлмәсендә бик аз гына вакыт яңгырап ала да шундук юкка чыга. Айзирәк өчен Якуб Ногман төнге даладагы ялгыз учак сыман. Хәзрәт Киев каласын бөтенләй ташлап китсә, Айзирәк караңгы һәм салкын базга кереп чумар төсле. Менә ни өчен һәркөн саен газиз дә, тансык та ул.

Тик хәзрәтнең йөзен соңгы араларда гүя болыт каплап китте. Якуб үз эченә йомылып, йомарланып калды. Авызыннан бер сүз алып булмый. Сораштыра башласаң, керпе төсле кабара да кадый.

—Син кенәз хатыны, унны-сулны барыбер аермыйсың. Синең кенәзеңә дә мин тукыган сүзләр ташка борчак орган кебек кенә. Минем сүзне санга сукмый киреләнеп кенә торса бер хәл иде әле. Ю-у-ук, кысла сыман гел кирегә сукалый бит, каһәр! Бу җиһанда фәкать бер генә Аллаһ бар, дип аңлата-аңлата телем сынып бетте. Ә ул, әнә, Саескан тавы өстенә һаман үзенең агач сыннарын мендерә дә тезә, мендерә дә тезә. Ачуым килмәгәе, шунда унбиш-егермеләп потның зиратын корып куйды инде...

Ниһаять, бер көнне учак кебек балкып керде хәзрәт. Авызы—колагында! Сүзләрен дә сәйлән урынына челтерәтеп сибә.

—Аллага шөкер, Румнан* килгән христиан епискубы, Коры үзәндә качып йөргән раввин, Балтыйк дәрьясы буенда яшәгән алманнар аббаты белән дүртебезне берьюлы кабул итә синең ирең, Владимир кахан. Әй-яй, шәп туры килде бит әле бу! Үз динебезнең өстенлекләрен ачып салу, тегеләрне дә үз ягыбызга аудару өчен менә дигән форсат, әйбәт форсат! Җинми кайтаммы соң! Кайтаммы соң!..

## 65

Владимир кенәз руханиларның барысын да үзенең тәхет залында, аягүрә басып каршылады. Иосиф каханга карата булган үч һәм нәфрәт хисе әле һаман хәтерендә күмер булып пыскый иде бугай, урыс хакиме яһүдине юньле-рәтле тыңлап та бетермәде.

—Әле сез, Ходай тарафыннан каргалып, үз иленнән сөрелгән һәм корыган агач яфраклары шикелле бөтен дөнья буйлап себерелеп йөргән яһүдиләр дә безне өйрәтергә, остазлар булырга маташасызмыни? Юк, сезнең сымак илсез-җирсез калырга исәп тотмыйбыз без!—дип Владимир аны сараеннан себеркеләп куды.

Алман аббаты кереш сүзен үк урыс потларын, аеруча Перунны нәҗескә батырудан башлап китте. Владимир аның белән дә дилбегәне үтә кыска тотты.

—Минем бабаларым сезнең атагыз каршына барып, дин ялынып йөрмәгән. Моннан ары да сездән аеры яшәп саргаймабыз әле...

Юнан побы сөйли башлагач кына Владимир кенәз уянгандай булды. Аеруча Адәм белән Һаваның яралышы, Тәүрат кануннары, чиркәүләрдәге чаңнарның шаңлы тантанасы, Адәм балаларының гөнаһларын юу, мәңгелек дөньяда көтеп торган җәннәт яки гөнаһлары өчен ләгънәт укыганнан соң гомерлек җәзага тарган мескен җаннар турында тыңлаганда кенәзнең күзләре җил кабарткан учаклар шикелле кабынып-янып торды. Юнан илчесе хәйлә кушудан да тартынмады.

—Син җәннәткә эләккәч тә иң беренче җан булып йөриячәксең, син

---

*Рум—безнең бабайлар телендә Византия, Константинополь.

анда да бөек булып калачаксың, тизрәк чукын, кенәз,—дип юха үгетләүләр белән тәмамлады ул үз сүзен.

Кулы белән ишарәләп, Владимир аны чүктергәндәй итте.

—Мөселман имамын да тыңлап карыйк. Син мине теге дөньяга озатырга бик ашыкма әле.

Якуб Ногман бик тәфсилләп Коръән сүрәләре, шәригать кануннары, болгарлар арасында тамыр җәйгән гореф-йолалар хакында сөйләп чыкты. Хәзрәттән саркыган хис һәм ялкын вакыты-вакыты белән кенәзгә дә йога, ул да тал ботагына кунып сайрарга җыенган сандугач шикелле канатларын җилпеп, талпынып ала иде. Ни үкенеч, кенәздәге комар һәм дәрт хисләре яңгыр астында калган учак сыман әкрен генә сүнде, сүрәнләнде. Тамакларын кырып үзе сүз алганда аның йөзе инде тау башына куелган Перун потныкыдай җансыз, салкын иде.

— Мөхәммәт атлы пәйгамбәрегез бик тә акыллы, төпле кеше булган. Хәтта, ул индергән Коръән синең белән минем ише карабашларның мактау сүзләренә бөтенләй мохтаҗ түгел. Тик шулай да, сезнең динегезгә минем күңелем ятып бетми әле. Әллә нинди, мал өчен корып куелган агач аран төсле тар, кысан ул. Аллаһ алдында баш иям дип, тәүлегенә биш мәртәбә тот та тезлән, тот та тезлән. Алай еллар буе тезгә чүгә торгач, телисеңме-теләмисеңме, Адәм баласында мескенлек, үзен түбән санау, коллык чире ярала, үсә башлый. Җитмәсә, ул тезләнүчеләрне аксөякләргә, карачураларга аерып тору да юк. Мин—хаким, ә мәчеткә кереп минем янәшәмә тезләнгән кеше—ертык киемнәрдән мәңге арынмаган шакшы карачура. Йә, мин ни өчен шул карабаш белән рәттән торыйм да, Аллаһ каршында булмаса, һич югы руханилар каршында, үземнең илдәшләрем алдында сансыз бәндә булып калыйм инде? Юк, миңа бу һич килешми. Христианнарда, әнә, кайсарларны, кенәзләрне, аксөякне алтарь янынарак, башкалардан аерып, өскә бастыралар. Аларның побы-епископы сине шәхси чукындыра, сиңа гына багышлап аерым мәдхия җырлый...

—Ходай тәгаләгә, Коръәни-кәримгә тел тидерү гөнаһ,—дип Якуб Ногман кат-кат авыз ачып караса да, Владимир кенәз Перун шикелле хәрәкәтсез утыруын белде.

—...Сезнең ул Аллаһ йортлары булып исәпләнгән мәчетләрегездә бөеклек, тантана, гауга-шау юк. Нindидер бер бәндә генә манарага кәҗә тәкәсе сыман менеп азан кычкыра да, башка диндарларыгыз шуның янына сарык көтүе төсле йөгереп килеп житәргә тиеш. Ә христианнарда, әнә, жиз чаңнар бар, катлы-катлы итеп төзелгән мәһабәт соборлар бар. Андый йортка керү, чаң шаулату—ул үзе үк һәр кешене күркә сыман кабарта, үсендерә, сиңа үзеңне бөек, гаярь тоярга ярдәм итә...

Владимир кенәз юнан побына караш ташлау өчен генә туктап-туктап торды, әмма күкрәк тутырып сулыш алуга ук янә тезеп китте.

—...Инде килеп, гөнаһ мәсьәләсе. Сездә гомер буе гөнаһ кылудан сакланырга кирәк. Гөнаһларың фәрештәләр канатына язылып бара, ул кара таплар өчен сине алда сират күпере, тәмугъ, җәза көтә. Син кылган гөнаһларыңнан котыла алмыйсың, теге дөньяга күчкәч син барыбер газраилләр кулына барып эләгәчәксең. Ләкин дүрт аяклы ат та абына бит. Ә адәм баласы үзенең гөнаһларын гомер буе җилкәсенә олау-олау итеп төяп йөрсенмени? Юк, мин менә шунысы белән дә каты риза түгел. Христианнарда, әнә, рухани каршында тезләнеп гафу үтендеңме, үкенү күрсәттеңме—кичәге гөнаһларың юыла да бетә, иртәгә янасын кыл, янә гафу үтен. Ичмаса, менә бу тормыштагы сыман...

Үзенең тайгак яшәү рәвешенә шәп аклану-калкан табуына сөенүдән Владимир кенәз очынып-очынып куйды.

—... Ә инде гөнаһларны санап чыгуга кучсәк, ай-һай, бөтенләй чүпчарны да гаеп саныйсыз сез. Дуңгыз ите ашама, чит хатынга нәфесеңне сузма, зина кылма, сугышма, урлашма, кеше җанын кыйма, ахыр чиктә килеп, хәтта аракы да эчмә. Кит инде, әкәмәт! Ул рәвешчә, Мөхәммәт пәйгамбәрнең үзенә тиң булып яшәп буламыни? Ул чагында нигә кирәк миңа андый тормыш? Күрше тавыгын басарга кызыкмаган әтәч—ул саусәламәт түгел. Урлашуны телгә алабыз икән, безнең халык ул һөнәрдән башка мәңге яши алмый, шундук аяк суза. Сугышмыйча, кан коймыйча, ә тулаем алганда күндәм һәм карусыз кол шикелле яшәргә җыенсаң, сине күрше халык, көндәш диняулары изеп китә. Гомумән, үзен-үзе якларга әзер тормаган дин озак яши алмый. Андый дин—ул коллар, җебегәннәр һәм куркаклар дине...

Владимир кенәз алда әйтәсе сүзен уйлап куйды, ахры, тәхетендә башын артка ташлап, туарылып көлде.

—...Ә шәраб, аракы, хәмер тыю хакында Мөхәммәт пәйгамбәр Коръәненә юкка гына язган. Кит, әкәмәт! Урыс халкы эчемлектән башка ничек яши алсын? Ул өч мәртәбә сөннәткә утыртуга риза булса-булыр, әмма аракы белән хәмерне мәңге кире какмас!..

Якуб Ногман инде тамырына балта чабылган тал чыбыгы кебек бөгелеп төшкән иде, Владимир кенәз яңа канат куйды.

—Динегездәге кимчелекләр хисапсыз күп булса да, бөтенләй баш тартмыйм. Бизмәнгә салып үлчәтү, илегездәге гореф-гадәтләрне капшап карау өчен Болгар җиренә ун кешелек илчелек җибәрәм мин. Ләкин христиан дineнең асылын белер өчен ул яралган җиргә, юнаннар иленә үзем барып кайтам. Менә шуннан соң җыелып янә бер үлчәрбез, әмма хәл итәрбез. Урыс дәүләте бөек динсез яшәргә тиеш түгел!

## 66

Владимир юнаннар иленә бару хакында юкка гына киная ташламады. Кайсаркала белән Киев арасында элемтә җепләренең өзелеп торганы юк, ә соңгы хәбәрләр кенәз күнеленә аеруча хуш килә иде.

—Юнаннарның Цимисхий атлы кайсарлары кисәк үлеп киткән. Ул берниндидә нәзер-аманат язып калдырмаган. Кайсаркалада хәзер мәхшәр хөкем сөрә. Пайтәхетне Фока исемле фетнәче сәрдәр чолганышка алган, ә Цимисхийның туганнары Василий белән Константин сарайда бикләнеп ни кылырга белми утыралар икән...

Владимир шундук утыз меңнән артык җайдакны ияргә атландырды. Аңлатмасы шома, иплe килеп чыкты.

—"Менә төшәм, менә төшәм" дип, үзләре синең авызыңа кереп барган җимешләрне өзеп капмас өчен ахмак булу кирәк. Юнаннарда йорт хуҗасы да калмаган, аларның ихаталарын саклаучы этләре дә бәйдән качкан икән. Атам Святославны кол урынына хур итеп куганнары өчен үч алырга ин-иң кулай вакыт. Таламыйча яткан кулга буар елан чире кагыла да ул үз атасының бугазына килеп урала, ди. Елан түгел, ә очар козгын йә бөркетләр булсак, бай юнаннар утарын барып талыйк...

Үзи елгасы тамагында утырган Иске Херсон дүрт-биш гасыр буе Юнан дәүләтенең төньяктагы терәк-кирмәне булып исәпләнә иде. Шуңа юл тоттылар. Сәүдә кәрваннарын озатып йөрү бәхетен татыган берничә сәйяхчы ир авыз суларын корытып тасвирлады.

—Херсонлылар бөтен диңгез яры буйлап сәүдә итә. Боларга алтын-көмеш таулары кораб-кораб булып кайтып тора. Бәҗәнәк йә урыс кыргыйларынын

талаулары мөмкин, безгә үзебезнең каланы ныгытырга кирәк, дигән сылтау белән юнан кайсарына ясак та түләмиләр. Болар күккә төкереп, балдамайда йөзеп кенә яши. Утта яндырылган балчык торбаларны ялгый-ялгый, һәр урамга, һәр тыкрыкка сууткәргечләр дә көйләгәннәр инде...

Херсонны тоташ камалышка алып, озын ай буена һөҗүм, янгын, тәшвиш оештырып караулар бернинди унышка да китермәде.

—Өч ел торсам-торам, әмма калагызны тезләндерми китмим!—дип куркытты Владимир кенәз, дивар янына килеп, чарасызлыктан тагын ни кылырга белми.

Каладагылар ыжлап та карамады. Кенәз, үҗәтләнеп-ярсып, даладан дивар буена олау-олау туфрак ташытырга тотынды. Херсонлылар: "Бу кыргый ни кыйлана?"—дип баш ватты, берни аңламады. Владимир "сер"не үзе ачып салды.

—Тышкы якта олы тау төзим дә калагызга өстән бәреп керәм! Йә үзегез бирелясез, йә җимереп бетерәм, башка юл юк!

Мондый дуамаллыктан херсонлылар да өнсез калды бугай. Каладан тышка җир асты юлы казып, урыслар көндез әзерләп куйган туфрак өемен төнлә белән кирмән эченә ташый башладылар. Владимир кич белән чатырына юнәлгән чагында кала тышында кибән-кибән балчык өелеп кала, тик иртән торып чыкса, ул таулардан инде җилләр искән. Янә шашынакотырына яна меңнәрне дала ягына чыбыркылап куа кансыз кенәз.

Әмма, ни үкенеч, һәр өйнең дә бер гарибе, сатлык җаны, имгәге табыла шул. Беркөн танда Владимир кенәз аяклары янына каен кайрысы уралган ук атылып төште. Кайрыдагы язуны белемлерәк боярлар кычкырып укыдылар.

—Сезнең артта, сулдагы тауның итәкләрендә ургыл чишмәләр бар. Су безнең калага торбалар буйлап шуннан агып килә. Шуларны җимерсәгез, шәһәрдә су бетәчәк... Каланы алгач мине үтермәссез. Сезне көтеп торучы Анастасий...

Атна-ун көн чамасы сусыз интеккәч, шәһәр капкаларын херсонлылар ачты. Кала башлыгы булып алган сатлык Анастасий инде кайсарлар сараендагы серне дә чишеп салды.

—Тәхетне ничек бүлешергә белмичә интеккән Василий белән Константинның Анна исемле сеңелкәшләре бар. Әле кияүгә чыкмаган, бик чибәр кыз. Юнан патшабикәсен үз хатының итү синең эчне тәртеп тишмәс иде...

Владимир кенәз Херсон хакимнәрен шундук Кайсаркалага илче итеп куды.

—Кайсарларга илтеп тапшырыгыз. Мин—кахан, Анна—патшабикә, бик кулай пар. Аннаны миңа кияүгә бирәләр икән, Фока дигән сатлык сәрдәрләрен үзем сытып ташлыйм. Ну, әгәр дә инде... битемә төкерсәләр... Херсон урынында да көл генә калдырам, Фокага да ун мең җайдак бирәм...

"Озынколаклар" аша әүвәл патшабикә Аннаның "ризалыгы-бәясе" турында җавап кайтып төште.

—Ул кыргый җәлладка кияүгә чыкканчы, мин чиркәү манарасы өстеннән сикереп үземә кул салам! Башкача кабатлап тормагыз, исемен дә ишетәсем килми!..

Алда кояш сыман үзенә тартып-ымсындырып торган тәхет, ә кала тышында пычак кайрап көткән хәвеф бар бит әле. Игәү сыман туктаусыз үгетли торгач, горур патшабикәне дә сындырганнар. Херсонга зур корабта кәләш Анна белән бергә Василий атлы кайсар үзе килеп җитте. Патшабикә Анна, асылда да, күз явынны алырдай сирәк чибәр, әмма боларның да шарты катгый, кырыс икән.

—Йә хәзер үк чукынасың да христианлыкка күчәсең, йә корабтан төшеп тә тормыйча кире борылабыз!

Кайсар Василий беркадәр көттергәннән соң гына өстәп куйды.

—Христианлыкка күчсәң, Дим-тарханны* да сиңа туеныргa бирәм.

Владимир таш диварга сөңгеләр терәп кысрыкланган ялгыз сугышчы хәлендә, чигенерлек бер ара юк иде. Карашын патшабикә Аннадан аера алмыйча, камыш сабагыдай капылт сынып төште.

—Мин риза, христианлыкка күчәм.

Шул сәгатьтә үк яр өстенә махсус корылган чатырлар эченә алып керделәр дә Владимир белән Аннага христианнарча никах укыдылар. Алар артыннан ук яубашлары белән урыс укчылары да Үзи елгасына куып төшерелде...**

Киевка кайтып кергәч, иң элек, Владимир кенәз Саескан тавындагы барча потларны кылыч белән үзе турап атты. Нарат агачыдай биек, дәһшәтле Перунны, ат койрыгына бәйләп, тау өстеннән Үзи суына сөйрәп төшерделәр. Аннары Киев халкы өчен бердәм фәрман ишетелде.

—Барлык кешеләр дә Үзи суына кертеп чукындырылачак. Имчәк балалары өчен дә ташлама ясау, кызганулар булмый...

Айзирәк айга-елга бер мәртәбә генә күренә торган ире Владимир каршына барып, әүвәл ялынып, елап та карады.

—Аллазар белән Алхозур тәпиләренә әле яңа гына баса башладылар. Бер карынны урталай бүлешү җинел түгел икән, алар болай да тумыштан ук чирләшкә һәм йончу булып үсә. Алар җилдән туган үксез-ятим түгел, үз балаларыңны кызган!

—Нинди Аллазар да, ниткән Алхозур ул?—дип үкереп җибәрде тормыш мәсләгe бөтенләй алышынып беткән, дилбегәсез кенәз.—Попны чакырып, бүген кич үк мин малайларыма Борис белән Глеб атын кушам. Ә хәзер, әнә, аларны кочагыңа ал да, бөтен кеше белән бергә шәрә калып Үзигә чум! Юкса, мин аларны синнән каерып алып монастырьга бирәм!..

Аллазар белән Алхозур икесе дә кичен, ут кебек кызышып, түшәккә егылдылар.

## 67

Еллар үтә тора, ә Айзирәкнең пыскып яткан ялгыз учагы янына килеп бер әрдәнә утын да өстәүче юк. Кичен ятса—ялгыз, иртән торса—ялгыз. Игез бала үсеп килү, әлбәттә, зур куаныч. Ләкин әллә нигә үги бала, ятим бала төсле унмаганнар, бәхетсезләр алар. Айзирәк инде ничә еллар буе сынап яши. Уенга-мазар чыгып киттеләрме, йә Аллазар тип-тигез җирдә аягын сындырып кайта, йә Алхозурның адым саен авыз-борыны каный. Владимир кенәзнең йөгерешеп йөргән малайлары гына да уннан артык хәзер. Ялагай тиуннар, боярлар алар өчен сирәк-мирәк ау да оештыра. Аллазар белән Алхозур анда чыгып китсәләр дә, нәкъ шул ук хәл. Кирәк чакта гына йә берсенең җәя кереше шартлап өзелә икән, йә икенчесенең борын төбеннән җәнлек качып китә. Өлкәнрәк агалар ару гына тәпәлиләр, ахры, игезәкләр сарайга бик еш кына күгәргән, йә елаудан шешенгән күз төпләре белән кайтып керә. Айзирәкнең малайлар сөйләшкәнне колак чите белән генә ишетеп калганы бар.

—Изяслав белән Чонтык Ярослав*** юри алдан кисеп куйганнар ул минем җәя бавын. Бер карабаш тиште.

---

* Дим-тархан—Тмутаракань.

** 988 елда булган вакыйгалар.

* Чонтык—бер аягы кыскарак, гарип кеше. Ярослав балачактан бирле шул кимчелек белән иза чиккән.

—Святополк баш күтәрергә ирек бирми безгә. Теге чакта төлкене тик шул гына сызгырып куркытты бит...

Айзирәк кенәзнен балаларын хәтердән барлап чыга. Святополк—Ярополк атлы кенәз үтерелгәч, анын хатыны Ангелина табып баккан бала. Владимир ул баланы үзенеке дип игълан иткән-итүен, ләкин Святополк егерме яшен күптән тутырса да, кенәз ана бер кала да бирми. Изяслав—этисе белән ике абыйсы суеп үтерелгәч, Владимирга кияүгә чыгарга көчләп мәжбүр ителгән варяг хатыны Рогнеда тапкан бала. Изяслав та байтак яшькә житеп килә инде, ә Владимир аны да үз янында буш ояга утыртылган анаказдай тота. Аксак Ярослав та шул ук Рогнедадан туган бала бугай. Айзирәк аларны әле һаман ятлап бетерә алмый. Тик һәммәсенен дә Владимирга үчле булып яшәүләрен белә. Үзләре ныклап аякка баса алмаганга күрә, алар үч-ярсуны Айзирәк балалары өстенә чыгарып түгәләр, жай табылган саен типкәлиләр инде.

Шулар арасыннан аерып алу өчен Айзирәк Аллазар белән Алхозурга гел Коръәнне укый. Әлбәттә инде, нык яшереп кенә. Сабыйлар тупсаны атлап чыгуга ук Борис белән Глебка әйләнәләр, алар бүлмәдә бикләнеп утырган чакта гына күндәм мөселманнар. Икесе дә инде күптән укырга-язарга өйрәнделәр, йөзәрләгән сүрәләрне ятлап бетерделәр, алар өчен сөенерлек кенә. Ләкин Айзирәк бүлмәсендәге учак жылысыннан көнләшүче юха еланнар табылдылар бугай, Аллазар белән Алхозурны әледән-әле монастырьга илтеп бикли башладылар. Әниләре салган белем оеткысы шифалы чиргә әверелгән, ахры, игезәкләр Иске Инжил, Яна Инжил китапларын да яртылаш-яртылаш ятлап өлгергәннәр. Белем бөкрене чыгармый, аны дөя өркәче урынына сыртка күтәреп йөрисе дә түгел, әйдә, ятласыннар. Көнче агалары боларга зыян-зәүрәт кенә салмасыннар, берүк...

Беркөн сарайда ачы гауга чыкты. Владимир үзенен иң карт хатыны булган Рогнеданы сараеннан куып, кала читендәге утарына күчерергә ният иткән икән. Газиз әтисен, ике абыйсын суюны кичергән Рогнеда гаилә түшәгендәге хыянәтне гафу итә алмаган, аннан йөз чөергән ире янына пычак күтәреп кергән. Инде калап үтерәсе дә булган, имеш. Владимир кенәз соңгы мизгелдә ана беләген каршы куеп өлгергән, ди. Барча кенәзбикәләрне, балаларны да Рогнедага хөкем карары чыгарганны тынларга чакырдылар.

Залга аяк басуга ук игътибар итте Айзирәк: кенәзнен сул кулы, чыннан да, канга баткан иде. Уң кулына, барыбер, кылыч тоткан. Йөзендә нур юк, кыяфәте шашкын. Рогнедага таба төбәлгән дә, тамак төбе белән генә, нәфрәт кушып сөйли.

—Менә, монда жыелган килендәшләрен карар чыгарсыннар, аннары мин сине үз кулларым белән суячакмын. Гафу итү, чигенү булмаячак!

Һәммә хатын, барча бала-чага кайнар казанга чумдыргандай куырылып, тын алырга да куркып утыра иде, Рогнеданың өлкән улы Изяслав чәчрәп чыкты.

—Кая, кылычынны китер мина, әткәй! Мондый хыянәтче хатынны үзем тотып турыйм!

Владимирнын күзләре акаюдан маңгаена менде.

—Син нәрсә, имгәк! Бу бит синең анаң!—дип яраланган арыслан шикелле үкереп жибәрде ул.—Ул сине шушы жир йөзенә табып үстергән бит!

Изяславнын йөзендә бер төк тә селкенмәде.

—Ни пычагыма дип, алайса, кулына кылыч алдын? Кизәнгәнсен икән, чаба да бел! Йә гел күтәрмә, коткы салма!

—Ну, юха жан!—дип читкә төкерде дә, кылычын идәнгә зеңгелдәтеп ташлап, Владимир ишектән йөгереп чыгып китте...

Икенче көнне Рогнеда белән Изяславны Витебск дигән калага озаттылар.

## 68

Иdел буен яшендәй көйдереп коточкыч хәбәр үтте.

—Суздаль дигән калачыкта урыслар ачлыктан балаларын ашый башлаганнар!..

Кыргый афәт сукыр кеше кулындагы зәһәр кылыч сыман унны-сулны белмичә, бар җиһанны айкап килә иде. Беренче булып, Ука елгасы тамагында утырган Янкала сугым малы кебек тавыш-тынсыз ауды.

—Ач урыслар һәрбер ихатаны нигезенә тикле талаганнар, кирмән хәзер пеләш баш шикелле шыр-ялангач калган...

Мул карлы кыштан соң кузгалган язгы ташкын вакытында тар елгалардагы йөзәрләгән-меңәрләгән боз кантарлары, утарга ябылган ярсу үгезләр шикелле, бер-берсенең өстенә өелешеп, сөзешә-сөзешә, тибешә-тибешә, ыңгырашып-үкереп, кайный-кайный ага. Суздальдән күтәрелеп чыккан ач-әрвахлар чирүе дә нәкъ менә шул язгы ташкын йә, булмаса, челләдәге коточкыч янгын сыман, Иделнең ике як ярын да сытып-ялмап, Болгар уртасына якынайды.

Казан кирмәненең диварлары әле һаман яртылаш та төзелмәгән иде. Ушкуйлар хакындагы көенечле хәбәр Янкаладан яшендәй тиз килеп ирешсә дә, дивар араларындагы өзек-ярыкларны имән бүрәнәләр, ком-таш белән аннан-моннан гына ныгытып өлгерделәр.

Сал-Сал баскыннарны Корыган елга буена чыгып каршы алды. Ач-әрвахлар чирүен һәммәсе дә өрәкләр өеренә тап булгандай акаеп күзәттеләр. Тимер мичкәгә ябып ыслаган балык төсле, корсаклары аркаларына ябышкан арык карачкылар. Күзләре агач түмәрендәге тишекләр шикелле эчкә батып калган. Корыган нарат ботагыдай кипшенгән куллары тартып озынайткан сыман, тезләренә җиткән. Янак сөякләре терсәк очы кебек тырпайган, борын яфраклары әрекмән яфрагы шикелле юп-юка, арба тәгәрмәчендәге тырнаклардай сирәгәеп калган тешләре шак-шок килеп тора. Киемнәрен адәм теле белән аңлатмалы түгел, эт өере талагандай иске, ертык, кылка. Аның каравы, коралларны байтак эләктергәннәр. Яртысында—хәнҗәр, кылыч, җәя. Калганнары икешәр аршынлы сапка утыртылган сөнге, сәнәк, чалгы тотып баскан. Сизелеп тора: бугазга ябышсалар, болар кан эчеп туймыйча җибәрәчәк түгел.

—Сугыш арбаларын алга чыгарыгыз!—дип үкерде Сал-Сал.—Боларны башка ысул белән өркетүе читен.

Ике гаскәр арасында яткан үзәнлеккә пар атларга җигелгән уннан артык олау атылып килеп чыкты. Хәзер инде баскыннар “аһ” иттеләр. Олау дигәннәре ике генә тәгәрмәчле җиңел арбалардан хасил. Арбалары тоташ калканнарга, аргамаклар тимер көбәләргә бөркәнгәннәр. Тәртә башларында өчәр япьле сөнге, үрәчәләрдә беләк буе кылычлар чыгып тора. Тимер калканнардан корылган тирмәләр эченә икешәр-өчәр яугир баскан бугай. Берсе дилбегәләр тартып ат куалый, калганнары калканнар арасындагы ярыклардан ук янгыры коя.

Сугыш арбалары баскыннар гаскәрен утлы кылычлар, дәү сөңгеләр төсле алты-жиде кисәккә телеп-ярып узды. Әллә калканнар астына качкан яугирләр угыннан, әллә үрәчә-тәртәләргә көйләнгән кылыч-сөнге йөзеннән дистәләгән баскын авып калды. Баскыннар җавап итеп очырган ук янгырыннан файда күренмәде. Йә уклар аргамакларга бернинди дә зыян-зәүрәт салмый, йә, инде аргамаклар абынып егылса да, болгарлар аларны бик тиз генә яналары белән алыштыра иде.

Баскыннар бозлы янгыр астында чебеш көтүе сыман төрле якка сибелеп

кача башладылар. Арада ис-акылын жуеп бетермәгән атаманнары калган икән әле, кылыч-сөнгеләрен жиргә ташлап, шулар аваз салды.

—Биреләбез, яуны туктатыгыз! Без сезнең белән үзара солых төзеп куйган кардәшләр бит. Дуслык, дуслык!

—Ә-ә, артыгызга ут капкач шәрә икәнегез исегезгә төштемени? Капкынга көйләнгән майлы калжаны бушлай гына йотарга исәп тотсаң шулай эләгәсең ул!—дип кәпрәеп сөйләнсә дә, Сал-Сал яуны туктатырга әмер бирде.

Баскыннар чирүенең башлыклары белән Казансу ярында очрашып сөйләшкәндә болай килештеләр.

—Без ун корабка төяп ашлык жибәрәбез, ә сез Янкаланы янадан торгызасыз...

Солых Киевтагы Владимир кенәз күңеленә хуш килмәгән. Суздаль тирәсендәге авыллардан жыелган бер чирү ач ирләр Смоленск ягына да барган һәм байтак биләмәне талап кайткан икән. Якун атлы сыңар күзле варяг сәрдәр ышыгына басып, Владимир Суздаль өстенә үч алырга килгән һәм меңәрләгән ач-әрвахне тураклатып аткан. Туймас кенәзнең "әмер-үтенече" Болгар иленә дә килеп ишетелде.

—Суздаль янында меңнәрчә туганыгыз ачка кырылып ята. Аларга янә бер кәрван ашлык белән ярдәм кулы сузу артык булмас иде. Казаныгызда төзелгән дуслык солыхын яңартырга вакыт...

Хәсән хан жәдәләшеп-карышып вакланмады, әмма яңа кәрван башлыгына катгый таләп куйды.

—Нәфес белмәс ул кенәзгә тапшыр: "Болгарларның сәүдә кәрваннары урыс иленә аяк басарга дер калтырап яши. Сезнекеләр талап кына туймый, безнең сәүдәгәрләрне суеп бетерәләр. Йорты-ихатасы рәттән туры килгән ике күрше кунакка йөрешеп көн күрергә тиеш. Шулай булмаса, алар үзара талаша йә урлаша башлый. Бүләк-күчтәнәчне чын күңелдән күтәреп кергән бер күршедән икенчесе капка-ишек ачкан өчен түләү-фәлән дә, аяк ялы да алмый. Әгәр дустанә күрше булып яшисең килә икән, ике ызан арасында сәүдә юлын булдыр. Синең канат астында яшәгән вак-төяк кенәзләрең, аяк ялы, тамга дигән булып, болгар кәрваннарын талаудан туктасыннар..."

Ике-өч айдан соң Болгар дәүләтенә сөенечле хәбәр кайтып төште.

—Владимир кенәз болгарларның сәүдә кәрваннарын урыс жирендә түләүсез йөртү турындагы солыхка кул куйган.*

## 69

Владимир кенәз сараеның нигезенә, әйтерсең лә, янә янгын капты. Ләһ** кайсарының кызына өйләндергән һәм үзенең улы дип игълан иткән Святополк көннәрдән-беркөнне табын артында энә белән кадагандай астан чагып алды.

—Атай миңа туенырга бер биләмә бүлеп бирә белмәде инде. Аеры өстәл сорап бабай янына качасы булыр, ахры.

Владимирның хәтерендә үз туганын суйган кансыз Ярополк калкып чыкты бугай, ул Святополкны шул кичтә үк зинданга ташлаттырды. Әмма яман үрнәк үләт чире кебек бик тиз йога, диләр. Хәзер инде аның тирәсендә сарайдан сөрелгән Рогнеданың улы Чонтык Ярослав шөпшә сыман бертуктамый гөжелдәргә тотынды.

—Ата кеше буе ишек ниргәсе чаклы булган һәр малаен башка чыгарырга тиеш инде ул, тиеш инде. Юкса, түбәләре белән ниргәгә бәрелә башлый бит ул малайлар, башлый, башлый...

* Киев дәүләте белән Болгар иле арасындагы мондый беренче солыхның 1006 елда төзелүе мәгълүм.
** Ләһ – поляк.

Куенында зәһәр елан асрап ятасы килмичә, ул Чонтык Ярославны Балтыйк буендагы Новгород каласына ук олактырган иде. Тегесе данлы шәһәр нигезенә әле сынар казык та кагып өлгермәде, ә кәҗәләнеп кычкырган тавышы бик тиз килеп җитте.

—Моннан ары Новгород кенәзлеге аерым дәүләт булып яши башлаячак. Мин Киевка ясак түләүдән бөтенләй баш тартам!..

Бу чаклы әрсезлектән коелып төшкән ата әүвәл бот чаба-чаба көлгән генә булды.

—Ну, баш бар да соң монда! Атасының җиләненнән итәк кисеп алып, аерым чатыр кормакчы, баштан-аяк ябынмакчы була. Ай-яй, зиһенле бу! *

Ләкин ике-өч ай буе ясак кәрваннарын көтеп яшәү бернинди нәтиҗәгә дә китермәгәч, шашкын карар кылды.

—Киевтагы барча ирне ияргә күтәрегез! Аксак тәренең ыштанын салдырып, бөтен Новгород каршында артын ярып кайтам!

Гаилә колагына гына ишеттерәчәк сүзе башка иде.

—Чукынган хатыннарның үстергән малайларына ышанычым тәмам коргаксыды. Без сәфәрдә йөргән чакта олугбәк урынына болгар хатынынnan туган улым Борис кала!..

Юк, Айзирәк балаларына тәхет биеклеген тәтеп карарга насыйп булмаган шул. Владимир кенәз биленә кылычын да тагып өлгермәде, аны Берестов харәмханәсендәге бер җария ятагыннан җансыз калган көе алып кайттылар. Ә аннары инде кенәз сараенда канлы туфан купты.

Атасы үлгән кайгыдан дип Святополкны зиндан чокырыннан чыгарганнар иде. Кай арада табып, нинди хакка яллап өлгергәндер инде, ул сарайга йөзәр-йөзәр юлбасарлар озатуында кайтып керде. Бер кулында кылыч, икенчесендә хәнҗәр, сүзләрне ут шикелле чәчеп кенә тора.

—Аның өчен үги булсам да, мин кенәзнең иң-иң өлкән улы. Тәхет миңа тиеш. Мин үземне-үзем бүгеннән үк олугбәк дип игълан итеп куям!..

Шәһәр читендә качып йөргән Борис янына берничә бояр килеп, егетне баш күтәрергә димләп карадылар.

—Атаң сине булачак олугбәк дип билгеләп куйган иде. Йола буенча, тәхет сиңа тиеш. Безнең бер сызгыруга ун мең кешелек гаскәр җыела. Әйдә, атаң урынына сине утыртабыз.

Борис кырт кистереп кенә каршы төште.

—Юк, Святополк минем әтием урынына калган кеше. Аңа каршы кул күтәрә алмыйм.

Гәрчә Борисның һәр сүзе түкми-чәчми барып ишетелсә дә, Святополк үзе яллаган катилләргә кансыз әмер бирде.

—Болгар хатыныннан туган Борис белән Глеб үтә зиһенлеләр. Аларны боярлар гына түгел, чиркәүләр дә яклый. Бер көтүдә алты-җиде тәкәне башлык итеп йөртсәң тәртип бетә. Миңа энекәш булып саналган кенәзләрнең һәммәсен дә суеп бетерегез!

## 70

Киевтан көч-хәл белән качып котылган Якуб Ногманның тәүге сүзләре үк болгар түрәләренең ис-акылын алды.

—Святополк, эт җан, Аллазарга чатыр япмалары аша сөңге кадаттырган. Ул әле исән калган булган, бәгырь. Тик катилләр кулыннан котылып буламыни? Чатырдан шуышып чыгуга кылыч белән чабып

* Рәсәй тарихында беренче булып әтисенә каршы кылыч күтәргән шушы бәндәгә "Мудрый" дигән кушамат тагылып йөри. Ф.Тютчев хаклы, "умом Россию не понять".

өзгәннәр балакайның башын. Ә Алхозурны анын үз пешекчесе үк, катилләр акчасына сатылган Горясер атлы бәдбәхет, сарык бәрәне урынына тез астына салып, пычак белән суйган. Менә шулай әрәм булды безнең газиз улларыбыз.*

Болгарлылар күз яшьләре түгеп елаштылар.

—И-и, чит ояга барып күкәй салган кәккүк хәленә калган икән безнең Айзирәккәй. Мондый ачы кайгыларга япа-ялгыз көе ничек түзә микән? Нигә үзең белән бергә алып кайтмадың ул мескен балакайны?

—Күпме үгетләп карадым, тыңламый бит. Чит-ят җирдә япа-ялгыз хәлдә ятып калмасыннар, үзем саклармын, ди. Анын бу җиһанда таянырдай кешесе юк бит инде, аны нишләтәсең?

Сакал-мыеклары чаларып чыккан Сал-Салның җаны болай да тәрәзәгә кунган күбәләк шикелле бәргәләнә иде, соңгы сүзләрне ишеткәч бигрәк бетеренде.

—Юк, Айзирәкне урыслар кулына ташлап калдырмыйбыз,—дип өзеп салды ул кинәт.—Миңа күпме гомер буйдак көе интегергә була? Үлсәм—үләм инде, әмма Айзирәкне туган иленә барыбер алып кайтам!..

* * *

Казансу аръягында беркөнне бәп-бәләкәй генә җайдаклар төркеме пәйда булды. Юл йөреп азау тешен чыгарган кешеләр җитез абайларлык: менәр чакрым араларны мең михнәтләр аша кичкән сәйяхчылар болар. Атларыябыккан, җайдакларның киемнәре тузган, ләкин йөзләрендә сөенеч, җиңү тантанасы учактагы ялкын шикелле янып-балкып тора. Һәммәсе дә, иярләреннән күтәрелә төшеп, елга аръягындагы тау башында мәчет манаралары, сарай гөмбәзләре белән әтәчтәй кукраеп утырган калага төбәлгәннәр.

—Син киткәндә бу урында сыңар казык кына калган иде. Ә хәзер, күрәсеңме, нинди матур кала калкып чыкты. Байтак еллар элек син Казансу буена утырып бер аяныч хикәят сөйләгән идең миңа, хәтереңдә микән? Имеш, Нургали атлы батырны Елантау өстендә кала корырга ният иткән өчен бу тауның хуҗасы—канатлы аждаһа—сукырайткан булган. Ул аждаһаны да, дошманнарны да куып җибәрдек без. Аллага шөкер, бу тауга без хуҗа. Нургали батырга язмаган өр-яңа каланы синең белән мин дә, икәүләп төзешербез. Кемнәр белә, бәлки, бу Казан каласы киләчәктә пайтәхет тә булыр. Ни генә язмасын, үз бәхете белән, сау-сәламәт сабыйдай үссен иде. Син туган җиреңә кабат әйләнеп кайттың, аякларың төкле була күрсен, Айзирәгем минем, җанашкаем!—дип янындагы юлдашын күкрәгенә кысты пәһлеван ир.

Кечкенә гәүдәле җайдак та назлы аваз салды.

—Амин, амин, шулай була күрсен, Сал-Сал батыр. Минем кебек кол хәленә төшү, туган халкыннан аерылып япа-ялгыз көю газапларын күрмәсен бу шәһәр. Берүк озын гомерле бул, азат һәм хөр яшә, Казан—газиз калам!

*2004*

---

* Киевта 1015 елда булган канлы вакыйгалар турында сүз бара.



**Рәсимә Гарифуллина**

# АК САРАЙДА СЕРЛӘР БАР

ПОЭМА

*Балык Бистәсе районы Түбән Тегермәнлек авылында, минем туган нигеземдә бүген дә борынгы бабайлар төзегән Ак Сарай саклана. Мондый таш сарайларның өчәү булганлыгы һәм нәселебезнең затлылык билгесе икәнлеге мәгълүм.*

*Түбән Тегермәнлекнең ямьле, балыклы Кирәмәт күле, хәзерге Җебанай елгасы, аның янәшәсендәге калын урманнар, борыңгы Чаллы болыннары Бирдебәк ханның күңеленә хуш килгән. 1357—1359 елларда Алтын Урдада тәхеткә килгән Җанибәк ханның улы Бирдебәкнең җәйләү өчен Чулман елгасының уң як ярына килүе (хәзерге Бирдебәк авылы да аның исеме белән аталган) мәгълүм. Бу хакта риваятьләрдә сөйләнелә. Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов раслаганча, Бирдебәк ханның еш кына бу якларда кунак булуы билгеле. Җәйге айларда ханнар Ак Сарайлар тирәсендә чатырларда кунакта булганнар. Үзләре генә түгел, ярханнары да ял иткән.*

*Нәсел шәҗәрәсенең Чыңгыз, Үзбәк, Бирдебәк ханнарга бәйле булуы турында мин кечкенәдән дәү әнием Бибимәрьям һәм бабам Гарифулладан ишетеп үстем. Моның шулай булуына безнең Ак Сарайда сакланган, буыннан-буынга тапшырылып килгән хан ярлыгы да шаһит.*

*Ярлык—хан тарафыннан бирелгән рөхсәт кәгазе, указ, грамота. Алтын Урданың берәр улусына яки буйсынган дәүләтләрнең бер өлешенә хуҗа булу өчен, дәүләтнең үзендә яки чит дәүләтләрдә дипломатик мөнәсәбәтләр алып бару, шулай ук җир биләү өчен ханнан ярлык алу зарур булган.*

*Безнең нәсел ярлыгының тарихы һәм язмышы бик гыйбрәтле дә, серле дә. Ал тамга (печать, мөһер) сугылган, чит-чите кызыл кайма белән әйләндереп алынган, ефәк сыман кәгазьгә гарәп хәрефләре белән язылган бу ярлык дүртклә бөкләнгән килеш Коръән эчендә саклана, китап үзе дә, ярлык кебек үк, бик борынгы, битләре саргайган була.*

*Безнең нигездә XVII йөз урталарында кураәзче, халык табибы исемен алган Садрый мулла, XVIII йөзнең 70 нче елларына кадәр Юлдаш бабай яшәгән. Бик акыллы, гаярь кеше булган. Ярлыкны ул Хисмәтулла бабайга тапшырган. Аннан ярлык Ваһаб, Сөнгатулла бабайларга күчкән. Ак Сарайда сакланган ярлыкны Сөнгатулла бабай*

---

Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА – *шагыйрә; публицистика жанрында да иҗат итә. Балык Бистәсе районында яши.*

*нигездән аерылып чыккан олы улы Заһидуллага әманәт итеп тапшырган. Ә Заһидулла: "Бу бик күп хокуклар бирүче хан ярлыгы, ыруның дәрәҗә билгесе, бөтен ышанычым син, сакла!"—дип улы Рамазанга әйтеп калдырган.*

*Ярлыкны нигез бүрәнәләре арасына яшереп куялар. Аның яшерелгән урыны читятлардан сер итеп саклана. Әмма, яңа йорт салырга өйне сүткәндә Коръән белән бергә ярлык та юкка чыга. Бу ярлыкны алган һәм үзендә тоткан кеше аның фән өчен кирәкле никадәр булуын аңламыйдыр да. Иманына тугрылыклы калса ул аны төп нигезгә яки музейга тапшырсын иде.*

*Нәсел тамгабыз буйга өч сызык. Кабер ташларына да бүгенге көнгәчә шушы тамга салына.*

*Ак Сарай хәзер дә исән-имин килеш саклана. Элеккеге кебек үк анда Дәүләт сәгате йөри. Ак Сарай һәм элеккеге утарны әйләндереп алган саклагыч таш базларның кайберләре егерме беренче йөздә дә тарихи ядкарь булып торалар. Нәселыруларыбызның олуг ханнарга тугрылыклы булуы, авылга нигез салучылар икәнлеге, дәүләткә хыянәтсез хезмәт итүләре турындагы серләрне саклыйлар...*

## Хан ярлыгы кемдә?

*"Хан ярлыгы Ак Сарайда, саклагыз!"*
Җиденче буын бабам Юлдаш васыяте.

**Ак Сарайның тирән серләре бар,**
**Гасырларга китә тамырлар.**
**Нигез ташларына баш иярләр**
**Горурланып, туар токымнар.**

**Ничә гасыр йөри телдән-телгә,**
**Васыять йөри күчеп нәселгә.**
**"Хан ярлыгы Ак Сарайда",—диеп**
**Буын саен васыять әйтелә.**

**Җиде буын кендек җеп тоташкан**
**Юлдаш бабам нәсел тоткасы.**
**"Хан ярлыгын җуймый саклагыз!"—дип**
**Аваз сала дәвер кыйтгасы.**

**"Ярлык яшерелгән Ак Сарайга,**
**Хан ярлыгын шуннан эзләгез!"**
**Юлдаш, Хисмәт бабам кайтавазы:**
**"Нәсел затлылыгын өзмәгез!!!"**

**Ничә гасыр телдән-телгә йөри**
**Әверелеп олы әмергә.**
**Улдан—улга васыятьнамә булып,**
**Дәверләрдән күчә дәвергә.**

**Зур тарихлы таш Сарайда күзләр,**
**Җиде катлы дивар нигезе.**
**Хәтта ташлар телгә килерләр дә**
**Әйтелер күк васыять сүзе.**

Болгар диварларын хәтерләткән
Ак Сарайның сере нидә соң?
Кемнәр бүген мең сер яшерелгән
Гасырларның сүзен сөйләр соң?

Ерак тарих—Бөек ханнар юлы
Таш диварга килеп тоташа.
Алтын Урда хаким булган чорга
Ак Сарайдан күчәм уй аша.

Гасырларны кичеп уй йөгерә
Алтын Урда—Чыңгыз чорына.
Хан ярлыгы хатирәсе яши,
Кушылып яши "Чулпы җыры"ма.

Берсе анам, берсе атам каны—
Нигез-тамырларым билгесе.
Бабаларым Ваһаб, Сөнгать, Нәҗми—
Намус өлгесенең көзгесе.

Ак Сарайга яшерелгән ярлык,
Кайсы ханнан килгән әмер соң?
Чыңгыз, Батый, Үзбәк, Бирдебәкме—
Ярлык язган әмир ул кем соң?

Олыс җитәкчесе иткәнме ул
Җиде буын бабам Юлдашны?
Илче иткәнме ул чит җирләргә,
Әмер җиткерүче юлбашмы?

Бәлки, җирбиләүче билгеседер
Ал тамгалы ярлык нәселгә.
Хан ярлыгын җандай саклаганга
Сарай диварына яшергән.

Һәм сакларга кушкан боерыкны,
Нәсел горурлыгы—ярлыкта.
Берәү аны ханнар буыны, ди,
Бик күп фаллар йөри халыкта.

Хан даирәсеннән чыккан углан, имеш.
Зур дипломат, диләр кемнәрдер.
Нәсел агачымның тамыры учар,
Тармаклары йөзләр, меңнәрдер.

Берсе әйтә:
"Ханның дәвамчысы Юлдаш,
Булсын сиңа чук-чук сәламнәр.
Ал каймасы—шуның шәһадәте,
Чыңгыз улын күрегез, адәмнәр!"

Ефәк чуклар белән төргән ярлык—
Хан мөһерен суккан чынлыкка.
Шөһрәтенә шаһит гомер бакый,
Ак таш Сарай тора тынлыкта.

Ышанычын шулай белдергән хан.
Ярлык күчкән улга, оныкка.
Үткәннәрдән аһәң яңгырашы:
"Җиде буыныңны онытма!"

Бирдебәккә ясак җыйган, диләр,
Чулман буйларыннан Юлдашны.
Җанибәк углының дусты булган,
Киңәшчесе, имеш, юлдашы.

Ал тамгалы ярлык шөһрәт биргән,
Исем биргән дан һәм дәрәҗә.
Нәселемдә Укмасыйлар каны,
Данлы, шанлы безнең шәҗәрә.

Баксаң, әле минем тамырларда
Чыңгыз ханнар каны агадыр.
Жучи нәселе угыллары бар да
Кардәш-ыру, ерак бабамдыр.

Ничә гасыр йөри бу васыять,
Юлдаш карттан күчеп нәселгә.
"Хан ярлыгын югалтмагыз!"—диеп,
Ул теләгән күпне әйтергә:

Гаярь, батыр, ир йөрәкле булу—
Гөлстанның гөле итәдер.
Намусың саф, ихтыярлы булсаң
Гомер һәрчак ваем үтәдер.

Ул сакларга кушып хан ярлыгын
Үлемсезлек теле җанына.
Ак Сарайда калган хан ярлыгы
Ихлас шаһит аның данына.

Ул сакларга кушкан милләтен дә,
Югалтмаска кушкан телен дә.
Хан ярлыгы әманәте булган
Бердәм саклар өчен илен дә.

Әмма җуйдык, ярлык әзсез китте,
Васыятьне үти алмадык.
Буын белән буын ялганмады—
Зур ялгышны соңлап аңладык.

Үзем бүген бабам урынына
Сүз әйтергә җөрьәт итәмен:
Хан ярлыгын аклар Ир туганны,
Хакын хаклар көнне көтәмен.

Болгар диварларын хәтерләткән
Таш Сарайның сере нидә соң?
Мең сер яшерелгән кыйтгаларда,
Хан ярлыгы хәзер кемдә соң?

## Дәүләт сәгәте

*"Дәүләт сәгате күзгә күренми. Ул муллык, бәхет, дәүләт теләп тора".*
Борынгы риваятьтән.

Ак Сарайда Дәүләт сәгате бар—
Гасыр чаптарында узганы.
Риваятьләр сөйли кайтавазлар,
Күтәрелә дәвер тузаны.

Ялгыз калып кына тыңлыйлар, ди,
Бу сәгатьнең серле тавышын.
Санап тора дөнья әйләнешен,
Айлар, еллар, гомер агышын.

Санап тора һәр минутын, мәлен,
Теләп тора тәүфыйк, сәгадәт.
Көнең бәрәкәтле, тормышың бай.
Нигезеңдә булса бу сәгать.

Балачакның серле мизгеленә
Дәшеп тора сәгать чылдыры.
Үткәннәргә әйдәп алып кайта
Дәүләт сәгатенең чылбыры.

Алып кайта яшьлек хыялларга,
Чынбарлыклар белән тоташа.
Күпме дастаннарда дан әйтелгән
Бу сәгатьтә кодрәт, тамаша.

Алтыннанмы икән, көмештәнме,
Бәллүр микән әллә телләре?
Хыялымда күрәм һәм үрелеп
Тартып куям сәгать герләрен.

Балачакның серле хатирәсе:
—Келт-келт сәгать йөри Сарайда.
...Мин серемне чишәм якын күргән,
Сабый дустым—күрше малайга.

Алып керәм, җитеп Ак Сарайга,
Ярсый йөрәк, хисләр талпына.
Ташлар арасыннан күзәтүче,
Карап торган күзләр бар сыман.

Дәү әнием хикәятен сөйлим:
"Дәүләт сәгате бар нигездә.
Бик бәхетле йортта гына була,
Озак еллар йөри ул бездә".

И, беркатлы балачагым минем,
Серле сәгать эзлим Сарайда.
Тавышы бар, әмма үзен тапмыйм,
Бәхет сәгатьләре соң кайда?

Тәүге кабат без икебез бергә
Серле сәгать чыңын ишеттек.
И, курыктык, күреп калырлар, дип,
Нидер булыр төсле без көттек.

Серләр ачылыр да, туктар төсле
Йөрүеннән сәгать телләре.
Йөрәк тибешеннән күтәрелде
Дәүләт сәгатенең герләре.

Тын да алмый, кулга-кул тотынып,
Без тыңлыйбыз сәгать тавышын.
Ә ул саный безнең балачакның
Үтеп барган еллар агышын.

Сәгать йөри, Дәүләт сәгате бу,
Ак Сарайга каян килгән ул?
Тыпырчына йөрәк шомланудан,
Сәгать йөргән төсле тибә ул.

Уктай атылабыз урамга без,
Төсе качкан күзләр ялтырый.
Сүз әйтерлек хәл дә калмаган ич,
Тешләр тешкә тими калтырый.

Килеп бәреләбез Дәү әнигә.
Әйтерсең лә, урлап тотылдык.
Йөзем комач төсле оялудан,
Кызалаклар төсле кызыллык.

Сакламадым серне, уртаклаштым,
Мин бит дәүләт серен чишкәнмен.
Болаңгырлы[1] куктәй күңелкәем,
Бәрәкәтләр китсә нишләрмен?

—Дустыңның да дусты булыр, кызым.
Нишләдең син, балам, и, җанаш?..
Үкенече—моңлы күзләрендә,
...Гомер буе сабак бу караш.

Сабыр гына аркабыздан сөйде,
Шуның белән бетте шелтәсе.
Сыя[2] суларыдай ташып акты
Күзләремнең яшьле әлпәсе.

Без аңладык шунда, ике сабый,
Сер сакламас күңел тарлыгын.
Һәм бүгеннән башлап икебезгә
Уртак булган серләр барлыгын.

Без аңладык шушы мизгелләрдә
Сер саклауның олы бәһасен.
Җирдә тугры булып вәгъдәләргә
Сер ачкычын саклап яшәсен.

---

[1] Болаңгырлы — болытлы, күңелсез
[2] Сыя — ташудагы эре кар.

Ак Сарай ул олы сер сандыгы,
Ак Сарай ул аклык өлгесе.
Ата-бабаларның намусына,
Тугрылыкка чынлык билгесе.

Хан ярлыгы серен саклый Сарай,
Әманәтне үтәү—ышаныч.
Дәүләт сәгатенең чыңнарыннан
Ак Сарайга иңгән куаныч.

Шанлы туйлар барган бу Сарайда,
Алтын касәләрдән сыйланып,
Юлдаш хаким кунак кабул иткән—
Сукман[1] дускайларын—җыйналып.

Аркыш[2] маллар, хәзинәләр төяп
Килгән монда ханнан илчеләр.
Чуралары[3] иккән мул уңыштан
Тәгам җыйган олы-кечеләр.

Мул тормышлы, төзек дәүләт булган,
Дәүләт сәгатендә—бәрәкәт.
Дуслык, Шәфкать, Иман булган җир бу,
Илаһилык яши—мең рәхмәт!

Нигез эргәсендә басып торам,
Ак Сарайда күңел тәрәзәм.
Дәүләт сәгатенең чын кодрәтен
Сөйли миңа ыру шәҗәрәм.

## Югалган ачкыч

*"Ак Сарай ачкычын югалткан каенатам*
*аны эзләргә килennәргә кушты һәм*
*табучыга төп нигезне бүләк итте".*
Дәү әнием Бибимәрьям истәлегеннән.

—Ак Сарайның җуйдым ачкычын,
Кем табалыр икән, эзләгез!
Табучыга мирас шушы нигез,
Соңра дәгъвалашып йөрмәгез.

Зирәк бабам улларына түгел,
Киленнәргә кушкан бу эшне.
Мал бүлгәндә, белә, улларына
Низаглашу бер дә килешми.

Таш баз өсте туфрак арасында
Ак Сарайның серле ачкычы.
Кайсы килен табар, кемгә булыр,
Татлы минутларның ачысы?

[1] Сукман – батыр.
[2] Аркыш – кәрван.
[3] Чуралар – игенче, бигә буйсынган кеше.

Дүрт киленнең тик өчесе эзли,
Туфрак мамык төсле йомшаган.
—Белми кала Мәрьям, кайда йөри,
Ачкыч эзләргә ник чыкмаган?

Биек болдыр бер нурланып ала:
—Мин монда,—ди, Мәрьям,—нәрсә бар?
—Ак Сарайның ачкычларын эзләш...
Дәүрләү аңлаталар хатыннар.

—Кем табалса нигез шуңа,—диде,
—Кайнатаның вәгъдә сүзе шул.
...Ялтырап китә ачкыч, туфракны
Бер сыпырып кына карый ул.

—Ачкыч миндә, эти, кемгә бирим?
Мәрьям йөгерә Сарай янына.
—Нигез сезгә, кызым, вәгъдә—иман,
Һәм сез хуҗа йортым малына.

Ач Сарайны үз кулларың белән,
Кереп кара, муллык күрерсең.
Шиккә калган килен эчкә уза,
Нинди серләр барын кем белсен?

Сарай тып-тын, нигез диварында
Гасыр моңы сеңгән ак ташлар.
Бәхет ачкычымы кулларында,
Ни күрергә язган бу башлар?

Сарай түрләрендә бүлем-бүлем,
Тәгам-ризык, бөтен кирәге.
Авыл халкын ашлы иткән Сарай—
Тәлим[1] байлык тормыш терәге.

Бу минуттан барысы да аңа,
Авыл язмышы да кулында.
Һич сынатмас, аклар өметләрне,
Мең киртәне җиңеп юлында.

Әллә йөрәк шулай ярсып тибә,
Сәгать йөргән төсле Сарайда.
Саташадыр, бәлки сөенечтән,
Башы әйләнгән чак болай да.

Келт-келт тавыш килә, салмак кына.
Йөрәк алай тибә алмый бит.
Куркуыннан гына үзен-үзе
Ул юатып шулай алдый бит.

Агарынып чыга ул Сарайдан
Һәм ачкычны суза атага.
—Сәгать йөри анда, сәер сәгать,
Юрамагыз сүзем хатага.

---

[1] Тәлим—күп.

Акыллы карт тик елмаеп куя:
—Дәүләт сәгате ул—шатлыкка.
Йорт хуҗасы сезне кабул иткән,
Сөйләп йөрмә шаулап халыкка.

Димәк, сезне үзенә иш күреп,
Варис итә нигез хуҗасы.
Сез булырсыз бай да, бәхетле дә,
Читләп узар дөнья нужасы.

Садрый мулла нигезе бу, балам,
Изге нигез, бай һәм дәүләтле.
Аның олпатлыгы, гыйлемлеге
Заманында дөнья шаулатты.

Дәва өчен кышын түбәнөйдә
Куражиләк белән сыйлады.
Гарип-горабаны терелтте ул,
Мохтаҗ-мөэминнәрне зурлады.

## Еланнан котылу

*"Буар еланнардан котылу өчен милләткә*
*Садрый мулла кебек зирәкләр кирәк".*
Сөнгатулла бабам фикере.

Авыру кызны китергәннәр берчак,
Кипкән-корган, үтми ризыгы.
Үлем көтеп ята җиләктәй кыз,
Сүнгән өмет, тормыш кызыгы.

—Мин урманда йоклап бер төш күрдем:
Сусавымны бастым су эчеп.
Шул сәгатьтән башлап янам-көям,
Китә җегәр, бетә дәрт-көчем.

Мулла әйтә:
—Сөтле табак кирәк.
Китерәләр нәкъ ул кушканча.
—Бар да яхшы булыр, сау уяныр...
Дога укып кызны йоклата.

Табактагы сөткә агу сала,
Кешеләрнең барсын чыгара.
Кыз йоклагач, сөтне эчәр өчен,
Тиеш елан эчтән чыгарга.

Ул чыкканда күрми калалар гел,
Барча кеше йоклый изерәп.
Көтә-көтә карт та йокымсырый.
...Елан үз кодрәтен сиздерә.

Яшь кыз берни сизми, авызыннан
Буар елан чыга сузылып.
Чәч толымы төсле күкрәгеннән
Ул идәнгә төшә шуышып.

Табактагы сөтне эчә башлый,
Садрый мулла кызны уята.
—Авыруның сере шушы, балам,
Саусыз итеп елан йоклата.

Агулы сөт үлем угы булып
Елан күкрәгенә кадала.
Әнә шулай кызны терелтә ул,
"Күрәзәче", дигән ат ала.

Шул еллардан бирле ияле йорт,
Гомер бакый олуг дәүләтле.
Бу нигезгә хәер-дога кылып,
Зекер әйтә Дәүләт сәгате.

## Ак Сараем безне кичерде

Әйләнәм дә кайтам балачакка,
Серне чишкән ерак елларга.
Кулга-кул тотынган сабый дустым
Сердәш булып яши һаман да.

Хәтеремдә, икенче көнне дә
Ак Сарайга кабат кергәнем.
Ишетмәдем Дәүләт сәгатенең
Сәгадәтләр теләп йөргәнен.

Юкка чыккан иде серле сәгать,
Үпкәләпме безгә киткән ул?
Шул югалту белән аваздаш күк
Газиз татар халкым үткән юл.

Үкси-үкси еладым бу көнне,
Гаепле мин үзем барсына.
Бер кайтырмы Дәүләт сәгатебез?
...Әрнешләрдән йөрәк ярсый ла.

Солтанатлы Сөембикәне дә
Сатлыкҗаннар ятка саттылар.
Дәүләт сәгатьләре яшерелгән
Сарай капкаларын ачтылар.

Таркаттылар илне, талаттылар,
Ханбикәне тоткын иттеләр.
Дәүләт сәгатьләре зекер әйткән
Диварларның серен чиштеләр.

Алтын айлы ап-ак Сарайларга
Кызыл качлар элеп куйдылар.
Татарларым, ыруларым минем,
Нәсел горурлыгын җуйдылар.

Явыз җәллад бөйрәгенә таккан
Үткен кылычының кынысын.
Үчлек каны баскан күзләрендә
Уйнап торды дошман кылычы.

Ничә гасыр үтте башны иеп,
Бер югалган даннар тиз килми.
Җимерелде Болгар, Казан, Чаллы—
Сатылганны дәвер кичерми.

Көрәш мәйданнары батыр сорый—
Яулап алыр өчен бөтенлек.
Дәүләт сәгатьләре дөрес йөрсә,
Татарыма килер чын хөрлек.

Ак Сараем минем халкым төсле
Җуйган иде Дәүләт сәгатен.
Бар гаепне мин үземдә күрдем
Һәм еладым бетеп тәкатем.

Кичерүен ихлас сорадым мин:
—Өмет аклармын,—дип үтендем.
Ак Сарайга сарылып сулкылдадым...
Аһ, үкендем соң мин, үкендем.

Еллар үтте, олыгайдык без дә,
Менә торгач тормыш баскычын.
Сабый дустым кулларында хәзер
Дәүләт Сараеның ачкычы.

Сарай эргәсендә тагын икәү—
Ишетелә сәгать чылдыры.
Куллар-кулга бәйләнгән шул көнгә
Тоташтыра гомер чылбыры.

Тормыш дәрьясында кайнаганда
Хәсрәт сулары да эчелде.
Дәүләт сәгатебез кире кайтты,
Ак Сараем безне кичерде.

Җир шарында бердәм татулыкта
Яшә, халкым гореф-гадәте!
Ак Сарайның чал диварларыдай
Имин булсын Дәүләт сәгате!

Хан ярлыгы васыятен җиткер,
Буын белән буын тоташсын.
Төзек килеш, Дәүләт сәгатебез,
Безнең йөрәкләргә тоташ син!

Сәгать суккан саен берләш, татар!
Илгә иңсен бәхет, сәгадәт.
Серләр яшерелгән Ак Сарайда
Дәүләт теләп торсын бу сәгать,
Бәрәкәттә булсын һәр сәгать!

Риф
Бәдри

# ЯРЫКТАГЫ КОЯШ

ШУК ПОВЕСТЬ

I

Син 1981 елның 19 декабрен хәтерлисенме? Юкмыни? Ай-яй тиз оныткансың! СССР дигән мәмләкәтнен 1 нче номерлы кешесенә—Ильич II гә житмеш биш яшь тулган көн ләбаса бу. Әлеге көнне бөтен планета түземсезләнеп көтте. Түше Алтын Йолдыз белән тулган кaһарманыбызга бу юлы нинди бүләк бирерләр икән дип.

Хәтерләмәгәч, мина ышанмый хәлен юк инде синен. Бик тә ямьсез-иләмсез көн иде ул. Кыш уртасында давылга тиң шәп-шәрә жил котырсын әле! Хәзер менә шул шыксыз көннең шөкатьсез бер сәгатендә Казан буйлап чапкан аклы-зәнгәрле троллейбусны күз алдына китер. Чаба дип, теркелди инде шунда. Чынлап торып жилдерергә көне көнме анын? Юлы тагын юлмы? Казан кешесе булсаң, монысын күз алдына китерүе бер дә читен түгел: троллейбус көпчәге дыркылдап чокыр-чакырга чумып алган саен басып баручылар, буш кулларын селтәп жибәреп, биючеләр сыман аяк очларына баса, алга-артка атлый, жилле генә башка балет хәрәкәтләре дә ясап куйгалыйлар.

Инде хәзер әнә шулай “па-де-де”ләп барган жиде-сигез кешенең берсен күз алдына китерик. Әнә ул абзый! (“Абзый” әсәрнең башыннан азагына кадәр диярлек безнең тирәдә чуалачак. Әйдә без аны, экономия жәһәтеннән, Л. Б. дип кенә атыйк.)

Л. Б. утыргычның елкылдап торган тимеренә иләмсез зур кулы белән тотынган. Башында—искерә төшкән күн бүрек, анын колакчыннары артка кайтарып бәйләнгән. Күлмәк өстеннән генә кыршылып беткән тимер юлчы шинеле кигән ул, аны да жилбәгәй жибәргән. Арыслан борыныдай борыны да, ат күзе хәтле яшел күзе дә, үгез муеныдай муены да килешеп тора тагын үзенә! Буена, гәүдәсенә күрә бар да тап-таман.

Монсу уйчанлык тулы шул яшел күзен тәрәзә аша бер ерак ноктага төбәп, дәшми-тынмый гына бара бирә әнә. Чираттагы балет хәрәкәте анын киң чыраеннан кайгылы вә мәгъруp кыяфәтне юып төшерсә дә, берничә секундтан ул, нәкъ шундый ук булып, кире урынына кайтып урнаша.

Әйткәнемчә, әсәребезнен бик тә кирәкле кешесе бу, шуна күрә, анын

бөтен нәрсәсенә игътибар итсәң иде. Әйтик, ни дип әле ул "яшен яшьнәтеп" бикләнә торган күн сумка тоткан? Юкса аның кулында бәйләм сумка—"җәтмә" була торган иде бит. Унмы-унбишме ел—гел шулай! Бу маршрутта йөрүчеләр Л. Б.ның әнә шул "җәтмә"сен булса да хәтерләп калганнардыр. Чөнки аны искәрмәү мөмкин түгел. Төптә пөхтәләп гәҗит кәгазенә төрелгән (гел!) нәрсә ятар. Кер сабыны хәтлерәк димме. Кайбер карчыклар юл буе шул төргәккә текәлеп бара торганнар иде. Ни икәнен беләселәре килеп.

Син дә игътибар ит әле шул төргәккә, гади нәмәрсә генә түгел ул.

Тегене күр, моңа дикъкать ит, дип, җелегенә төштем бугай инде. Гафу ит, зинһар. Беләм ич, болай да барын искәреп, аңлап торасың. Бетте, юк ул синең кебек акыллы укучы хәзер!

Чехов агай ни дигән әнә? Сәхнәдә мылтык эленгән икән, ул кайчан да булса бер атарга тиеш, дигән. Безнең тамашачы, укучы сәхнәдә, әсәрдә күзеңә керәм дип торган әнә шул мылтыкны күрми. Мылтыгын күрә икән, атканын шәйләми кала. Кая атканын чамалауише нечкәлекләр турында тел дә тибрәтеп тормыйм инде. Тамашачы булыр өчен маңгаенда ике күз, укучы булыр өчен хәреф тану җитә дип уйлыйлармы? "Күзле бүкән" дигән сүз дә бар бит әле!..

Һи, үзем тагын! Имеш, язучы, әдипмен. Ак кәгазьдә каләм йөртү Казан урамында машина йөртү генә дә түгел ул. Әнә бит, каләм дигәнең салулап тагын әллә кая кереп киткән. Һич башкалар кебек, фәлән булды, фәлән булганнан соң төгән булды дип тезеп кенә бара белмим инде! Бәй, өйрәнәм генә бит әле! Бу беренче повесть кына бит әле минем.

Кайда калган идем соң? Ә, әйе, безнең троллейбус һаман юлда!

Менә троллейбус данлы революционер исемендәге киң урамнан шул ук данлы революционер исемендәге мәйданга килеп керде.

Чү, ни бу? Безнең Л. Б. янында утырган кызыйның өстенә авып бара түгелме? Аварсың да, рульне сулга шулай текә борсалар. Стажер-фәләндер инде. Л. Б. ахыр чиктә тотынып калды калуын. Әмма бу көтелмәгән хәлдән соң кызыйның моңарчы йокымсырап барган намусы уянып китте. Кызый җәһәт кенә торып басты: "Утырыгыз, абый!"

Бу нарасый комсомолка кемгә урын тәкъдим итүен, әлбәттә, белми инде. Тагын бер нәрсәне белми иде әле ул. Утыз еллап элек "абый"ны бер шәп кенә утырткannнар иде. Шуннан бирле аның—бер генә тапкыр да(!)—арт шәрифләрен утыргыч-фәләнгә тидергәне юк.

Бүтән бер мәмләкәттә булды бу хәл. Кызган плитәгә утырттылар аны. Чыжлап артыннан төтен чыкса чыкты, шөкер, кемлеген ачмады, серне ычкындырмады!

Шефлары соңыннан бу хакта бер бик тә мәгънәле сүз әйтте: "Аның кара көйгән арт чүмечләре бераүләрнең орден-медальләренә биргесез!"

...Әйе, шулай дигән иде шеф. Бусы инде өченче бер илдә, үз "конторлары"нда... Ул мөхтәрәм зат күптән отставкада. Анда хәзер Л. Б.ның "орденнары" турында белүче дә калмагандыр инде. Үзен дә каш җыерып кына искә алалардыр. Әйе, шулайдыр. Югыйсә, пенсиягә бер ел калып барганда, кинәттән "эшенне түгәрәклә" дигән фәрман җиткермәсләр иде.

Үзләренә тагасы иде ул "орденнар"ны! Шундый шыксыз көндә салкын троллейбуста айкалып-чайкалып барсыннар иде менә...

Суыкта шулай дыркылдый торгач, Л. Б.ның сатин күлмәге астына таракан керде. Агай шинель төймәсен эләктереп куярга мәҗбүр булды. Шуннан соң хәле көйләнә төште үзе.

"Ә тараканнар кая китте?" дип, син миннән таракан таптыра күрмә тагын. Әдип образлы тел белән язарга тиеш дигәнгә күрә генә кыландырып язуым. "Салкын үтте" дигәнне шулай "таракан керде" дип әйтү дә бар бит.

Тараканнар мәсьәләсендә һич борчылма, алдагы бүлекләрдә син аларның иң кәттәләре белән очрашырсың, шуларга ияреп шаккатмалы хәлләргә дә тап булырсың әле...

Мангаена "4", ян-якларына "44" саны төшерелгән, буявы кыршыла башлаган электр бахбае бу вакытта икенче бер данлы революционер исемендәге урамнан юырта иде инде. Бер үк вакытта ул шул данлы революционер исемендәге районнан да бара иде. Тәртәләре ычкынмаса, шашкын җил чайкалдырган чыбыклары өзелмәсә, йә алардагы күренмәс куәт агудан туктамаса, тиздән ул бөек даһи революционер исемендәге районга килеп керәчәк. Ләкин моның өчен аңа шул бөек даһи революционер исемендәге күпер аша үтәргә кирәк әле...

Троллейбус дөбердәп ошбу күпергә килеп кергәч, Л. Б.ның калын иреннәре читендә җыерчыклар хасил булды. Һичшиксез, елмаю галәмәте иде бу. Л. Б. боз юрганын ябынып гамьсез генә черем иткән борынгы елгага бәйле бер вакыйганы исенә төшерде булса кирәк...

* * *

Мәскәү түрәләрен дә йокысыз калдырган бу олуг юбилей алдыннан Казан түрәләре тыныч кына йокы бүсә ала дисеңме? Мондый мәҗлескә бүләксез килү татар бие өчен килешмәгән эш кенә түгел, хәтәр эш тә иде. Чөнки Казандагы биек вә чайкалгыч урындыкка утыртылган татар бие башкалары белән бергә үтә бер авыр вазифаны да үз өстенә ала. Бу—татар халкының тарихи гаебен юу вазифасы.

Татар халкының тарихи гаебе чиксез зур. Шуңа күрә һәр татар бие, беренче көннән алып соңгысына кадәр баш күтәрмичә юып та, варисына аны нәкъ элекке хәлендә тапшыра.

Татар халкының гаебе шуннан гыйбарәт: башка балыклар, әй, юк ла, халыклар урыс чуртанының авызына үзләре йөзеп керсә, татар керергә теләмәгән. Житмәсә, кылчыклы да булып чыккан әле. Казансу эчендәге бинаи һәйкәл кайберәүләр уйлаганча һич тә тарихи төшләр күреп йоклап ятмый, ә бәлки нәкъ менә шуны бертуктаусыз искәртеп тора.

Озын сүзнең кыскасы, Татарстан өлкә комитетының йокысызлыктан шешенеп беткән пропаганда бүлеге мөдире кабинетына бер татар галиме, атамалар белгече килеп керә. Компартия ветераннары хәтерлидер: бу бинага үтеп керү өчен кесәңдә партбилет булу гына җитми—взносларың түләнгән булу да шарт иде. Ошбу галимебез исә взнос түләмәгән килеш тә кертелә торган дүрт-биш коммунистның берсе иде. Мондый мәртәбәгә ничек ирешкән соң ул? Бәрәскә, Бәрәзә һәм Бирәзә авылларының (Урта, Түбән, Югары, Кече, Зур, Олы, Иске, Яңа...) исеме "Берёза" дигән сүздән алынганлыкны исбатлап.

Галим бу юлы да буш кул белән килмәгән иде. Олуг юбилей мөнәсәбәте илә бик тә тәгаен тәкъдиме бар иде аның: бөек даһи революционер исемендәге күпер астыннан мыштым гына кадими исем белән агып яткан елгага юбиляр исемен бирергә. Ягъни бөек тә, даһи да, революционер да булмаган, аның каравы тиңсез каһарман булган исән юлбашчы исемен.

Шушы сүзне ишетүе булды, бүлек мөдире аны идеология секретаре янына җилтерәтеп алып китте. Тагын биш минуттан алар өчәүләп Беренче кабинетына таба титаклыйлар иде инде.

Ишек төбе бүлмәсендә юлга аркылы баскан чибәр егетне секретарь сул кулы белән эшереп кенә куйды.

Кабинетта күлмәк якасын джемпер өстеннән кайтарган бер адәм дә әрле-бирле йөри иде.

Беренче аларны сабыр гына тыңлады, ара-тирә "тәк-тәк" диюдән узмады.

Әмма күреп торалар ич: йөзләре үк яктырып китте!

—Ярый, хуш. Прецедентлар бармы?

Мөдир бу сорауга әзер иде.

—Идел-Дон каналы Ленин исемен йөртә.

—Ә бу—канал гына түгел, тере елга!—Мөдирнең активлашуын чамалап алган галим җиңүне үзенеке итеп беркетергә тели иде.—Мин җиде төн рәттән йокламадым. Чаллы элеваторын да, Сөембикә манарасын да, Ослан тавын да, Казан каласын да күздән кичердем. Иң шәбе—елга. Урыс белән татарның уртак елгасы.

Секретарь колачлырак фикер йөртүен күрсәтергә кирәк тапты:

—Монысын хупласалар, Иделгә Ленин исемен бирү инициативасы белән чыга алабыз. Моңарчы ничек башларына килмәгәндер. Идел буенда туган, революцион чыныгу алган.

Беренченең йөзе чытылып куйды. Идеяне бу рәвешле ул үзе үстерергә тиеш иде бит.

—Анысын уйларлар. Политбюрода зирәк аксакаллар утыра!

Ләкин табышны үзенеке санаган мөдирне (исем табучыны ул тапты бит!) туктатырлык түгел иде инде.

—Бу—диалектик бүләк! Хәтта юлбашчыбыз бер заман нитсә дә... Гафу итегез... Иптәш Ленин эргәсенә китсә дә... Исем шул чакта да мәгънәсен җуймаячак. Юлбашчыбызны мәңге тере итеп гәүдәләндерәчәк. Әдипләр, әйтик, болайрак язар: “Иртәнге кояшның алтын нурларында Брежнев бүген аеруча гүзәл!.. Брежнев тынгы белми, Брежнев дулкынлана! Яки...”

Шул чакны, һич көтмәгәндә, бу кабинет өчен сәер тоелган нәфис тавыш яңгырады:

—Әгәр дә мәгәр, алар болай дип язсалар: “Котбетдин, Гайфетдин һәм Сәйфетдин Брежнев кырына ятып бер яртыны бөкләделәр. Аннары Брежневка кармак салдылар”.

Мөдир аяк астында идән чайкала башлаганын тойды. Ләкин, сер бирмәскә тырышып, йөзенә мәсхәрәле кыяфәт чыгарды.

—Безнең язучылармы? Безнең язучылар алай дип язмас! Безнең язучылар без теләгәнчә язар!

Әмма уен оттырылган, гүзәл идея харап ителгән иде инде.

—Ярар, мөгез чыгармыйк, сыналган юлдан барыйк,—диде Беренче салкын гына.—Чаллы шәһәренә документ әзерләгез!

(Шушы хәлдән соң Чаллы алты ел Брежнев булып яшәп алды...)

Коридорга чыккач, мөдир сорап куйды:

—Теге гөрбиян кем соң ул?

—Шуны да белмисеңмени?—кәефе кырылган секретарь аңа акаеп карады.—Илһам Шакиров ич. Беренченең ишеген тибеп кенә ача ул.

Мөдир мондый түрәне белми иде. “Тегеннән”, димәк. Әйтәм аны тавышы бөердән чыга!

Менә шулай итеп, мескен елгабызга юлбашчы исеме тәтеми калды. Нык оттырды ул. Чөнки адашы исән чакта гына булса да аны җәберләргә җөрьәт итмәсләр иде. Юкса, соңгы елларда, Арча крахмал заводыннан ике тапкыр кислота агыздылар үзенә, балыклары, бакалары үлеп бетә язды. Каменкадагы туберкулезханә “агынтылары” да өзлексез кушыла торды, кырларны ашлыйсы ашламалар белән аны ашладылар. Бусы әле—халык сөйләгәне генә. Яшерен заводлардан яшерен төстәниләр генә агып ятмагандыр тагын?!

Моны белсә Л. Б. гына белә инде. Күпне, бик күпне белә ул. Сөекле хатынын култыклаган Беренче Казан күгендә йолдызлар кабынган илаһи минутларда импорт туфлиләрен гамьсез генә шык-шык тидереп барган

асфальт астында хәтәр завод барлыгын да белә әле ул. Белү—аның эше. Әмма аның ни белгәнен Казанда беркем дә белми. Белгәнен белдермәү дә аның эш вазифасына керә.

"Кем була сон ул, йә, тилмертмә, әйт инде!",—диярсең хәзер син миңа, әйеме? Бик әйтер идем дә, ярамый бит. Сер! Әсәрнең азагына кадәр генә түз инде.

Сер дигәннән, мине кешеләрнең серне кемгәдер саклауга биреп була дип ышанулары шаккаттыра. Меңләгән еллар элек тә болан тиресе ябынган кызыйлар: "Сиңа гына әйтәсе серем бар иде",—дип, икенче бер борынгы туташны тау куышыннан дәшеп чыгарганнар. Мин менә бу сүзләрне язганда да ничәмә-ничә колак "Башка берәүгә дә әйтмә!"—дигәнне ишетеп тора.

Адәм баласы нигәдер серне бәйләнгән бау, төен рәвешендә күз алдына китерә. Шуңа күрә дә сер хакында "чишелде", "чиштем" дип сөйли. Төен, әгәр дә ул "каз боты" булмаса, чишелмәгән килеш череп беткәнчегә кадәр дә ята ала. Әмма сер төен түгел шул. Сер ул—бөгелгән агач кебек. Аның бик тә тураясы килә. Сер никадәр серлерәк булса, аның тураю дәрте дә шулкадәр көчлерәк. Житмәсә, яфраклары белән ул сине кытыклап та тора бит әле. Түзә-түзә дә кеше, кемгәдер ычкындыра инде серне. Иң кызыгы шул тагын: тегесе дә ычкындыргач, ана ихластан үпкәли. Соң син үз сереңне бөгеп торып интегергә теләмәгәнне кеше нигә интегергә тиеш ди? Ычкындыра, әлбәттә... Менә шулай, сөйләгәндә дә "чиште" дип түгел, "ычкындырды" дип сөйләү дөрес.

Тукта әле, җәмәгать, мин ни дип интегәм соң алай булгач? Бу сер бераз гына минем сер, ул төп синең сер ләбаса, Л. Б. әфәнде! Ягъни Лю Барский әфәнде! Бигайбә, ычкындырам мин аны.

Син һич тә пенсионер тимер юлчы түгел. Син—пенсионер тимер юлчы тиресе ябынган шпион! Америка үзәк разведка идарәсенең Казандагы резиденты! Синең хәзер бер татар гәҗитендә төпләнгән әшнәң Гуммер янына барышың!

Йөзең чытык булу да көн бозылгач "орденнарың" сызлаудан гына түгел. Көймәң комга терәлде синең, Лю Барский әфәнде!

Ә бит юкса мәгълүмат җыюның нинди мөкаммәл системасын булдырган идең. Син, пенсионер тимер юлчы, редакциягә Юдино яки Казан депосыннан вак-төяк хәбәрләр сырлап киләсең. "Комсомол-яшьләр экипажына—"яшел урам!", яисә "Юл профилен шәп белеп" кебекне. Синең таракан ермачлаган язуыңны башка берәү дә танымау сәбәпле, аларны Умәрнең өстәленә кертеп ыргыталар. Рәхмәт йөзеннән син ана "җәтмәң" төбендә фил рәсемле һинд чәе ташыйсың. Тик бүлмәдәге егетләрнең юкка гына авыз сулары килә—филле кап эчендә һич тә хуш исле товар түгел. Тыгызлап төрелгән кәгазь акча—иллелекләр, йөзлекләр анда!

Командировкадан кайтып кермәгән Умәр аларны "эшче һәм авыл хәбәрчеләре"нә таратып чыга. "Хәбәрчеләр" исә әзерләп куйган "хәбәрләрен" тапшыра. Умәр өендә, туалетка бикләнеп, аларны анализлый, эшкәртә. Үзәкне кызыксындырырлык мәгълүмат булса, Л. Б. Умәрнең редакциядәге эш өстәлендә бөтен шартын китереп ясалган айгыр рәсеме күрә. Ул чагында ана Умәрнең бүлмәдә үзе генә калганын көтәргә кирәк. Әгәр дә инде андый мәгълүмат юк икән, рәсемдәге айгыр ясалып ук житмәгән була.

Соңгы бер-ике елда Л. Б.ның тып-тыгыз "филләрен" күбесенчә әнә шундый, симез биядән әлләни аерылып тормаган айгырлар каршылый шул. "Филләр" үзләре дә бит әнә, юл мәшәкатьләре кичереп тормыйча, Казанда ук "Запорожец", "Москвич", "Жигули", "Волга" иише "транспорт чаралары"на әйләнеп баралар икән. Умәр аларны, үзеннән тыш, хатынына,

бажасына һәм хәтта яслегә йөрүче кызына да яздырган. Хәзер менә җиде тәрәзәле бакча өе әтмәлләп ята икән!

Дөресен әйтим, ихластан кызганам мин сине, Л. Б.! Күпләр монда әллә кайдан килгән әллә кемнәрнең артын ялап та балда-майда йөзәләр, чып-чын орден-медальләр, хәтта Алтын Йолдызлар алалар. Ә син гомерең буена ихластан үз кавемеңә хезмәт иттең, күпме михнәт чиктең. Инде менә сыңар ботың хәтле ниндидер Гуммер-Умәр аркасында бөтен карьераң чәлпәрәмә килде!...

Хәер, тәгәллек җәһәтеннән, эшеңдәге кайбер чатаклыкларны да күрсәтеп үтик.

* * *

СССРны таркату планының мөһим бер өлеше булган УБТАУЖ (Урыс Белән Татар Арасына Ут Җибәрү) операциясенә Л. Б. бик дәртләнеп керешкән иде. Казанга килгәннең икенче көнендә үк Казансу буена төште ул. Бетонланган яр буйлап әрле-бирле йөри торгач, туй кыйпылчыгына—җыр-гармунлы төркемгә тап булды. Төркем, канлы шәфәкъ суында йөзгән бинаи Һәйкәлгә текәлеп, ава-түнә җыр башкара иде:

...Башкалабыз Москвадан ул
Якты нур ала-а-а-а!..

Җыр үзәккә туктаусыз китеп торган затлы мехлар һәм кара алтынга җиткәч, Л. Б. тәвәккәлләде. Җырламыйча читтәрәк басып торган хатынга болай дип мөрәҗәгать итте ул.

—Гүзәл ханым, сез миңа, ерактан килгән турист кешегә, әйтмәссезме: каршыдагы соклангыч архитектур корылма нинди максат белән салынды икән?

Аның исәбенчә, бу сорау төркемне шартлатырга тиеш иде. Башы шәп башланды. "Гүзәл ханым" чырыйлап кычкырып җибәрде:

—Га-ри-фул-ла-а-ау! Гарифулла ди-и-и-им! Вунә теге нәрсә нинди нәмәрсә ул?

Җыр тукталды. Төркемнең икенче читеннән: "Ниткән нинди нәмәрсә тагын?"—дип сорадылар.

—Вунә генә ич инде, күзең чыкмагандыр ич! Син от роду казанский, беләсеңдер. Читтән килгән адәм сорый.

"От роду Казанский"ның "нәмәрсәне" беренче күрүе икән. Кайберәүләргә корылма таныш, ләкин ни икәнен белмиләр булып чыкты. Бераздан хәл көтелмәгән борылыш алды. Пинжәк якасына Ленин значогы беркетелгән пеләш абзый мәгънәле генә тамак кырып куйды.

—Тәк-тәк! Берәү дә белмәгәч... секретный объект булып чыга инде ул. Ә бу мосафир... секретный объектлар белән кызыксынучы булып чыга!..

Ярый ла данлы чекист исеме белән аталган урамдагы мәгълүм йортта тарихтан хәбәрдар кешеләр утыра икән. Алларындагы "дело"ларга ятып озак кына көлешкәч, берсе, бик тә канәгать кыяфәт белән Л. Б.ның җилкәсенә шапылдатып сукты да, "Гуляй! Объектларга бүтән алай бармак белән төртеп күрсәтмә!"—диде.

Җинел ычкынды Л. Б. Әмма килеп җитмәс борын әлеге оешма белән танышу аның планына кермәгән иде шул.

Тагын берничә уңышсыз омтылыштан соң УБТАУЖ операциясенә нокта куелды. Татарның милли хисен уяту мәетне кытыклап көлдерүгә тиң булып чыкты...

* * *

Әйе, эшен хөрти синен, Л. Б. әфәнде. Почетлы пенсия эләкми дә эләкми инде, әле бит, син "орденнар" алганда имезлек суырып яткан манка малайлар каршында үрә катып, отчет та тотарга туры киләчәк.

Син, әлбәттә, һәр вак-төягенә кадәр уйланылган соңгы операциянә беркадәр өмет баглыйсын инде. Бу—акланырга тырышуың гына да, Гуммердан үч алуың гына да түгел. Операция планын—акыл, хис һәм илһамнын уртак баласы. Бу—синен аккош жырың, "Илиада" поэмаң, "Идегәй" дастанын!

Тегендәге "конторыгыз" өстәленә сумкаңнан чинаган-сүгенгән Гуммер-Умәрне селкеп төшерү, әйе, гажәп күнелле булачак. Ым-ишарә дигәндә данлы Марсель Марсога биргесез бу затның ул өстәлдәге кыланышлары да тинсез тамаша булачак... Бусы хак. Әмма... Әмма монын өчен Умәрне ул сумкага тыгарга да кирәк бит әле. Менә бу кадәресенә, гафу ит, ышанып житмим. Чөнки Умәрне мин дә бераз беләм.

## II

Аксак таракан, арткы уң аягына чүгә төшеп, теләр-теләмәс кенә карангы юллардан юырта бирде. Кәефе юк иде бүген Аксак тараканнын. Хәер, кәефе кичә дә, өченче көн дә юк иде анын.

Каян килсен ди ул кәеф? Үзе ач, балалары ач. Житмәсә, семьяда бер тамчы авторитеты калмады. Кичә хатыны ни ди? "Әтиегез сез валчыккайларны ачка тилмертә, аннан тапканчы сезне Симездән генә тапкан булсамчы!"—ди! "Ул әнә иртәнге якта гына да һәркайсы бүрткән борчак шае ике кекс валчыгын выжылдатып кайтарып куйган",—ди! Сүзме инде шушы? Симездән тапкач, ул балалар шушы " сез валчыккайлар" буламы инде?... Сон, Харислам кабинетыннан Аксак та выжылдатыр иде аны. Харислам ул редактор ләбаса.

Алдатты шул Аксак, нык алдатты.

Журналист ауруслар (тараканнар адәм затын шулай "аурос" дип атап йөртә) Казансу буендагы яңа нәшрият бинасына күчеп, бүлмә бүлешә башлагач, тараканнар да бүлмә бүлеште. Башкалар чатыр чабып әйбер ташыганда Умәрнең ике кулын кесәгә тыгып сызгырып йөрүенә карап, бу йортта иң зур түрә шул икән дип уйлаган иде Аксак. Аягын да шушы бүлмә өчен сугышып сындырган иде. Умәр исә гап-гади бер бүлек мөдире булып чыкты. Бераздан мөдирлектән дә очырдылар үзен...

Аксакнын тагын аягы сызлый башлады. Көн бозылганга инде ул. Олы Дөньядан әллә ниткән шомлы авазлар ишетелеп тора әнә.

Аксак, перископын күтәргән су асты көймәсе кебек, плинтус ярыгыннан мыекларын чыгарды, аларны чайкап-болгап алды. Шикле нәрсә сизелмәде, әмма ашыгырга кирәк иде: ауруслар чәй мәжлесен төгәлләп киләләр бугай. Өчесе дә шунда, чөкердәшәләр генә! Гомер күрешмәгәннәр диярсен... Бу ике көн ялны таракан башына гына уйлап чыгардылар. Ул ике көндә ни ашарга тиештер таракан?

Аксак, авырткан аягын ныграк күтәрә биреп, иплэп кенә чыга башлады. Тик... шундук кире сикерде. Тел-лин мел-лин, бет мыегы! Хәйриснең өстәле астыннан Мөгезле таракан чыгып килә иде! Нәрсә сөйри соң ул? Әһә, транспарант!

Мөгезле белән очрашмавын хәерле иде. Кем белән сөйләшеп торганыңны күреп калсалар!.. Житмәсә, әгитли-оялта башлар. Таракан жыенына барырга димләр...

Ашыкканда очрамасаң, мөгезле булмассың!.. Синең кебек мәйданда бет

сугарып йөрер хуты юк Аксакның: күзенә мөлдерәп карап торган кырык тугыз бәләкәче бар аның. Ярый ла синең кырык алты гына.

Таракан җыены имеш! Син башта тараканның тамагын туйдыр. Аннары уйлап карар таракан, барыргамы синең ул җыенына, әллә юкмы... Гаделлек җитми имеш! Тараканның кара канын коялар имеш! Тараканны изәләр, тараканны сыталар имеш! Ә син—сыттырма! Ә син—тоттырма! Тараканга ярык беткәнме?!

Аксак иплән кенә башын чыгарып карады. Мөгезле таракан кукраеп плинтус өстендә тора иде. Транспарантын стенага сөяп куйган.

Йә, ни дисең инде? Ник тора ул, ни калган аңа анда?!

Аксак аслатып кына юыртып алды да, стена буйлап батарей ышыгына кереп чумды. Бу тапкырлыгына үзенең дә күнеле булды: батарей ярыгыннан ауросларның табыны да, Мөгезле дә уч төбендәгедәй күренеп тора иде.

Мөгезле әкрен генә йөренә, борылгалый. Аның китәргә уенда да юк! Ә ауррслар инде табынны җыярга керештеләр! Аксак башта теш арасыннан гына черт итеп төкерде, аннары бик тә хәтәр таракан сүгенүе белән сүгенеп куйды. Шунда келт итеп исенә дә килеп төште: таракан җыены бүгенгә билгеләнгән ләбаса!

Аһ, алаймыни әле ул! Син... көтеп торасыңмыни әле?! Көт, әйдә, көт! Хәзер өерелешеп килеп җитәрләр. Уңнан да, сулдан да. Саф-саф булып! Җырулар җырлап! Нотыгыңны әзерлә. Тамагыңны көйлә: "Яшәсен!" вә "Бетсен!"нәрең бөтен мәйданга ишетелерлек булсын!

Бар иде, бар Мөгезленең бәхетле чаклары. Янында таракан халкы мыжлап торыр иде. Хәзер, әнә, транспарантының икенче таягын тотарга сыңар таракан юк!

Аксакка кинәт күңелле булып китте. Ул, дәртләнеп, ярык турыннан аслы-өсле йөри башлады. Бер тапкыр, туктап, алгы тәпиләрен укмаштырып, таракан кукишы да күрсәтеп алды әле.

—Менә сиңа, мә сиңа! Менә сиңа—гомумтарр-рракан бәхете! Менә сиңа—тарр-рраккан бердәмлеге!..

Чү, тукта!—Аксак таракан, Мөгезленең каядыр текәлеп торуын абайлап, алгы сул тәпиен күз өстенә китерде. Каршы тарафта плинтус ярыгыннан, чайкала-чайкала, колга хәтле ике мыек чыгып килә иде. Биш минут та үтмәде, зур гына баш, тагын күпмедер вакыттан ауросларның пәлтә төймәсе хәтле гәүдә күренде. Тел-лин бел-лин! Иренчәк шәрифләре ләбаса бу! Хатыны җим эзләргә куып чыгарган инде моны.

Менә Иренчәк өч уң аягын нәзакәтле бер әкренлек белән күчереп куйды да, ял итәргә туктады. Аның гәүдә сызыгы хәрәкәт сызыгыннан 10-15 градус сулгарак төбәлеп калды. Менә ул иплән кенә сул тәпиләрен дә күчерде. Гәүдә бу юлы уңгарак төбәлеп калды. Тәпи йөрергә өйрәнгән чакта ук иренчәк булганга, аякларын ул шулай юрга ат кебек—иң гади ысул белән күчерә иде... Бераз хәл алгач, Иренчәк тагын кузгалды. Ул әкрен генә, иренеп кенә, әмма туп-туры Мөгезлегә таба бара иде!

Менә Иренчәк, көче бетепме, чираттагы адымын яртылаш кына атлады. Шул сәбәпле аның гәүдә сызыгы һәм, димәк ки, күз карашы да, Мөгезлегә текәлеп туктап калды. Тараканнарның иң ялкавы, дөнья хәрәсәне шактый вакыт хәрәкәтсез торды. Тик бу хәрәкәтсезлек ял ләззәтен чагылдырмый иде инде: Иренчәкнең гәүдәсе, утта кыздырылган тимер сыман, яктырганнан-яктыра барды, аркасындагы аркылы сызыклар да аермачык күренә башлады. Менә аның ике койрыкчасы калтыранып алды. Кинәт ниндидер хикмәтле көч бу симез гәүдәне өскә чөеп, 180 градуска борды да куйды! Шуннан... Юк, моны тараканга әйтсәң таракан ышанмас! Тәпиләрне бу кадәр дә котырынкы ешлыкта күчерү Биюче тараканның да кодрәтеннән

килмәс иде. Кире юлны очкан чебен тизлегендә чабып үтеп, Иренчәк баштүбән плинтус чокырына сикерде. Сикерерсен дә нибуч. Мөгезле тараканны һәм анын "мөгезле" транспарантын күрсән. "Таракан кавеменә—таракан хөрлеге!" дигән.

Аксакнын күптән мондый ләззәт кичергәне юк иде. "Ас-са! Ас-са!" дип бөтен көченә акырды ул эченнән генә. Онытылып китеп кул-аякларын да чәбәкләп жибәрмәкче иде дә... "дөп" итеп идәнгә мәтәлеп килеп төште. Уйланып торырга вакыт юк иде. Чатыр чабып, кире теге позициясенә менеп урнашты. Жайсыз егылганын шунда гына аңлады. Аксак аягы үтереп сызлый иде...

Бичаранын авыртудан уйнаклаган күз карашы ауservлар табынына төште. Умәр бала ыштаны кебек жете бизәкле чүпрәк белән өстәл сөртеп маташа иде. Умәр жыештыргач, бетте инде—чебен күзе хәтле валчык та калмаячак. Их, бет мы-егы! Бер бәхетләрең булмаса, баеп булмый урлап та!— "дуст" дигән химик корал башына житкән бабасы мәрхүм шулай дип жырлый торган иде...

Менә Аксак үзенең мәэюс күз карашын унга күчерде. Плинтус өстендә боегып кына Мөгезле басып тора иде. Аксакның мыеклары калтыранып куйды. Бар да шул мәлгунь аркасында гына. Катқыры! Дөмеккере! Берәр ауросы сытмый да бит үзен ичмасам. Бәтинкә үкчәсе белән. Менә болай итеп, борып-борып, борып-борып!..

Үч-нәфрәт кайнар дулкын булып бөтен тәне буйлап йөгереп үтте. Аксакка тагын рәхәт булып китте. Аяк сызлавы да басылды. Мөгезле дә башкача газапламады, башын аска иеп, транспарантын сөйрәп әкрен генә китеп барды.

Аксак, кача-поса, тиз арада табын урынын тикшереп чыкты. Юк инде, ашказанын актарып ташларлык тәмле истән гайре берни дә калмаган. Сукрана-сукрана яраткан урынына—Умәр өстәленең уң ишеге өстендәге ярыкка кереп урнашты. Монда Мөгезле белән бәхәсен тынычрак, фәлсәфирәк кимәлдә дәвам итте ул.

"Һәр тараканда баш бар, көчле-елгыр алтышар тәпи бар, аурос авызына карап тормыйк, мөстәкыйль үз тормышыбызны корыйк",—диме?

Башның олысы безнең Баш тараканда инде анын. Ул бер дә алай дип сөйләми бит әле. "Таракан—аурос бердәмлеген ныктыйк!"—ди... "Бөек кушаяклылар кавеме белән язмыш безне мәңгегә бәйләде!"—ди... Дөресен дә дөрес инде. Аурос авызына карап тормасаң, ачтан тәгәрәп катарсың. Бәйрәмнәре дүрт-биш көнгә сузылганда чыкмаган жаныбыз гына кала ләбаса.

Әнә бит тышкы дөньяда нинди мәхшәр. Мин монда корыда, жылыда ятам. Аста—идән, өстә түшәм дигәндәй. Уты да тагын: үзләре яндыралар, үзләре сүндерәләр—бер мәшәкате юк! Кемнәрдер канәгать түгел бит әнә. Имеш, тараканнын үз кояшын чыгарырга вакыт икән. Кояшын белмим, мөгез чыгарырга оста сез!..

Аларга тагын хокуклар да житми икән әле. Соң, иртән торгач мыек чистарту, тәһарәт алу хокукы үзен хак таракан санаганга бер дә аз хокук түгел ләбаса... Тегеләрдә тараканнарны сыту хокукы бар, янәмәсе. Ни бит инде. Бүгенге көн реалияләре... Юк, реалийлары... Әллә реалиләреме? Әнә шул нәрсәләр белән исәпләшмичә булмый бит инде... Тараканга хокук бирсәнме? Тараканга хокук бирсәң, ул ярты дөньяны кара канга батырачак... Монысын әйт тагын. Имештер без жирдә динозаврларга кадәр үк яралган беренче тараканнарның варислары икән! Нишләсен ди Аксак сезнең ул бөек таракан тарихыгыз белән? Мөмкин булса, ых та итми юеш корты кыргаякка әверелер иде әле ул. Кырык аякка жим күбрәк иярә бит...—Әнә

шундый фәлсәфи уйларга чума торгач, Аксак изрәп китте. Инде нәвем базарында йөргән килеш тә мыгырданып алды әле ул: "Һе! Таракан кояшы диген, ә! Уйлап табарга кирәк бит шуны!"

Аннары ул таракан төше күрде. Майлы шулпада йөзеп йөри икән. Шулпасын да шулпа, майлысын да майлы, тик авызга керми. Тамак турында түгел, баш турында уйларга—йөзеп чыгарга кирәк чөнки!..

Ә майлы шулпаның исе, борынны ярып үтеп, инде ашказанында фетнә кубарып йөри.—Һич түзмәле түгел! Түзмәде дә Аксак—уянып китте. Ләкин ис... юкка чыкмады! Ул куе, тәмле истән аның зиһене томаланды, башлары әйләнде. Биш тәпие белән берьюлы чытырдатып ябышмаса, мәтәлеп тә төшәсе иде әле... Ни булсын, шул Умәр инде—авызын зур итеп ачкан да катып калган. Гел шулай итә. Ниткән гадәттер инде ул!..

Ауросларның быдыр-быдыр сөйләшкәннәренә колак салып ята торгач, Аксак тагын йокыга куерды.

Йокы аралаш кына ишетте Аксак: бүлмәгә кемдер кереп, нидер әйтте. Өч каләм өч тавышка берьюлы шыгырдый башлагач, йокы чоңгылына баш-аягы белән чумды ул...

...Кинәт өстәл ишеге тирбәлеп куйды. Аксак, хәвеф сизеп, дерт итеп уянып китте. Нindидер нәрсә зур тизлек белән төшеп килә иде. Аксак шундук аска сикерде, кыеклатып Хәйрис өстәле астына чабып керде дә, өстәлнең тәрәзә ягына сарылып бер минут чамасы "юк булып" торды. Аннары җанфәрманга ачык идәнне кичеп, ярык янында гына туктап калды. Биш минутлап бер уйсыз, йөрәк тавышын гына тыңлап ятты ул. Йөрәге исә аның: "Мин дә исән, син дә исән! Мин дә исән, син дә исән!" дип тибә иде.

Бер уңмаган гел уңмас диген таракан мәкален юаныч итеп кайтып китәргә дә уйлаган иде инде. Әмма шунда каяндыр, әллә биектән, әллә күнеле түреннән инде, боерулы бер өн ишетте ул: "Ят, таракан! Көт, таракан!"

III

Редакциянең бу бүлмәсендә дә чираттагы эш көне кайный. Быелгы йә былтыргы кардәшләреннән әлләни аерылып тормас кебек иде ул. Чөнки гел гадәттәгечә башланып китте. Умәр генә, давылга сылтап, кырык минут соңга калып килде. Әмма ул да йоласын бозмады: өстәл янына килеп чүмәшүгә чираттагы айгырын әтмәлләп атты, монысы да аерымлык билгеләреннән мәхрүм иде.

Машинистка Раушания сылу янына беренче булып керер өчен егетләр ярыша-ярыша хат эшкәрттеләр. Аннары бер-ике саллырак әйбер дә эшләп аттылар. Планеркада тәкъдим ителәчәк материаллар исемлеген дә төзеп куйгач, тынычлап чәй мәҗлесе корып җибәрделәр. Көндәгечә гәп куерды. Киң фикерле, тынгысыз җанлы кешеләр буларак, гаилә, кибет хәлләре белән генә чикләнеп калмады алар. Республика, ил, дөньякүләм мәсьәләләрне хәл кылуның бердәнбер дөрес вариантын тәкъдим иттеләр. Бердәнбер дөрес вариантлар ким дигәндә өч булу сәбәпле, чәкәләшеп тә алгаладылар. Шулай да, ошбу кыенлыкларны исән-имин ерып үтеп, егетләр берзаман галактикаара киңлекләргә килеп чыктылар. Әмма Галәмнең яралуы мәсьәләсендә фикер уртаклыгына ирешелмәде. Шулай да, ямьсезгә җибәрмәделәр, гыйльми бәхәсне алдагы эш көненә чигереп торырга булдылар. Инде... (ике егетнең йөрәге ләззәтле сулкылдап куйды!) милли мәсьәләгә күчәргә дә була иде. Рафил белән Хәйрис мәгънәле генә карашып алдылар. Хәйрис тамагын кырды...

Сизәм, аптырабрак калдың әле син. Аңлаешлырак булсын өчен бераз артка чигеп алырга туры килер.

Хәйрис белән Рафилнең кызыл тышлы өр-яна редакция таныклыкларын әледән-әле түш кесәләреннән чыгарып карап, "без кем!" дип йөргән чаклары иде бу. Бер тапкыр шулай, редакция бүлмәсенең редакцион урындыкларында кукраеп утырган чакта, пенсиягә күрше редакциядән чыккан агай килеп керде. Йомышын йомышлагач, бераз тегесен-бусын сораштырып утырды. Аннан, тавышын әкренәйтә төшеп, әйтә куйды:

—Тынлап-тынлап торам да, сезнең телегезгә тышау кидермәгәннәр икән әле.

Егетләр аптырап бер-берсенә караштылар.

—Артык тугарылмагыз диюем. Дус бар, Госман бар дигәндәй...—Шунда абзыйның тавышы пышылдауга ук күчте.—Бу бинада һәр өч кешенең берсе... тегеннән утыртылган.

Рафил белән Хәйриснең күз карашлары беректе. Бу бүлмәдә алар нәкъ өч кеше утыралар. Өченче кеше Умәр иде...

* * *

Хәзер мин әсәрнең алдан ук куркытып торган өлешенә килеп җиттем. Аның бер каһарманы Л. Б. булса, икенчесе—Умәр. Каһарман булгач, мин бит инде аны синең күз алдына китереп бастырырга, әдәбият дәреслекләрендәгечә әйтсәк, образын тудырырга тиешмендер. Ә Умәр ул сиңа мәшһүр Әлмәндәрише генә түгел!

Туфан Миңнуллинга инде мең дә беренче хат килде бугай. Әлмәндәр безнең авылда да бар ул, дигән. Һәр кешегә азмы-күпме охшаш кемсәләр була. Хәтта әле ике тамчы су кебек тәнгәлләр дә очраштыргалый. Минем үземнең дә әллә ничә тапкыр шапылдатып җилкәгә суктылар. "Нихәл, фәлән!" дип. "Фәлән" түгеллекне белгәч, үпкәләп китеп баралар иде... Мәшәкать киметер өченме, Ходай Тәгалә адәм затларын серияләп иҗат итә булса кирәк. Бер дә юкта, серияле детальләрдән җыядыр. Ә менә Умәрнең иң бәләкәй детальләренә хәтле "мин Умәрнеке!" дип кычкырып тора. Умәрнең җилкәсенә берәү дә ялгыш шапылдатмый. Умәрне хәтта "при исполнении" булган алкашлар да бутамый.

Хәзер мин менә шул дөньясында бердәнбер затның портретын ясарга тиеш буламдыр бит инде... Портретны аны күздән башлыйлар бугай. Умәрнең күзе... Юк, гафу итегез, мин Умәрнең күзе шундый төстә дип кистереп әйтә алмыйм. Вәзгыятенә күрә үзгәреп тора бугай ул. Ә менә Умәрнең күз карашы... Умәрнең күз карашы гәптәшеннән читтәрәк йөрер. Әйтерсең лә ул күз карашы синең белән бөтенләй кызыксынмый. Башны бераз гына боруың була,—ялт!—ул синең йөзенә кадалып куя. Лаборант туфрактан проба алган кебек кенә.

Умәрнең борыны... Юк, җәмәгать, Умәрнең Сталин премиясе алган данлы "почти адашына" мәшһүр Нәфисәсен ясау күп җиңелрәк булгандыр. Нәфисәнең колагы мондый, авызы мондый дип язган икән автор, безнең ышанмый хәлебез юк. Чөнки Нәфисә әкият бит ул. Кемнең күргәне бар аны? Ә менә Умәр мәсьәләсендә бераз гына хилафлык китте исә, мәхшәр кубачак. Чөнки Умәрне белмәгән кеше юк. Әгәр "Алар Умәрне белә" дигән баш куеп, исемлек бирсәң, журналда бу әсәргә урын да калмас иде. Аннары да ике ел буе шикаять явачак әле. "Нигә мине, Умәрнең якын дустын, төшереп калдырдыгыз?!"—дигән. Чөнки шундый кеше инде ул Умәр. Умәр белән бергә лифтка утырган адәм лифттан чыкканда Умәрне кунакка чакыра. "Килми калсаң, үпкәлим!" дип. Умәрнең йомшак, назлы (әмма дәһшәтле дә була алган!) тавышын бер ишеткән кешегә Умәр белән бер карында яткандыр кебек тоела башлый. Ә Умәр бит тавышын ишеттереп кенә калмый, сүз дә әйтә әле. Ә сүзне Умәр әйтә белә инде ул!..

Умәр һәм хатын-кыз—бусы үзе бер зур тема. Тема гына түгел—упкын, чоңгыл! Чумсам чыгалмасымны белгәнгә, шунысын гына әйтәм: унжиде яшьлек машинистка кызлардан алып иртәдән кичкә кадәр буласы пенсияләрен чутлап утырган түтәйләргә кадәр Умәргә "Умәрчик!" дип дәшә.

Социализмда "матди кызыксындыру принцибы" дигән нәрсә бар иде. Умәргә хас бер сыйфатны "матди кызыксынучанлык" дип атап булыр иде. А пунктындагы матди байлыкның Б., В., яки Г.ның кесәсенә агып яту ихтималы Умәрнең төн йокыларын качыра. Тормышының иң кызыклы сәхифәләре дә әнә шул А. һәм Б. В. Г. ... лар арасындагы бәйләнешләрне эзләүдән гыйбарәт бугай аның. Шерлок Холмс индуктив һәм дедуктив ысулларга таянса, Умәр үзе чыгарган ике кагыйдәне корал итә: 1) булган мал урланмыйча кала алмый; 2) җаны бар кеше урламыйча түзә алмый. Шул куш көпшәле мылтыкны төбәп Умәр кемнәрне генә өнсез калдырмагандыр. Түрәләрне инфарктка ук җиткерә торган иде.

Дөресен әйтик, гаделлек өчен Умәр алып барган аяусыз көрәш аның үзенә дә җинел бирелмәде. Һәм әле 90 сум окладына да берни өстәмәде.

Менә шундый чәч агарта торган һәм яхшук мәшәкатьле "хоббие" бар иде Умәрнең. Тагын бит әле теге "фил машиналары"н да бер-бер артлы урам әйләндереп алып кайтырга кирәк. Машина тик торганны яратмый ул! Менә шул сәбәпле Умәр Л. Б.ның мәкерле йомышларын үтәргә вакыт табып җиткерә алмый иде. Һич тә Л. Б. уйлаганча күңел бирмәгәннән түгел...

Язганымны укып-укып карыйм да, кулдан каләм төшә. Шушы да булдымы Умәр? Соң чын Умәр бит бу Умәрне ишекле-түрле куып йөртә! Ул аңа сул кулының өч бармагын да бирмәячәк!

Язучыларыбызның әдәби ел йомгакларында һәр даим бер олы сорау куела: "Татар әдәбияты нигә дөньякүләм уныш казана алмый?". Иманым камил,—Умәр образы әдәбиятыбызны дөнья әдәбиятының түренә менгезеп утырта алыр иде. Тик менә Умәрнең үзен китапка кертеп утырту кадәресен кем эшләр? Тере классикларыбыздан берәүнең дә кодрәтеннән килерлек эш түгел бу. Аяз Гыйләҗев, Ркаил Зәйдулла, Зөлфәт Хәким өчәүләп тотынып карасалар гына инде. Әмма... Ике татар язучысы бергәләп "Унике урындык" түгел, сынар табуретка да ясый алмаячак. Алар тагын өчәү дә булсалармы? Өч татар язучысына бер каләм тоттыру шактый хәтәр эш ул.

Чү, сабыр, чәбәләнмә. Ни әйтергә теләгәнеңне беләм. Әйе, "Идел" журналы авторлары "Арысланнар араны"н—биш борынга, "Әчтерхан чикләвеге"н—дүрт борынга яздылар. Тик шунысын да онытмыйк: әлеге шаян роман белән шук повестьның һәр бүлегенә бер мөстәкыйль "борын" беркетелде бит. Әгәр дә ул дүрт-биш егетне бер бүлмәгә бикләп куйсаң, ни чыгар иде? Берни дә чыкмас иде. Берни дә чыкмау бер хәл, беркем дә чыкмас иде, ул бүлмәдән. Гәҗитләрдә уртак хәсрәтнамә чыгар иде: "...Иҗат процессында... батырларча... татарларча..." Шулай булгачтын, Умәр образын иҗат итүне киләчәк буын татар әдипләренә калдырып, әсәрне дәвам итик без. Кай җирдә тукталдым әле? Ә, әйе, Хәйрис белән Рафил Умәрдән күптән шикләнеп йөриләр иде инде. Инопланетан түгел микән дип. Бактың исә, әнә ничек икән ул!.. Әмма татар журналистларының кыюлыгына чик-чама бармыни соң? Рафил белән Хәйрис тә куш йөрәкле егетләр булып чыкты. Алар бу хәлдән хәтта ки кызык та таба башладылар.

Әйткәнемчә, Хәйрис тамак кырды. Рафил, Умәрнең күзенә туп-туры карап, әкрен генә "татар..." диде. Инде Хәйрис Умәрнең күзенә текәлеп катты. Ул да, ярты минутлап шулай кадалып торгач, бер сүз өреп чыгарды: "...халкы!". Бераз тынлыктан соң Рафил кабат шул рәвешле "татар..." диде. Хәйрис бу юлы чукрак кеше дә ишетерлек итеп ярып салды: "...милләте!"

Умәр төсе үзгәреп-үзгәреп алган күзләрен егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә күчерде. Менә ул, авызын нык кына ачып, катып калды. Егетләр Умәрнең бу гадәтен беләләр. Көтмәгәндә бер-бер катлаулы хәл килеп чыкса гел шулай итә ул. Авызы, фотоаппарат чаршавы кебек, биш-ун секунд ачылып тора. Умәр гүяки шушы хәлнең сурәтен ала, күзе, колагы, авызы, борыны—булган бөтен сизү-тою әгъзалары белән мәгълүмат туплый. Авыз ябылгач, хисаплау машинасы эшен хәтерләтеп, күзләрендә төрле төстәге утлар яна-сүнә башлый... Бу юлы машина нинди нәтиҗә чыгаргандыр, монысы бер Ходайга мәгълүм.

Арысланның тамак астын кытыклауга тиң ошбу батырлыктан соң тәмләп кроссворд чишеп алганда да ярар иде. Бу зыялылар шөгылен алар өчесе дә ярата. Әмма беренче икесе карандашны Умәргә тоттырмаска тырыша. Чөнки Умәр, ихтыяҗ булса, кроссворд тәртәсенә кергән сүзләрнең бер-ике хәрефен күз дә йоммый үзгәртә. Биш хәрефле сүзне дүрт шакмакка сыйдыру исә аңа ике тиен—бер акча!

Хәйрис инде “Огонек” журналының тиешле битен дә ачып куйган иде. Ләкин яшь матбугат әһелләренә бүген шакмаклы уйнау насыйп булмады. Ишектә җаваплы секретарь Ниязамовның йомры башы күренде.

—Егетләр, һәркайсыгыздан берәр отклик! Бабайга тагын Герой биргәннәр!

Биргәннәр тек биргәннәр инде. Егетләрнең мона һич исе китмәде. Бабайга Герой бирелү гадәти хәл иде. Ничәнчесе була бу—арада бәхәс әнә шул хакта гына чыгарга мөмкин.

Ильич-II алган Йолдызларның санын тырышканда белеп була ла ул, ә менә бу егетләр ошбу гәҗиткә әзерләп биргән откликларның исәбенә чыкмалы түгел!

* * *

Отклик!.. Татар журналистика бакчасындагы хикмәтле түтәл! Нинди генә купшы кәгазь гөлләр чәчәк атмый монда, мескен татар теле нинди генә кыяфәтләргә кереп бөгелми ошбу түтәлне тәрбия кылыр өчен!

Ни соң ул татар гәҗитләрендәге отклик, ягъни татар отклигы? Мәскәү хакимнәре пырт иткәндә Татарның “ярхәмекалла!”сы бу. Әмма аны әле әйтә дә белергә кирәк бит. Хакимнәр төче мактауга гына разый түгелләр. Бөтен шартын китереп, дәлилләп, үзләре үк ышанырлык итеп мактарга кирәк аларны. Ягъни кәгазь чәчәкләр дә тере чәчәкләр кебек табигый ямь сирпеп торсын. Бер чәчәк икенчесенә охшамасын. Искәрмәсләр димә: татар биенең яраннары иң әүвәл шушы түтәлгә күз сала.

И, ошбу гаҗәеп түтәл янында аптырап басып торачак замана аспиранты! Дөньяның башка бер генә илендә дә булмаган әлеге журналистик жанрның хикмәтенә төшенә алырсың микән син?.. Иртәгә үк бу гәҗиттә, һичшиксез, урак батырының отклигы басылып чыгачак. Хәзерге минутта пыр тузып эшләп йөргән егетнең йөрәк хисләре редакциягә ничек килеп ирешер икән соң? Син бит моны болайрак күз алдына китерергә мөмкинсең.

Фәләненче партсъезд исемендәге колхозның ремонт мастерскоенда, көндезге ашка өенә кайтып килгән механик Габдүш сөенче алды.

—Иптәшләр, әле яңарак кына шатлыклы хәбәр килеп ирешге. Леонид Ильичыбыз тагын Герой булган! Тегесендә үткәндәге кебек Советлар Союзыныкы иде, бу юлысы, аннан да алдагы юлысы кебек, Хезмәт Герое!—һавалы бер тантана белән шулай диде Габдүш. Кремльдән беренче аңа шылтыратканнар диярсең!

Шул сүзне ишетү белән комбайнчы Хафизулланың кинәт күңеле тулды. Бар, бар ла ул дөньяда гаделлек!

Артык нечкәреп китүен хезмәттәшләренә сиздермәскә тырышып (иратка килешми!), Хафизулла солидоллы кулын башта майлы чүпрәккә, аннары халат итәгенә сөртте. Дулкынланудан халатын тунга алыштырырга да онытты, ярымшәрә күкрәге белән давыл ярып почта тарафына ыргылды ул. Бер сәгать буе линиядәге элемтәчеләрне эт итеп сүккәч, аны, ниһаять, редакция белән тоташтырдылар.

—Әллү, әллү, кем әле бу? Умәр, дисеңме? Карале, Умәр дус. Генераль секретаребызның бүләкләнүе уңаеннан шалтыратуым. Йөрәк түреннән кайнап чыккан хисләремне халыкка җиткермичә кала алмыйм, пажалысты, мин сөйләгәннәрне язып кына ала күр инде!..

Болай ук булмас ла, дисеңме, аспирант иптәш? Ничек була соң алайса? Әйдәле, без дәшми-тынмый гына шушы өч егетне күзәтеп торыйк.

Әнә бит, Ниязамовның бөдрә чәче җилфердәп алуга ун минут та үтмәде, Рафил каләмен куеп телефонга үрелде. Өстәлендә әзер текст ята. “Соңгысы булмасын!” дигән баш астына ике кат сызылган. Хәзер Рафил “Урак-чүкеч” заводы комсомол комитеты секретарена шылтыратып, “фәләнгә әйт, иртәгә откликы чыга, аптырап калмасын”,—диячәк.

Ә безнең Умәр нигә ишекле-түрле йөри әле? Урак батыры шылтыратканны көтә мәллә? Юк, урак батырының кап-кайнар сүзләрен Раушания гүзәл инде тукылдатып та бетергән, әнә, пешмәс өчен читеннән генә тотып, алып кереп тә килә. Умәр, каләмен уйнатып, текстны укый башлады. “Бөтен авыл сөенде!”нең астына сызды, як-якларына кызыл юл тамгалары куйды... Урак батыры аптырап калмас. Чөнки ул, ферма матуры кебек үк, алдагы ун-унбиш елда булачак бөтен бөек эшләрне дә хупларга ризалыгын күптән биреп куйган инде.

Ә менә зыялылар мондый интим хисләрне белдерүгә бик тә җаваплы карый. Өйләренә яки эшләренә шылтыраткач, алар хис-тойгыларын телефонга йә шундук түгеп сала, йә кәгазьгә төшергәч үзләре хәбәр итә. Бу нечкә эшнең чын осталары бар. Әнә бит, танылган әдип үзенең “ярхәмекалла!” сын Хәйрискә әйтеп яздыра да башлады инде: “Татар... урамында... бәйрәм!” Полосага салынгач, алтын каләмле ручкасын кыстырып килеп, укып та китәчәк әле ул аны.

* * *

Тыштагы гарасат тәэсиреннәнме, Умәрнең күнеле тыныч түгел иде. Башында, чаң кебек, бер уй кабатланды: “Айгырны ясап бетерергә кирәк!” “Айгырны хәзер үк ясап бетерергә кирәк! Мәгълүматын соңрак та юнәтә алам бит мин аның”. Ләкин, ләкин... “Кем уйлаган шулай бәләкәйдән тора диеп кеше бәхете!..”—бер эстет шагыйребез шулай дип язган. Бик тә белеп язган! Менә Умәр кызыл хәрендәшен алырга дип өстәл ишеген ачып җибәрде. Ишек өстендә... таракан оеп утыра иде... “Һай, иблис!” дип, Умәр Рафил өстәлендә яткан китапны ялт кына үрелеп алды да җилле генә селтәнде. Мөдәррис Әгъләмнең саллы поэзиясе мылтык аткан тавыш чыгарды. Тик тактада бернинди эз-фәлән калмаган иде. Умәр тиз генә китапның теге ягын әйләндереп карады. Анда да “Бәясе 40 тиен” дигән язудан гайре бернинди тамга-фәлән юк иде. Умәр, таракан халкы белән эш иткән кеше буларак, өстәл башына үрелеп, ярты минутлап чекрәеп карап торды: “Иблис” хәзер җан-фәрман шунда чабып чыгарга тиеш. Тик ул күренмәде. Умәр, ярсып, шатыр-шотыр өстәлен үк күчереп ташлады. Таракан юк иде! Шул өстәлне кире күчереп маташканда ишек (бүлмә ишеге!) ачылып китте. Ишек кысасында ишек хәтле адәм күренде. Бу, әлбәттә инде, Л. Б. иде.

Л. Б. һәркайсысы белән кул биреп күрешеп чыкты. Умәр белән күрешкәндә күз кырые белән генә айгырга карап алды. Аның бәгыре таш булып катты. "Булсын! Бик шәп!—дип уйлап куйды ул ләззәтле бер ачу белән.—Биш минуттан син сумка төбендә тупырдап ятачаксың!"

Умәр айгырга бакканда Л. Б.ның яшел күзе хәнҗәр йөзедәй зәңгәрсуланып куюын искәрде. Сул почмакка урнаштырылган кара сумка да бүлмәгә кара шом бөркеп тора иде. Ни була алыр икән анда? Элек күп бәлалардән йолып калган эчке тоемы нигә дәшми соң?

Умәрнең эчке тоемы бу вакытта, мәсьәләнең катлаулылыгыннан гаҗиз булып, аптыраганнан шом субъектын килешләрдә төрләндерә иде. Үзен генә дә түгел—шом объектына ялгап:

Син сумка
Син сумканың
Син сумкага...

Күпме генә сузма, урын-вакыт килешеннән дә ары төрләндерә алмыйсың. *Син сумкада*... ятачаксың,—ни дисен, шулай дип әйтте инде. Сумка хәтле өч булган Умәргә! "Тычканга үлем, мәчегә көлке!"—эчке тоемына ихластан рәнҗеде Умәр. Ләкин аның запаста тагын бер тоемы бар иде әле. Туктаусыз айгыр ясап ялыккан рәссам тоемы аңа шундук канга манчылган зу-у-ур балта сурәте ясап бирде. Балта бу тәгаен вәзгыять белән бик ярашмаса да, Умәрнең эче жу итеп китте... "Егетләр монда чакта тия алмас",—берләнбер таянычы булып шушы өмет калды хәзер. Умәрнең күңелендә беренче тапкыр хезмәттәшләренә карата җылы, хәтта ки кайнар хис уянды. Бу минутта алар аңа сылу, яшь хатынынннан да газизрәк булып тоелды. Ләкин Л. Б. өметне тиз кисте.

—Аста редакторыгыз очрады әле,—диде ул гөбедән чыккан тавыш белән.—Обкомга барышы икән. Пленуммы, бюромы ди шунда.

Шул минутта ук мәгълүм булды: һәр ике егетнең кичектергесез эшләре бар икән бит.

Хәер, өмет ул чакта да киселеп үк бетмәгән иде әле. "Урталарына кысылып чыгып кит!—Эчке тоемы Умәргә шулай диде.—Аннан, иң җитез машинаңны җигеп, Урта Азиягә элдерерсең".

Әмма Л. Б.га да эчке тоемы нидер әйткән ахры. Ул, алдан ук Умәрнең юлына аркылы басып, "Умәр, сиңа шәп хәбәр алып килдем",—диде... Ишектән соңгы булып чыккан Рафилне Умәрнең нәүмиз күз карашы озатып калды.

Ишек шартлатып бикләнде. Умәр, булган бөтен көч-егәрен, елгырлыгын, гайрәтен туплап, аяусыз сугышка әзерләнде. Ләкин каршында чын профессионал, ягъни иблистәй нечкә акыллы зат басып торганын чамалап житкерми иде шул әле ул. Гади бер агент буларак, фәннең разведкага хезмәт иткән тармакларындагы фантастик казанышлардан да бихәбәр иде ул.

Чәнчерме, сугармы, бугазга үрелерме дип баш ваткан Умәргә сөеп карап, Л. Б. ишетелер-ишетелмәс кенә әйтеп куйды:

—Синең исемгә радиограмма килде, Гуммер. Язып алырга ярамый, хәтерлә: "Хаштын, баштын, ике йөз кырык дүрт, шак, мак".

Берни аңламаган Умәрнең ике күзе тиентен шакмак булды. Йомран тишегe хәтле булып авызы ачылды. Л. Б. бу тишеккә бәләкәй генә ап-ак шар томырды. Шуннан соң Умәр... күз алдында кечерәя башлады! Менә каушап калган эчке тоемы, ниһаять, "Төкер!" дип боерды. Умәр төкерде. Нык төкерде. Бераз кечерәя төшкән шар тек итеп тәрәзә як плинтуска килеп бәрелде. Шуның белән әсәрдән чыккандыр дип уйлый күрмә, бу шарның чын маҗаралары алда әле!

Шардан арынгач та Умәр бер ун секундлап кечерәя бирде. Процесс төгәлләнгәч, Л. Б. каршында карачкыдагы кебек җилфердәгән ак кримплен күлмәге һәм идәнгә тиеп торган галстугыннан тыш бер генә киеме дә булмаган, урта группа бакча баласы хәтле генә Умәр басып тора иде. Һәм бу кәрлә Умәр әле зураеп шуып төшкән чалбар-ыштанына, әле Л. Б.га карап кулларын бутый, әче тавыш белән чиратлап яный, ялвара, елый вә сүгенә иде.

Л. Б.ның эченә корт керде, чөнки аңа ярты Умәр түгел, чирек Умәр кирәк иде. Сул кесәсендә теге шарның игезәген капшап тапкач, Умәрнең күзенә туп-туры карап, ант биргән пионер кебек тантаналы төстә ярып салды ул:

—Иштен, киштен, тиштен, туксан тугыз, сим-сим!

Умәрнен башы кечерәйсә дә акылы кечерәймәгән икән— бу юлы авыз ачылмады.

—Зурайтам бит, ач авызыңны!

Алдарсың Умәрне алай гына, бар! Артка чигеп, "Башта үзең кабып күрсәт!",—диде. Тегесе капмагач, авызын җеп калынлыгы гына ачып, шундый ук калынлыктагы тавыш белән әшәке итеп сүгенде дә, кәҗә бәтие күк башта урындыкка, аннан өстәлгә сикереп менде. Менеп тә житте, Л. Б.га тибеп тә җибәрде. Тибүнең көче гәүдәгә бәрабәр булса да, төгәллеге ару иде—Л. Б. бөгәрләнеп килде. Шул арада Умәр, Рафил өстәлендәге капрон җилем шешәсен ачып, Л. Б.ның битенә сиптерде. Ул да булмады, Хәйрис өстәленнән алып, капкачын ачып, ике каш арасына туп-тулы кара савытын томырды. Л. Б. күзен угалап торган арада, йөгереп килгән мәлгә жилле генә сикереп, очлы тырнаклы тәпие белән тегенең ияк астына китереп типте. Үгез егәренә ия шанлы разведчик, каушап калып, ишеккә таба чигенде. Умәр аны эзәрлекләп тормады—биеклекне җуясы килмәде. Өстәл өстенең стратегик әһәмиятен Л. Б. да аңлап өлгергән иде инде. Менә ул, ярсыган үгездәй үкереп килде дә, кинәт кенә Умәр өстәленең капкачын күтәрде. Умәр, акробатика остасыдай һавада бишме-алтымы кат мәтәлчек атып, тәрәзә янына очып барып төште. Ушына килеп чиный-чиный Хәйрис өстәленә менәргә маташканда Л. Б. Умәр өстәлендә басып тора иде инде... Менә ул тәрәзәгә таба атлап китте. Умәр хәзер рәхәтләнеп өстәл астыннан мүкәләп үтә ала иде. Ләкин эчке тоемы аңа: "Кермә, җүләр, сытыласың!"—диде. Чүбек такта уйлап табылганчы ясалган карт өстәл исә шыгырдаса шыгырдады, ыңгырашса ыңгырашты, әмма түзде. Эчке тоемы белдекләләнеп тагын нидер әйтмәкче иде дә, Умәр аңа: "Тының чыкмасын!"—диде.

Бүрәнә хәтле кулларын җәеп җибәргән, ботларын аерып атлап килгән, күзен кан баскан, чәче-бите җилемгә һәм шәмәхә карага манчылган бу албасты куркыныч иде! Менә албасты, кулларын җәйгән килеш, "ДЫПП" итеп Хәйрис өстәленең икенче башыннан сикереп төште дә, Умәрне сул почмакка кысрыклап китерде. Бүтән чигенер хут юк иде. Шунда ул усал бер йомарламга әйләнде. Хәзер ул Умәр түгел, бульдог алдындагы мачы! Бульдог тагын ярты адым атласа мачы, дөнья йөзендәге иң куркыныч тавыш белән чинап, яман сикерәчәк! Шуннан соң ни булыр? Тәҗрибәле кешеләр белә: бите умырылып төшкән бульдогның чиный-чиный качып китүе дә бар, аның авызында мачы сөякләре шатырдаса да гаҗәп түгел. Бу юлы эш ничек төгәлләнер икән?

Менә Л. Б. сул аягын алга шудыра төште. Шул вакытны... бик каты итеп ишек дөбердәттеләр. Л. Б. шундук уң кесәсеннән зәңгәрсу төстәге бәләкәй шар чыгарып, Умәргә сузды. "Баштаүзен"ләп торырга вакыт юк иде. Умәр сыйны иренենә тидереп карады да, үсә башлаганын сизеп,

авызына капты. Һәм, тулы Умәргә әйләнүен көтеп тә тормастан, мөһим бер ноктага житүгә, башы белән китереп орды. Л. Б. ыңгырашып батарей янына капланып төште. Идәндә яткан чалбары белән Умәр аның кулларын бәйләп тә куйды. Аннары үзенең күпне күргән һәм күпне күрсәткән каләмен алып килде. Л. Б.ның уң колагына текәлеп-текәлеп карап торганнан соң, ниндидер бер жиренә китереп тә төртте. Л. Б.ның колагы һич авыртмады, авыз эчендә теле генә чәнчешеп куйды.

Ишекне тагын дөбердәттеләр. Аннары бүлмәдә көек исе таралды. Ишектә, башта аны тотып торган ике тупса, аннары йозак турысында, аермачык булып утлы сызыклар сызылды. Эчке якка авып барган ишек буйлап, очыннан төтен чыгып торган таягын алга төбәп, өч бөртек чәчен жилфердәтеп, пионер малай чаклы гына бер карт чабып узды. Л. Б.ның чәче үрә торды: Рауф! Рауф бит бу!

Илләрендә кат-кат кисәткәннәр иде аны. Иң зур хәтәр—Рауф, ул берьюлы өч жирдә була ала, жиде төрле кыяфәткә керә ала, иң яраткан кыяфәте—таякка таянган карт, дигәннәр иде...

Умәр, тап-таман трусигын күтәрә-күтәрә, тыныч кына әйтеп куйды:

—Менә бер куркыныч адәмне тоттым әле. Шпион-фәлән түгел микән дим.

Ярсудан бит мускуллары тартышып куйган Л. Б. нидер әйтмәкче иде дә, авызыннан гыжылдап һава гына чыкты. Ул никтер телдән язган иде.

Юк, чын разведчик болай эшләргә тиеш түгел, әлбәттә. Ләкин Л. Б.ны, ягъни Лю Барскийны гаепләү мөмкинме соң? Менә бит ул, иленә герой булып кайтасы кеше, карага манчылып, жилемгә батып идәндә аунап ята. Ул үзе тугры хезмәттәш итеп сайлап алган зат—сынар боты кадәрле маңка малай аны ганимәт мал сыман уртак дошманнары кулына тапшыра! Юк, түзмәде инде аның күп газаплар кичергән жаны, мондый да мәкерне гафу итә алмады. Л. Б. әүвәл Рауфка ике тапкыр сул күзен кысып, башы белән Умәргә таба изәде, аннары чабата хәтле телен чыгарып борын очын ялмап алды. Таяклы бабай шундук елмаеп жибәрде, ике тапкыр уң күзен кысты. Аннары ул, каяндыр бала башы хәтле зурайткыч пыяла тартып чыгарып, аны Умәрнең борыны турысына китерде. Шәле бәрәңгесе хәтле булган борын очында зәңгәр язу ярылып ята иде: "А N179".

* * *

Рафил белән Хәйрис монсу гына сөйләшеп утыралар. Ни турында гына сүз башламасыннар, ахыр чиктә ул барыбер Умәргә килеп ялгана. Ике атна буена шулай инде. Чәй мәжлесенең дә яме китте. Умәрсез чәй шикәрсез чәй кебек икән ул.

Эшкә дә күнелләре ятмый. Рафил удар төзелешләр перекличкасын өзде. Хәйрис комсомол документларын барлау кампаниясе турындагы мәкаләдә хата жибәрде. "Гомер буе саклагыз!" диясе урында "Умәр буе саклагыз!" дип язып чыгарды. Бу мәкаләне Харисламнан башка беркем дә укымау сәбәпле генә жәнжал купмый калды. Харислам исә "Умәр" түгел, "гомер" дип төзәтү бирергә курыкты, беркемгә берни әйтмәде. Чөнки инде болай да гәжитне шпионнар оясына әйләндерден дип күзен ачырмыйлар иде.

—...Шул көннән тараканнарына кадәр юкка чыкты бит аның,—күз карашын бушап калган айгырлар аранына текәп, Рафил сүзен дәвам итте.—Үлгәннәр дияр иден—мәетләре юк.

—Аулакта тәмләп йокы бүсәләрдер,—диде Хәйрис, авыз ерып. Аннан, шаяртуының хәзерге монсу халәт белән ярашмавын сизеп, житдиләнде.

—Без татарлар да эзсез-нисез юкка чыгарбыз инде.

Шулай диде Хәйрис һәм кинәт куырылып килде. "Аһ, тинтәк, аһ, башсыз!

Умәр юк дип бөтенләй тугарылдың! Соң, Умәр—ул өченче кеше түгел икән ләбаса!"

Бөтен нәрсәдән көтелмәгән мәгънә табарга яраткан Рафил Хәйриснең сүзенә тансык ризыкка ташланган кебек ташланды.

—Юк, юк, Хәйрис, алай түгел ул. Алай түгел! Менә син шпион да шпион дип Умәрнең тетмәсен тетәсең. Шуны аңламыйсың: Америка кадәр Американың шпионы булыр өчен беләсеңме никадәр талант, акыл, эчке егәр кирәк? Юк, Умәр кебек затларны бирә алган татар халкы үлмәс, мәңге яшәр!—Рафил кинәт Хәйриснең үзенә сәер бер карау белән карап торганын искәрде. Ул эсселе-суыклы булып китте. "Аh, шайтан алгыры! Шуңа да башың эшләмәсен инде. Соң, Умәр бит, тегеннән үк булып чыккач, тегеннән булмады булып чыга! Димәк, өченче кеше дигәнебез...

Әмма Рафилнең каушавы озакка бармады. "Юк, безне алай җиңел генә каптыра алмассың, Хәйрис чын исемең кем!"

—Әйе, татар халкы үлмәс, мәңге яшәр. Бөек совет халкының канында яшәр ул!—бу сүзләрен Рафил махсус күрше бүлмәдәгеләр дә ишетерлек итеп әйтте.

IV

Юк, таракан кавеме үлмәгән дә, йокламаган да иде. Ул шул ук җирдә, әмма бөтенләй бүтән төрле яшәү белән яшәп ята иде... Аксак таракан теге серле фәрманга буйсынып көтә бирде. Көтә торгач, йоклап та китте. Менә бер заман янә боерулы өн ишетте ул: "Уян, таракан!" Бу юлы аваз каяндыр эчтән, ашказаны тирәсеннән яңгырады шикелле. Ул уянды һәм шул мизгелдә үк гаҗәеп бер хәл күрде: Умәр авызыннан ниндидер ак нәрсә атылып чыгып, аңа табан очты. Таракан тарихына "Бөек Төкерү" булып керәчәк гүзәл мизгел иде бу. Әмма ул чакта Аксак таракан мизгелнең хәтәрлеген генә тойды. Ул кыймылдарга-нитәргә өлгергәнче теге нәмәрсә аның янында гына шыкылдап плинтустан кире сикерде. Аксак коты алынып аска чумды, анда, караңгы юлда мыекларын бәрә-бәрә, чапты да чапты. Ләкин аны гаҗәп тәмле бер ис куып тотты. Аксак, куркуын да онытып, кире килде, каударланып өскә үрмәләде. Һәм ис чыганагын эзләп тапты. Бу ап-ак шарның татлы мал икәнен, татлы гына түгел, затлы татлы мал икәнен аның ашказаны да, бөтен сизү-тою әгъзалары да әйтә иде. Әйтә генә түгел, кычкыра, шәрран яра иде! Көтелмәгән уңыштан, исерткеч тәмле истән Аксакның башлары әйләнеп китте. Әмма оеп торыр чак түгел, ут өертергә кирәк иде! Алты тәпиен дә, димәк ки, аксагын да ныгытып терәп, җан тирләрен чыгарып шарны плинтус өстенә этеп меңгезә алды ул. Шар ярыкка сыймый иде. Почмактагы тишеккә хәтле тәгәрәтеп барасы булды.. Тишеккә этеп төшергәч и ул борчылулары Аксакның—әллә кайларга тәгәрәп китеп югала күрмәсен, башкалар үз малы итмәсен дип! Ләкин шар югала торганнардан түгел иде. Ап-ак нурларын сирпеп, еракстан ук балкып күренеп тора иде ул!..

Аксак таракан өенә кайтып килә. Аксак таракан өенә мал апкайтып килә! Аксак таракан башкаларның төшенә дә кермәслек тиңсез мал апкайтып килә!!

Тигез юлдан шар җиңел тәгәри. Аксак таракан җырлый-җырлый кайта. Башта биш-алты тапкыр "Сабыр төбе татлы мал!" дип суза, аннары, такмак әйткән шикелле тиз-тиз генә, "Мөгезлегә бирмәде, Аксакка бирде! Мөгезлегә бирмәде, Аксакка бирде!"—дип куя.

Үз тыкрыкларына җитү белән Аксак бөтен авылга ишетелерлек итеп кычкырып җибәрде:—К-кат-тын! К-капканы ач!—Тараканнар,

тараканбикәләр тәрәзәгә сарылды. Яшьләр, бала-чага урамга сибелде. Аксакның хатыны, каушап, башта баскычтан егылып төште, аннары капка бигеп таба алмый интекте. Капканы күрше егетләре киереп ачып куйдылар. Аксакның кырык тугыз баласы чинашып шарга ташланды, урын өчен көрәш, ыгы-зыгы китте. Әмма бу вакытта Аксакның түземе чигенә житеп ашкан иде инде. Ул, сабыйларны төрле якка селтәп очырып, шарны назлап кочып алды. Гажәеп татлы, туклыклы сый ана баһадирлар куәте биргән кебек булды. Тик шунда, мәжлеснең ямен жибәреп, кемнәрдер яман шаулаша башладылар. Аксак йөзен чытып борылып карады. Олы, симез тараканнар божрасы кысылганнан-кысыла бара иде. "Ю-у-ук! Шар минеке!"—дип жан ачысы белән кычкырып жибәрде ул. Аннан, божраны өзеп чыгып, читәннән казык суырып алды. Әмма кизәнергә базмады. Чөнки тараканнар нигәдер куркыныч рәвештә зурая баралар иде. Менә казыгы да, зураеп-авыраеп, шапылдап аяк очына килеп төште. Берни дә аңлый алмаган Аксак жиргә ятып үксеп елап жибәрде. Шуннан тирән йокыга да китте.

* * *

АТТӘ (Аурос Төкереп Ташлаган Әйбер) бу бинадагы барлык тараканнарның да уртак малына әйләнде. Башта купкалап алган даудәгъвалар тиз басылды: зурайганнан зурая барган шарның азык-төлек мәсьәләсен бөтенләйгә хәл иткәнлеге гужның-гужына да ачык иде. Аның тирәсендәге һавага кадәр туклыклы иде! Хатыны белән кырык алты баласы Мөгезлене дә өстерәп алып килделәр. Теле АТТӘгә тию белән Мөгезленең мөгезе кителде дә төште. Берәүләр аны таракан музеена куймакчы иделәр дә, Баш таракан рөхсәт итмәде, яндырырга кушты. Мөгез янганда бик тә ачы ис чыгып, тараканнарның күзенә сыланды. Ни жуйганнарын бөтенләй аңламасалар да, шул рәвешле һәр таракан ачы күз яшьләре түкте.

Яраннары шарны Баш тараканга табыну әйберсе итмәкче дә булганнар иде. Имеш, АТТӘнең асыл мәгънәсе бөтенләй башка икән, АТА, ӘТТӘ дигәнне аңлата икән ул, ягъни "Таракан атабыз"ны. Имеш, АТТӘ ул—Баш тараканның ауруслар белән озак вакытлар алып барган киеренке сөйләшүләре нәтижәсе икән!.. Ләкин баш асты тараканнар һәрвакыттагыча озак мыштырдадылар шул. Таракан аңында Бөек Төкерүнең беренче версиясе тамырланып өлгергән иде инде: ауруслар АТТӘне таракан кавеменә Аксак таракан аша биргән—аның бөек сабырлыгын һәм күндәмлеген искәргәнгә... Сыйны кем, кайчан, күпме кабул итәргә тиешлекне "тәртипкә салу"—рөхсәт системасын гамәлгә кертү омтылышы да уңышсызлыкка дучар булды. АТТӘ белән арада бәләкәй генә киртә торса да, тараканнарның күзен кан баса иде.

Баш таракан командасы, аптырагач, шарны тишеп үзләренә махсус бүлмә ясатырга да уйлаган иде. Алар гади мыекбайлар белән янәшә басып, бөтен халык күз алдында тел чыгарып шар яламаслар бит инде! Ләкин бу эшләре дә уңмады. Таракан затларында хәзер кемгәдер нидер ясау гаме юк иде инде. Житәкче тараканнар үзләре исә корал тотып эшләүне түбәнлек санадылар. Аннан, корал дигәннәре дә, башка бөтен әйбер кебек, нигәдер гел зурая, авырая бара иде аның... Ахыр чиктә алар, ялт кына колгага колга бәйләп, шуларны жәһәт кенә сузып, шарның өстенә менеп ята алдылар.Өскә үрмәләү дигәндәме? Өскә үрмәләү дигәндә таракан житәкчеләрендә әллә ниткән гыйфрит көч-куәтләре, иблис акыллары табыла икән ул!

Шар зурайган саен түрә тараканнар үзләрен тудырган таракан халкыннан ерагая, бетәшә бардылар. Тик аларның үзләренә бу бөеклеккә ашу булып тоела иде.

Бөтен нәрсә дә ажгырып зураюның исерткеч тәэсире томанлана барган таракан аңында татлы бер хис уята иде. Баштарак "Таракан биләмәләренең кинәюе", "Таракан кавеменең тиңсез үсеше" кебек темаларга фәнни конференцияләр дә үткәрелгәләде әле. Соңыннан болар онытылды. Тараканнарга берни дә кирәкми иде инде. АТТӘ генә берәр-кая китә күрмәсен, шул гына исән булсын!

Иске дин дә онытылды, аның каравы, яңача намаз укучылар ишәйде. Белдекле тараканнар аңлатып бирүенчә, таракан дине ул заманга ияреп үзгәрергә һәм тараканнарның фани дөньяда тук, имин яшәвен тәэмин итәргә тиеш икән. Яңача намаз исә АТТӘгә карап чалкан сузылып яту һәм корсак шәрифләрен сыпыра-сыпыра заманча тәкбир әйтүдән гыйбарәт икән.

Ошбу гыйбадәтне тараканнардан гайре беркемнең дә тамаша кылмавы кызганыч. Юкса күргән бер генә аң иясе дә, күнелен илаһи бөеклек биләп алуын тоеп, тетрәнми калмас иде...

Менә АТТӘнең пакь нурлары яктысында меңләгән корсак елкылдап-елкылдап куя. Меңләгән тамактан берьюлы изге сүзләр агыла:

—Ауроска рәхмәт! Ауроска рәхмәт! Ауроска рәхмәт!..

Аш эшкәртү җәһәтеннән сәфәр кылып алулар да шәп нәрсә. Аксак тараканга гадәттә хәллерәк ун-унбиш үсмер ияртә. Алар, ничек булды да ничек булды ул, дип, мең дә беренче кат АТТӘ тарихын сөйләтмичә калмый. Сәләтлерәкләрне АТТӘ зурлыгының ашказаннары зурлыгына нисбәте дә кызыксындыра. Менә бу юлы да берсе хыялга бирелеп сорап куйды:

—Минем тәпиләргә әтинең тәпиләрен, әнинең тәпиләрен, энеләрем-сеңелләремнең тәпиләрен дә кушсак... АТТӘ әнә шул хәтле елга җитәрме икән?

Тагын да хыялыерагы сорауның колачын нык киңәйтте:

—Юк, менә бөтен-бөтен-бөтен тараканнарның да тәпиләре хәтле елга җитәме АТТӘ?

Моның ише сорауларга Аксакның җавабы бер була:

—Таракан кавеме мәңгелек ул, энекәшләр! Калганы сезнең кайгы түгел аның.

Аксыл йөзле, зәгыйфь сыйраклы, йомры корсаклы үсмерләр илле-алтмыш адым китү белән кайту ягын кайгырта башлыйлар. Чөнки кайтыр юл һәрвакыт озынрак булып чыга. "Барудан алда кайтырыңны уйла" дигән мәкаль таракан аңына бәләкәйдән сеңдерелә.

Кире борылуга, таракан күген кысрыклап киңәйгәннән-киңәя барган якты шарны күрәсең. Ажгырып зурайган бу шар таракан дөньясын менә-менә сытып ташлар сыман. Тараканнар аннан чырыйлап качарга тиеш иде кебек. Әмма таракан халкы аның бу үзлегенә күнеккән инде. Шарның якты нурлары ерактан ук аларның ашказаннарын җылытып, җаннарына өмет өстәп тора.

Чыкты, чыкты ла ул мәңге баемас таракан кояшы!

# *Җәүдәт Дәрзаманга 60 яшь*

## Самими шагыйрь

Гомер буе балалар әдәбиятына хезмәт иткән, бөтен иҗади егәрлеген шул максатка юнәлткән каләм ияләренең берсе ул—Җәүдәт Дәрзаман. Аның каләменнән төшкән шигырьләр, әкиятләр, повестьлар менә инде берничә буын татар баласын ихлас, зирәк, иманлы бала итеп тәрбияләүдә катнаша.

Балалар язучысы, шагыйрь һәм прозаик Дәрзаманов Җәүдәт Харис улы 1945 елның 13 октябрендә Татарстанның Лениногорск районы Сугышлы авылында туа. 1964 елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Хәрби хезмәттә булып кайтканнан соң ул янә университетта укуын дәвам итә һәм аны 1972 елда тәмамлап чыга. Аның шуннан соңгы хезмәт юлы балалар дөньясы белән бәйле: ул әүвәл Татарстан радиокомитетында балалар тапшырулары редакторы, аннан "Ялкын" журналында җаваплы сәркатиб һәм 1988-1994 елларда журналның баш мөхәррире булып эшли. 1995 елдан Дәрзаманов кабат радиокомитетта—1996 елның сентябренә кадәр "Татарстан" телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт компаниясенең программалар бүлеге мөдире, соңрак ул нәфис тапшырулар редакциясенә баш мөхәррир итеп билгеләнә.



Шундый сүз йөри: "Балалар шагыйре нинди була, дип сорасагыз, нәкъ менә Дәрзаман кебек булыр",—диләр.

Шагыйрьгә бирелгән югары бәя бу. Язмышка тиң бәя. Көн саен, минут саен, шигырь саен дәлилләүне сорый торган бәя. Бу бәя аның матур холкы, ихлас табигате хакында сөйли, күңеленең асыл сыйфатларына ишарәли...

Җ. Дәрзаманның шигъри самимилеге хакында күп уйланганым булды. Ниһаять төшендем: бу аның бала чагыннан килә. Шагыйрьнең биографиясе белән азмы-күпме таныш укучы белә: ул бишенче класста ук шигырьләр яза башлый, Лениногорск шәһәренә йөреп, язучы Шамил Бикчурин җитәкләгән әдәбият түгәрәгендә катнаша, бу берләшмәнең иң актив әгъзаларыннан берсе булып китә, район газетасы битләрендә төүге шигырьләрен бастыра. Ә инде 1961 елда күренекле балалар әдибе Җәвад Тәрҗемановның сүз башы белән күләмле генә шигырьләр циклы "Яшь ленинчы"да дөнья күрә...

Минемчә, Җ. Дәрзаман, шагыйрь буларак, балалык чорында ук формалаша. Шагыйрьлек тойгысы аның күңеленә бала килеш кереп калган. Шул тойгыны ул кадерләп, тәрбияләп, үстереп, гомере буе саклап килә.

*Тубаләрдән тамчы тама,*
*Җиргә бәрелә зыңлап.*
*Тимерче сабан төзәтә,*
*Тавышы тора чыңлап,—*

дип яза ул үзенең беренче шигырендә *("Яз", 1957).*

Ә менә бу юллар—соңгы шигырьләреннән:

*Тубәләрдә тыпырдады,*
*Тыпырдады тактада.*
*Коймаларны шакып узды,*
*Шыбырдады капкада...*

*("Җәйге яңгыр.")*

Шул ук тойгы, шул ук халәт. Ә-ә, юк… Бу юлы инде шагыйрьнең "бала күңеле" олы тормыш узган, ул инде һәр матур хистән, җете образдан мәгънә таба белә:

*Шулчак нидер чатнады да*
*Чәлпәрәмә ватылды.*
*—Ур-ра, гол!—дип, шат тамчылар*
*Түбән таба атылды.*

Шул рәвешле, шагыйрь иң гади пейзаж шигыреннән дә кызыклы ситуация, вакыйга тудыра алды, аны бала кызыгып укырлык итте. Әйе, Җәүдәт Дәрзаман—чын мәгънәсендә "ситуация шагыйре". Бала кешегә әйтәсе сүзен, бирәсе дәресен ул һич сиздермичә, ниндидер кызык вакыйгага ияртеп, отышлы табылган образлы детальләр аша бирә белә. Менә шул ук "туп темасына" тагын бер шигырь. Автор, өйдә туп тибеп уйнамагыз, ярамый, әйбер-кара ватарсыз, дими, бары тик кызык ситуация генә тәкъдим итә:

*Туп сикерә "туп" та "туп",*
*Булмый гына туктатып!*
*Идәннән дә сикерә,*
*Түшәмнән дә сикерә,*
*Сикерә дә сикерә,—*

дип, ул тупны уйната-уйната да:

*Тәрәзәне күр анда:*
*Ишек ясап буранга,*
*Туп сикергән… урамга!—*

дип, шигырьне бернинди акыл сатусыз-нисез төгәлләп тә куя. Тиешле нәтиҗәне, әлбәттә инде, укучы бала үзе ясамый калмый.

Дәрзаман шигъриятенең төп үзенчәлеге шунда, ул балаларның кимчелекләреннән көлеп язмый, ә аларның психологиясен, холкын тәгаен белеп һәм сокланып иҗат итә. Телнең һәр үзенчәлегенә рәссамнәрчә төгәл шигъри буяу табып, аны сабыйлар күңеленә искиткеч җылы һәм самими итеп иңдерә белә ул. Бу бигрәк тә аның "Безнең әлифба" дип исемләнгән дүртьюллыклар циклында аермачык чагылыш тапкан. Әлеге шигъри парчаларны укып, балаларча хисләнергә дә, педагогик алымнарны тоемларга да, тормышчан мәгълүмат алырга да мөмкин, әлбәттә инде, хәреф өйрәнү дә күңелле.

*Кызыл канат тарта, дисәм,*
*Кысла капкан кармакны.*
*Ычкындырыйм диган идем,*
*Кысты-куйды бармакны!*

Җ. Дәрзаман бик абруйлы исемгә ия—ул Абдулла Алиш исемендәге бүләк лауреаты. Шагыйрьне, чынлап та, "Нечкәбил" авторының иң тугры шәкерте дип әйтергә мөмкиндер. Беренче җыентыкларында ук ул үзен әкият-поэма остасы итеп таныткан иде, гомере буе бу жанрга тугры булып калды ("Ирбатыр", "Карурман кунаклары", "Монтаһәр коесы", "Төнге маҗара", "Канатлы каһарман", "Нур-задә", "Айбулат", "Илләр гизә Илгизәр"). Алиштагы җанлы образлылык, бала күңелен шундук җәлеп итә торган кызыклы интрига, самими һәм халыкчан сөйләм теле—боларның барысы да Җ. Дәрзаман каләменә дә хас үзенчәлекләр.

Җ. Дәрзаман проза өлкәсендә дә күп эшли—аның "Җиләкле көннәр", "Бизмән йолдызлыгы" повестьлары кечерәк сыйныф укучыларына атап язылган булса, "Җир авазы" повесте зур тормышка аяк баскан яшьләрне күз уңында тотып иҗат ителгән. Соңгысында игезәкләр Әмин белән Дәмин, аннары Әлфия, Әмир кебек кызыклы һәм гаять каршылыклы образлар аша язучы авыл балаларының күпкырлы һәм катлаулы тормышын, аларның уй-хыялларын, өметләрен, сагышларын җете төсләргә бай тел һәм җылы хисләр белән тасвирлаган.

Җ. Дәрзаман—күпкырлы иҗат иясе. Лирик жанрларда да ул үзенең самимилеген югалтмый, бәлки бу күңел сыйфатын яңача балкытып кына җибәрә. Ул—"Яшә, Татарстан", "Синең өчен", "Ышан бары йөрәк авазыңа" кебек популяр җырлар авторы. Аның "Солдат булдым" җыентыгы буенча Ринат Еникеев җырлар циклы иҗат итте.

Атаклы җырчы Гөлсем Сөләймановага багышланган поэма авторы буларак та билгеле ул. Җыр, моң—гомумән Дәрзаманның күңел халәте. Аны без шулай ук шәп гармунчы һәм курай, кубыз остасы буларак та яхшы беләбез.

Һичшиксез, "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" (1994), "Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе" (2002) Җ. Дәрзаман, әгәр дә шундый исем булса, "Татарстанның иң самими шагыйре" дигән мактаулы исемне дә беренчеләрдән булып алыр иде.

**Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ**

# Җәүдәт Дәрзаман

## Туп

Туп сикерә "туп" та "туп",
Булмый гына туктатып!
Идәннән дә сикерә,
Түшәмнән дә сикерә,
Сикерә дә сикерә—
Бар өйне ду китерә.

Чалтырт!
Күзгә көл булды,
Туп та шунда шым булды.
Безнең туп бик чая ул,
Шәп сикерде бая ул,
Эзлик әле, кая ул?

Түшәмдәме?
Туп бит ул—
Идәндә дә юк бит ул!
Тәрәзәне күр анда:
Ишек ясап буранга,
Туп сикергән... урамга!

## Балык тотты

Кармакларны алабыз да
Салабыз яңабаштан—
Кызык булмас, колак каксаң
Килеп капкан табыштан.

Тарта бугай, калкавычым
Вак дулкыннар тарата.
Алмый торам, балык халкы
Алдашырга ярата.

Инде тартам, алып булмый,
Балык зур, мин кечкенә—
Ярга селтәп атар идем,
Җитеп бетми көч кенә.

Вәт балык бу! Шундый тартты,
Куйдым да бер чайкалып,
Аяк таеп, дөмберт суга—
Үземне тотты балык!

## Нур дәү инде

Бәби син, ди
Әни дә,
Сабый син, ди
Әби дә.
Син әле
Нәни, диләр,
Мә, сиңа
Мәми, диләр,
Үпкәли Нур
Әнигә,
Үпкәли Нур
Әбигә,
Дәү малайны
Һаман да
Ник саныйлар
Бәбигә?
Ник үртиләр
"Нәни" дип,
Яза белә
"Әни" дип.
Яза белгәч
"Әни" дип,
Нур дәү инде,
Әйе бит?!

## Солдат булдым

Каеш будым билемә,
Тасма тактым җиңемә,
Йолдызлы бүрек кидем,
—Мин солдат булдым!—
дидем.
Иңемә мылтык астым,
Әти каршына бастым:
—Килдем, иптәш командир,
Әйдә, берәр фәрман бир!
—Смирно!— диде әти дә,—
Печән ашат бәтигә.
Бераз утын ярырсың,
Аннан... суга барырсың!
Шуннан китте, и китте,
Мине чын солдат итте.
Бетте ялкау гадәтем,
Санаулы һәр сәгатем.
Иртүк торам, юынам,
Сөлге белән уынам,
Ялт иттерәм тешләрне,
Аннан эшлим эшләрне.
Бүлмәмдә тәртип хәзер,
Ни кирәксә, шул әзер.
Солдат булу шулай ул,
Өйрәнгәч, бик уңай ул!

## Күзле кычыткан

Кычытканмы?
Кычытканның
Беләм мин ике төрен.
Берсен озак сөйләп тормыйм,
Яхшы беләсез серен.

Анысының тылсымы бар—
Яфрагы сырлы-сырлы.
Кире булсаң, үҗәт булсаң,
Сикертә үрле-кырлы!

Ыштаныңны төшерә дә
Йомшак җирне "пешерә":
"Моннан соң сүз тыңлар идем!"—
Дияр көнгә төшерә.

Икенчесен әйтмим дә мин,
Анысын мин санламыйм.
Санламавын да саңламыйм,
Тик шунысын аңламыйм:

Ник әйттеләр икән аңа
Сукыр кычыткан диеп?
Әллә "өтмәгәнгә" микән,
Китсә дә тәнгә тиеп?

Ул, ичмасам, кагылсаң да
Сыйпап иркәли генә...
Ә тегесе бакчаларга
Юлны киртәли менә!

Киртәләсә киртәләсен,
Анысы аның эше.
Бакча басар өчен генә
Йөрми бит инде кеше:

Җиләк, кыяр күптән беткән,
Белмим, нәрсә карыйдыр?
Күзле булгач, күрәләтә
Чакмаса да ярыйдыр!

## Кепка, туп һәм... сандали

Алмагачта алма күрдек
Туп уйнаган чагында.
Шул алманы күрми калсак,
Уйнар идек тагын да.

—Алманы мин алам!—дидем.
—Алма!—диде Галләми.
Анысы, мин Галләмине
Санга сукмыйм әллә ни.

Бары йодрыгыннан гына
Йөрим шүрләштергәләп:
Бик теләсәм, җиңәм аны...
Абый белән бергәләп!

Абый шунда: —Ул алманы
Мин алам!—димәсенме,
Шул алмага төбәп, тубын
Югары чөймәсенме!

Тубы кунды алмагачка,
Хәзер инде кәләбез...
Тик алай да, кунган тупны
Алу җаен беләбез:

Мин кепкамны салып чөйдем,
Сандалиен—Галләми.
Галләминең сандалие
Кунып калды.
Әлләли!

Әлләлиен әлләли дә,
Куаныч юк әллә ни:
Алмагачта чайкалалар
Кепка,
Алма, туп һәм...
Сандали!



## Халисә Мөдәррисова

# КӨЗНЕҢ НУРЛЫ НӘКЫШЕ

* * *

**"Их аның кебек булырга!"—**
**Көнләшеп чибәрлеккә,**
**Үртәлеп яшь түгә кызый,**
**Капланып чирәмлеккә.**

**"Их, алар кебек булырга,**
**Яшәргә сарайларда!.."—**
**Язмаган андый нигъмәтләр**
**Гап-гади малайларга.**

**"Их, шулар кебек яшьлекне**
**Барларга ватыклардан,**
**Чибәрлек, байлык кирәкми,**
**Дәва юк картлыклардан".**

**"Картайсам да, их, тимерләр**
**Кебек идем әле,**
**Сәламәт булсам дөньяда**
**Терекләр идем әле..."**

**Каберләрнең ташларына**
**Вакыт җавабын уйган:**
**"Сез—минем кебек булырсыз,**
**Мин—сезнең кебек булмам!"**

---

Халисә МӨДӘРРИСОВА — *шагыйрә, прозаик; татар, башкорт телләрендәге "Көмеш дага", "Шәмәхә төн" һ. б. китаплар авторы. Башкортстанда яши.*

## Ике арада

Тибрәлә болыт түбәмдә,
Уйнамый яшен-камчы,—
Остаз кебек спас керде,
Тәрәздә—елак тамчы.

Оеп калган кебек дөнья,
Тынган—тыелган җил дә,
Ә күңел күкләргә дәшә,
Тик нидер баса иңгә.

Тыйма мине, күзләремнән
Эзләмә көзге чалым.
Җәй дә, көз дә түгел җанда,
Минем дивана чагым.

Күңел сизә, зәңгәр күкләр
Тагын бер күкрәр әле:
Соң түгел, җәйләрнең көзгә
Авышкан гына мәле,
Авышкан гына мәле...

* * *

Кояш белән бу көзге көн
Качышлы уйный кебек.
Көмеш пәрәвез тибрәлә—
Әйтерсең дымлы керфек.

Кыш бөтенләй булмас ахры,
Изри дөнья тынлыкта.
Көзге кебек балта йөзе
Ял итә утынлыкта.

Чормада балан бүкәне
Былтырдан калган микән?
Яздыр ла бу, көз дигәне—
Бөтенләй ялган микән?

Кинәт, җанны өтеп алып,
Тәүге кар күзе төште:
Ялгышкан, уенга борган
Саксыз бер сүзең төсле.

## Даная

Бикләп куелган ишектән
Кеше түгел, җил керми.
Авыр пәрдә кормасында
Алтын ай нуры бии.

Беләсеңме, җил барыбер
Күңел итәген кага.
Бакчадагы ак сиреньнән,
Таң атуга, бал тама.

Сакла әйдә, ишек бикләө,
Битәрлә дә, тиргә дә.
...Барыбер тәрәз аръягында
Алтын тузан тирбәлә...

## Мизгелләр

Була мизгел, шундый мизгел була:
Эчләремне сызып үтә сагыну.
Шыр ялангач күңел кылларымны
Көйдереп лә ала ачы яну.

Була мизгел, ул мизгелдә кайчак
Кабатланмас бәхет баштан аша,
Бу дөньяда синең барлык миндә
Шатлык катыш моңнар булып таша.

Була мизгел, син янымда мизгел—
Күзләр ачып, күзләр йомган ара...—
Табышлар һәм югалтулар белән
Тетрәндереп, минем җанда кала.

* * *

Хушлаша көз, китүендә—
Үкенече, сагышы.
Сары яфрак ява җиргә—
Көзнең нурлы нәкыше.

Үләннәрнең чал чәчендә
Кырау күренеп кала,
Ертык болыттан бер учма
Җылы нур төшеп ала.

Җылы нур... Бәллүр тамчылар...
Җир—томан куенында.
Тамчылар—алдаткыч өмет—
Өянке толымында.

## Васильево. Төнге фонтан

Төнге фонтан шыбыр-шыбыр ни сөйли?
"Соң инде, соң, бар да үтте",—дип көйли.
Кушылгандай аңа күлнең камышы,
Камышлыкта—кыр үрдәге тавышы.
Офыкка күмелгән поезд гүләве,
Җанда—аймылыш язмышлар түләве.
Үтте бар да ераклашкан моң кебек
Уйга кергән, оталмаган җыр кебек,
Учка төшкән, тоталмаган нур кебек,
Бүген инде—кайтарулар соң кебек.
Хәзер төшеп ватылган ак касә ул,
Наратлар арасындагы рәшә ул.
Чәчелде дә, түгелде дә, уалды,
Күк йөзендә кош юлыдай моң калды.
Төнге фонтан шыбыр-шыбыр юл алган:
Сакланмаган...
        Табылмаган...
                Югалган...

* * *

Җәйнең соңгы төне бу төн,
Шундый тын бу төн.
Җыйган, җыелган, тулышкан—
Булмышы бөтен.

Әйтерсең болытлар ярып
Яшен үтмәгән,
Явасы коен күкләрдән
Коеп бетмәгән.

Төнге фонарь яктысында—
Гүяки тере—
Көзге күбәләкләр түгел,—
Ак таҗ бөртеге!

Ачык балкон ишегеннән
Үтеп бүлмәмә,
Төнге кошның канат җиле
Шәмдә тибрәлә.

Илаһ серле матур бүләк
Әзерли кебек,
Әле көз түгел дөньяда,
Әле җәй кебек.

Тик учакта дымлы төндә
Ут түгел—төтен.
Җәйнең соңгы төне бу төн,
Ямансу бу төн.

* * *

Сөю, сөю, таштан ташка сикереп
Елый-көлә ага кышкы инеш.
Яр-ярлары бәсле керфек кебек,
Чигәләргә инде көмеш иңеш.

Сөю, сөю, бөре күзен ача,
Болыннарда шыта батыр гөлләр,
Буразналар бүртеп орлык көтә,
Җанда җан яралыр назлы төннәр.

Сөю, сөю, күкләр колач җәя,
Бөтерелеп ага ак болытлар,
Инкарь итеп җирдә бар үлемне
Гөлләр чәчәк аткан бу минутлар.

Сөю, сөю, көзге мәгърүр урман—
Агачларда ялкын, ут кабыза.
Тулып пешкән алма шарт ярылып
Игелекле җиргә сут тамыза.

Сөю, сөю, һәр мизгелең үзгә:
Кыя кебек ныклы, йә күбек син.
Ялтлап янган затлы алмаз кебек.
Кабатланмас язгы төш кебек син.

Сөю, сөю,
Бакый мәңгелек син.

* * *

Тына бара дөньяларым,
Тарая бара,
Төшә бара төн пәрдәсе—
Карая бара.

Акрыная күңелем сазы,
Сагая бара,
Бәллүр боздай бер нечкәрә,
Бер тая бара!.

Ашыга-ашыга бу гомерем
Ай, кая бара!..

*2004—2005.*

*Дискуссия: “Безнең заман герое”*

## СҮЗ КАДЕРЕ

*Әйтер сүзең әйтеп кал...*
жыр

Без—каләм тота алучы һәркем—еш кына кирәксә-кирәкмәсә дә Тукайның “Тәнкыйть—кирәкле шәйдер” дигән гыйбарәсен кабатларга яратабыз, гыйлемлегебезне күрсәтергә теләпме, урынлы-урынсыз кулланырга тырышабыз. Акыллы сүзләр алар. Ә акыллы сүзнең дөньялыкта күп очракта кадере юк. Бигрәк тә бүгенгебездә. Иҗатыңдагы бөтен чүп-чарны коеп, җиз иләктән уздырган Галиҗанәп Сүзне кем генә сөеп кабул итә ди инде? Без бит—даһи, язганнарыбыз—шедевр! Тәнкыйть исә еш кына әнә шул бөеклектән тартып төшерә. Авыр була, авырта, каһәре! Хәер, соңгы елларда тәнкыйтьнең асыл мәгънәсе үзгәрде инде. Тоташ мактаудан тора ул хәзер. Әгәр бүгенге тәнкыйть мәкаләләре буенча гына әдәбият хакында фикер йөртсәң, “бәрәкалла, чәчәк атабыз икән!” дип кинәнергә генә кала. Макталган һәр иҗатчы бу очракта рәхәтләр чигеп, авыз суларын кортып, “тәнкыйть—кирәкле шәйдер!” дип сөрән салачак. Бик теләп! Ә бит чынлыкта Тукай, инде 1907 елда ук ни дигән: “...тәнкыйть итүченең дә кем очрады шул булуы ...ярамыйдыр. Мөнтәкыйд *(тәнкыйтьче—Ф.Б.)* булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы матлүбтер *(таләп ителәдер—Ф.Б.)*. Юк исә, бер гаразы шәхси *(шәхси файда—Ф.Б.)* илә дә тәнкыйть итүчеләр күптер”. Әйтерсең, безнең көннәрне күзәтеп яза шагыйрь! Тәнкыйтьебезнең һәвәскәр булуына, тешсез, өркәк икәнлегенә борчыла! Шулай да “Казан утлары” журналында икенче ел барган дискуссия Сүз кадеренең җегәре әле кимемәгән икәнлеген раслый. Исән икән әле тәнкыйди сүз! Потенциаль мөмкинлеген җуймаган икән әле! Капма-каршы фикерләр агышы, төрле эчтәлектәге карашлар—тәнкыйтьнең төссез бер күзәнәкле сүз боткасына әйләнеп бетмәвенә ышанычлы дәлил.

...Менә, үземне ярым мәҗбүр итеп булса да оптимист ясап кереп киттем әле каләмем артыннан. Нинди кәеф белән барып чыгармындыр аргы якка—нәмәгълүм. Ярар инде, нигә дип алдан фараз кылырга. Соңгы ноктаның ни рәвешле куелуын белгән халдә фикер йөртсәң, нәрсәгә дип уйлануларың белән бүлешеп азапланасың ди? Сүз дөньясы—ил ул. Ил—киң ул. Киң дөнья—ача-ача иңләсәң генә дөнья ул.

* * *

Бу бәхәс күптән өлгереп килә иде инде. Мәсьәләнең шул рәвешле куелуы да (“Безнең заман герое”) сөйләшүнең шактый кырыс, ифрат бәхәсле тонда барачагына ныклы ишарә иде. Күренекле әдәбият галиме Гали ага Халит моннан 40 ел ук тәнкыйтьнең дөрес тонын, психологик дөрес тәэсирен һәм ышандырырлык көчен булдыруның бик әһәмиятле эш икәнлеге хакында язып чыккан иде: “...чын объектив әдәби тәнкыйть ... язучыга һәм аның иҗатына ышанып, аның әсәре изге ният белән язылган дип караганда гына була ала. Димәк, безнең тәнкыйть кешегә һәм аның эшенә иң элек ышаныч һәм ихтирам белән карау сыйфатына ия булуны үзенә максат итә һәм итәргә тиеш. Тәнкыйтьнең хәзерге әдәби хәрәкәт, заман темасы һәм заман герое кебек үзәк мәсьәләләргә язучылар җәмәгатьчелегенең игътибарын юнәлтә алуы, хәтта шуңа җитәкчелек итүе—... аның фәкать тормыш белән аерылмас бәйләнеше нигезендә

генә булырга мөмкин". Бу фикерләр бүген дә тәнкыйди Сүзнең умыртка баганасын тәшкил итәләр. Әдәбият тормыш тәгаме белән ризыкланганда гына сәламәт һәм житлегеп яши ала. Уңай геройга да бәяләмә – чынбарлыкның үзендә. Тормыш һәм кеше исә туктаусыз хәрәкәттә, үзгәрештә. Бер генә калыпта яши алмый ул. Заман үзгәрә, бәяләмәләр дә бер аспектта гына катып кала алмый. "Ничек сурәтләргә сине, замандаш?" дигән фәлсәфи сорау һәр чорда да актуаль һәм үзәк мәсьәлә булды. Шулай булды, шулай булачак. Башкача мөмкин түгел. Сүз кадерен генә җуймаска иде...

Дөресен әйткәндә, минем бу дискуссиягә кушыласым килмәгән иде. Ничә тапкыр кулыма каләм алып, ничә тапкыр кире куйганымны инде төгәл генә әйтә дә алмыйм. Язам, сызам, башлыйм, ташлыйм – Туфан Миңнуллин әйтмешли, әллә ничек кенә "маймыл"ын табып булмый бит. Ә язасы килә! Дөресрәге, күңелдә кайнаган буталчык, анык кына булмаган уй-хисләрне түгеп бер бушанасы килә. Журналда басыла килгән мәкаләләрне игътибар белән укып карыйм. Бер хикмәт чыкмас микән дим. Алар да чуар, томанлы фикерләр монда да бихисап. Инде бер башлагач, туктап кала алмаячагымны да тоям. Кирәсе ризык тешеңне сындырып кирә дигәндәй, әйтәсе сүзең дә каләмеңне сындырып булса да чыга икән ул. Димәк, мәсьәлә өлгергән, проблема күзгә чекрәеп карап җавап көтә.

Бәхәс болай җанлы гына башланды сыман. Дөрес, көткәннән кайтышрак булды, әмма беренчеләргә һәрвакыт кыен инде ул. Учак кабынсын өчен дә әүвәл ботак-чатак жыярга кирәк бит әле. Бер кабынгач, китәр шаять, дигән өмет белән күзәтәм язмаларны. Бар күңелгә тиеп-тиеп алганнары, бар битараф калдырганнары. Татарча язылып та, татарның ни акылына, ни җанына кагылырга сәләтсез, бары тик "нәрсә әйтергә теләде икән соң бу? " дигән сәерсенү уятырга гына сәләтле язмалар да юк түгел.

Адәм баласының табигате шундый инде, ул дөньяны танып белү өчен кемнедер юлдаш итеп алырга, аның тормышын, эш-гамәлләрен, уй-кичерешләрен үзенә үрнәк, яисә гыйбрәт итеп алырга тиеш. "Заман герое кем ул?" дигән мәсьәлә әнә шул тормыш үзе тудырган вәзгыятьтән үсеп чыга. Көндез чыра яндырып урамнан баручы бер борынгы философ "нишләвең бу?" дип сораучыларга шулай җавап биргән бит: "Кеше эзлим!" Без дә бүген шул халәттә: кеше эзлибез. Заман баткагыннан тартып алырлык, караңгылыкта иза килеп адашып, каңгырап йөргән вакытта юл күрсәтерлек герой эзлибез. "Болай яшәп булмый бит инде", дигән уй да шушы халәтебезне көчәйтә.

Мәгълүм хакыйкать: яңа әдәбият яңа геройдан башлана. Соңгы чор (1990-2005) әдәбиятының герое кем икәнен аңлау өчен иң әүвәл иҗат дөньясының эчтәлеген ачу зарур. Моның өчен хәзерге вәзгыятькә бәя бирү таләп ителә. Йә, нинди соң син, бүгенгебез?

Абсолют хакыйкатькә дәгъва кылмыйм. Бу мөмкин дә түгел. Каләмемнән тамган фикерләрем – минем шәхси уйларым, шәхси күзәтүләрем. М. Мәһдиев хаклы:"Шәхес бик сирәк очракта гына объектив була ала. Ләкин әдәбият – шәхси уйлардан торырга тиеш. Югыйсә, автор буларак, мин – нигә?" Шулай, бары тик шулай гына. Югыйсә, нәрсәгә дип каләмгә тотынырга ди? Бер-ике үзең хөрмәт иткән авторны атарга да, "мин аларның әйткәннәре белән килешәм", дип мөһер сугарга һәм – вәссәлам!

Низами сүзләре булса кирәк: "Сәфәргә кузгалган кеше йокыга талса йә баш киемен, яисә инде башның үзен югалтырдыр". Йокламаска иде бит! Бүрек үзе татарча әйткәндә "чурт с ним", баш жәлкерәк. Йә, ярар ла! Башлагансың икән, туктама инде. М.Әгъләмов сүзләре искә төшә:

*Ахыргача!*
*Ахыргача барам—*
*Юк, калмады көчне саклар чама,*
*Чорлар аша хәбәр китерергә*
*Янып егылачак атлар чаба.*

Томан сарган яшәешебездә кыйбла тапмый изаланган чагыбыз. "Болганчык суда балык тоту уңай", дигән халык әйтемедәй, кемнәрдер шуннан файдаланып калырга ниятли: акыл өйрәтә, хак юл күрсәтергә вәгъдә итә, үзе артыннан ияреpгә өнди. Шулай күзгә багып саташтыру, буташтыру уеньн дәвам итә. Акыл сату базары

вәзгыятендә яшибез, нишлисең. Ә базар — базар инде ул. Тукай заманында әйткән бит: "Берсе алдый, шунда берсе алдана". Кызганыч ки, алданучылар күбрәк. Рәшит Фәтхерахманов ("Казан утлары", 2004, 3 сан) мең кат хаклы: "Кеше холкы бу чорда үзенең бөтен яклары белән ачылды: түбәнлек, үзең өчен генә яшәү, үз мәнфәгатьләреңне генә кайгырту җәмгыятьтә өстенлек ала башлады, профессиональ үтерүчеләр, дәүләткүләм җинаятьләр чоры бу". Сүз дә юк, бик тә имансыз, буталчык заманда яшибез. "Кыйбласызлык чоры" (рус телендә тагын да төгәлрәк төшенчәсе бар: "безвременье") дип атар идем мин аны. Сүз кадерсезләнгән заман. Сүзгә ышаныч кимегән чор. Шәп сүзләрне лозунгларга әйләндереп үтләткәнче тәкърарлагач, нинди кадер-хөрмәт турында фәлсәфә куертырга мөмкин инде. Әнә шуннан фәлсәфә сафсатага әйләнә дә куя инде. Шуңа да мин хәзер "урра!" авазлары белән сугарылган гыйбарәләрне бик кабул итеп бетерә алмыйм. Шул сәбәпле сөйләшүне башлап җибәргән Р. Шәрәфиевнең ("Казан утлары", 2004, 1 сан) "Татар килә!" дигән пафослы бәянына мәгълүм дәрәҗәдә сак карыйм. "Ерактанрак карый белмәгәнебезгә күрә генә әлегәчә аның килүен яки киләчәген абайламый торганбыздыр?" — ди ул бездән бигрәк үзен ышандырырга тырышып. Килә инде ул анысы... Әнә шулай килә-килә килеп терәлдек тә инде без. Каямы? Р. Фәтхерахманов атаган "бозыклык реализмы"на.

Әгәр дә без заман героеның нинди булуы турында сөйләшү башлаганбыз икән, иң беренче нәүбәттә сүз кадерен торгызырга тиешбез. Әдәби каһарман сөйләячәк сүз кадерен. Шунсыз әдәбиятка ышаныч һәм ихтирам тәрбияләп булмаячак. Шуңа күрә "укучы бүген китап укымый" дип лаф орулар кысыр хәсрәт кенә ул. Сазлык баткагыннан әвәләнгән сюжетлардан гыйбарәт язмаларны нәрсәгә дип укырга ди? Манкортлар, шовинистлар, зиначылар, җинаятьчеләр тантана иткән вәзгыятьне үзебез дә бар күзәнәкләребез белән күреп, тоеп торабыз, ләбаса. Безгә аны теле-радио тапшырулар көн дими, төн дими өстебезгә коеп торалар. Газеталарны ачар хәл юк, шомлы вакыйгалар җаныбызга үрмәләргә керешә. Ә матурлык кайда? Һич югында, матурлыкны табуга, күрсәтергә омтылыш кайда? Әйтерләр, әдәбият тормыш чынлыгын чагылдырырга тиеш, диярләр. Ә кем чагылдырмаска тиеш, ди? Язучының төп бурычы тоннель ахырында да яктылык күрә һәм күрсәтә алу, дөм караңгы төндә дә йолдыз җемелдәвен тоя белү түгелмени? Чынлыкта бар бит ул яктылык, әлегә анда барып кына җителмәгән. Йолдызлар да үз урыннарында, тик аларны болыт кына каплаган. Әдәби әсәр бит архив материалларына нигезләнеп язылган фәнни хезмәт, яки бары тик натуралистик, фактографик тасвирлардан гына корылган иҗат җимеше түгел. Реаль җирлектән үсеп чыга торган язучы фантазиясе, автор хыялы сюжет канвасын бизи торган язманы чын әдәби әсәргә әйләндерә торган мөһим хасият ул. Әгәр дә без чынбарлыкны тудырабыз дигән сылтау белән сыер савучы Фатыйма апайны язлы-көзле өстеннән төшмәгән кара халаттан, аягыннан салынмаган резин итекләрдән сурәтләсәк, аның сүз байлыгын чыгымчы сыерларга юнәлтелгән лексиконы аша гына бирсәк — бу кырыс реализм була инде, әйеме? Ә нишләп әле без аны затлы киемнән мәҗлестә матур итеп җырлап утырганда күрергә тиеш түгел? Ә нигә дип безгә аның белән иренә, балаларына сөеп карап, иркә сүзләр белән эндәшкән чакта очрашырга ярамый? Чынбарлыкны бизәү түгел бит бу. Бу — сәнгать, ә сәнгать бер генә төстән тора алмый. Табигатьнең Язы, Җәе, Көзе, Кышы булган кебек кеше гомеренең дә, тормышның да төрле фасыллары була. Кояшта кара таплар барлыгын белүебез белән мактанабыз бит әле. Ә соң ник шыксыз, салкын яңгырлы көзге көндә (укы: бүгенге чынбарлыгыбызда) сары яфракларга сеңеп калган җәй җылылыгын тоя алмыйбыз соң? Алыйк М.Мәһдиевнең "Без — кырык беренче ел балалары" повестен. Дәһшәтле еллар: сугыш афәте, шәхес культының шомлы авазы, ачлык-ялангачлык — барысы хакында да әйтелә анда. Ә вакыйгалар нинди юмор, оптимизм, тормышка, киләчәккә никадәрле өмет һәм ышаныч белән сугарылганнар! Кайта-кайта укылучы, укыган саен кешеләргә, халкыңа, туган телеңә булган мәхәббәт хисен көчәйтүче бу әсәрне мин татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре рәтендә атыйм. Язучының "Кеше китә — җыры кала" повестенда сугыш чоры татар авылы сурәтләнә. Кан, үлем, ятимлек һәм бетмәс-төкәнмәс ышаныч. Соңгысы бөтен афәтләрне якты төсләр белән сугара. Яшәүгә көч бирә, каһәрле язмышка тап булганнарның күңелләренә җан өрә.

Дискуссиядә күтәрелгән мәсьәләләр, соңгы 20 еллар кысасында каралырга тиеш

булсалар да, фикерем тагын да ачыграк булсын өчен вакыт чиген киңәйтебрәк алып, Әмирхан Еникинең иң гүзәл әсәрләреннән булган "Матурлык" хикәясенә тукталуны кирәк тапты́м. Эчке матурлыкны күрә һәм күрсәтә алуның гүзәл үрнәге ул әсәр. Искә төшерик әле: мәдрәсәдән җәйге ялга өйләренә кайтучы шәкертләр юлдаш шәриктәшләре Бәдретдиннең өйләренә туктап, чәйләп алырга уйлыйлар. Авылдагы иң фәкыйрь йортны күреп бер хәйран калсалар, Бәдретдиннең авыру каһәрләгән әнисен күргәч, алар бөтенләй тетрәнеп китәләр. Сөйләүче исеменнән бәян ителүче тасвир чынлап та тетрәнерлек: "Аңа күтәрелеп карагач та минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды, бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде". Әмма бераздан Ананың ни рәвешле улына карап утыруын күргән лирик герой күңелендә башка хисләр ургый башлый: "Ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым". Шәкерт күңелендәге чиркану һәм кызгану тойгылары тәмаман таралалар да бетәләр, җан кузгалышында эреп югалалар.

Ә инде әсәр ахырында язучы героена кушылып әнә шул эчке гүзәллекне, бөек пакъьлекне, ифрат та саф хисләр чолганышыннан туган нәфис образны якларга, сакларга омтыла: "Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!"

Ана һәм Бала арасындагы мәхәббәт, олуг, изге хисләр, җан җылысы әдипкә шыксыз калыпта якты төсләр ургылышыннан гыйбарәт дөньяны күрергә һәм шуны укучы җанына бөтен барлыгына китереп җиткерергә ярдәм итәләр.

Бу Матурлыкны берниндн театр уены да, телевидение дә бар куәтенә беркайчан да китереп җиткерә алмаячак. Аны күрергә түгел, ә тоярга кирәк. Моны бары тик галиҗәнап Китап кына башкарырга сәләтле. Шуңа да "китап укучылар кими" дигән сүзләрне ишеткәч, киләчәк буыннарның нинди гүзәл дөнья, нинди эстетик, рухи байлык югалтачакларын уйлап, сискәнепләр китәм. Р.Фәйзуллин моннан берничә ел элек әрнеп, борчылып "Китап гасыры китәме?" дигән мәкаләсе белән чыгыш ясаган иде *("Казан утлары", 2000, 1 сан)*. Башлыча, ул анда болай ди: "Китап гасыры үтеп бара. Бу сүзләрне кәгазьгә төшерәм, ә җан бәргәләнә. Кул яза, күңел килешми. Ә нишлисең, Вакыт Галиҗәнапләренә каршы чара юк. ...Ризасызланып булса да килешергә туры килә: гасырыбызның соңгы чирегендә телевидение һәм компьютер системасы информация пространствосыннан басма Китапны шактый кысрыклады да".

Китап дәвере китеп бара...Нинди шомлы фараз! Китап сүзе китә. Һәр басмаязма сүзне Коръән тәгъбире итеп санаган заманнар тарихка күчеп бара. И-и, һәр яңа китапны зур вакыйга итеп кабул иткән гөнаһсыз, беркатлы чаклар! Сез дә үткәннәрдә генә калырсыз микәнни? Сезне саф, чиста килеш яшь буынга тапшырып кала алмаган өчен нинди генә җәзалар көтә икән безне бакыйлыкта? Фанилыктагы көчсезлегебезне, чарасызлыгыбызны нинди генә акланулар калыбына төреп бирергә тырышырбыз икән соң? "Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш: Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым", — дигән Тукай заманында әрнеп. Керләндек шул, керләнүебез дәвам итә дә итә. Р.Фәйзуллин хаклы, мең мәртәбә хаклы: тормышыбызга бәреп кергән яңа технологик чаралар аңыбызны, хисләребезне коточкыч агулавын гаять уңышлы дәвам кылып киләләр. Бигрәк тә телевидение. Без үлеп-бетеп америка киноларын карадык, карыйбыз. Андагы баһадир геройларга соокландык. Бер коралсыз килеш вьетнам солдатларын олаулап кырган мәһабәт бәдәнле сугышчыларның гамәлләренә бихуш булдык. Хәзер аңлыйбыз да бит: Вьетнамга басып кереп, халкын кол итәргә теләгән "бөек" Америка хурлыклы рәвештә тар-мар килеп илдән типкәләнеп куылды. Мыскылга калды, бичара. Бу аның үтенә тигән тарихи вакыйга иде. Дөньяның иң алдынгы техник чаралары белән баштанаяк коралланган держава, фәкыйрь, примитив сугыш әйберләре генә булган илнең бөек патриотизмы каршында җиңелеп мескенлек түбәнлегенең иң төбенә бәреп төшерелде. Хурлык баганасыннан ул инде беркайчан да котыла алмаячак. Шуңа күрә аклану ниятеннән ул бер-бер артлы шундый "фильм-боевиклар" төшерә һәм телевидение аркылы ничәмә-ничә канал буенча көн-төн шуны бар дөньяга тарата. Заманында Америка экспансиясенә каршы үз самодержавачылык идеологиясен куя алган Советлар Союзының варисы булып калган Россия бу чараларны аеруча тырышып башкара. Фәкыйрь агайның

бай абзый алдында бил бөгеп торуы кебегрәк кызганыч хәл инде бу. Нишләтәсең, ашыйсы килә бит. Бәлки, буйсынучанлыкның чиксезлеген күреп, "ипи нормасын" да арттырыр әле. Кыюлыкның, горурлыкның да чиге бар, мескенлекнең — юк. Мескен кешенең сүзе дә сүз түгел. Аның мыскал да кадере булмый. Бичара, гаҗиз бәндәнең әйткәнен ишетмиләр дә, тыңламыйлар да. Ни пычагыма ди ул? Мескен хәлгә калган Илнең дә сүзе мескеннәрчә чыга. Әнә шулай бөек шәхесләрне тудырырга тиешле Ил үзе дә герой булудан туктый. Ул хәтта тискәре герой да була алмый. Тискәре герой булу өчен дә шәхес булырга кирәк. Ил кадәр ил шундый хәлгә төшә икән, аның балалары нindirәк төс-кыяфәттә гомер сөрә? Бу хакта уйлавы куркыныч та, чиркангыч та. Үз-үзеңә бөртек тә хөрмәт калмавы бар, валлаһи.

Хәер, Американың басып алу сәясәтен аклаган фильмнарына яшел ут биргән Россиянең хәлен дә аңлап була инде анысы. Аның үзен дә Әфганстанда "интернациональ бурыч" (Ходаем, тагын бурыч! Бурычлы булу мескенлекнең төп сыйфатларыннан инде ул) үтәп йөргән җиреннән сөреп чыгардылар бит. Ә акланырга кирәк. Әнә, бөтен дөнья жандармы булырга омтылган янкилар бүген Гыйракта, Әфганстанда башбаштаклык кылып йөриләр. Россиянең исә Чечен җирендә алып барган сәясәтен халыкка "дөрес" итеп аңлатасы бар. Шуңа да ул чит мәмләкәттән үрнәк алып, сериаллар тудырыпмы-тудыра. Анда үз азатлыклары өчен көрәшүче чечен халкы барысы да террорист, бандит, җинаятьче, ә акча эшләү бәрабәренә шуларны кырып йөрүчеләр — һәммәсе герой икән. Уңай герой! Эчтәлеге инде таныш. Катнашучылары да шул иске танышлар — рус солдаты киемле, русча сөйләшүче америка яугирләре. Кабахәт сәясәт, җирәнгеч пропаганда. Боларны көн дә күреп, ишетеп торгач, ничек "керләнеп бетмисең" ди инде! Ярый әле, әдипләребез шулар арасында татар вәкилен күреп, шуны каһарман дәрәҗәсенә күтәреп әсәр иҗат итмәделәр. Югыйсә, тәҗрибә бар иде бит. 1917 елдан соң совет империясе сәясәтен тормышка ашырып Урта Азиядә үз кардәшләребезгә каршы сугышып йөргән татар бригадасын гына алыйк. И, мактандык та инде, горурландык та инде шуларның гамәлләре белән. "Татбригада сугышчылары җыры" үзе генә дә ни тора:

*Дошманга каршы сугышка,*
*Ленин чакыргач безне.*
*Татбригада атка менде,*
*Сакларга илебезне.*

Нинди дошман? Үз азатлыгы хакына яуга күтәрелгән үзбәк, төрекмән, йә таҗик халкымы? Нинди илне сакларга? Йөз меңләгән гөнаһсыз шәһидләр сөякләре өстендә төзелгән канлы империяне сакларгамы? Шулмыни инде безнең "илебез"? Ә без җырлапмы-җырлыйбыз: "Дошманнарның (нинди дошманнар? — тел, дин кардәшләребезме?) җиңдек барын (җиңдекме? тел, дин, кан берлеге ягыннан җиңелдек түгелме?) данлы елларда (бәлки, канлыдыр?)". Без бит шушы ятлар язган тамашада шамакай ролен уйнап, шундый да фаҗигале елларны данлап җырлап үскән буын. Бездән нинди Дудай батыр яугирләре чыксын ди? Безме Батырша оныклары? Безме Сөембикә варислары? Безме заман геройлары? Оят, билләһи, оят! "Кардәшлеккә чикләр юк", — дип нәгърә орган булабыз бит әле. Кардәшлекне чикләүләргә дә чик юк икән, ләбаса! Шуны белеп алган "өлкән туганнар" моны бик оста итеп файдаландылар. Әллә ни ерак китәргә кирәкми: кырым татарларын илләреннән куганда безнең татар сугышчылары да — немец фашистларын тар-мар итүдә батырларча сугышкан гаярь милләттәшләребез дә — актив катнаштылар. "Без хокуксыз халык" дип сылтау табарга була анысы. Тик аклану да мескенлекнең бер сыйфаты инде ул. Шуңа күрә анда тукмыйлар безне, монда тәпәлиләр. Кыйналып куркытылып беткән эт беркайчан да бүрегә каршы барачак җан иясе була алмый. Аның өрүен чүпкә дә санамыйлар. Шуңа да узган гасырның туксанынчы елларында бер кузгалып алган идек тә, югарыдан бармак янагач, бик тиз шиңдек. Әз генә ирешелгән мөстәкыйльлек чараларыбызны алып бетерделәр бит инде. Зарлана-каргана чигенәбез. Болай барсак, чигенер җиребез дә калмый инде. Әнә, бүген туграбызны, байрагыбызны бөтенләй алдыру турында сүзләр куера. Алырлар да шул, алдырганда сүзсез торгач. Сүзебезнең кадере булмагач, безне кадерсезлиләр дип нигә үпкәләргә? Димәк, без шуңа лаек кавем. Вәссәлам!

Менә бит, сүз кадере турында сөйли башлагач, әллә кайларга кереп кителде. Темадан читкә китүемне тоям, буталуымны да сизәм. Болганчык заманда буталмыйча булмыйдыр да инде ул. "Бер болганмый су да тонмый, болганмый булмый, булмый", дип җырлыйлармы әле? Шулай да бер эзгә төшмичә булмастыр ул. Һәрхәлдә тырышырга кирәктер.

Язылган кадәрендә төшенкелек рухы өстенлек итсә дә, мин үземне беткән гаҗизгә санамыйм. Юк, ни булса да оптимист булып калам әле мин. Шулай кирәк, башкача ярамый. Югыйсә... Әмма ясалма пафос белән сугарылган, ялган баскан дөньябызда хакыйкать тантана итә дип шәрран ярган ахмак оптимист түгел. Югыйсә, кайбер мәкаләләрдә чагылган фикерләргә караганда "ниһаять, шәп тормышта яши башладык бит" дигәнрәк хисләр калгандай була. Бәхәстә катнашкан И.Вәлиулла *("Казан утлары", 2004, 8 сан)* заман вәзгыятенә бәя биргәндә шулай яза: "М.Горбачевның Үзгәртеп кору сәясәте башланганнан соң илдә үз-үзеңне үтерү күренеше нык кына кимеде". Кычкырасыларым килде: иптәш — әфәнде, Сез кайсы заманда яшисез? Сез әллә океан уртасындагы кеше яшәмәгән утрауда гомер сөреп, дөньядан бөтенләй бихәбәрдәрме? Өзек-төтек килеп ирешкән информацион мәгълүматларга караганда да соңгы 15-20 елда үз-үзенә кул салып мордар китүчеләр саны күрелмәгән дәрәҗәдә арткан икән бит! Сәбәпләре күптер, ләкин, беренче чиратта, кешенең ышанычы бетте: җитәкчеләргә, сәясәтчеләргә һәм, нәтиҗәдә, үз-үзенә. Яшәү мәгънәсен югалтты адәм баласы. Иң аянычы, аны күп афәтләрдән саклый торган Сүз кадере китте. Аны аракы, наркотик кебек тилерткечләр кеше җаныннан бәреп чыгардылар.

Танылган язучыбыз М.Мәһдиев моннан егерме ел элек үк "Бәхилләшү" повестенда бу хакта язып чыккан иде инде. (Дөрес, ул аны тиле-миле көтүче Мөбарәкша аркылы әйттерә, әмма барыбер автор фикере бит инде ул): "....кичә газиттә укыдым. Берәү яза: халыкта эчүчелек фактлары күренә башлады, ди, моның сәбәбе билгеле инде, халыкта акча күбәюдән, ди. Бу бит дөрес түгел. Ә газитә шуны яза. ...Менә кеше шулай икегә бүленде: газитә бер төрле, тормышта — икенче. Ике арадагы аерманы аракы белән тигезли башлады кеше. Кеше икегә бүлендеме — йә эчә башлый, йә чирли". Мордарлык — шул ук чир инде ул. Куркыныч чир! Аерым кеше өчен генә түгел, җәмгыять, ил күләмендәге чир!

Шунысы да бар, хәзер телевизорның кайсы каналын гына ачма, криминал котырган сериаллар ташкыны аңыңны биләп ала. Җинаятьчеләрне эзәрлекләүче "ментлар" уңганнар да, булганнар да. Алар гаделлек сагында торып, һәртөрле бандит, үтерүче, талаучы, хулиганлык кылучы элементларны олавы белән генә әләктереп торалар. Алар уңай геройлмы? Ә нишләп алайса ул изге, гадел гамәлләр тантана итмиләр — җинаятьчелек кимеми? Әллә җәмгыять ул элементларны үзе тудырып торамы? Шулай булгач, җәмгыять үзе төп җинаятьче була түгелме соң? Мондый вәзгыятьтә яшәргә мәҗбүр булган гади кешегә башкаларга, тормышка ышаныч саклавы да авырдыр әле ул. Әллә ил җитәкчелеге тәүлек буе шундый криминал сериаллар күрсәтелүенә фатыйха биреп, халыкның начар яшәвен акларга телиме? Ягъни: "менә ярдәм итәсе иде дә бит, җинаятьчелек котырына, корткыч элементлар ил байлыгын талапмы-талыйлар, алар белән көрәшү дә зур чыгымнар таләп итә" һ.б., һ.б. Мин мордарлыкны каты рәвештә инкарь итәм. Акламыйм мин аларны, әмма аңлыйм. Һәрхәлдә аңларга тырышам.

Заманы нинди, әдәбияты да шундый диләр. Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрнең исемнәренә генә игътибар итик әле: "Сары йортлар сере" *(М.Кәбиров)*, "Элмәк", "Төнге юллар" *(Т.Галиуллин)*, "Саташып аткан таң" *(Ф.Сафин)*, "Бәйсез этләрне атарга" *(Ф.Латыйфи)*, "Албастылар" *(Г.Гыйльманов)*, "Канатсыз акчарлаклар" *(Ф.Бәйрәмова)*, "Могикан" *(В.Имамов)*, "Өермә" *(М.Маликова)*... Санап кына чыгарлыкмы соң аларны! Болары бит әле күләмле проза әсәрләре. Ә поэзия белән драматургиягә кереп китсәң... Мәкалә дәвамында исемнәр белән генә мавыгып утырырга кала инде андый очракта.

Исемнәргә игътибар юнәлтүемнең сәбәбе шул: алар сискәндерәләр, шомландыралар. Әсәрләрне укымыйча ук инде тоярга мөмкин: монда кан, үлем, фаҗига; монда кара көч тантанасы, шайтан туе; монда авторның өметсезлек, гаҗизлек белән сугарылган сызлану фәлсәфәсе. "Китап күңел үстерә", дип әйтергә яратабыз. Болай да төшенке күңелләрне никадәр үстерәдер мондый эчтәлек, белмим, әмма аның хәзерге тормышыбызга, бүгенге халәтебезгә бик тә аваздаш булуын беләм. Без андагы

гаделсез җәмгыятьнең корбаннары—изелгән, яньчелгән геройларда үзебезнең чалымнарны күрәбез дә, кичерешләребезне тоябыз да шаклар катып үз-үзебезгә сорау бирәбез: "Йа, Хода, чынлап та безме соң бу? Рухыбызны үтергәннәр бит безнең, кешелегебезне таптаганнар, горурлыгыбызны изгәннәр бит безнең! Җирдә тышкы кабыгыбыз гына калган, шәүләбез генә йөри икән, ләбаса! Кем соң без?" Мондый сорауларга әсәр геройлары җавап бирергә тиеш иде. Алар безгә юл күрсәтергә, сазлыктан чыгарга булышырга тиешләр иде. Ахыр чиктә, юатырга тиешләр иде. Үзләре дә чарасыз, гаҗиз булган бу затларны заман герое, үрнәк герой дип атый алабызмы? Юк, алай дип атый алмыйбыз. Ә бит андый каһарман кирәк, үтә дә кирәк бит ул, шайтан алгыры! Җәмгыятьтә тоткан урыннары буенча да, тормышта биләгән позицияләре ягыннан да көчле шәхесләр бар иде бит ул игезәк корбаннарыбыз арасында. Моның типик мисалы—Факил Сафинның "Саташып аткан таң" романындагы Әхмәтсафа Дәүләтьяров образы. Реаль тормыштан алынган бу шәхес давыллы, үтә катлаулы еллар тудырган зур фигураларның—фаҗигале фигураларның берсе. Ул—Татарстанның иң югары җитәкчеләреннән. Аңа заман шундый шартлар тудырган иде ки, ул Ходай биргән сәләте, көче, гайрәте, акылы белән, һичшиксез, татар милләтенең лидеры, әйдәп баручыларыннан булырга тиеш иде. Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Габделбарый Баттал кебек узаманнар белән иңгә-иң торып хәрәкәт итәргә сәләтле шәхес иде, ләбаса! "Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән",—дип Тукай тәкрарлаган милли рух исән иде бит әле! Азатлыкка омтылган башка халыкларның аңлы катлауларына таянырга була иде. Ахыр чиктә, артта утны-суны кичкән яугирләрдән оешкан татбригада бар иде бит. Иде шул, иде ... Нәтиҗәдә нәрсә булды? Татар лидерлары үзара талашып, баррикаданың ике ягында торып сугышучы төркемнәргә таралдылар да беттеләр. Ачы хакыйкать: "Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар". Ашадылар инде, ашадылар... Татарны бер-берсенә өстерә-өстерә ашадылар. Халыкның тагын бер ачы гыйбарәсе: "Татар башын татар ашар". Таркаулык әллә безнең милли сыйфатыбыз микән соң ул? Шуның аркасында Казан ханлыгы да җимерелгән, тарих безгә 1917 елдан соң бирелгән мөмкинлекләр дә шул сәбәпле тар-мар килгән. Бүген дә шул хәл кабатлана. Ятлар бездән "ике татар—өч партия" дип көләләр икән, үпкәләрлегебез юк. Авызың кыек булганга көзгегә нигә үпкәләргә?

Дәүләтьяров—үзе төзегән, ышанган, чын күңелдән хезмәт иткән тиранияннең фаҗигале корбаннарыннан берсе булды. Романда ул шул рәвешле бәян ителә дә. Әсәрдә үтә гыйбрәтле бер эпизод бар: кыйналган, изелгән Дәүләтьяров төрмә камерасында Шамил Усманов белән очраша. "Ни өчен бу газаплар безгә, безнең ни гаебебез бар?" дигән әрнүле соравына Кызыл Армиянең дивизия комиссары шулай җавап бирә: "Гаепме? Бар анысы. Без революциягә сукырларча ышандык. Без тарихның табигый агышына каршы гамәл кылуда турыдан-туры катнаштык, кан, үле гәүдәләр өстендә яңача тормыш төзергә маташтык. Бу иң зур ахмаклык булган. Мин моны соңрак аңладым, таш капчыкка эләккәч, уйларга вакыт бар менә...". Ачы хакыйкать! Тоталитар режим идеологиясе белән исәңгерәгән акылның соңарган искә килүе... Халкыбызның каһәрле язмышыннан туган тагын бер гыйбарәсе бәгырьне актарып узды: "Татар акылы төштән соң", яки инде "Татар акылы тау менгәч". Соңарган үкенүдән дә авыр нәрсә юктыр бу дөньяда.

Ф.Сафин Дәүләтьяровны олы фаҗигале язмышка ия персонаж итеп расларга тырыша. Ул аны кызгана да, укучыны кызгануын уртаклашырга чакыра кебегрәк тәэсир дә кала. Ләкин шәхсән мин үлеп-бетеп кызганулар дөньясына чума алмадым. Ф.Миңнуллин заманында татарның зур шәхесе, атаклы язучысы Галимҗан Ибраһимов язмышы турында уйланып болай дигән иде:"Кайчакларда Галимҗан Ибраһимов күз алдына революция солдаты булып түгел, ә бәлки аның корбаны булып килеп баса. Хәзер без аларның барысын да уптым илаһи шәхес культы корбаннары дип йөртәбез. Хәлбуки, термин төгәл түгел..."

Революция солдаты һәм революция корбаны... Бу парадоксаль төшенчәне Дәүләтьяровка карата да кулланырга мөмкин. Системага җаны-тәне белән бирелеп, репрессия машинасының шөрепләре булып хезмәт иткән кешеләр, үтә зур һәм ихлас тырышлык белән, меңләгән-меңләгән гөнаһсыз җаннарның гомерләрен өзүгә булышлык итмәделәрме? Ахыр чиктә, үзләренең фаҗигале язмышларына да алып килмәделәрме? Уйландыра торган хәлләр. Ә мондый затларны заман герое итеп

атый алабызмы соң алай булгач? Мин моңа зур шикләнү белән карыйм. Айдар Хәлимнең гаять саллы мәкаләсендә *("Казан утлары", 2005, 1-2 сан)* әйтелгән түбәндәге фикере белән килешми мөмкин түгел: "Дәүләтьяров—каһарман, тик ул иңенә авыр гыйбрәт төшкән "каһарман" ...фаҗигаи, чынлап та күздән канлы яшьләр чыгарып, чын мәгънәсендә җанны яшькә сугара, елата, сокландыра, горурландыра, рухны күккә алып менә торган каһарман булып килеп чыга алган булса, ул безнең әдәбиятның чынлап та яңа флагманы буларак кабул ителгән булыр иде. Әлегә ул бары кызгандыра гына ала".

Тоталитар режимның идеологиясен уздыручы рупоры булган, системаның икейөзлелеккә корылган Сүзен халык аңына сеңдерүче, тормышка ашыручы, нәтиҗәдә, үзе дә шул Сүзнең һөҗүме астында сытылган, юкка чыккан Дәүләтьяровларга караганда, җинаятьчел җәмгыятьнең гөнаһсыз корбаннары—саф, чиста күңелле, гаять ярдәмчел, әмма ерткыч мохитның пычрагыннан үзен коткара алмаган Җәүһәрия *(М.Маликова. "Өермә")*, намусына тап төшерми яшәү юлыннан тайпылмаганы өчен кешеләр тарафыннан читкә тибәрелгән, рухи изелүгә дучар ителгән Мәдинә карчык *(М.Кәбиров. "Сары йортлар сере")*, милләтнең каймагы дәрәҗәсенә үсеп житәргә тиеш булып та, фаҗигале тәкъдир тегермәнендә тарттырылган Сирин *(Ф.Латыйфи. "Ишелеп төшкән бәхет")* язмышлары ныграк тетрәндерә мине, күбрәк ачындыра. Ә аның шикелледәр илдә меңләгән-меңләгәннәр бит. Алар—пакь җаннылар, кешеләрне афәттән саклап калырга теләүчеләр, адәм балаларын үзенә суырып алган "Сары йорт"ның нигезен какшатырга теләүчеләр. Әмма бу затлар Р.Сибатның Заһидулласы кебек "ялгызаклар", аларда эт өеренә каршы торырлык милләткүләм көч юк. Караңгы төндә дөньяны бер генә мизгелгә яктырта алган нур бөртекләре генә алар. Ә безгә аңыбызга килергә, милли рухны тутыклардан чистартырга гасырлар кирәктер. Өердән чыгарга омтылу да фаҗигаләр белән уратылган—чөнки "бәйсез этләрне аталар".

Хәзерге әдәбиятны күздән кичергәч, шул аңлашыла: заман—җинаятьчеләр, фахишәләр, имансызлар, икейөзлеләр, умырткасызлар, манкортлар, кабахәтләр, намуссызлар заманы икән. Бу "гаскәрнең" башында торучы янарал—Явызлык икән. Димәк, заман герое—ул Кара Көч булып чыга инде. Ә бу өергә каршы чыгарга теләүчеләр—ялгызаклар, сәерләр,сыек буынлылар икән. Алайса, ни көтә соң безне? В.Имамовның йорт түбәсеннән аска ташланып гомерен чикләгән Вәлит, үз биленә ияр салдырмаган өчен әрәм ителгән аты—Могикан язмышларымы? *("Могикан" повесте)*. Сүз дә юк, татар белән ат бер-берсенә береккән җаннар инде алар. Америка әдибе Фенимор Купер романындагы Чингачкук—могикан кабиләсенең соңгы вәкиле. Могикан язмышы—татар язмышы буламыни инде? Ирексездән, Г.Исхакыйның "Инкыйраз..." ындагы Җәгъфәр хәтергә килә.

Күңелсез нәтиҗә. Әмма нишләмәк кирәк. Р.Шәрәфиев белән ничек килешмисең ди инде: "Берөзлексез үзебезнең авыр язмышыбызда казыну, чиребезне ачык күрсәтеп тә, аңа дәва эзләмәү безгә рух көче өстәми, әдәбият исә, гасырдан—гасырга сүнгән йолдызлар, канатсыз акчарлаклар, өзелгән өметләр, бәхетсез егет һәм бичара кызлар, "атылган кош, адаштырган эттәй, үткәннәргә мәэюс карый" торган мескеннәр хакында кинәнеп, тәм табып яза, милләткә инкыйраз юрый". Димәк, әдипләребез бүгенге батлаклыктан чыгу юлын күрмиләр, алгарак карап, аз булса да таң яктылыгын күрергә җөрьәт итмиләр, системадан көчлерәк, аңа каршы чыгарлык, милләтне уятырлык, аны әйдәрлек Сүз әйтер каһарманнарны таба алмыйлар. Әдипләребезнең соңгы елларда тарихка күбрәк мөрәҗәгать итүләре шуның белән дә аңлатыладыр. Ерак үткәндәге "мин әйттем!" дип сүзен өзеп салырлык тарихи шәхесләрне, кодрәтле затларны мәйданга чыгару герой эзләүнең төп хасияте инде ул. Янә бер мөһим сәбәп: чын, тарихи үткәненне белми торып, бүгенгеңне дә аңлап булмый, киләчәгеңне фаразлау мөмкин түгел. Әдәбият киләчәктә дә шул төп ике тармак буенча хәрәкәт итәрдер сыман: бүгенгенең шыксыз картинасын сурәтләү, үткәннең данлы да, шанлы да, канлы да булган вакыйгаларын тасвирлау.

Тарихтан гыйбрәт алу кирәк, бик кирәк безгә. Ләкин заман пычраклыгын аклау өчен үткәннәрне гаепләү, бакыйлыкка күчкәннәрнең рухын каһәрләү хисабына түгел! Бездә андый тенденция дә сизелә хәзер. Ыбыр-чыбыр сөйләүләргә, язмаларга ис тә китмәс иде (ахмак ни сөйләмәс?), әмма шушындый ук мөнәсәбәт мәгълүм затларның чыгышларында да күренгәләгәч, сискәнеплләр куйдым. Бирелә Айдар Хәлимнең "Казан утлары" (1-2 саннар) журналында дискуссия уңае белән язылып басылган

"Сез беләмсез кая барганны?" исемле күләмле, саллы мәкаләсен күздә тотам. Алдан ук әйтеп куям, максатым мөхтәрәм шәхесебезнең мәкаләсен анализлау түгел. Моның өчен аерым сөйләшү, фикерләшү сорала. Ниятем шагыйрь, публицист, күрәшче-милләтпәрвәрнең ачыну, әрнү белән язылган, бәгырьләрне актарып ташлаган, йокымсыраган татарны уятырлык ялкынлы фикерләре турында гәп куерту да түгел. Мактау, соклану хисләремне дә читкә тибәрәм — авторның аңа мохтаҗлыгы юк. Мин аның күңелгә тигән, кәефне кырган кайбер карашлары белән бәхәсләшергә телим. Язучыны ихтирам иткәнем өчен бәхәсләшергә телим. Хөрмәт итмәгән кеше белән вакланып бәхәсләшеп тә маташмыйм мин.

Димәк, бәхәсләшергә рөхсәт итегез!

Айдар Хәлимнең язмасын укып чыккач та күңелгә килгән беренче уй: шәп язылган, зәһәр язылган, үтеңне сытарлык итеп язылган! Дискуссия менә шундыйрак мәкалә белән башланган булса, сөйләшү дә башкачарак накалда барыр иде. Хәер, ялгышам, язма үзе дә башка чыгышларга анализ ясау, бәя бирү рәвешендә дөньяга килгән бит. Мәкалә белән танышкач, баш миендә шыткан икенче уй: монда хәлләр! Булган бу, агач мәчет өстендә таш манара сыман булган.

Язманың зур гына өлешен Мансур Вәли-Барҗылының журналда басылган (*"Казан утлары", 2004, 6 сан*) мәкаләсенә мөнәсәбәт биләп тора. Фикерем шул хакта. Айдар әфәнде мәкалә башында "минем үземне һәм барчабызны, беркемнең дә шәхесен кимсетмичә, тәнкыйтьлисем, каезлыйсым килеп китә", — дип итагать күрсәтсә дә, бәяләү барышында бу бик үк сакланмый. Һәм сөйләшү объектив бәя бирүдән бигрәк, шәхси мөнәсәбәтләр аспектына күчә бара сымаграк тәэсир калдыра. Хәер, бәлки ялгышамдыр. Нәрсә охшамый соң Айдар Хәлимгә Мансур Вәли-Барҗылы мәкаләсендә? Күп нәрсәләр охшамый. Килешергә була автор белән, килешмәскә була. Шәхси уйланулар абсолют хакыйкатькә дәгъва кылмыйлар бит инде! Сәерсендергәне шул булды, А. Хәлим М.Вәли-Барҗылыны "Соңгы елларда шактый серле, шактый томанлы, шактый "экзистенциаль маргаизм" белән сугарылган хикәяләр язу белән мавыгучы" дип, аның проза иҗатына тибеп уза. Татарча әйткәндә "причум" монда тәнкыйть мәкаләсе? Инде фикер әйтелгән икән, аны исбатларга да кирәктер бит? Бу инде тәнкыйть итү түгел, ә бәйләнү, каныгу дип атала.

Фикерем читкә китмәсен өчен үземне әрнеткән, ачындырган бер мәсьәләгә дикъкатемне юнәлтим әле. М.Вәли-Барҗылы мәкаләсендә шундый юллар бар: "Герой исеме ул, һичшиксез, зур батырлык, зур фидакарьлек белән бәйле. Ә батырлык, фидакарьлек дигәндә минем күңелгә иң баштан сугыш елларыннан Шакирҗан Мөхәммәтҗанов, Газинур Гафиятуллин кебекләр, сиксәненче еллар армиясе тормышыннан Рифкать Миргазизов сыман асыл, кыю егетләр килә". Менә шушы фикергә кубарылып ташлана да инде Айдар Хәлим. Уй сөрешенә караганда "чит мәнфәгатьләр хакына яңа империаль сугышка" керү "коллыкка төшерелгән милләт" өчен мәгънәсезлек икән. Тукта, бу нәрсә? Татарларның Бөек Ватан сугышында катнашуы — ахмаклык дигән сүзме соң бу? Карале, кызык кына килеп чыга бит. Сугыш башлангач, татар егетләренә җыелырга да әйтергә кирәк булган икән: без бу яуда катнашмыйбыз, чөнки без кол ителгән халык вәкилләре. Шәп бит? Швейцария сыман илләр кебек нейтралитет игълан итәргә дә, үз эш-мәшәкатең белән тик йөрергә. Күпме егетләребез исән калыр иде, әйеме? Мәгънәсезлекнең чиге юк аның. Әнә, хәзерге яшьләр арасында шундый сүзләрне ишетергә мөмкин: әгәр Германия җиңгән булса, без шәп яшәгән булыр идек. Мөстәкыйль дә булыр идек, өстәлебездә арзанлы "Бавария" сырасы да торыр иде... Заман фәлсәфәсе, замана балалары, нишлисең... Әмма милләтнең асыл улы Айдар Хәлим ни ди бит: "...капланганнармы әле алар пулеметлар авызына? Капланса, кайчан, кайда, кем, ничек, ни өчен, нинди хозурлыклар өчен бирелгән бу мәгънәсез корбаннар?" Бу — Җиңүнең 60 еллыгын билгеләп үтәргә, күз яшьле тантанага әзерлек барган көннәрдә әйтелгән сүзләр. Бу — бүген бик аз калган фронтовикларыбызның җанына яңа яралар өстәүгә, үлгәннәрнең рухын рәнҗетүгә тиң гамәл.

Мин — фронтовик улы. Шөкер, әтием исән-сау. Бик сугыш турында сөйләргә яратмый. Үзем дә аз сораштырам инде. Бер нәрсәгә гаҗәпләнә идем: пиджагыннан орденын төшермәгән эти, Казанга РКБ га (Республика клиник больницасы) килгәндә һәрвакыт шуны салып куя. Күптән түгел район газетасында аның хакында чыккан мәкаләне укыгач кына белдем: врачка чиратта торганда әллә нинди сүзләр ишетүдән

гарьләнгән, күңеле кайткан булган икән. Кабахәт сүз җанын каһәрләгән икән. Ә фронтовиклар адресына бозык сүзләр юнәлә дә юнәлә. Ходай миңа күпме гомер биргәндер, әмма насыйп булган кадәресендә мин мондый черек, пычрак карашлар белән көрәшәчәкмен. Аяусыз! Ачыктан-ачык!

Айдар Хәлимнең мантыйгын да аңлавы кыен. Гафиятуллиннарны ахмак үлем белән гомерен очлаган адәм затлар дип санасын да ди инде, алайса, нигә Җиңү байрагын Рейхстаг түбәсенә Егоров белән Кантариядән бер тәүлек диярлек алдан кадаган Гази Заһитовның танылмавына хәсрәтләнә? Гафиятуллин да, Заһитов та бер армия солдатлары, ләбаса, бер үк максат хакына утка кергән ил уллары! Кайда монда мантыйк?

Ә нигә А.Хәлим М.Вәли-Барҗылының менә бу фикеренә игътибар итми? "Әнә шул изге көрәш вакытында Газинур да, Шакирҗан да үз иптәшләренең гомерен саклап калу, алар исән калсын өчен газиз тормышларын корбан итәләр". Нәрсә, альтруизм дигән бөек гуманистик көч татар өчен хас түгелмени? Башкаларның гомере хисабына үзеңне корбан итү... Менә бит тәнкыйтьченең төп фикере кайда!

Иптәшләренең, сугышчан дусларының гомерен саклап калу өчен үлемгә барган Газинурны "Кызыл армиянең кирза итеге" дип мыскыл итүне бәяләргә мин татар телендә сүз тапмадым. "Бер гомерне саклап калган кеше бөтен галәмне дә коткарыр"—дигән борынгылар. Тарихыбыздагы Сөембикә-ханбикә, Кол Шәриф шундый затлардан түгел иделәрмени? Янә мисаллармы? Г.Ибраһимовның "Диңгездә" хикәясен хәтерлик. Хикәяләүче Насыйр картның бабаларыннан берсе—Гаптулла хаҗи утырган корабны гаять зур балык тота. Ул корбан сорый икән. Шобага Гаптулла хаҗига чыга... Аны кәфенләп, тере көенчә суга ташлагач кына кораб урыныннан кузгала...

Мәйданнарда мөстәкыйльлек хакына ач тора-тора гомерен чикләгән татарның олуг шагыйре Рәшит Әхмәтҗанов иҗатына мөрәҗәгать итик:

*Таныдым. Теге давыл бу.*
*Нигезгә бәрә! Димәк,*
*Ул тынсын өчен упкынга*
*Корбан бирергә кирәк...*
*Төн җитте. Чират—минеке*
*Суырып алыр агым...*
*Һәм булыр упкыннан чыгып*
*Башны калкыткан чагым.*

.................................

*Соңгы күренү булыр ул,*
*Соңгы үрелүләрем,—*
*Батармын туганнарымның*
*Озайтып гомерләрен.*

... Бирердә шәрехләүләр артык дип беләм.

...Сүз кадере бетеп барган заманда яшибез. Бу вакытта нәкъ менә хакыйкатьне кыйбла итеп алган иҗат үрнәкләренә, төпле өйрәнүләргә һәм өйрәтүләргә ихтыяҗ бермә-бер арта да инде. Адәм баласының тормышта тоткан кыйбласы булырга тиеш. Безнең ата-бабаларыбыз Коръәнне һәм хәдисләрне яшәешнең төп кануны итеп таныганнар, шуның белән татар халкын милләт буларак юкка чыгудан саклап кала алганнар. Безгә бүген Исхакый кисәткән коточкыч инкыйраз афәте яный. Шуңа мин вакыт сынавын узган галиҗәнап Сүзгә табынам. Сүз кадерен югалтмыйсы иде!

Сүз кадерен белгән геройны саклап калу—безнең уртак бурычыбыздыр.

**Фәрит БӘШИР**

Гыйлем
Фән

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***МОГҖИЗА*** *г.* — Акыл җитми (гаҗиз итә) торган эш, күренеш. Ислам белгечләре Аллаһы тарафыннан пәйгамбәрләр ярдәмендә ясалган могҗизаны изге кешеләр (*әулиялар / вәлиләр*) ярдәмендә ясалган *кәрамәтләрдән* аерып карыйлар. Суфи Аллаһияр бу турыда:

*Пәйгамбәрләр хикмәтле эш күрсәтсә,*
*Могҗизадан исәпләнә, әлбәттә.*
*Вәхий иңгәнче мондый эше — дәлил*
*Пәйгамбәр булачагына, белсен ил,* — дип яза.

Коръән-кәримдә һәм хәдисләрдә пәйгамбәрләр эшләгән бик күп могҗизалар турында сөйләнә. Бервакыт, мәсәлән, корәеш кабиләсе кешеләре Мөхәммәд галәйһиссәламнән могҗиза күрсәтүен үтенгәч, ул күктәге айны икегә ярган. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең Ходайбийә сәфәре вакытында бармакларыннан су агызып, яугирләренең сусынын басуы да могҗизаның бер мисалы. Сөләйман пәйгамбәрнең Бәлкыйс патшабикәнe тәхете белән бергә Кодеска күчереп куюы, хайваннар белән сөйләшүе, хәзрәти Йунысның Хут балыгы карынында исән калуы, хәзрәти Гайсәнең үлгәннәрне терелтүе, пакизә Мәрьямнең балага узуы һ.б. да могҗиза исәпләнә. Шулай ук Муса пәйгамбәр дә аятьләр һәм могҗизалар белән җибәрелгән була. Мәсәлән, ул үзенең тылсымлы таягын җыланга әверелдереп күрсәткән. Чыганакларда Муса пәйгамбәрнең, җылан сурәтенә кереп, Фиргавен каһиннәренең бауларын йотуы турында да сөйләнә. Шулай ук Салих пәйгамбәрнең кара таштан дөя ясавы да — могҗиза.

Шәрыктә изге кешеләр ясый торган могҗизаларга ышану суфилар арасында аеруча күп таралган була. Гадәттә ул могҗизалар дога уку юлы белән ризык яки су барлыкка китерү, күз ачып йомган арада әлләникадәр ераклыкны үтү, явыз үлемнән котылып калу, берәр изге кеше үлем түшәгендә яткан вакытта күзәтелгән гадәттән тыш күренешләр һ.б. булган. Болары — кәрамәтләр. Кол Шәриф "Кыйссаи Хуҗа" әсәрендә Хөбби Хуҗаның суелган сыер тиреләренә сулыш өреп аларны терелтүе, бикле ишектән чыкмыйча күздән югалуы, диңгезгә батучы кәрванны ярда торган килеш коткарып калуы кебек кәрамәтләрне сурәтли.

Көнбатыш дин белемендә (теологиядә) могҗизаларны физик һәм метафизик төрләргә бүлеп карыйлар.

Физик могҗиза бу дөньяда илаһи көчнең табигатькә турыдан-туры тәэсир итүе нәтиҗәсендә барлыкка килсә, метафизик могҗизалар "теге дөнья"га карыйлар. Физик могҗизалар исә галәмәтләргә (*сигна*) һәм чын могҗизаларга яки *миракльләргә* бүленә. Бәндәләргә көтмәгәндә килгән гадәттән тыш ярдәм, вакыйгаларның табигый агышында һичшиксез һәлак булырга тиешле адәмне гайре табигый көчләрнең үлемнән йолып калуы кебек могҗизалар беренче төргә керәләр. Муса пәйгамбәрнең таягын җыланга әверелдерүе, үлгән кешене терелтү һәм аңа җан өрү, Пәйгамбәрнең айны икегә ярууы исә чын могҗиза, миракль булып санала.

Метафизик могҗиза тулысынча гайре табигый вөҗүдкә, күкләргә мөнәсәбәтле. Аерым алганда, пакизә Мәрьям-ананың балага узуы, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең мигъраҗ кичәсендә күкләргә ашуы — болары, әлеге классификация буенча, әлбәттә, метафизик могҗизаларга карый диярgә мөмкин.

Шуны да әйтеп китик, могҗизаларның классификациясе кайбер христиан авторларында башкачарак та булырга мөмкин. Керәшеннәрдәге "җәшерек"ләр дә могҗиза исәбенә керәләр.

---

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

Гетеның "Фауст"ында: "Могҗиза — иманның сөекле баласы" дигән сүзләргә тап булабыз.

Могҗиза табигать кануннарына каршы килми, ләкин алардан югарырак тора һәм аларны җиңә дию могҗизаның асылын һәм илаһи чыганагын яхшырак аңлата кебек.

Материалистлар могҗизага ышанмыйлар, әлбәттә. Алар фикеренчә, *"могҗиза — ишәкләр өчен фикер патшалыгыннан гамәл патшалыгына алып бара торган басма ул" (Маркс һәм Энгельс. "Немец идеологиясе")*. Гомумән, могҗизага ышанучыларны алар "ишәк" дәрәҗәсенә төшерәләр һәм әлеге фикер ияләре өчен примитив сүгенү иң саллы дәлил булып хезмәт итә шикелле.

Хәзерге заман белешмәләрендә "могҗиза" төшенчәсенә, мәсәлән, мондыйрак аңлатма бирелә: "Могҗиза — дини һәм мифологик күзаллауларда теге дөнья көчләре катнашлыгында барлыкка килгән гайре табигый, фантастик күренешләр." Ягъни асылда могҗиза төшенчәсе илаһи көчләр белән, Алланың үзе белән бәйле рәвештә туган. Әгәр дөньяда могҗизалы хәлләр күзәтелә икән, димәк, Алла бар дигән сүз. Шуңа күрә дини концепцияләрне тәнкыйть итүчеләр "могҗиза" мәсьәләсен үз файдаларына хәл итәргә омтылалар да. Әйтик, дини риваятьләрдә, хәдисләрдә сөйләнгән могҗизаларны йә тулаем инкяр итәләр, яисә бүгенге фәнни карашларга туры китереп, рационалистик нигездә аңлатырга — чынлыкта аларның могҗиза түгеллеген дәлилләргә тырышалар. "Муса таягын", булмаган дип санап, әкияткә чыгарып та була торгандыр. Яки Кәгъбәдәге "кара таш" гади бер метеорит кисәкләре булганга, алар берниндн дә илаһи көчкә ия түгел дип ышандырырга тырышучылар бар. Әледән-әле дөньяны шаулатып ала торган "очар тәлинкәләр"нең дә күпчелеген күзаллаулар белән яки ерак утлар шәүләсе һәм башка физик күренешләр белән аңлатып була, әлбәттә. Дөрес, ничәдер генә процент аңлашылмастай очраклар да кала-калуын, ләкин боларын һич югында киләчәктә фәнни нигездә аңлатып булачак дип әйтергә берәү дә комачауламый.

Яисә демографиядә очрый торган бер кызыклы факт: демографлар сугыш вакытларында ир балалар туу проценты арта дигән фикерне еш кабатлыйлар һәм аларга ышанырга туры килә. Ә статистика кануннары буенча *x*- һәм *y*-хромосомаларның туры килү проценты 50 гә 50 булырга тиеш (ир бала яки кыз бала туу шуңа бәйле). Дөрес, демография мәгълүматлары ир балаларның болай да 1-2 процентка артыграк тууларын күрсәтә кебек. Әмма монысын ир балалар арасында үлү проценты да күбрәк булуы һәм табигый сайланыш, шулай да хәзергә билгесез юл белән (ир балалар күбрәк туганда кеше дигән биологик төрнең ышанычлырак саклануы аркасында булырга мөмкин) әлеге нисбәтне малайлар файдасына үзгәртә дип акылга муафыйк рәвештә аңлатырга мөмкин шикелле. Ләкин сугыш афәтенең ир һәм кыз балалар туу процентына ничек тәэсир итү механизмын гаклый нигездә аңлатып булмый, монда илаһи көчләрнең катнашлыгын танырга туры килә, чөнки фән моның сәбәбен иртәгә ачар әле дип өметләнү илаһи көчкә кайтарып калдырудан бер дә артык түгел. Димәк, без көндәлек тормышыбызда күптән инде *(кешелек тарихында зур һәм дәвамлы сугышлар була башлаганнан бирле)* могҗиза күреп яшибез булып чыга. Ә демографларның кат-кат исәпләүләрен шик астына кую кулай алым түгел.

Әмма могҗизаларның нечкәрәк төре дә бар. Боларын "фикри могҗизалар" дип атап булыр иде.

Шуларның берничәсен күздән кичерик.

Мәсәлән, инглиз физигы Джинс, әгәр дә су салынган савытны эссе мичкә куйсаң, суы кайнап чыгу урынына бозга әверелергә мөмкинме? дигән сорауга җавап эзләп карый. Ул газлар кинетикасында кулланыла торганга охшаш формулалар ярдәмендә тиешле хисаплау эшләре башкарып, суның бозга әверелү ихтималлыгын "санап" чыгара. Нәтиҗәдә Джинс суның бозга әверелү ихтималы юк дигән фикернең дөрес түгеллеген, бәлки бу хәлнең ихтималы бик тә аз икәнлеген таба. Менә шушы мәсьәләнең чишелешен "Джинс могҗизасы" дип атыйлар.

Дж. Максвелл исә шушыңа охшаш мәсьәләне икенче төрлерәк мисалда чишә *(мәшһүр "Максвелл демоны" күбәүләргә билгеле булганга, бу гәмани тәҗрибәне тәфсилләп тормыйбыз)*.

Миллионлаган маймыллар язу машинкасы клавиатурасына ничек килде шулай басып "уйнасалар", очраклы рәвештә, әйтик, "Гамлет" текстын басарга мөмкиннәр. Теория

күзлегәннән караганда, мондый могҗиза *(анысы "Борель могҗизасы" яки "дактилографик могҗиза" дип атала)* да юк дәрәҗәсендә кечкенә ихтималлыкка ия, ләкин аны намөмкин хәл дип булмый. Шунысы кызык, мондый ихтималлык халык теленә дә кергән: "Корылмаган мылтык та ун елга бер ата" дигән сүз бар. Кыскасы, мондый тәҗрибәләрдә намөмкинлек белән "югары дәрәҗәдә наихтималлык" арасында кискен чик калмый, юкка чыга. Димәк, какшамас дип исәпләнгән табигать кануннарының бозылу ихтималы нульдән зуррак икән.

Станислав Лем тагын да "хыялыйрак" бер очракны күздән кичерә. Броун тәҗрибәсендәге кебек тәртипсез хәрәкәт итүче молекулалар микроскоп астында: "Әй, кеше! Бу-без, атомнар!" дигән язу тәшкил итеп тезелсәләр, бу әле кемдер яки нәрсәдер аларны шулай тезеп куйган дигән сүз түгел. Бу—гадәттән тыш наихтимал туры килү, һәм мондый ихтималлык миллиардтан бер булып, Лем фикеренчә, аны игътибарга алмаска да мөмкин икән. Әйе, әлеге язуны илаһи көчләр барлыкка китергән дип расларга без дә ашыкмыйбыз, әмма мондый ихтималлыкны игътибарга алмаска мөмкин диюгә без принципта каршыбыз.

Шунысы кызык, "Лем могҗизасы"ның реаль чынбарлыкта да күзәтелгәне бар ахрысы. Мәс., күп кенә чыганакларда хәбәр ителгәнчә, Төркиядәге Кайсәри өлкәсендә Каракай авылында яшәүче Хәли бәй дигән бер умартачы "Зафәр" исемле журнал редакциясенә гарәп хәрефләре белән аермачык итеп "Алла" дип язылган язулы умарта кәрәзе күтәреп килә. Җентекләп тикшергәннән соң, бу язуның техник ысуллар белән түгел, бәлки бал кортлары тарафыннан эшләнүенә ышанганнар. "Алла" сүзен кеше органнарының рентген рәсеменнән уку очраклары да булды (анысын кан юллары "сызган"). Безнең карашка, "Алла" сүзенең гарәпчә язылышы бик гади булганга, җанлы һәм җансыз табигатьтә аңа охшашлы бизәкләр шактый еш күзәтелергә тиеш. Шуңа күрә без мондый очракларны могҗиза исәбенә кертмәү яклы. Еш кабатлана торган күренешнең могҗиза булуы икеле, аның гади генә сәбәпләрен эзләп табарга була.

Ихтималлыкның "нульдән зуррак" булуы принципта могҗизага урын калдыра. Дөрес, соңга табарак Борель үзе әлеге "югары дәрәҗәдә наихтимал" кебек термин куллanудан баш тартып, "чын яки объектив дөреслек", "төгәллек" *("достоверность")* кебек термин куллануга күчә һәм "әгәр без әлеге тәҗрибәләр намөмкин" дигәндә "мондый намөмкинлек безнең өчен чын дөреслек була дип өстибез икән, без чиксез кечкенә ихтималлыкларны аңлы һәм принципиаль рәвештә исәпкә алмыйбыз" дигән фикерне күтәреп *(яклап)* чыга, ягъни асылда Борельнең һәм Лемның фикерләре тәңгәл. Фактта Борель аңлаешлы терминологияне томанлы сүзләр белән алмаштыра, чөнки ни өчен әле без чиксез кечкенә ихтималлыкларны исәпкә алмаска тиеш? дигән әлеге дә баягы сорау тумыйча калмый һәм без янә мөшкел хәлгә төшәбез.

Э.Юан: "Могҗиза—материя белән рух арасындагы күпер ул, тегесе дә, бусы да хәлык кылучы иҗаты,"—дип белдерә.

Кыскасы, без күп кенә фикер ияләренең дөньяда могҗизага да урын калдырганлыкларын күрәбез.

***МӨӘЗЗИН*** *г.*—Азан әйтүче, азанчы, мәзин, *нади*. Электә мөәззин мөселманнарны гыйбадәткә чакыру өчен йорт борынча йөрергә тиеш булган. Манаралар төзелә башлагач, азанны шуннан әйтүгә күчкәннәр. Баштарак матур һәм көчле тавышлы теләсә кем азан әйтә алган. Кечерәк мәчетләрдә азанны имам үзе әйтә. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең мөәззиннәре икәү булган (берсе—кара тәнле кәнизәкнең улы *Билал ибн Рабах* (Билал Хәбәши) һәм икенчесе—булачак хәлифә Әбубәкернең хезмәтчесе *Ибн Өмми-Мәктум*), шуңа күрә зуррак (берничә манаралы яки берничә мәәззәнәле) мәчетләрдә ике мөәззин тотуны мактаулы эш санаганнар. Ә башта Билал Хәбәши мәчеткә күрше йорт түбәсенә менеп азан әйтә торган булган. Шуны да әйтеп китик, Сөнгатулла Бикбулат Пәйгамбәрнең мөәззиннәреннән тагы *Сәгыд ибн Гаизне* һәм Мәккә мөәззине *Әбү Мәхзура Әүс ибн Могирәне* дә санап күрсәтә. Баштарак мөәззин кеше манарадан торып мөселманнарның өй-йортларын, шәхси тормышларын күрмәскә тиеш дигән таләптән чыгып, мөәззин итеп сукыр кешеләрне билгеләү тәртибе дә булган, соңыннан бу эшне күзлеләргә дә йөкли башлаганнар.

Урта гасырларда мөәззиннәр бер оешма *(корпорация)* төзегәннәр, аның башында

*рәис әл-мөәззинин* торган. Мөәззиннең вазифасы — көнгә биш тапкыр мөселманнарны намазга чакыру. Ләкин VII гасыр ахырыннан Мисырда мөәззингә төнлә өстәмә догалар уку да йөкләнә. Моңардан тыш, IX гасырның икенче яртысыннан мөәззиннәр махсус бүлмәдә төнлә дини китаплар укырга тиеш булганнар. Мөәззинлек еш кына нәселдән күчә торган булган. Өченче изге хәлифә Госман заманында мөәззиннәргә хезмәт хакы түләү кертелә. Хәзерге вакытта мөәззин имамның беренче ярдәмчесе булып санала. Хатын-кызлар мөәззин вазифасын башкара алмыйлар.

Мөәззинне, мулла белән чагыштырып, кимсетеп карау да булган. Мәсәлән, "мөәззиннәр Хуҗа Насретдиннең ишәге тупрагыннан яратылган" дигән сүз йөргән.

*/ / Указлы мөәззин.*

Тагын кара: ***АЗАН, АЗАН ӘЙТҮ.***

***МӨДДӘТ*** *г.* — Вакыт, ара, срок. */ / Руслар Толстойны, Гогольне укыган мөддәттә татарлар да Гаязны укыячак, монда мәгънә эзләп уку, мәгънә эзләмичә уку дигән ике нәрсә булырга мөмкин түгел...* "Татарстан хәбәрләре. — 1992, 10 март. *Мөддәте тәдрисия* — уку вакыты, дәвамлылыгы. *Мөддәт кагыйдәсе* — сроклар кагыйдәсе. *Мөддәтле* — вакыты билгеләнгән, вакытлы. *Бер мөддәт кичектереп тору* — беразга *(беркадәр вакытка)* кичектереп тору. *Озак мөддәтле кредит. Мөддәт гомер. Хәлифәлек мөддәте.*

***МӨҖӘДДИД*** *г.* — Яңартучы, яңалык кертүче, новатор, реформатор. Пәйгамбәр сүзләренә караганда, һәр гасыр башында Аллаһы халыкларга мөҗәддид җибәреп, ул аларга иманнарын аңлатачак. Мәүлана Мөхәммәд Али фикеренә караганда, гасыр башындагы 23 ел *(Пәйгамбәр үзе хезмәт иткән чор)* мөҗәддидләр өчен аеруча бәрәкәтле булырга кирәк. Монда гасыр башы дигәндә һиҗри исәп буенча йөз ел башын аңларга кирәк, әлбәттә. Соңгырак дәверләрдә галимнәр һиҗри гасыр башларында туган шундый мөҗәддидләрнең исемлеген дә төзеп караганнар, ләкин исемлекләрендә күренекле затлар булмаган диярлек *(Адам Мец)*.

*/ / Яңа килгән мөҗәддид, үзеннән алда килгән мөҗәддид кебек үк, динендә югары дәрәҗәдәге иманга һәм гыйлемгә ия булып, Ислам шәригатен яңадан торгызырга тиеш булыр.* Ишми ишан.

Күплек саны шәкеле — *мөҗәддидун.*

***МӨНӘҖӘТ*** *г.* — **1.** Котылу, арыну *(яман уйдан, ниятгән һ.б.)*, пакьләнү; кайгы-хәсрәтләрдән яклавын сорап Аллаһыдан ялвару. Мөнәҗәт гыйбадәт кылучының иң эчкәреге теләкләрен чагылдыра һәм аның Аллаһыга шәхси мөрәҗәгатеннән гыйбарәт. "Шәрык алынмалары сүзлеге"ндә мөнәҗәткә тагы түбәндәге өстәмә аңлатма бирелә: "Фарсы телендә Аллаһ белән яшерен генә "аралашу", ялгыз гына гыйбадәт кылу, төнлә белән дини эчтәлекле шигырьләрне көйләп башкаруны аңлата". **2.** Дини эчтәлекле тезмә әсәр, мәдхия, псалом. Татар мөнәҗәтләрендә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормыш юлын тасвирлауга багышланганнары да бар. 3. Бу сүз "гимн" мәгънәсендә дә кулланылган.

Мөнәҗәтләрнең килеп чыгышы иртәнге мөнәҗәт-догаларга барып тоташа. Гадәти намазлардан аермалы буларак, мөнәҗәт-дога еш кына җирле телдә булган. Аннемари Шиммель фикеренчә, татарларда беренче карашка традицион булып күренгән мөнәҗәтләр суфичылык йогынтысында барлыкка килгәннәр.

Мөнәҗәтләр ешрак гарәп һәм төрки телләрдә яңгыраган. Аларның шигъри төзелеш кагыйдәләре VIII гасырда гарәп галиме әл-Хәлил тарафыннан бәян ителгән. Шигъри-музыкаль жанр буларак, мөнәҗәтләр Урта Көнчыгышта, Урта Азиядә һәм шулай ук татарлар арасында киң таралыш алганнар. Галимнәр Идел буенда мөнәҗәтләргә Коръән сүрәләре һәм дини эчтәлекле Ислам әдәбияты уку зур йогынты ясаган дип саныйлар. Шул ук вакытта аларда Идел буе халыкларының тарихи җырлары, эпосы белән тыгыз бәйләнеш тә сизелә.

1920-80 елларда мөнәҗәтләр онытылды, аларны беркем дә җыймады һәм өйрәнмәде. 1980 елларда мөнәҗәтләр тормышыбызга яңадан кайттылар һәм үзләренә лаеклы урынны алдылар.

Мөнәҗәт сүзенең күплек саны шәкеле: *мөнажат* — мөнәҗәтләр.

***МӨНКАРИЗ, МӨНКАРЫЗ*** *г.* – Сүнгән, беткән, юкка чыккан; нәселе корыган, инкыйразга йөз тоткан. // *Казан дәүләте мөнкариз булганнан соң, авылларда тереклек итүче бабаларыбызның беренче мәртәбә Дагыстан голямасы тәртипләре рәвешендә вә аннан соң, кайсы гасырлардан башлаптыр, Бохара әхвalenә ияреп гыйлем тәхсыйль иткәнлекләре беркадәр мәгълүм.* Р.Фәхреддин. *Язып вә кучереп утыруларым бездән соңлар укырлар рәвешендә бер фикер берлә түгел, динсез латин кауме өчен төркләрнең бу мәмләкәттә мөнкариз төркләр вә мөселманнарның әсәрләрене укуга ихтыяҗлары вә ләззәтләнүләре булмаслыгы мәгълүм.* Р.Фәхреддин.

*Монкариз* язылышы да очрый.

***МӨСЕЛМАН*** *гф.* – **1**.Ислам динен тотучы, мөслим. Мөслим сүзенең күплек саны шәкеле *мөслимин* сүзеннән килеп чыккан. Шәркыят һәм Ислам белгече Т.А.Шумовский "мөселман" сүзенең беренчел мәгънәсе "савыктыручы" булган дип исәпли." **2**.Югославиядә Ислам дине тотучы һәм серб-хорват телендә сөйләшә торган халык. Аларга мөселман исеме Югославиянең беренче президенты маршал Тито тәкъдиме белән бирелгән.

***МӨСЕЛМАН ЗИРАТЫ ҺӘМ ХАТЫН-КЫЗ*** – 1920 елның язында Казандагы мөселман зиратын идарә итәргә сайланган вәкилләр шурасының карары буенча хатын-кызларны каберстанга кертмичә, аларны якыннарының каберен зиярәт кылудан мәхрүм итә торган карар кабул ителгән. Дөрес, карар бер тавыштан чыгарылмаган, Фатих Әмирхан әйтмешли, "азчылыкның бу карарга каршы нык игътираз итүенә дә карамастан, шураның *кечкенә бер күпчелеге* шушы хаксыз карарны чыгарган." Соңыннан карар җәмәгатьчелек таләбе буенча үзгәртелгән, чөнки ул "һичбер төрле дини ихтыяҗларга бина ителмәгән" булган. Мәгълүм ки, Мөхәммәд Пәйгамбәр хатын-кызларның якыннары каберен зиярәт кылуына каршы булмаган.

***"МӨСЕЛМАН КАЗЫЛЫГЫ"*** – 1910 елларда Казан сәүдәгәре Габдулла Килдиев тарафыннан җитештерелгән колбаса сорты. Ирекле базар шартларында милли реклама үрнәге буларак, исеме игътибарга лаек. Мондый алымны сабынчылар да кулланганнар. Мәсәлән, иске Рәсәйдә "Гөлҗиһан" сабыны дигән исле сабын чыгарылган.

***МӨСТӘГАР*** *г.* – **1**.Кушамат, ялган исем; псевдоним. // *Наме мөстәгар* – яшерен имза, псевдоним. *"Йолдыз"да мәкаләләре булган ике йөз егерме кеше арасында минем имзам һәм наме мөстәгарем саналган, ягъни мин анда йөз ун өлештән бер кисәк булып кергәнмен.* Ф.Әмирхан. **2**.Әҗәт, бурыч.

***МӨФЛИС*** *г.* – Бөлгән кеше, банкрот. // *Кыз бирә калсак, дүрт йөз сум көмеш мөһер язып, атларын, ауларын, печәнләрен саттырып, йитмәгәненә кияү вә коданы бурычка чумдырып мөфлис калдыру кирәк.* Габделкәбир Ишкулов ахун хотбәсеннән (XX гасыр башы).

***МӨХИТ*** *г.* – **1**.Әйләнә-тирә, тирә-юнь; тирәлек. **2**.Океан.

"Татар теленең орфографик сүзлеге"ндә (1983) "мохит" язылышы кабул ителгән.

***МӨХТӘСИБ*** *г.* – Урта гасырларда мөхтәсибләр базарларда сәүдә кагыйдәләренең үтәлешенә күзәтчелек иткәннәр. Тора-бара алар Ислам әхлак кануннарының үтәлешен тикшереп торучыларга әйләнгәннәр һәм зиначылыкны, эчкечелекне, рибачылыкны, ураза кагыйдәләрен бозуны кисәтү дә аларга йөкләнгән. Бездә аларның вәкаләтләре тагы да киңәйгән: мөхтәсибләр меллалар өстеннән күзәтеп торучы дин белгече, инспектор, контролер, хисап алучы хезмәтен үти башлаганнар.

1931 елгы "Татарча-русча сүзлек"тә *мөхтәсиб* – "магометанский благочинный."

*Дәвамы киләсе саннарда*

Tarix
Тарих



Тәлгат
Насыйров

# ОКТЯБРЬ ҺӘМ ЭЗӘРЛЕКЛӘНГӘН ТАТАР МАТБУГАТЫ

1917 елгы октябрь түнтәрелеше вакытында һәм аннан соң большевиклар үзләренең хакимиятен ныгытуда иң әһәмиятле, хәлиткеч юнәлешләрнең берсе итеп алар белән килешмәүчән матбугатны юк итүне саныйлар һәм аңа каршы аяусыз көрәш җәелдерәләр. Кыска гына вакыт эчендә Россиянең төрле төбәкләрендә күп санлы газета-журналлар ябыла, аларның наширләре һәм мөхәррирләре кулга алына, басмаханәләре, кәгазь һәм акча запаслары конфискацияләнә.

Большевиклар оештырган коралллы баш күтәрүнең беренче көнендә үк—1917 елның 25 октябрендә (7 ноябрьдә)—Россия башкаласы Петроградта хәрби-революцион комитет "Русская воля", "Новое время", "Вечернее время", "Биржевые ведомости", "Народная правда" газеталарын ябарга боерык бирә *(Петроградский военно-революционный комитет.—Т.1.—М., 1967.—С. 134).* 26 октябрьгә каршы төндә, "Наше общее дело" газетасы, редакциясендә тентү үткәрелгәннән соң, чыгудан туктатыла һәм мөхәррире кулга алынып, Петропавел крепостенә озатыла. 26 октябрь иртәсендә коралланган матрослар "Речь" һәм "Современное слово" газеталарының тарату бүлегенә юнәләләр һәм анда булган барлык газета саннарын урамга алып чыгып, утта яндыралар. Шул ук көнне хәрби-революцион комитет күп кенә башка газеталарны ябу, аларның мөхәррирләрен һәм әйдәп баручы хезмәткәрләрен кулга алу өчен, матбугат комиссары карамагына 120 кызылгвардиячеләрне җибәрүне таләп итә. Башкалада шулай ук "День", "Петроградский листок", "Петроградская газета", "Новая Русь", "Живое слово", "Копейка", "Дело народа", латыш телендәге "Рабочая газета" һәм башка көндәлек матбугат басмаларын чыгару тыела *(Красный архив. 1937. N 5 (64). С. 190; Петроградский военно-революционный комитет.—Т. 1. М., 1967.—С. 157, 175, 239; Советы в Октябре.—М., 1928.—С. 8).*

Тартып алынган басмаханәләр, кәгазьләр большевистик газеталар чыгару өчен кулланыла. Мәсәлән, 1917 елның 27 октябрендә хәрби-революцион комитет "Речь" һәм "День" газеталарының басмаханәләрен РСДРП(б) Үзәк Комитеты басма органнары булган "Солдатская правда" һәм "Деревенская беднота"га тапшырырга карар итә. "Новое время" басмаханәсенә большевикларның төп басма органы—"Правда" газетасын бастырырга әмер бирелә.

1917 елның 27 октябрендә Халык Комиссарлары Советы (Совет хөкүмәте) үзенең беренче утырышында "Матбугат турында декрет" кабул итә һәм ул икенче көнне В. Ульянов (Ленин) имзасы белән "Правда" һәм башка газеталарда игълан ителә.

Тәлгат НАСЫЙРОВ (1925) *—тарихчы-галим; «Октябрь һәм Татарстан матбугаты», «Хәсән Урманов» исемле китаплар, журналыбызда басылган күпсанлы язмалар авторы. Тарих фәннәре кандидаты. Казанда яши.*

Бу документ Петроград хәрби-революцион комитеты үткәргән чараларны яклаудан башлана. “Түнтәрелешнең гаять авыр һәм хәлиткеч сәгате һәм аннан соңгы көннәрдә,—диелә әлеге документта,—Вакытлы Революцион Комитет төрле төстәге контрреволюцион матбугатка каршы күп кенә кырыс әмәлләр кулланырга мәҗбүр булды”. Большевикларга каршы матбугатны бастыруның зарурлыгын дәлилләргә теләп, анда шундый юллар язылган: “Буржуаз пресса буржуазиянең куәтледән куәтле коралларының берсе булып тора. Бигрәк тә яңа хакимият, эшчеләр һәм крестьяннар хакимияте бары тик ныгып кына килә торган кискен чорда, бу коралны тулысы белән дошман кулында калдырып булмый... бу коралның куркынычлыгы бомбалар һәм пулеметлардан һич тә ким түгел” *(Декреты Советской власти. Т. 1-25 октября 1917 г.—16 марта 1918 г.—М., 1957.—С. 24-25).* Шушы декрет совет режимының үзәктә һәм урыннарда чыгып килгән большевикларны якламаган матбугатны көчләп тар-мар итүгә, басмаханәләрен, кәгазьләрен, акчалата капиталларын тартып алуга юнәлдерелгән эзәрлекләү чараларын рәсми рәвештә канунлаштыра.

Басма сүз һәм төрле фикерлелек иреген бууга төбәлгән Петроград хәрби-революцион комитетының оппозицион газеталарны ябуы һәм матбугат турындагы ленинчыл декрет демократик җәмәгатьчелекнең зур канәгатьсезлеген тудыра. Моны большевикларның үзләренә дә танырга туры килә. Әйтелгән матбугат турындагы декретта бу хакта: “Шуңа күрә шунда ук бөтен тирә-яктан: яңа социалистик хакимият үз программасының төп асылы—матбугат ирекле генә базынды дигән каты кычкырынулар башланды”—дип әйтелә.

Матбугат турындагы декрет тирәсендә аеруча кискен торыш, аны кабул иткәннән соң бер атна үткәч, совет властенең иң югары дәүләти органы—Бөтенроссия Башкарма Комитетының 1917 ел 4 ноябрендә узган утырышында чагылыш таба. Анда беренче булып чыгыш ясаган большевик Ю. Ларин (элеккеге меньшевик) матбугатны эзәрлекләү адымнарыннан, шулай ук “революцион хакимият үткәрә торган кулга алу, тентү һәм шуңа охшашлы барлык кысрыклаулардан ваз кичәргә” кирәклеге турында сөйли. Ул: “Халык Комиссарлары Советының матбугат турындагы декреты гамәлдән чыгарыла. Сәяси репрессияләр, Үзәк Башкарма Комитет тарафыннан сайланган һәм шулай ук кулга алу, газеталарны ябу һәм башка инде кылынган барлык эшләрне яңадан карарга хокуклы трибуналның алдан бирелгән рөхсәте буенча гына үткәрелә ала”,—дигән резолюция тәкъдим итә. Шундый ук карашта сул эсерлар А. Л. Колегаев, В. А. Карелин һәм Б. Ф. Малкиннар да тора. Соңгысы, аерым алганда, болай ди: “Без социализмны, корал кулланып, көчләп диярлек кертергә уйлаганнарның күз карашын кискен рәвештә кире кагабыз. Без корал белән тәнкыйтьләүне танымыйбыз, ләкин тәнкыйть коралы Ирекле Россия Республикасының һәрбер кешесенә бирелергә тиеш. Без Бөтен Россия Башкарма Комитетына кичекмәстән матбугат иреклеген чикләүләрнең барсын да юкка чыгарырга тәкъдим итәбез” *(Протоколы заседаний Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета Советов Р., С., Кр. И Каз. Депутатов II—созыва.—М., 1919.—С. 26-27).*

Бу җыелышта большевиклар Л. Д. Троцкий, В. И. Ленин һәм В. А. Аванесов матбугат турындагы совет декретын яклап чыгалар. Соңгысы тарафыннан большевиклар фракциясе исеменнән тәкъдим ителгән резолюциядә: “Буржуаз газеталарны ябу—кораллы баш күтәрү һәм контрреволюцион омтылышларны бастыру вакытындагы сугышчан ихтыяҗлар өчен генә түгел, ә матбугат өлкәсендә, басмаханәләр һәм кәгазь хуҗалары—капиталистларның иҗтимагый фикерне хәл итүче чикләнмәгән хокуклы хөкемдарлар була алмаслык, яңа режимны урнаштыру өчен кирәк булган көчү чарасы иде. Якындагы чара—хосусый басмаханәләрне һәм кәгазь запасларын конфискацияләү һәм аларны үзәктәге һәм урыннардагы совет хакимияте биләвенә тапшырудан гыйбарәт”—дип язылган була *(Декреты Советской власти.—Т. 1.—С. 43-44).*

Джон Рид әйтүенчә, бу резолюция тыңлаучыларның ярсулы протестын тудырган, аны уку: “бик ачулы кычкыру тавышлары белән бүленеп” барган *(Джон Рид. 10 дней, которые потрясли мир., 1957.—С. 220).* Җыелышта артык күп өстенлек алмаган 34 тавыш белән большевиклар фракциясе резолюциясе кабул ителә. Аңа 24 каршы белән 1 битараф тавыш бирелә.

Тавыш бирү үткәннән соң, П. П. Прошьян сул эсерлар фракциясенең белдерүен игълан итә. Ул белдерүдә Бөтенроссия Башкарма Комитеты утырышында кабул ителгән әлеге резолюция "сәяси террор системасының һәм ватандашлар сугышы кабызуның ачыктан-ачык һәм билгеле чагылышын" күрсәтүче документ дип бәяләнә. Сул эсерлар фракциясе большевиклар белән хезмәттәшлек итүдән ваз кичүен, революция өчен һәлакәтчел террор системасын берничек тә якламавын, үзенең барлык вәкилләрен Хәрби-революцион комитеттан, штабтан һәм башка җаваплы постлардан чакыртып аласын хәбәр итә.

1917 ел вакыйгаларында актив катнашкан, беренче чакырылыш Советларның Бөтенроссия Башкарма Комитеты әгъзасы, билгеле меньшевик-интернационалист Н. Н. Суханов, большевикларның оппозицион матбугатка каршы һөҗүмнәре турында сөйләп: "Матбугатны мондый массалы рәвештә кыйнау царизм тарафыннан бер вакытта да үткәрелмәде... Бу матбугат эшләрендәге кеше ашаучылык... Хәер, бу бит—азиатчыл интернационалист Ленинның асыллары (принциплары)"—дип язган *(Суханов Н. Н. Записки о революции.—Т. 3. Кн. 5, 6, 7.—М., 1992.—С. 346, 366).*

Матбугат турында совет декреты кабул ителгәннән соң озак та узмый, 1917 елның 26 ноябрендә Петроградта Рус язучылары берлегенең беркөнлек махсус "Газета-протест"ы дөнья күрә. Аның авторлары арасында төрле-төрле әдәбият, журналистика даирәләре һәм җәмәгать төркемнәре вәкилләре—В. Короленко, З. Гиппиус, Д. Мережковский, Е. Замятин, Ф. Сологуб, В. Засулич, А. Потресов, Питирим Сорокин, М. Неведомский һәм башкалар була. Аларның "Сүзне үтереп булмас", "Идеалны пычрату", "Кызыл дивар", "Иблис хезмәтчеләре", "Залимнарга", "Матбугатны эзәрлекләүчеләргә протест" һәм башка мәкаләләрендә ленинчыл декретның антидемократик асылы, совет хакимиятләренең, большевистик режим белән риза булмаган матбугатны юк итү буенча үткәргән гамәли эшләре кискен тәнкыйтьләнә һәм илдә матбугат иреклеген торгызу таләп ителә. Шундый ук тухтагы "Слову—свобода" исемендәге беркөнлек газета Мәскәү язучылары тарафыннан да чыгарыла *(Крестьянская Казанского губернского земства газета.—1917.—17 декабря).*

Ләкин сыйнфый килешмәүчәнлек рухы белән сугарылган Ленин һәм аның тарафдарлары Россия либерал-демократик катлаулары фикеренә колак салмыйлар һәм большевистик булмаган матбугатка каршы рәхимсез көрәшне дәвам итәләр. Матбугат турындагы совет декреты нигезендә 1918 елның көзенә кадәр Россиянең барлык төбәкләрендә дә күптелле большевистик булмаган көндәлек матбугат юк ителә. А. З. Окороковның хисаплавынча, совет власте органнары тарафыннан илдә 460 тан артык буржуаз һәм вак буржуаз газеталар чыгарудан туктатыла (бу саннарга журналлар керми) *(Окороков А. З. Октябрь и крах русской буржуазной прессы.—М., 1970.—С. 310).* Матбугат турындагы декретта: бары тик яңа хөкүмәткә ачыктан-ачык каршылык күрсәтүгә һәм аңа буйсынмаска чакыручы пресса органнары гына ябылырга тиеш дип әйтелгән булса да, ахыргы чиктә, совет хакимиятләре тарафыннан үткәрелә торган яңа тәртипләргә битарафлык, ә кайбер мәсьәләләр буенча хәтта лояльлек күрсәткән басмалар да тыелган. Бу большевиклар партиясенең матбугат өлкәсендә үзе генә идарә итә торган, чикләнмәгән хакимият урнаштыру нәтиҗәсе була.

Большевистик булмаган газета-журналларның барысы да диярлек, контрреволюцион, совет властенә каршы юнәлештә булуда гаепләнеп, административ-боерык һәм көч куллану юлы белән ябыла. Аларны Россиядә совет власте урнашуын тәнкыйтьчел рухта каршылауда, аның декретларын һәм монархия төшерелгәннән соң барлыкка килгән демократик хакимият һәм идарә органнарын тар-мар итү буенча кылган гамәли эшләренә, предприятиеләрдә эшчеләр контроле урнаштыруга, банк, фабрика һәм заводларны национализацияләүгә, төрлечә фикер йөртүне тыюга каршы чыгуда һәм башка "җинаятьләр"дә, гаепliләр. Газета-журналларның бер өлеше акча, кәгазь, матбага һәм башка матди-техник әйберләр белән тәэмин итүдә совет оешмалары тарафыннан тудырылган кыенлыклар аркасында үзләренең эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр була.

Октябрьдан соңгы беренче айларда большевистик булмаган татар телендәге газета-журналлар да эзәрлекләнә һәм яшәүдән туктатыла.

Татар көндәлек матбугаты патша заманында да даими кысрыклауларга дучар ителә һәм сикәлтәле үсеш юлын узарга мәҗбүр була. Патша хөкүмәте Россия уртасында яшәүче төрки телле халыкларга карата, аның чикләрендә көн күрүчеләр белән чагыштырганда, күпкә кырысрак сәясәт алып бара. Үзбәк, казакъ, әзербайҗан, кырымтатар телендәге вакытлы матбугат XIX гасырның 30-80 елларында ук чыга башласа, Казан татарлары телендә ул XX гасыр бусагасын атлагач кына барлыкка килә. 1808 елда Казан университетының физика профессоры И. И. Запольский "Казан мөхбире" дигән беренче татар газетасын чыгармакчы була, әмма аның тырышлыгы тормышка ашмый кала.

Йөз ел дәвамында рус һәм татар халкының алдынгы карашлы фикер ияләре М. Г. Никольский, Каюм Насыйри, Мөхәммәтвәли Яхин, П. И. Пашино, В. С. Курочкин, Хөсәен Фәезханов, Ириней Нафаль, аталы-уллы Әбделхәер һәм Тажетдин Котлыяровлар, О. С. Лебедева һәм башкалар, патша дәүләтенең рәсми оешмаларына татарча газета-журнал чыгарырга рөхсәт сорап күп тапкыр мөрәҗәгать итәләр. Үтенеч гаризаларында аларның күбесен Казан һәм Россия башкаласы Санкт-Петербургта чыгару күздә тотыла. Татарча көндәлек матбугат басмаларын Оренбург, Орск, Томск, Әстерхан һәм башка шәһәрләрдә дә нәшер итү турында үтенечләр була. Тик бу мөрәҗәгатьләрне хөкүмәт даирәләре кире кагалар, хәтта монархистик рухта, патша тарафдарлары тәкъдим иткән фикер юнәлешендә булырга тиешле газета-журналларны бастыруны да рөхсәт итмиләр. Мәсәлән, Санкт-Петербург гарнизонының консерватив күз карашлы гаскәри ахуны Гатаулла Баязитов, 1891 елдан башлап, унбиш ел дәвамында, татар телендә газета чыгарырга рөхсәт сорап, патша хакимиятләренә алты тапкыр мөрәҗәгать иткән. Ләкин аларның берсе дә канәгатьләндерелмәгән.

Фәкать 1905 ел революциясе тудырган шартларда гына патша хакимияте мондый рөхсәтне бирергә мәҗбүр була һәм шул елның 2 (15) сентябрендә Санкт-Петербургта "Нур" дигән беренче рәсми татар газетасы дөнья күрә. Аның мөхәррире һәм нәшер итүчесе әле әйтелгән Гатаулла Баязитов була, ул вафат булгач, бу эшне аның улы Мөхәммәтсафа Баязитов дәвам итә. 1914 елга кадәр чыгып килгән "Нур" газетасы татар вакытлы матбугатының башлангычы итеп исәпләнә.

"Нур" артыннан Россиянең башка төбәкләрендә дә татарча газета-журналлар пәйда булалар. Кайбер чит илләрдә татар мөһаҗирләре нәшер иткән көндәлек матбугат басмалары барлыкка килә. 1905 елның сентябреннән 1917 елның Февраль революциясенә кадәр Россиядә, Төркиядә һәм Алманиядә типографик ысул белән сиксәнгә якын милли басма дөнья күрә. Алар гарәп имлясында, ә керәшен татарлары өчен икесе кириллицада басыла. Болардан тыш рәсми һәм яшерен рәвештә утызга якын гектографик һәм кульъязма газета-журналлар чыга. Бер кульъязма газета Венгриядә чыгарыла. Бу вакыт эчендә патша даирәләре татарча газета-журналлар нәшер итү турындагы егермедән артык үтенечне кире кагалар. *(Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905-1925. К., 1926.—203 б.)*


Патша цензурасының һәм полициянең антимонархистик демократик матбугатны эзәрлекләве, наширләрне һәм мөхәррирләрне кулга алу, репрессияләү, сөргенгә озатуы нәтиҗәсендә күп кенә татар көндәлек басмалары чыгудан туктый. Алар арасында Казанда нәшер ителгән "Азат", "Азат халык", "Таң йолдызы", "Тавыш" газеталары һәм "Таң мәҗмугасы" журналы да була. Сонрак Санкт-Петербургта нәшер ителгән "Өлфәт", "Нәҗат", "Дума", Мәскәүдә чыккан "Ил", "Сүз", Әстерхандагы "Идел", "Халык" газеталары, "Туп" журналы, Оренбургта нәшер ителгән "Урал" газетасы, "Яз", "Карчыга" журналы, Уральскида чыккан "Яңа тормыш", Ташкентта басылган "Асия" ("Азия") газеталары, Кызылъярда (Петропавел) нәшер ителгән "Ишим даласы" газетасы һәм башкалар шул исемлекне тулыландырды.



Россиядә монархия беткәнче, 1917 ел февраль аена кадәр Казанда, Оренбургта, Уфада, Вяткада, Мәскәүдә һәм Берлинда татар телендә 17 газета һәм журнал чыга. Ә Әстерхан, Санкт-Петербург, Уральск, Ташкент, Самара, Томск, Троицк, Кызылъярда алар яшәүдән гел туктыйлар.

Патша самодержавиесен төшерүгә китергән 1917 ел Февраль демократик революциясе Россиядә төрле телләрдәге матбугатның үсешенә киң юл ачкан. 1917 елның көзе ахырына типографик ысул белән татар телендәге көндәлек матбугат басмалары Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Петроград, Мәскәү, Псков, Самара, Сембер, Сарытау, Вятка, Минзәлә, Чиләбе, Уральск, Кызылъяр, Троицк, Семипалат, Томск, Сәмәрканд, Хуканд һәм Ташкент шәһәрләрендә чыгып килгәннәр. Яшь галимә Диләрә Госманова ачыклавынча, гектограф, шапирограф һәм башка типографик булмаган ысулларда бастырылган татарча газеталар (һәр кайсы берәр яисә берничә санда гына) Касыйм, Царицын, Ижау, Пермь, Верный (Алма-Ата), Гурьев, Гельсинфорс, Перовск (Сыр-Дарья өлкәсе), Семипалат шәһәрләрендә, Уфа губернасы Бөре өязе Әсән авылында һәм җиде армия берләшмәләрендә дә пәйда булганнар. Тик аларның бер генә саны да диярлек әлегәчә табылмаган *(Усманова Д. М. Вопросы национально-государственного самоопределения на страницах татарской периодической печати (1917 апрель 1918 г.г.).—К., 1994.—С. 242-244).*

1917 елның октябренә Россиянең төрле төбәкләрендә татар телендә типографик ысул белән илледән артык газета һәм журналлар чыгып килгәннәр. Алар арасында сәяси-фикри юнәлешләре буенча консерватив, либерал-демократик, революцион-демократик һәм социал-демократик яисә шуларга өлешчә якынлыкта торган басмалар булган. Аз санлы консерватив рухтагы көндәлек матбугат басмаларыннан 1917 елның февраленә кадәр үк дөнья күргән, кириллицага нигезләнгән миссионерчыл "Сугыш хәбәрләре" белән "Дус" газеталарын һәм татар руханиларының уң канат вәкилләре күз карашларын чагылдырган "Дин вә мәгыйшәт" һәм "Мәгълүмате Мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя" журналларын күрсәтеп була. 1917 елның 10 октябрендә, соңгысы урынына, Эчке Россия һәм Себер мөселманнары төрек-татарлары Милли Идарәсенең басма органы буларак, "Мохтарият" ("Автономия") исемле яңа журнал чыга башлаган.




Октябрь алдыннан чыгып килгән татар вакытлы матбугатының иң күп өлеше либерал-демократик газеталар һәм журналлардан торган. Бу төркемне Февраль революциясенә кадәр үк дөнья күргән зур күләмле эре басмалар, шулай ук самодержавие җимерелгәннән соң барлыкка килгән, сыйнфый көрәш, пролетар диктатурасы тәгълиматын танымауларын һәм үзләренең гомуммилли табигатен игълан иткән газета-журналларның күпчелеге тәшкил иткән. Алар Россиядә 1917 ел Февраль революциясе җиңүен һәм аннан соң үткәрелгән демократик үзгәрешләрне хуплап каршылаганнар. Бу пресса битләрендә илдә җәелгән милли-азатлык хәрәкәте мәсьәләләре, бигрәк тә 1917 ел дәвамында Мәскәүдә, Казанда, Уфада булып узган гомумроссиячыл мөселман съездлары, Милли Мәҗлеснең беренче җыелышы материаллары киң яктырылыш тапканнар; шул форумнарда татар һәм башкорт халыкларының милли-дәүләтчел үзбилгеләнү мәсьәләләре тикшерелүе, ул максатларны гамәли башкару өчен Милли Шура, Хәрби Шура һәм Милли Идарә кебек милли демократик оешмаларның төзелүе һәм эшчәнлеге турында күп санлы хәбәрләр бирелеп килгән.

1917 ел Февраль революциясеннән соң һәм Октябрь якынлашканда мәйданга килгән социалистик юнәлештәге Казандагы "Аваз" һәм "Кызыл байрак", Уфадагы "Ирек", "Авыл халкы", "Безнең юл", Оренбургтагы "Эшче", кайбер армиячел газеталар революцион-демократик басмалар төркеменә кергәннәр. Алар барысы да, нигездә, илдәге хакимиятнең Советлар кулына күчүен яклаганнар. Бу чорның социал-демократик юнәлештәге басмаларның берләнберен, билгеле төзәтмәләр белән, Уфадагы татар-башкорт социал-демократлары чыгарып килгән "Алга" газетасы тәшкил иткән. Ул Октябрьгача "Бөтен илләрнең пролетарийлары, берләшегез!" шигаре астында нәшер ителгән аз санлы милли газеталарның берсе булган *(Амирханов Равиль. Татарская дореволюционная пресса (В контексте "Восток—Запад").—К., 2002.—С. 74).* Бу газетаның соңгы 8 саны 1918 ел гыйнвар ае уртасында чыккан.

Самодержавие төшерелгәннән соң һәм Совет властенең башлангыч чорында

чыгып килгән төрле сәяси-фикри юнәлештәге газета-журналлар материаллары белән танышу, ул чак Россиядә бер-берсенә каршы торган иҗтимагый-сәяси көчләрнең омтылышлары килешә алмаслык булганын күрсәтә.

Большевистик булмаган консерватив һәм либерал-демократик татар вакытлы матбугаты, гомумән алганда, 1917 ел октябрь вакыйгаларын һәм большевикларның аннан соң кылган гамәли эшләрен канәгатьсезләнү белән каршылаган. Аеруча кискен тәнкыйть сүзләре, Россиядә милли мәсьәләне большевикларча чишүне яклаганнары өчен, Коммунистлар партиясе күрсәтмәсе нигезендә үзәктә һәм урыннарда төзелгән совет татар-башкорт комиссариатларына, аларның җитәкчеләренә каршы юнәлдерелә. Мәсәлән, татар телендә чыгып килгән Мәскәүдәге "Ил", Казандагы "Корылтай", Уфадагы "Тормыш" һәм башка тарихта билгеле либерал-демократик газеталар Совет хөкүмәтенең РСФСР Милләт эшләре Халык Комиссариаты составында Үзәк мөселман (Татар-Башкорт) Комиссариатын, шундый ук тәңгәл комиссариатларны губерна һәм өяз советлары хозурында төзү турындагы карарларын хупламаганнар. "Корылтай" газетасы 1918 елның 31 гыйнвар санында: "Россия мөселманнары барысы да (?) большевиклар хөкүмәтен әле таныганнары юк... Эшләрен дә большевиклар хөкүмәте тәшәбес (теләк) илә тәшкил ителә торган комиссариаттан каратачак түгелләр",—дип язган. Шул ук газета 1918 ел 28 февралендәге "Казан Мөселман Комиссариаты төзелү мөнәсәбәтенә" исемле баш мәкаләдә: "Безнең Эчке Россия мөселман төрек-татарларының милли, мәдәни эшләребез хакында законнар төзүче миссиябез (Милләт Мәҗлесе) бар һәм Милләт Мәҗлесе кабул иткән законнарны гамәлгә ашыручы миссиябез (Милли Идарә һәм вилаять һәм авыл мәҗлесләре) бар. Болай булгач, Сталин комиссариаты янына нигезләнгән "Мәркәз Мөселман Комиссариаты" ни өчен кирәк тә, вилаятьләрдә "Мөселман комиссариатлары" нигә кирәк?—дигән сорау куя.




Совет хөкүмәте, Үзәк мөселман (Татар-Башкорт) комиссариаты һәм аның филиалларының Милли Шура, Хәрби Шура, Милли Идарә кебек гомуммилли демократик оешмаларны, аларның урыннардагы бүлекчәләрен тар-мар итүе, татар телендәге большевистик булмаган көндәлек матбугат битләрендә аеруча кискен сүзләр белән тәнкыйтьләнә. Мәсәлән, 1918 елның 26 мартында РСФСР Милләт эшләре халык комиссары И. Сталин, Эчке Россия мөселманнары эшләре буенча комиссар Мулланур Вахитов һәм комиссариатның хәрби эшләре буенча мөдире Йосыф Ибраһимов Бөтенроссия Мөселман Хәрби Шурасын, аның белән бәйле гарнизон һәм округ комитетларын һәм башка хәрби оешмаларны юк итү турындагы карарга кул куйганнар. Аларның барлык эшләре, документлары, милке, капиталлары урыннардагы мөселман совет комиссариатлары карамагына тапшырыла. Бу унайдан "Корылтай" газетасының 1918 елның 4 апрелендә мөхәррир Мәхмүд-Фуат Туктаров язган башмәкаләдә: "Руслар өчен милли әмәл максадларының харап булуының башы 26 октябрь булса, безнең өчен бу көн 26 март булды",—диелә.





1918 елның 21 апрелендә Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты рәисе Мулланур Вахитов Эчке Россия һәм Себер мөселман төрек-татарларының Милли Идарәсен, аның белән бәйле барлык губерна, өяз һәм район оешмаларын, аерым алганда, милли фондны юкка чыгару турындагы карарга кул куя. Аларның бөтен милке, капиталлары һәм документлары РСФСР Милләт эшләре Халык Комиссариаты хозурындагы Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты карамагына тапшырыла *(Мухарямов М. К. Октябрь и национальный вопрос в Татарии (октябрь 1917—июнь 1918).—К., 1958.—С. 158-160).* Бу унайдан Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхретдинов, Салихҗан Урманов һәм башка билгеле җәмәгать эшлеклеләре ВЦИК рәисе Я. М. Свердловка, Халык Комиссарлары Советы эшләре җитәкчесе В. Д. Бонч-Бруевичка "Милли Идарәне тарату мөнәсәбәте белән мөселманнарның протесты"н тапшыралар. Анда санап үтелгән милли оешмаларның таратылуы һәм аларның милекләрен тартып алу "мөселманнарның гомуми ризасызлыгын тудыра"

дип күрсәтелгән була *(Хайрутдинов Р. Г. На путях к советской автономии.—К., 1971.—С. 80).* Милли Идарәнең һәм аның структурасындагы берәмлекләрнең таратылуы унаеннан либераль-демократик матбугат сәхифәләрендә күп санлы, большевикларга карата тәнкыйтьле язмалар дөнья күрә. "Димәк, җинаятьнең иң бөеге эшләнде, дип яза "Алтай" газетасы үзенең 1918 ел 29 апрель санындагы "Милли Идарәнең таратылуы" исемле баш мәкаләдә... Бу татар тарихы күргән хыянәт вә җинаятьләрнең иң зурларыннан булуы белән бәрабәр милли вә мәдәни эшләргә иң дәһшәтле зарбә (зыян) төшерә торган бер җинаятьдер".

1918 елның апрель-май дәвамында Сталин һәм Вахитовлар кул куйган карарлар нигезендә Мәскәү һәм Бөтенруссия Милли Шуралары юк ителә. Региональ большевикларның актив катнашуы белән губерна һәм өязләрдәге демократик милли оешмалар да тар-мар ителә.




Совет комиссарларының мондый эшчәнлеге демократик җәмәгатьчелекнең һәм большевистик булмаган матбугатның ачыктан-ачык канәгатьсезлеген тудырган. Казандагы "Иттифак" газетасы 1918 елның 8 маенда дөнья күргән "Алтын токкабыз сынды" исемле зур күләмле мәкаләсендә шундый юлларны язган: "Үз эшләребезне эшләп ятканда өстебезгә бәла килде, милли оешмаларыбыз таратылды. Милләткә вә милли оешмаларыбызга һәм милләт юлындагы кешеләрнең башына килгән соңгы айлар эчендәге афәт һәм бәлаләрнең иң дәһшәтлесе, аның үз кешеләребез, үз адәмнәребез тарафыннан эшләнүе булды. Үз егетләребез үк күпләрне "контрреволюционерлар" дип яптырды, милли оешмаларыбызны "буржуаз" дип таратты, эш башында утырган үз большевикларыбыз, энәсеннән җебенә кадәр революция җимешләрен сүтте, җимерде. Чөнки большевиклар туздыру, җимерү, вату, сындыруның һәр төрлесен кыла беләләр. Бу аларның һөнәре... Фәкать күзләрен кан баскан большевиклар милләт һәм динне тәмам тамырларыннан корытты... Фаҗига шунда ки, моны эшләүчеләр үзләрен халык вәкилләре дип атап, бу эшләрне дә халык теләге вә халык файдасына дип эшли бирәләр". Шул ук матбугат басмасы 1918 ел 10 май санында: "Бу эшләрне башкарган кешеләр тиз көннәрдә милләт һәм тарих алдында зур җаваплылык кичерәчәкләр",—дип кисәтә.




Күпчелек татарча либерал-демократик газета битләрендә бигрәк тә көчле тәнкыйть сүзләренә РСФСР Милләт эшләре Халык Комиссариаты составындагы Үзәк мөселман (Татар-Башкорт) комиссариаты һәм Хәрби эшләр Халык Комиссариатының Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе Мулланур Вахитов дучар ителә. Аның шәхесе турында газеталарның тулы бер битен алып торган махсус мәкаләләр бастырыла. Аны "кызыл байракчы большевик", "татарларның баш комиссары", "хезмәт буенча өлкән җитәкчеләрнең ихтыярын үтәүче", "татар милли хәрәкәтен эзәрлекләрүче" дип бәялиләр. Мисал өчен "Алтай" газетасының 1918 ел 8 май санында бастырылган: "Мулланур Вахитов милли, мәдәни мохтариатыбызны хәл кылды, ләкин без теләгәнчә түгел, ә үзе һәм иптәшләре, рус, яһүди, вә грузин большевиклары теләгәнчә"—дигән сүзләрне китерергә була.

Үзәктәге һәм урыннардагы татар-башкорт совет комиссариатларының җитәкче хезмәткәрләре большевистик булмаган милли матбугатны эзәрлекләү һәм тар-мар итүдә бик актив катнашканнар. Бу хакта "Иттифак" газетасы 1918 елның 18 апрель санындагы "Үз большевикларыбыз" дип аталган мәкаләдә: "Милләтебезнең иң газиз газеталары туктатылды, иң мөхтәрәм мөхәррирләребез тотылды... Моны тик үз кешеләребез, үз адәмнәребез, үз большевикларыбыз кылды, милләтебезне шул хәлгә китерде",—дип язган. Рус телендә чыгып килгән "Казанское слово" газетасы, үзенең 1918 ел 4 июнь санында, либераль-демократик милли матбугатка карата совет комиссарлары үткәрә торган репрессив чараларны бәяләп: "мөселман большевиклары штрафлар яисә башка ярымчаралар белән генә чикләнүне һич тә кирәккә санамыйлар",—дип ассызыклаган.

Совет хакимияте урнашканнан соң беренче булып туктатылган татар вакытлы

матбугат басмасы—“Уфаның авыл көнкүреше журналы” дип аталган. Әлеге басма Уфа вилаять земствосы органы буларак, 1914 елның 28 апрелендә ике телдә барлыкка килгән. Рус телендәге варианты “Уфимский сельскохозяйственный листок” исемен йөрткән һәм аның җаваплы мөхәррирләре булып төрле елларда П. Коропачинский белән П. Толстой эшләгән. Дубликат рәвешендә чыгарылган татарча варианты исә Сәгыйть Рәмиев тарафыннан тәрҗемә ителгән. Басманың һәрбер саны тышлыгында авыл тормышын сурәтләгән рәсемнәр урнаштырылып килгән. Журнал нигездә икътисад, бигрәк тә, авыл хуҗалыгына кагылышлы мәсьәләләргә даими игътибар иткән, шулай ук самодержавиенең төшерелүе, Учредительное собраниегә сайлаулар кебек агымдагы зур сәяси вакыйгаларны да шактый киң яктырткан. Журналның татарчасында әдәби парчалар да басылгалаган. Аның 136 саны, ә соңгысы 1917 елның 1 декабрендә чыгарылган.

1917 елның 6 декабрендә чират икенче татар журналына житә—дини, әдәби, гыйльми һәм сәяси “Әд-дин вә әл-әдәб” дигән журнал яшәүдән туктый. 1906 елның 17 мартында Казанда басыла башлаган бу җәдитчел журналга мәсъүл мөхәррир Галимҗан Баруди (Галиев) җитәкчелек иткән. Ул күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, “Мөхәммәдия” мәдрәсәсен нигезләүче мөгаллим була, соңрак мөфти итеп сайлана. 1908 елның маенда патша хөкүмәте журналны чыгаруны тыя. Баруди кулга алына, панисламизмда гаепләнеп, төньякка—Вологда губернасына сөргенгә җибәрелә. Бернichә айдан соң ул чит илләргә чыгу рөхсәте ала, Ливия һәм Сүриядә яши. 1910 елда Казанга кайта һәм полициянең яшерен күзәтүе астында тормыш итә. 1913 ел башыннан әлеге журналны яңадан чыгаруны дәвам иттерә. Журнал битләрендә нигездә шәригать кануннарына аңлатмалар урнаштырыла, мөселман фәлсәфәсенең гомуми һәм аерым мәсьәләләре яктыртыла, шулай ук мәгарифкә, әхлакка, исламга нигезләнгән милли мәдәният мәсьәләләренә кагылышлы материалларга да беркадәр урын бирелә. Басманың җәмгысы 129 саны дөнья күрә.

1918 елның 8 гыйнварында Казанда 1913 елның 27 октябреннән бирле айга ике мәртәбә хатын-кызлар өчен махсус чыгып килгән әдәби, хокукый, икътисади, әхлакый, гыйльми, рәсемле “Сөембикә” журналының соңгы саны нәшер ителә. 115 саны чыгуы мәгълүм. Хатын-кыз яшәешенең барлык тармакларын, шул хисаптан, иҗтимагый, сәяси гаилә хәлләрен әтрафлы яктыртуны максат итеп куйган басма. Нашире һәм мөхәррире—Якуб Хәлили. Язышучылары Ф. Сөләймания, М. Мозаффария, Багбостан ханым М. Акчурина, Н. Думави, Ш. Әхмәдиев, Г. Гафуров-Чыгтай, Н. Исәнбәт һәм башкалар.

1918 елның 22 гыйнварында, Казанда 1917 елның 1 мартыннан бирле чыгарылып килгән “Балалар дөньясы” журналының соңгы, сигезенче саны дөнья күрә. Журнал “Өмет” басмаханәсендә, татар хатын-кызлары өчен беренче махсус журнал—“Сөембикә”не чыгаручы Якуб Хәлили мөхәррирлегендә нәшер ителә. Бу басмада Г. Баттал, С. Җәлал, С. Рәмиев, Ф. Бурнаш, М. Корбангалиев, М. Фәйзи, Ф. Бакиров, Н. Исәнбәт, Ш. Әхмәдиев, Г. Динмөхәммәтов һәм башкалар катнаша. Журнал татар балаларына әдәби һәм милли тәрбия бирүгә зур өлеш керткән.




Большевиклар тыйган татар телендәге иң беренче газета “Чыңгыз баласы” дип аталган. Өстәмә рәвештә аны “Казан мөселман хәрби комитеты хәбәрләре” дип тә исемләгәннәр. Ул “Милләт” матбагасында әлеге комитетның аңлату-берләштерү шөгъбәсе тарафыннан нәшер ителгән. Газетаның беренче саны редколлегия мөхәррирлегендә 1918 елның 1 гыйнварында, ә соңгы, өченче саны исә—19 гыйнварда дөнья күргән.

1918 елның 18 (31) гыйнварында, Оренбургтан дутовчы казаклар куып чыгарылган көнне, хакимият большевикларның Хәрби-революцион комитеты карамагына күчә. Шул комитет составында В. Н. Мискинов җитәкчелегендә матбугат эшләре буенча махсус комиссия төзелә. Әлеге комиссар шушы ук көнне шәһәрдә чыгып килгән большевистик булмаган газеталарны ябу турында әмер чыгара *(Ананьев В. Оренбургский военно-революционный комитет.—Оренбург, 1959.—С. 6)*. 1918 елның 20 гыйнварында, әйтелгән әмер нигезендә, Оренбургта 1917 елның октябреннән

бирле нәшер ителеп килгән мөселман хәрби комитеты рәсми басмасы "Безнең теләк" исемле атналык газета, яна хакимияткә битарафлык позициясендә торырга тырышкан булса да, чыгудан туктатыла. Ул "Вакыт" газетасы типографиясендә, аның кәгазендә һәм шрифтлары белән бастырылып килгән. Сәхи Гәйфи мөхәррирлегендәге бу басманың 12 саны дөнья күреп калган.




Бер атна да узмый, "Безнең теләк"нең язмышын 1906 елның 21 февраленнән башлап Оренбург шәһәрендә билгеле татар миллионерлары—алтын приискалар хуҗалары, агалы-энеле Мөхәммәдшакир һәм Мөхәммәдзакир (Дәрдмәнд) Рәмиевләр наширлегендәге, 2309 саны дөнья күргән "Вакыт" газетасы да кичерергә мәҗбүр ителә. 1917 елның ноябренә чаклы аның өзлексез мөхәррире булып Фатих Кәрими, ә шул елның 9 ноябреннән ябылганчыга кадәр билгеле татар язучысы һәм драматургы Ярулла Вәли эшли. Бу газетаның редакциясе составында чорының танылган журналистлары һәм әдипләре Ризаэтдин бине Фәхретдинев, аның улы Габдрахман Фәхретдинов, Борһан Шәрәф, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Кәбир Бәкер, Рәкыйб Рәкыйби, кырым шагыйре Госман Акчокраклылар эшләгәннәр. Газета битләрендә читтән торып Һади Атласи, Зариф Бәшири, Йосыф Акчура, Муса Ярулла (Бигиев), Әхмәт-Зәки Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Сәгыйдь, Һади Сәгъди, Газиз Гобәйдуллин, Хәйрулла Госмани һәм башка күренекле җәмәгать эшлеклеләре, әдипләр актив катнашканнар. Заманындагы татар газеталары арасында "Вакыт" иң алдынгысы була. Сәяси мәкаләләрдә сак һәм үлчәүле тонда яза, дини һәм милли мәсьәләләрдә үз артыннан ияргән милли матбугатка юнәлеш биреп бара. Уку-укыту эше, тел һәм әдәбият, мәдәният мәсьәләләренә киң урын бирә, милли театр, музыка сәнгатен җәелдерүгә теләктәшлек күрсәтә. Эчтәлеге, техникасы, мәкаләләренең теле һәм тематик киңлеге ягыннан иң дәрәҗәлесе була. 1918 елның гыйнвары ахырында, Оренбург шәһәреннән Дутов гаскәрләре чигенеп киткәннән соң, бер атна узгач, "Вакыт" газетасы чыгудан туктатыла. Шул ук вакытта татар, башкорт һәм Россиянең башка мөселман халыклары арасында шөһрәт казанган "Шура" журналы да туктатыла. Бу ике атналык, рәсемнәр белән бизәлгән әдәби, фәнни һәм тарихи журнал 1908 елның 20 гыйнварыннан ун ел буе өзлексез Оренбург шәһәрендә басылып килгән һәм аның барысы 240 саны чыккан. Журналның наширләре шул ук бертуган Мөхәммәдшакир һәм Мөхәммәдзакир Рәмиевлар, ә мөхәррире Ризаэддин бине Фәхретдинев. Соңгысына журнал ябылганнан соң, тормыш итү өчен матди мөмкинлекләр булмаганлыктан, Уфага Диния Нәзаратына казыйлык хезмәтенә күчәргә туры килә. Татар журналлары арасында "Шура" иң күренеклесе була. Милли басмалар сафында материалга иң бае, энциклопедик характердагы буларак, зур абруй казанып, киң тарала, күп укыла. Татар матбугатында хезмәт иткән каләм ияләренең барысы да диярлек бу журналда язышалар. Журналда даими рәвештә мәшһүр шәхесләр, зур вакыйгалар, гомуми иҗтимагый-сәяси тормыш, дини мәсьәләләр, тәрбия, сәламәтлек, тарихи язмалар, әдәби әсәрләр-шигырьләр, хикәяләр, табышмаклар, мәзәкләр, библиография һәм тәнкыйть, редакциягә мөрәҗәгатьләр, аларга бирелгән җаваплар урнаштырылып киленгән була.




Әйтелгән матбугат органнарының туктатылуы уңае белән, ул чакта Россиядә чыгуларын дәвам иткән татарча газеталарның барсында да диярлек махсус белдерү игълан ителгән. Әлеге белдерүдә, хәзерге татар телендәге сүзләргә күчереп әйткәндә: "Вакыт"ны алдыручыларга! 1918 ел 26 гыйнвары иртән сәгать унда Оренбург мөселман хәрби-революцион комитеты тарафыннан уникe ел милләт хезмәтендә дәвам итеп килгән "Вакыт" газетасының матбагасы, кәгазе конфисковать ителде вә газета туктатылды, вә банктагы ярты миллионнан артык торган акчасы югарыда күрсәтелгән комитетка күчкәнгә, "Вакыт" вә "Шура" алдыручыларга ул җаваплыдыр. Бу хәлнең барлыкка килүенә итәк астыннан һәм ачыктан-ачык хезмәт иткән кешеләргә татар тарихы, әлбәттә, тиешле бәясен бирер. Наширләр тарафыннан вәкил—Ярулла Вәли",—дип язылган була.

1918 елның 6 (19) февралендә совет органнары тарафыннан тартып алынган “Вакыт” газетасының матбагасын һәм кәгазен файдаланып, большевиклар үзләренең “Оренбург мөселман хәрби-инкыйлаби комитетының мөхбире” дигән газетасын чыгара башлыйлар. Тугыз саны чыкканнан соң, ул газета “Оренбург вилаяте мөселман эшләре комиссариаты мөхбире” исемен ала. Бу басмаларны чыгаруны Уфадан килгән, анда элегрәк нәшер ителгән социал-демократик юнәлештәге “Алга” газетасының мөхәррире А. Хәбиби һәм аның актив хезмәткәре Б. Нуриманов оештырганнар.


1918 елның 30 гыйнварында, алтынчы саны чыкканнан соң, Казан губерна земствосы органы “Крестьян тормышы” исемле газета совет органнары тарафыннан туктатылган. Ул рус телендә 24 гыйнвардан 1 февральгә кадәр нәшер ителгән “Крестьянская жизнь” газетасының күчермәсе булган. Аңа Казан губернасы земское собраниесенең вәкиле Владимир Вегер мөхәррирлек иткән.

1918 елның гыйнварында Хуканд шәһәрендә татар һәм үзбәк телләрендә 1917 елның сентябреннән башлап чыгып килгән “Ил байрагы” исемле газета дә, совет власте органнары боерыгы буенча ябылган. Аның нашире—“Гайрәт” ширкәте, ә мөхәррире—Булат Салиев булган. Әлеге басманың 1917 ел ахырында—унжиденче саны дөнья күргәнлеге һәм аның сәхифәләрендә Мөхәммәт Хәсән, М. Мәһбуди, Габдрахман Сәгъди, Зариф Бәшири, Рәшит Таһири, Ләлә Арслановаларның (соңрак—профессор) язышканнары мәгълүм.

1918 елның гыйнварында Вятка шәһәрендә, берничә саныннан соң, “Хәбәр йөртүче” дигән газета чыгудан тукталган. Ул 1915 елның февралендә “Сугыш хәбәрләре” исеме белән дөньяга килгән һәм 1917 елның декабренә кадәр нәшер ителеп, “Хәбәр йөртүче” дип атала башлаган. Аның барысы кырыкка якын саны чыккан. “Сугыш хәбәрләре” тарихтагы беренче керәшен газетасы, ягъни рус хәрефләре, кириллица белән бастырылган. Аны нигезләүче һәм редакторы, тарихтагы мари телендәге беренче “Война увер” (“Сугыш хәбәрләре”) һәм удмурт телендәге беренче “Войнаысь ивор” (“Сугыш хәбәрләре”) газеталарыныкы кебек үк, Павел Петрович Глезденев (1867—1923) булган. Бу шәхес Казанда духовная академия тәмамлап, 1907 елдан башлап Вяткада инородецларның миссионерчылык курсларын җитәкләгән, ә совет чорында исә Вяткадагы халык мәгарифе институтында укытучы һәм гыйльми секретарь булып хезмәт иткән. Әйтеп үтелгән өч милли газеталар, П. П. Глезденев үтенече буенча, Вятка губернаторы А. Г. Чернявский боерыгы белән, төбәктәге рус булмаган халыкны Беренче Бөтендөнья сугышы фронтларында бара торган хәрби хәрәкәтләр белән ана телендә таныштыру өчен чыгарылганнар.

1918 елның 9 февралендә татар вакытлы матбугаты басмалары арасында иң өлкәннәреннән берсе булган—1906 елның 31 декабреннән башлап Оренбургта басылып килгән, 555 саны дөнья күргән, консерватив юнәлештәге дини, фәнни, әдәби һәм сәяси “Дин вә мәгыйшәт” журналы яшәвеннән туктатыла. Типографиясе большевистик мөселман хәрби-революцион комитет тарафыннан конфискацияләнә һәм аның бер өлеше Чиләбе шәһәренә совет газетасы чыгару өчен озатыла. Журналның нашире Мөхәммәдвәли Хөсәенов, ә мөхәррирләре төрле елларда Заһидулла Хәйруллин, Фәезхан Даутов, Галәметдин Ислямовлар булган.

1918 елның 26 февралендә, 88 саныннан соң Казанда Мәркәзи Хәрби Шураның нашир әфкяре “Безнең тавыш” исемле газета яшәүдән туктатыла. Ул 1917 елның 29 маенда чыга башлаган һәм Россиядә татар телендә ул чорда нәшер ителүче хәрби газеталар арасында иң күп тиражлысы һәм күренеклесенә әверелгән. Бу хакта фронтлардан килгән күп санлы солдат хатлары сөйли. Вакыты-вакыты белән көнлек тиражы 8000 данәгә җиткәләгән. “Безнең тавыш” сәхифәләрендә дөнья күргән кайбер материаллар башка газеталарда дә күчереп бастырылган. Газета үзенең төп игътибарын мөселман-татарларның фронттагы һәм тылдагы әхвален, милли хәрби берләшмәләр төзүгә багышлый һәм милли үзбилгеләнү мәсьәләләрен яктыртуга юнәлткән. Аның мөхәррирләре һәм редколлегия әгъзалары булып төрле вакытта Габделгазиз Монасыйпов, Габдулла Сәйманов, Хәлил Әбелханов, Габдулла Мозаффаров, Гобәйдулла Дәүләтшин һәм Садрый Вәлидев (Җәлал) эшләгән.




1918 елның шул ук 26 февралендә, 16 саныннан соң, Казанда 1917 елның 19 ноябреннән бирле рус телендә чыгып килгән "Известия Всероссийского Мусульманского Военного Шуро" газетасы да туктатыла. Ул "Өмет" типографиясендә редакция комиссиясе мөхәррирлегендә чыгарылган.

Бу басмаларның эшчәнлеген бәяләп, Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты рәисенең урынбасары Галимҗан Ибраһимов 1918 елның 23 февралендә "Чулпан" газетасында басылган "Жинелделәр!" исемле мәкаләсендә: "Хәрби шура, аның ике газетасы совет властен сүгүдән башка нәрсә тапмадылар. Бу рәсми газеталарны укыганда Дутов, Каледин һәм Корнилов исе әллә каян аңкып тора иде",—дип яза. Бу уңайдан Казанда чыгып килгән "Корылтай" газетасының 1918 ел 4 апрель санында, аның мәсъул мөхәррире Мәхмүд-Фуад Туктаров имзасы белән басылган: "Инде ни булачак?" исемле баш мәкаләдән: "Совет комиссарлары татарлар арасында Корнилов, Каледин, Дутовларны эзләделәр һәм таптылар",—дигән сүзләрне күрсәтеп китәсе килә. Бәлки бу юллар Галимҗан Ибраһимов исеменә дә юнәлдерелгәндер.




1918 елның февраль аенда Кызылъяр (Петропавел) шәһәрендә "Яшьлек таны" исемле журналның ул елгы, ахыргы ике саны чыга. Аның оештыручылары һәм мөхәррирләре, соңрак чит илләргә китеп мәшһүр галимгә әверелгән профессор Рәшит Рәхмәти Арат белән танылган язучы, драматург Хөсәен Габдүш булган. Әлеге басма 1917 елда урта уку йортлары мөселман шәкертләренең "Берлек" дип аталган җәмгыяте тарафыннан 7 санда нәшер ителгән.

1918 елның март аенда татар телендәге биш газета һәм өч журнал ябыла. Мартта Уральск шәһәрендә 19 саныннан соң Урал вилаять мөселманнарының Милли Шурасы тарафыннан чыгарыла торган сәяси, иҗтимагый "Мөхбир" газетасы туктатыла. Ул 1917 елның 10 октябреннән башлап Габдессогуд Ишмөхәммәтов мөхәррирлегендә нәшер ителгән. 17 мартта, өч саны дөнья күргәннән соң, Петроградта Муса Ярулла (Бигиев) мөхәррирлегендә чыгып килгән әдәби, иҗтимагый, милли-сәяси газета "Әл-Минбәр" ("Трибуна") газетасы яшәүдән туктый. Әлеге басманың нашире "Әманәт" ширкәте булган. 27 мартта Бөтенроссия Мөселман хәрби шурасы органы "Идел-Урал өлкәсе" газетасының соңгы, икенче саны чыгып кала. Әлеге басма "Безнең тавыш" газетасының дәвамы буларак, Идел-Урал өлкәсен вөҗүдкә чыгару мөселман халык комиссарлыгы наширлегендә һәм Әфтахетдин Габидуллин мөхәррирлегендә 24 мартта дөнья күргән була.





1918 елның 28 мартында "Безнең юл" газетасының соңгы, 36 нчы саны чыга. Ул 1917 елның 21 сентябрендә "Ирек", "Солдат теләге...", "Авыл халкы" исемнәрендә Уфада чыгып килгән өч төрле оешма газеталарының берләшүе нәтиҗәсендә нәшер ителә башлаган. Аның 22 саны Г. Ибраһимов (баш мөхәррир), Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Әхмәров һәм Ш. Сүнчәләй составындагы редколлегия тарафыннан чыгарылган. Ул чакта "Безнең юл" революцион-демократик позициядә торган. Г. Ибраһимов Петроградка, Ф. Сәйфи-Казанлы Казанга киткәннән соң, Бу газета бер оешма—Уфа мөселман хәрби шурасы органы гына булып кала. Аның чираттагы, 1918 елның 29 гыйнварында дөнья күргән 23 саны Ф. Әхмәдиев, Г. Алпаров, Г. Әлмөхәммәдов, С. Хәсәнкаев, И. Кадыйри составындагы яңа редколлегия тарафыннан нәшер ителгән. Газетаның иң соңгы берничә саны, Идел-Урал штатын вөҗүдкә чыгару коллегиясенең Уфа бүлекчәсе органы буларак, бары тик бер генә мөхәррир—Г. Алпаров җитәкчелегендә бастырыла. 1918 елның 6 мартында Мәскәүдәге "Чулпан" газетасының 10 нчы санында Үзәк мөселман комиссариаты рәисенең урынбасары Г. Ибраһимов, "Безнең юл" газетасын Совет властенә каршы торуда гаепләп, каты орышулы мәкалә бастырган. Шуннан соң өч атна узгач, "Безнең юл" газетасы туктатыла.

1918 елның март аенда 1912 елның 15 декабреннән бирле Казанда "Милләт" һәм Харитонов басмаханәләрендә чыгарылып килгән, үзенең сыйфатлы полиграфик


эшләнүе белән аерылып торган, күренекле каләм осталарының иҗат трибунасына әверелгән һәм күп санлы укучыларның хөрмәтен яулаган, 123 саны дөнья күргән ике атналык нәфис-әдәби, гыйльми, иҗтимагый-сәяси һәм рәсемле "Ан" журналы яшәүдән туктаган. Ул "Гасыр" китап нәшрияты органы булган. Төрле елларда мөхәррирләр булып А. Хәсәни һәм Г. Ибраһимовлар эшләгән. Аның сәхифәләрендә Ф. Агиев, Ф. Әмирхан, Һ. Атласи, Ж. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, М. Гафури, Н. Думави, Г. Тукай, Г. Гафуров—Чыгтай, Ш. Камал һәм башкалар язышканнар.

Татар телендәге газета һәм журналларның күбесе 1918 елның апрель аенда ябылган. Бу хакыйкатьне соңрак Гаяз Исхакый болай дип билгеләп үтә: "1918 елның апрелендә, большевик хөкүмәтенең декреты белән бөтен Идел-Урал өлкәсендәге милли матбугат бетерелгән һәм барысының да матбагалары таланып алынган иде" *(Исхакый Гаяз. Элек сүз // Мирас. К., 1992.—N 2.—39 бит).*

4 апрельдә Казандагы татар газеталарының иң күренеклеләреннән берсе булган, Мөселман комитеты органы—"Корылтай"ны чыгару тыела. Әлеге газета 1917 елның 2 июлендә чыга башлаган һәм тиз арада Россия күләмендә танылган татар көндәлек матбугат басмасына әверелгән. Аның сәхифәләрендә бастырылган мәгълүматлардан еш кына Казанда һәм башка шәһәрләрдә нәшер ителгән татар газеталары да файдаланып килгән. "Корылтай" гомумсәяси мәсьәләләрдә үзәкчел гомумдемократик юнәлештә булган, милли бердәмлек идеясын алга сөргән. Аның һәр санында беренче сәхифә башында татар һәм рус телендә эре хәрефләр белән: "Яшәсен Кушма Халык Җөмһүрияте (Федеративная Демократическая Республика)!", "Яшәсен милли вә мәдәни мохтарият" (Культурно-национальная автономия!)!"—дигән лозунгшигарләр урнаштырылган. Газета Россиядә ул чорда ук социализм төзү мөмкинлеген танымаган. Бу хакта ул: "Большевиклар дигән бер партия куәт алып китте. Боларның максатлары бу көннән үк Россиядә социализмны кертү булганга, алар хуҗалар берлә эшчеләр арасындагы тартышны көчәйгәннән көчәйттеләр, кыздырдылар... Россиядә бу көннән үк социализм кертү дигән фикергә... бер гакыллы кеше дә, әлбәттә, кушыла алмый, шуның өчен большевиклар дигән халыкның максатлары барып чыкмаслыгы үзеннән үзе ачык мәгълүм",—дип язган. "Корылтай" газетасының мөхәррире билгеле сәясәтче һәм журналист Мәхмүд-Фуат Туктаров булган. Соңрак, аның эшчәнлеген бәяләп, Гаяз Исхакый: "ул большевик режимын катгыян танымады, алар берлә һичбер эшдә уртак эшләрне кабул итмәде, "Корылтай"да бик каты итдереп антибольшевистик пропагандасын алып барды"—дип язган *(Исхакый Гаяз. Солых һәйәте әгъзасы Фуад бек Туктар вафат // Татарстан.—1993.—N 4.—31 б.).*




1918 елның 4 апрелендә 52 саны чыкканнан соң Оренбургтагы көндәлек сәяси, иҗтимагый вә әдәби "Яңа вакыт" газетасы туктатыла. Аны атаклы татар миллионерлары—алтын приискалары хуҗалары бертуган Мөхәммәдшакир һәм Мөхәммәдзакир Рәмиевлар наширлегендәге "Вакыт" газетасында 1906 елдан бирле мөхәррир булып хезмәт иткән һәм аның җитәкчелеге белән килеп чыккан билгеле бер килешмәүчелек нәтиҗәсендә редакцияне ташлап киткән күренекле журналист Фатих Кәрими 1917 елның 1 ноябрендә нигезләнгән була. Бу басманы "бәйсез мөселманнар нашир әфкяре" дип атаганнар. Газетаның наширләре—З. Дәминев һәм И. Галәветдинов. 1918 елның июлендә ак гаскәрләр Оренбургка кергәннән соң "Яңа вакыт" газетасы янадан чыга башлый. Газетаның монарчы сакланган 105 саны 1918 елның 3 октябрендә чыгарылган.




1918 елның апрель ае башында атна саен диярлек Сембер шәһәрендә чыгарылып килгән әдәби, сәяси һәм иҗтимагый милли газета "Җөмһүрият" туктарга мәҗбүр ителә. Сембер вилаять мөселманнарының милли шурасы нашир әфкяре буларак, ул 1917 елның 14 сентябрендә пәйда булган. Мөхәррирләре төрле вакытта—Ибраһим Биккулов, Нури Госманов һәм Габделрәүф Шәһидуллин. "Җөмһүрият" газетасы ябылу белән үк, аның ахыргы мөхәррире Габделрәүф Шәһиди 1918 елның 15 апрелендә "Авыл" дип аталган берегеп эшләү


(кооперация) һәм авыл хуҗалыгы журналын чыгаруга керешә. Тик ул басманың гомере бик кыска була: май аенда икенче саны чыккач ук туктатыла.

1918 елның 15 апрелендә Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты рәисе Мулланур Вахитов һәм матбугат эшләре буенча комиссар Мөхәммәтхади Кильдебәков шундый документка кул куйганнар: "Эчке Россия мөселман эшләре буенча Комиссариатның 12 апрелендәге һәм Милләтләр эшләре буенча Халык комиссарының 13 апрелендәге карары нигезендә Мәскәүдә чыгып килгән "Ил" газетасы, контрреволюцион юнәлеше һәм Татар-Башкорт җөмһүриятенә провокацион мөнәсәбәте өчен ябыла. Бу карарны үтәү Комиссариат әгъзасы Алеевка йөкләнә *(Политика Советской власти по национальным делам за три года. 1917.—ноябрь 1920.—М., 1920. С. 80-81).* Гаяз Исхакый тарафыннан нигезләнгән "Ил" газетасы 1913 елның 22 октябрендә Петербургта чыга башлаган. 1914 елның ноябреннән 1915 елның март ахырына кадәр Мәскәүдә басыла һәм патша хакимиятләре боерыгы белән ябыла. 1917 елның 23 мартында "Ил" газетасы янадан чыга башлый. Аның 1918 ел 16 апрелендә соңгы 31 (134) саны 15 данәдә генә дөнья күрә: совет органнары аның күбәйтелеп басылуын тыялар. Ул сан Габдулла Тукайның үлүенә 5 ел тулуга багышланган була. Газета мөхәррире Г. Исхакый, үч алудан шикләнеп, Мәскәүдән китәргә мәҗбүр була *(Исхакый Гаяз. Гәзитчелек эшендә 25 ел // Әдәби җомга. 1992, 24 апрель.).* "Ил" газетасының конфискация ителгән басмаханәсен һәм кәгазен большевиклар үзләренең татар телендә "Кызыл Армия" дигән хәрби һәм төрек телендә "Ени дөнья" исемле коммунистик газеталарны чыгару өчен файдаланалар.

Эчке Россия һәм Себер мөселман төрек-татарларының Милли Идарәсе органы буларак 1917 ел 10 октябрендә чыга башлаган "Мохтарият" журналы, 1918 елның 14 апрелендә, тугызынчы саныннан соң, Уфа совет хакимиятләре боерыгы белән тыела. Аның сәхифәләрендә әйтелгән гомуммилли оешманың эшчәнлеге, Милли Мәҗлеснең беренче җыелышы турындагы мәгълүматлар һәм карарлары бастырылган. Журналның мөхәррире-сәркәтибе Мөбәрәкшә Хәнәфи булган.

Шул елның 17 апрелендә Үзәк-Татар-Башкорт комиссариаты исеменнән Бәхтигәрәй Шәфиев, Мәскәүдән Петроградка барып, Милли шураның андагы бүлеген һәм "Шималь ягы" исемле газетаны яптырган. "Берләшүдә—көч!" шигаре астында 1918 елның февраль ае ахырында Милли идарә әгъзасы Кәрим Сәгыйдь наширлегендә һәм мөхәррирлегендә "Әманәт" ширкәте басмаханәсендә дөньяга килгән "Шималь ягы" газетасының соңгы сигезенче саны тулысы белән Габдулла Тукай истәлегенә багышланган була.

Уфа вилаять Советы каршындагы мөселман комиссариаты, "пролетар революциясенә каршы коткы тарату"да гаепләп, 1913 елның 12 октябреннән чыгып килгән "Тормыш" газетасын, 1918 елның 25 апрелендә, 832 саныннан соң бастырудан туктата. Аның басмаханәсе һәм барлык мал-мөлкәте конфискацияләнә. "Тормыш"ның башлангычы—"Сибирия" дигән газета 1912 елның 18 февралендә Томск шәһәрендә дөньяга килгән һәм 1913 елның көзенә таба Уфага күчерелгән. "Тормыш"ның беренче нашире һәм мөхәррире, соңгарак жандарм идарәсенең яшерен хезмәткәре икәнлеге фаш ителгән, Мөхәммәтвәгыйз Нәүрүзов булган. Тиздән газета Уфаның танылган бае Гыйбадулла Госманов наширлегенә күчкән, ә мөхәрриятне Закир Кадыйри җитәкли башлаган. "Тормыш" еш, кайчак атнасына алтышар тапкыр чыга торган, эчтәлекле һәм укый торган татар җәмәгатьчелегенең абруен казанган басмага әверелгән. 1918 ел башында Милли Идарәгә сайланган З. Кадыйри газетаны калдырган һәм мөхәррирлек вазыйфалары Гыймадетелислам (Гумдә) Хәбиревкә күчкән. "Тормыш" газетасы Россиянең төрле шәһәрләрендә үзенең махсус корреспондентларын тоткан. Аның актив авторлары арасында Шакир Якубов, Нурмөхәммәт Бохараев, Нурулла Кадыйров, Вали Хангилдин, Габдулла Шөнаси һәм башкалар булган.




1918 елның 30 апрелендә Сәмәрканд шәһәрендә 1917 елның 16 апреленнән бирле татар һәм үзбәк телләрендә нәшер ителеп килгән зур күләмле, күп тиражлы, һәр саны дүртәр биттән торган иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм әдәби "Хөррият" газетасы, 87 саны дөнья күргәч, совет органнары тарафыннан

туктатыла. Аның нашире "Заравшан" ширкәте, аннары Мөхәммәд Урумбаев, мөхәррирләре Кабирша Мансуров, Гаптерәүф Фитрят һәм Хажри Шакруллаевлар булган. Газета Б. А. Газаров типографиясендә чыгарылган. "Хөррият" Казандагы "Корылтай" һәм "Безнең тавыш" газеталары белән тыгыз элемтәдә торган һәм үз сәхифәләрендә әлеге басмалардан татар милли хәрәкәтенә кагылышлы материалларны күчереп бастырып килгән.

1918 елның апрелендә, 5 саны пәйда булгач, Верный (Алма-Ата) шәһәрендә, 1917 елның 19 декабреннән башлап нәшер ителеп килгән әдәби-нәфис, рәсемле сатирик "Садак" журналы чыгудан туктаган. Ул литографик ысул белән танылган татар язучысы, тәрҗемәчесе, журналист Зариф Бәшири мөхәррирлегендә бастырылган. Басманың нашире—"Садак" җәмгыяте.

Большевикларның матбугат ирегең кысуы, эзәрлекләве аннан соң да дәвам итә. 1918 елның 7 маенда, Әстерхан вилаять Советы хозурындагы мөселман комиссариатының гадәттән тыш утырышы, аның рәисе Касыйм Туйбактинның хәзерге хәл турындагы нотыгын тыңлаганнан соң: "кичектерүсез мөселман милли идарәсен, мөселман дружинасын таратырга, "Сарай" газетасын ябарга, "Нәшрият" басмаханәсен тартып алырга"—дигән карар кабул итә *(Борьба за власть Советов в Астраханском крае. (1917—1920 г.г.) // Документы и материалы. Часть первая.— Астрахань, 1958.—С. 260)*. "Сарай" газетасының соңгы, арестовать ителгән саны: "юнәлеше үткәрелә торган үзгәрешләргә туры килми",—дигән дәлил белән таратылудан тыела. Әлеге басма, Әстерхан губернасының Милли шурасы органы буларак, 1917 елның 8 ноябреннән бирле нәшер ителгән. Башка шәһәрләрдә даими корреспондентлары житәрлек булмавы сәбәпле, күп кенә яна мәгълүматларны ул "Ил", "Корылтай", "Яңа вакыт", "Кояш", "Тормыш" һәм башка татар телендәге газеталардан җыйнап бастырып килгән. "Сарай" газетасы Россиянең үзбилгеләнгән дәүләтләрне берләштерүче демократик җөмһүрият булуын яклаган. Аның баш мөхәррире танылган язучы, педагог, әдәбият тәнкыйтьчесе Нәҗип Гасрый, ә нашире—Фатих Шаммасов (Ф. Шамси).




1918 елның 1 маендагы өченче саны дөнья күргәч, Әстерханда хатын-кызлар өчен 1917 елның 15 октябреннән бирле чыгарылып килгән махсус әдәби, иҗтимагый, фәнни тәдриси, ягъни фәнни дәрес бирүче, дини һәм милли "Азат ханым" журналы, совет органнары боерыгы буенча туктатыла. Ул, "Сарай" газетасы кебек үк, "Нәшрият" типографиясендә бастырылган. Шигаре: "Яшәсен хөр Россиянең азат мөслимә ханымнары! Россия мөслимәләренең бөтен хокуклары ирләр белән бертигез булучылыгы вөҗүдкә чыгарылсын!". Хатын-кызларга аң-белем бирү, аларның иҗтимагый-сәяси тормышта актив катнашуына ирешү һәм нигезле хокукларын, шул хисаптан, дин өлкәсендә дә, яклау мәсьәләләрен яктыртып килә. Журналның нашире һәм мөхәррире Гыйсмәтулла Мөслимов, бизәлеш хезмәткәре—Шәриф Саттаров, язышучылары: Г. Терешкавия, М. Крымская, Г. Байчурин һәм башкалар.

Большевистик булмаган вакытлы милли матбугатны ахырынача тар-мар итүне тизләтүгә Үзәк Татар-Башкорт комиссариатының үзенең урыннардагы бүлекләренә 1918 ел май ае ахырында җибәргән рәсми күрсәтмәсе хәлиткеч этәргеч булган. Анда: "үз шәһәрләрендә чыга торган большевистик булмаган матбугат органнарына житәрлек игътибар итмиләр. Мәсәлән, Казандагы "Алтай", "Йолдыз", "Кояш", "Иттифак" газеталары "Милли Идарәне тарату мөнәсәбәте белән мөселманнарның протест"ын һәм большевикларның бу эшен гаепләүче башка язмаларны да бастырганнар",—дип әйтелгән. Үзәк комиссариат үзенең төбәкләрдәге татар-башкорт комиссариатларыннан һәм бүлекләреннән киләчәктә тәнкыйть язмалары бастырган газеталарга карата, аларны чыгудан туктатуга кадәр булган, ин каты чараларны куллануны таләп иткән *(Чулпан.—1918.—1 июнь)*.




Үзәк Татар-Башкорт комиссариатының директив күрсәтмәләрен тормышка ашыру нәтиҗәсендә, 1918 елның июнь-август айларында большевистик булмаган

татар вакытлы матбугатын тар-мар итү тулысынча диярлек тәмамланган.

1918 елның 7 июнендә Казан совет хакимиятләре шул ук елның 31 гыйнварыннан бирле "Өмет" типографиясендә нәшер ителеп килгән "Иттифак" газетасын, 14 саны чыкканнан соң, яптырганнар. Ул Бөтенроссия исламият җәмгыяте (дини галимнәр) нашир әфкяре булган. Газетага И. Габидов, С. Иманкулов һәм К. Салихов муллалар составындагы редколлегия мөхәррирлек иткән. Нигездә әлеге басманың оештыручысы һәм әйдәп баручысы Исмәгыйль Габидов (Габиди) булган. 1913—1917 елларда И. Габиди Казандагы иң зур мәчетнең имам-хатибы вазыйфаларын үтәгән. 1917 елда мөфти Галимҗан Баруди, Габделбари Баттал һәм Борһан Хәбиб белән бергә Ташкентта татар һәм үзбәк телләрендәге "Шураи ислам" газетасын нигезләгән шәхес була. "Иттифак" күбрәк төрле дини оешмаларның эшчәнлеген яктыртып тора, иҗтимагый-сәяси вакыйгалардан да читтә тормый. Аерым алганда, газета Милли Мәҗлеснең Идел-Урал штатын булдыру турында карарын хуплап яза, ә совет органнарының Милли Идарәне һәм аның арыннардагы оешмаларын таратуын кискен тәнкыйтьли. Газета сәхифәләрендә шулай ук әдәби парчалар, шигырьләр дә күренгәли.




1918 елның 10 июнендә совет хакимиятләре Казан шәһәрендә чыгып килгән "Игенче" исемле тагын бер татар газетасын тыйганнар. Бу басма 1917 елның 14 августында губерна земствосы нашир әфкяре буларак дөньяга килгән, ә соңгарак—Казан губернасы крестьяннары депутатлары советының мөселман фракциясе газетасына әверелгән. Аның баштагы мөхәррирләре земская управа әгъзалары Мулланур Вахитов һәм Хәяледдин Сәйфетдинов булган. 1918 елның 2 гыйнварында Учредительное Собрание әгъзасы буларак, Петроградка китү сәбәпле, М. Вахитов бу газетаны калдыра, яңа мөхәррир итеп Ш. Габиди (Чыршы) билгеләнә. Мулланур Вахитов эшләгән дәвердә "Игенче" газетасы революцион-демократик позициядә тора, ә аннан соң, редакциягә яңа җитәкчеләр килгәч, аның сәяси юнәлеше шактый үзгәрә. Аерым алганда, газета большевикларның Милли Идарәне таратуын хупламый. "Игенче"нең 1918 ел 29 апрелендә чыккан 42 нче санында, югарыда күрсәтелгән мөселман фракция имзасы белән, "Печән базары вакыйгасы" исемле мәкалә урнаштырыла һәм анда Казан Советының мөселман комиссариаты адресына тәнкыйть сүзләре әйтелгән була. Шуның өчен газетаның бу саннарын комиссариат арестовать итәргә теләгән, тик фракция почтасы моңа каршы килгән. "Игенче" газетасы эшен тикшерү трибуналга тапшырылган *(Алтай.—1918.—6 май)*. Әлеге комиссариатның рәсми органы—большевистик рухтагы "Эш" газетасы 1918 ел 24 маенда дөнья күргән санында: "Әгәр дә "Алтай", "Кояш" һәм "Йолдыз"ның язучы аламалары чын мәгънәсендә ерткыч бүреләр булсалар, "Игенче"нең язучы кисәкләре исә сарык тиресенә бөркәнгән бүреләр",—дип язган һәм "Игенче" газетасының ябылуын таләп иткән. Әлеге басманың язмышы Уфадагы "Безнең юл" газетасы язмышына охшаш. Үзәк мөселман комиссариаты нашир әфкяре "Чулпан" 1918 елның 9 августында чыккан санында "Игенче" һәм "Безнең юл" газеталары Совет властенә яла якканнары өчен ябылдылар дип язган *(Нуруллина Р. М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917—1925 гг.).—К., 1978.—С. 42)*. Ниндидер сәбәпләр аркасында, хәзергәчә китапханәләрдә "Игенче" газетасының аз гына саннары сакланып калган.

1918 елның 21 июнендә чират иң өлкән Казан газетасы—"Йолдыз"га да килеп җитә. 1906 елның 15 гыйнварыннан өзлексез чыгып килгән бу газета озак еллар дәвамында татар вакытлы матбугатында үзенең таратылу күләме белән икенче урынны алып килгән һәм укучыларының зур ихтирамын казанган. Россиянең матбугат эшләре буенча Баш идарәсенең бер хисабында әлеге басма турында шундый сүзләр әйтелгән: "Газетаның үзенчәлеге шунда ки, "Йолдыз" укучыларына тәкъдим ителә торган материалны, массаларга мөмкин кадәрле аңлаешлы тел белән яктыртырга тырыша. Бу, әлбәттә, әлеге басманың шөһрәтен арттыра. Игътибарны шунсы да җәлеп итә: "Йолдыз" татар сөйләм теленә кергән күпчелек рус сүзләрен гел кулланмый диярлек, ә аларны чиста татар сүзләре, яисә неологизмнар, яисә

образлы әйтемнәр белән алыштыра". Газетаның сәяси рухын, материалларын тасвирлау үзенчәлекләрен бәяләп, күзәтүче шундый сыйфатларын билгеләп үтә: "Аның әдәби дошманнары мәсхәрәләп килгән икеле-микеле һәм аңлаешсыз әйтемнәре, еш кына кулланыла торган "янәсе" һәм читләтеп әйтелгән сүзләре, бу газетаны хәзергәчә аерып торалар. Әмма, хәзерге минут таләпләренә "җайлашучанлык" сәләтенә карамастан, газета үзенең милләтчел төсен тулысынча кагылгысызлыкта саклады".

"Йолдыз" газетасы уң һәм сул көчләр тарафыннан даими тәнкыйтькә дучар ителгән. Тик ул һәрвакыт үзәкчелек юнәлешен үткәргән. Шушы сәясәт, каршылыкларны читләтеп үтү тактикасы аңа әзерлекләнүләрдән сакланып калырга мөмкинлек биргән: ул революциягә кадәр чорда һич тә штраф һәм башка җәзаларга тартылмаган бердәнбер татар газетасы булган. Аның нашире-мөхәррире күренекле журналист Әхмәтһади Максуди. Газета редакциядә күп еллар буенча мәшһүр татар драматургы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Галиәсгәр Камал хезмәт иткән. Ул еш кына мәсъүл мөхәррир вазыйфаларын да башкарып килгән. 1917 елның февраленә кадәр газета редакциясендә Г. Баттал, Ш. Әхмәдиев, Г. Монасыйпов, И. Биккуловлар да эшләгәнлеге билгеле. "Йолдыз"ның 1900 саны дөнья күргән.

"Йолдыз" ябылып өч көн үткәч, 1918 елның 24 июнендә, милли пресса арасында киң билгеле көндәлек "Кояш" газетасы да яшәүдән туктатыла. Ул Казанда 1912 елның 10 декабрендә барлыкка килә һәм барысы 1245 санда дөнья күрә. Газетаның баштагы нашире китап сатучы Кәримовлар, ә 1915 елның 9 апреленнән бөтен хокуклар аны нигезләүче һәм алмашсыз мөхәррире Зәкәрия Садретдиновка күчә. "Кояш" газетасының аның беренче саннарыннан алып ахыргысына кадәр танылган татар язучысы Фатих Әмирхан эшләгән. Редакциядә шулай ук Гыймад Нугайбәк, Заһид Нуркин һәм Ибраһим Биккулов та хезмәт иткән.

Әлеге басманың эшчәнлеген бәяләп, Казанның матбугат эшләре буенча Вакытлы комитет әгъзасы Н. И. Ашмарин үзенең хисап-күзәтүләрендә шундый юлларны язган: "Кояш" Казанда татар телендә һәр көн саен чыга торган, бәйрәмнәрдән соң көннәрдән тыш, бердәнбер газета булып тора һәм үз хисабына Россия Телеграф Агентство телеграммаларын алдырып килә". "Газетада, үзләренең әдәби эшчәнлеге белән танылган татар яшьләренең кайбер вәкилләре катнаша, аннан тыш Россиянең төрле төбәкләрендә, хәтта чит илләрдә дә яхшы хәбәрдар корреспондентларын тота. Шуна күрә "Кояш" бик эчтәлекле һәм бу мөнәсәбәттә Казан басмалары арасында беренче урынны тота... башка татар газеталары кебек үк "Кояш" газетасы татарча-милләтчел, ләкин нинди дер сәяси партия органы булып хезмәт итми".

"Кояш" 1917—1918 ел башында Мәскәүдә, Казанда, Уфада булып узган төрле Бөтенроссия мөселман съездларының барышын, кабул ителгән карарларын, аларны гамәли үтәү буенча башкарылган чараларны, большевикларның демократик татар милли хәрәкәтен җимерүен киң күләмдә һәм эчтәлекле яктырткан газеталарның берсе. Бу мөнәсәбәттән ул киләчәк буын галимнәренең дә файдалы фәнни чыганагы булып хезмәт итә ала.

1918 елның июнендә Казандагы 1910 елның 15 мартында чыга башлаган сатирик-юмористик һәм рәсемле "Ялт-йолт" журналы туктатыла. 1916 елның ноябреннән, кушма 120-122 саны дөнья күргәч, 1918 елның июненә кадәр, ел ярым дәвамында, әлегә ачыкланмаган сәбәпләр аркасында, ул нәшер ителми. Журналның нашире—"Юл" көтепханәсе, рәсми мөхәррире—Әхмәт Урманчиев. Бу басма сәхифәләрендә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ф. Сәйфи Казанлы, Н. Думави, Х. Кильдебәк һәм башкалар язышканнар. "Ялт-йолт", үзенең озак вакыт яшәве, күп язучылар катнашуы һәм эчтәлеге буенча, татар телендәге сатирик-көлке журналлар арасында әйдәп баручылардан булган. Совет чорында чыккан соңгы 123 санында яна хакимиятнең эшчәнлеген, аерым алганда, большевистик булмаган матбугатны эзәрлекләвен тәнкыйтьләүче материаллар һәм сатирик иллюстрацияләр урнаштырылган.

1918 елның 2 августында Ташкент шәһәрендә литографик ысул белән чыгарылып килгән әдәби, сәяси, сатирик, юмористик рәсемле "Чаян" журналы, антибольшевистик рухта булганы өчен, совет органнары тарафыннан туктатыла.

Ул 1917 елның 15 июлендә дөньяга килгән. Нашире—татар сәүдәгәре Гайнулла Шәһидуллин, сонрак—"Чаян" ширкәте, төрле вакыттагы мөхәррирләре—Хәләф Түләкев, Ибраһим Таһиров.

1918 елда атналык милли "Оренбург мөхбире" исемле газетаның да чыгудан тукталуы билгеле. Тик аның кайсы айда, числода һәм күпме санда нәшер ителгәнлеге әлегә кадәр ачыкланмаган. Бу басма 1917 елның июлендә Оренбург мөселман бюросы наширлегендә пәйда булган. И. Рәмиев бәяләвенчә, бастырылган материалларның күбрәген рәсми хәбәрләр, төрле оешмалар тарафыннан чыгарылган карарлар тәшкил иткән. "Информацион листок" рәвешендәрәк битараф юлдан барган дияргә була. Үзлегеннән мөстәкыйль фикер һәм караш әйтергә бик ашыкмаган.

Шулай итеп, совет дәүләт органнары 1918 елның җәе ахырына кадәр татар телендәгә 40 лап газета-журналларның күпчелеген административ-боерык, ә бер өлешен исә акча, кәгазь матбага һәм башка кирәкле әйберләр белән тәэмин итүдә кыенлыклар тудыру юлларын кулланып, чыгудан туктатырга мәҗбүр иткәннәр. Бу сан 1917 елгы Октябрь революциясе алдында һәм аннан соңгы беренче атналарда барлыкка килгән татар вакытлы матбугат басмаларының күпчелеген тәшкил иткәнлеген күрсәтә.

Пролетариат диктатурасы органнарының большевистик булмаган прессаны көчләп юк итүе басма сүз һәм төрлечә фикерләү иреген бозган һәм шуна күрә демократик җәмәгатьчелекнең урынлы ризасызлыгын тудырган. Мәсәлән, Мәскәүдәге "Ил" газетасы тукталуы унае белән Казанда чыга торган "Алтай" газетасы үзенең 1918 ел 22 апрель санында куштырнак эченә алынган "Халык дошманы" дигән редакцион мәкалә бастырган. Анда "Ил", газетасының тукталуы турында хәбәр алынганын белдергәннән соң, түбәндәге юллар язылган:

"Димәк, "Ил"не яптылар.

Кем япкан?

Әлбәттә, мөселман комиссариаты япкандыр.

Татар-башкорт җөмһүрияте төзүче, татар милләтен бер милләт иттереп кенә түгел, хәтта татарга мәмләкәт ясап бирергә азапланып, тырышып йөрүче яшь йөрәкле милли егетләребез япкандыр. "Яшь йөрәкләр"не язган мөхәрриребез Галимҗан әфәнде Ибраһимов һәм аның яраннары япкандыр. *(Бу өземтәдән, "Ил" газетасын ябу турында М. Вахитов һәм М. Кильдебәков кул куйган рәсми карарның "Алтай" редакциясенә килеп җитмәгәнлеге күренә.—Т. Н.)*

"Ил", рус самодержавиесенең ин кара көннәрендә, татар матбугаты рус золымына каршы бер сүз дә әйтергә җөрьәт итә алмаган бер заманнарда, шул самодержавие берлә тартышып, халкыбызны бүгенге революция көннәренә хәзерләп килүче, бердәнбер татар газетасы иде.

Бүгенге "искиткеч халык дусты" булып киткән, иң сул революционер булып йөри торган яшь йөрәкле большевикларыбызның халык файдасына бер кәлимә булсын сүз әйтергә калтырап торган, полицейскийны күрсә, урамның икенче ягына кача торган бер заманнарда, "Ил" бер ялгызы революционер иде.

Хәзерге иң сул революционерларыбыз бәлки ул вакытларда "Ил"не кулына алганда: городовой күренмиме икән?—дип як-ягына карана торган булгандыр.

Менә шул "Ил" бүген инде контрреволюционер булып танылды. Шуның өчен ябылды. Аны Николай хөкүмәте дә ике мәртәбә япкан иде. Ул вакытта да: ул халыкны котыртучы, аздыручы, халык дошманы дип танылган иде.

"Ил"нең мөхәррире Гаяз әфәнде Исхакый бүген контрреволюционер булып танылды. Ул да халык дошманы булып китте. Гаяз әфәнде үзенең әдиплек хезмәтеннән башка, татар әдәбиятының атасы булып танылуыннан башка, 15 елдан бирле революционер булып йөри һәм шул юлда никадәр шәхси эзәрлекләүләр, мәшәкатьләр чикте, полицейскийларның йодрыкларын да татыды, төрмәсендә дә булды. Себерне дә күреп кайтты. *(Бу очракта Г. Исхакыйның төньяк сөргеннәрендә булып кайтуы искә алына.—Т. Н.)* Безнең хәзерге иң сул революционерларыбыз Николай хөкүмәте каршында һич "былчыралмаган" садыйк шәхесләр булып танылган бер заманнарда, Гаяз әфәнде иң куркынычлы бер революционер булып таныла иде. Ул төрмәдән чыккач, Себердән кайткан вакытларында да үзе теләгән

жирдә иркенләп тора алмый иде. Аны исправниклар, губернаторлар үз шәһәрләреннән куалар иде.

Гаяз социалист иде, Гаяз революционер иде. Гаяз милләтче иде. Пантюркист иде, панисламист иде. Бу "куркынычлы" һәммәсен бергә җыйган, һәрберсеннән дә "куркынычлы" тагын бер сүз бар иде: Гаяз танчы иде.

Бүген инде танчы контрреволюционерлар булып китте. Халык дошманы итеп игълан кылынды.

Ни өчен?

Гаязның гаебе нидә?

Нигә ул кинәттән генә үзгәреп китте? Безнеңчә, Гаяз әфәнденең үзгәргәне юк, ул һаман да революционер. Аның канында, яратылышында революционерлык рухы бар. Ләкин ул большевик түгел. Россиядә, хосуси үземезнең татарга бүгеннән социализм кертүнең мөмкинлегенә ышанмый. Гаязның бөтен гаебе шунда.

Бу ләгънәтне бирүчеләр кемнәр?

Бусын инде тарих тикшерер. Ул җавабын бирер. Кемнең чын контрреволюционер, кемнең чын халык дошманы икәнен ачык итеп танытыр.

Әмма хәзергә әле Гаяз әфәнде контрреволюционер—халык дошманы. "Ил" дә халык дошманы икән. Аны да хәзергә укымыйча торырга кушалар.

Нишләмәк кирәк, укымабыз шул. Аның урнына "Чулпан"ны *(Үзәк Татар-Башкорт комиссариатының нашир эфкяре, беренче татар совет газетасы.—Т. Н. )* укырмыз, большевик булырмыз" *(Алтай.—1918.—22 апрель).*

1918 елның июнь ае башында "Казанское слово" газетасы "Большевистик булмаган мөселман матбугатын эзәрлекләү" ("Репрессия на мусульманскую небольшевистскую печать") дигән мәкалә бастырган. Анда мондый юллар бар: "Хәзерге вакытта Россиядә большевистик булмаган бер мөселман газетасы да калмады диярлек. Оренбургта басмаханәсе, кәгазе һәм бөтен капиталы конфискацияләнеп, иң популяр һәм иң карт "Вакыт" газетасы ябылды. Уфада, Әстерханда, Мәскәүдә, Петроградта, Казанда һәм башка шәһәрләрдә дә газеталар ябылдылар".

Әмма большевистик булмаган татар вакытлы матбугаты яшәвеннән туктамый. 1917 елның октябреннән соң үткән чорда Россиядә һәм чит илләрдә аның шактый киң челтәре дөнья күрә.

Ватандашлар сугышы вакытында, 1918—1919 елларда Урта Идел, Урал һәм Себернең вакытлыча ак гаскәрләр булган төбәкләрендә татар телендә большевикларга каршы булган 20 газета чыга: Казанда—"Корылтай"; Самарада—"Безнең фикер", "Халык"; Уфада—"Уфа хәбәрләре", "Яңа хәят", "Ак Идел", "Ил теле", "Ватан"; Бәләбәйдә—"Берек"; Чиләбедә—"Башкорт"; Оренбургта—"Яңа вакыт", "Башкорт тавышы", "Башкортстан хөкүмәтенең теле", "Гәләбәси"; Кызылъярда—"Юл", "Маяк"; Омскида—"Хакыйкать. Наша газета", "Каһарман башкорт"; Семипалатта—"Халык сүзе" һәм Томскида "Том сүзе". Шул ук вакытта меңләгән данәдә басмаөндәмәләр таратыла. Ватандашлар сугышы чорында чыккан большевистик булмаган матбугат совет хакимиятенең, асылда, тоталитар булуы, кызыл террор, крестьяннарның икмәген тартып алу, көч кулланып Кызыл Армиягә мобилизацияләү һәм аның сафларыннан күпләп качу, барлык кешене диярлек мәҗбүр итеп хезмәткә тарту турында даими язып торган. Тик ул шәһәрләргә Кызыл Армия частьләре кергәч, бу газеталар чыгудан туктатылганнар.

1905—1945 елларда һәм Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң күп кенә чит илләрдә татар мөһаҗирләре матбугаты үсеш ала. Аны 1917 елга кадәр Россиядән чит мәмләкәтләргә күчеп киткән һәм аннан соң большевистик режимны кабул итә алмыйча, туган җирләрен калдырып китәргә мәҗбүр булган татар зыялылары, Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышлары вакытында әсирлеккә төшкән хәрбиләр оештырганнар.

Әлегәчә табылган чыганаклардан күренгәнчә, 1905 елдан бүгенгә кадәр чит илләрдә бу чорның төрле елларында типографик һәм башка ысуллар белән татар телендә 66 газета һәм журнал чыгарылуы мәгълүм. Аларның иң күбесе Алманиягә туры килә: биредә 18 татар газетасы һәм журналы нәшер ителгән; Кытайда—16, Төркиядә—14, Финляндиядә—8, Япониядә—5, Румыниядә—2, ә Венгрия, Швеция

һәм АКШта—берәр вакытлы матбугат басмасы дөнья күргән. Хәзерге көндә татар телендә Румыниядә бер газета һәм бер журнал, Кытайның Урумчи шәһәрендә бер журнал һәм Американың Сан-Франциско каласында бер газета чыгып килә. Алманиянең Франкфурт-на-Майне шәһәрендә фәлсәфә фәннәре докторы Алия Тайсина "Бертуган" исемле татар-башкорт журналын чыгарып килә *(Насыйров Тәлгат. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары.—2001.—N 7).*

Чит илләрдә чыккан милли газета-журналлар татар халкының тарихы, дәүләтчелегенең үсеше, күренекле җәмәгать, дәүләт һәм дин әһелләре, әдәбият һәм сәнгать осталары турында яза. Анда дөньяның төрле якларында яшәгән татар диаспорасының иҗтимагый һәм сәяси, рухи һәм мәдәни хәле киң яктыртылган.

1917 елның октябреннән соң нәшер ителгән татар мөһаҗирләре матбугаты, гомумән алганда, большевикларга каршы яза. Алар Советлар илендә барган вакыйгаларны, дин әһелләрен эзәрлекләүне, крестьян хуҗалыкларын мәҗбүри коллективлаштыру, урыслаштыру сәясәтен, аеруча татар һәм башка халыкларның имлясын кириллицага күчерү, киң колачлы сәяси репрессияләр һәм башка тискәре күренешләрне нык тәнкыйтьлиләр. Язмаларда совет җәмгыятендә социалистик үзгәртеп корулар буенча большевиклар оештырган экспериментның киләчәге юк икәнлеге фараз ителә. Шуңа да мөһаҗирләр матбугатын Советлар Союзында тарату тыела һәм бу эш эзәрлекләнә.

Гомумән алганда, 1917 елның октябреннән соң үткән чорның төрле елларында Россиядә һәм чит илләрдә татар телендә типографик һәм башка ысуллар белән 100 дән артыграк большевистик булмаган газета-журналлар нәшер ителгән. Аларның сәхифәләрендә татар халкы тарихын, мәдәниятен һәм иҗтимагый-сәяси фикерен тирәнтен, риясыз өйрәнү өчен кирәкле кыйммәтле мәгълүматлар тупланган. Шуңа күрә Россиядәге һәм башка мәмләкәтләрдәге төрле китапханәләрдә, архивларда һәм фәнни учреждениеләрдә, аерым шәхесләрдә хәзергәчә сакланган татар телендәге газеталар, журналлар, китаплар һәм башка әдәби чыганакларын эзләп табу, аларның оригиналларын яисә фотокүчермәләрен Казанга алып кайтып туплау буенча күп көч һәм тырышлык таләп итә торган эшне тагын да җанландыру бурычы тора. Шулай ук матбугат басмаларын чыгару белән шөгыльләнгән наширләр, мөхәррирләр һәм журналистларның тормыш юлы һәм эшчәнлеге белән бәйле материалларны эзләп табу һәм җыйнау да бик зарури эш.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Ә

**ӘМИР** (Әмирев) Мирсәй (Мирсәяф) Мәсәлим улы (6.1.1907, Уфа губ. Эстәрлетамак өязе, хәзерге Башкортстан Респкасы Мәләүез р-ны Җиргән а. — 1.6.1980, Казан), прозаик, драматург, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1945). 1939-41 елларда Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-тында укый. 1928-29 елларда "Кызыл яшьләр" г-тасы һәм "Авыл яшьләре" ж-лында җаваплы сәркәтиб. 1931-32 елларда ТатЛОКАФ идарәсе сәркәтибе, 1933-35 — "Чаян" ж-лы сәркәтибе. 1936-37 — Татарстан кит. нәшр-ты матур әдәбият бүлеге мөхәррире. 1937-39 елларда репрессияләргә дучар була. 1941-44 — Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире. 1943 елда әдәби хезмәткәр һәм хәбәрче булып "Ватан өчен" фронт г-тасында эшли. 1926 елда "Авыл яшьләре" ж-лында "Дуслар һәм дошманнар" исемле беренче хикәясе басыла. Колхозлашу хәрәкәте чорында авылдагы социаль каршылыкларны публицистик пафос белән сурәтләгән "Безнең авыл кешесе" (1933) повестеннән соң, Ә. шул ук темага, атаклы "Агыйдел" (1936; русчага тәрҗемәсе "Агидель" М., 1948; Татар академия театры спектакле, 1974; ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, 1974) әсәрен язды. 1940 елларда Бөек Ватан сугышы вакытында совет кешеләренең батырлыкларын, тормышка, туган җиргә мәхәббәт хисләрен публицистик-лирик планда тасвирлаган хикәя, очерклар бастырды ("Исеңдәме", 1972). Ә. драматургия жанрына еш мөрәҗәгать итте. Бу өлкәдә иң зур иҗади уңышы булып "Миңлекамал" (1944; Татар акад.театры спектакле, 1944) драмасы санала. Ил азатлыгы хакына үз җилкәләрендә тормышның авырлыкларын татыган, нык ихтыярлы, рухи яктан бай, оптимист күңелле татар хатын-кызының реалистик образын тудырды. Сугыш чоры авылының хезмәт энтузиазмын, батырлыгын, әхлак, мәхәббәт проблемалары белән бергә үреп сурәтләгән "Тормыш җыры" (1946; шул ук театр спектакле, 1947), сугыштан соңгы чынбарлыкка багышланган "Җыр дәвам итә" (1947; шул ук театр спектакле, 1948), "Наилә" (1947; шул ук театр спектакле, 1947), "Гөлшаян" (1958; шул ук театр спектакле, 1958), ), Бөек Ватан сугышы елларында Казан галимнәре тормышыннан "Профессор Саматов" (1949), гаилә һәм мәктәп арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдырган "Минем хатын" (1955; шул ук театр спектакле, 1955), гражданнар сугышы елларында авылдагы кискен каршылыкларга корылган "Хөррият" (1960, шул ук театр спектакле, 1960) героик драма, комедияләре белән Ә. татар сәхнә әдәбияты үсешенә сизелерлек өлеш кертте. Аның пьесалары шулай ук Башкорт академия театрларында да уңыш белән барды. Ә.нең юмористик стильдә язылган, мавыктыргыч сюжетлы әсәрләре дә шактый: "Кысыр хәсрәт" (1954) җыентыгы, "Пар күгәрчен" (1929), "Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре" (1931), "Балыкчы ялганнары" (1971; русчага тәрҗемәсе "Рыбацкие байки", 1973) повестьлары, фельетоннары. Җиңел, йөгерек телдә язылган кечкенә хикәяләре ("Батыр исемле малай турында хикәяләр", 1941; "Алдакчы бозау", 1940 һ.б.) Ә.не талантлы балалар язучысы итеп танытты.

Сугыштан соңгы еллардагы иҗатының казанышлары булып "Ялантау кешеләре" (1954), аның дәвамы булган "Саф күңел" (1959) романнары тора. Соңыннан "Саф күңел" (1964) исеме белән басылып чыккан бу дилогия сугыш чоры чынбарлыгының киң панорамасын күз алдына китереп бастыра, совет кешеләренең нык ихтыярлыгын, фронтта да, тылда да фидакярлеген калку итеп гәүдәләндерә. "Җан көеге" (1969) повестендә исә, язучы, куркак җанлы, дезертир бер кешенең гыйбрәтле язмышын бәян итә. "Үзебез турында" (1971) исемле җыентыгында әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләре тупланган. Гомеренең соңгы елларында әдип автобиографик материалга нигезләнгән

документаль повестьлар иҗат итте. "Без бәләкәй чакларда" (1979), "Үсә төшкәч" (1981) дигән өлешләре язучының утызынчы еллар уртасына кадәрге тормыш вакыйгаларын үз эченә ала. Трилогиянең дәвамы булган "Кичә турында бүген" 2002 елда гына басылып чыкты. Ә. И.С.Тургенев, В.Г.Короленко; А.Е.Корнейчук, Б.Л.Горбатов, Г.Гулиа әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте. Ә. — иҗтимагый-политик тормышта актив катнашкан әдип. 1937, 1961-68 елларда ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. 1963-71 дә РСФСР ЮС депутаты, 1963-67 дә РСФСР ЮС Президиумы рәисе урынбасары, 1967-71 РСФСР ЮС рәисе урынбасары. Ленин ордены, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән бүләкләнде.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1966-67; Әсәрләр: 3 томда. К., 1987-88; Грехи моей молодости. М., 1968; Курай. М., 1978.

Әд.: Бикмухаметов Р. Чистая душа / /Литературная Россия. 1967. 6 янв.; Горбунова Е. Перед лицом новой действительности. М., 1978; Мустафин Р. Образ времени. К., 1981; Хатипов Ф. Мирсәй Әмир. К., 1964; Мусин Ф. Мирсәй Әмир / / Чор белән аваздаш. К., 1983; Миңнуллин Ф. Талантлар юлы / / Балта явызлар кулында. К., 1994.

*Р.Х. Сверигин.*

**ӘМИРИ** (Әмиров) Гайнан Гыймазетдин улы (25.8.1911, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Янавыл р-ны Яңа Уртауыл а. — 1.10.1982, Уфа ш.), шагыйрь, прозаик, публицист, РСФСРның (1969), БАССРның (1976) атказ. мәдәният хезмәткәре. Башкорт телендә иҗат итә. Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1939). 1930—32 елларда "Коммуна" (Уфа ш.) г-тасында эшли, 1933—35 тә Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1940—50 нче елларда СССР ФАнең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында, 1955—57 дә "Әдәби Башкортстан" ж-лы редакциясендә эшли. 1930 нче елларда тел байлыгы белән аерылып торган, башкорт авылы тормышын тирән психологизм белән тасвирлаган "Яңы уйзар" (1932) исемле очерклар китабы, "Кәмһетелгән Шәмсетдин, трудденһез Нуретдин" (1935) исемле лирико-публицистик поэмасы дөнья күрә. Ә. поэзиясенең публицистик пафосы Бөек Ватан сугышы елларында фольклор мотивлары б-н баетыла. "Һалдат йөрәге" (1944) җыентыгына кергән "Батырзар йыры", "Волга йыры", "Ерән кашка аткайым" җырлары аеруча популярлык казана. "Йәшәү шатлыгы" (1950), "Йәшәү — яныу" (1953), "Яззың бер тамсыһы" (1964) исемле җыентыкларында сугышчы-фронтовикның тыныч тормышка кайту темасы, хезмәт романтикасы чагылыш таба. Ә. нең 1960—70 нче еллар поэзиясендә яшәү-үлем, кешенең тормыштагы урыны турындагы уйлanулары тирән фәлсәфи яңгырашка ирешә (рус теленә тәрҗемәсе "Августовские звёзды" җыентыгы, 1981). Башкорт халкының милли герое турындагы "Салауат күпере" (1970—75) поэма-монологы башкорт поэзиясендә күренекле урын ала. "Моразым" (1961) исемле повестендә Ә. милли традицияләрнең һәм гореф-гадәтләрнең бүгенге тормыш шартлары б-н каршылыкка килүен кискен рәвештә тасвирлый. Ә. балалар өчен "Август төнендә" (1936), "Байрак өсөн" (1938), "Алтын" (1940) исемле хикәя җыентыклары, "Трупкасы карт" (1941), "Вәли" (1947), "Дала әкияте" (1960) исемле шигырь җыентыклары яза Ә. — М.Гафуриның "Кара йөззәр" повесте (В.Галимов белән берлектә, 1937), "Таштугай" (1940) легендасы буенча эшләнгән инсценировкалар авторы. Очерклар һәм эсселар тупланган "Ак елкән" (1971) исемле җыентыгында татар һәм башкорт әдәбият һәм сәнгать әһелләре портретлары урын алган. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнгән.

Әсәр: Һайланма әсәрзәр: 2 томда. Өфө, Толпарзар. Өфө, 1976.

Әд.: Агиш С. Башкорт язучысы Г.Әмиригә 50 яшь / / Совет әдәбияты. 1961. N 9.

*Р.К.Әмиров.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БАШКАЛА СЕРЛӘРЕН АЧА

Казанның 1000 еллыгы алдыннан башкалабыздагы "Мәгариф" нәшрияты "Без тарихта эзлебез" сериясеннән дистәләрчә яңа китаплар бастырып чыгарды. Алар арасында "Казан тарихы документларда һәм материалларда. XX гасыр" дип аталганы да бар. Рус телендә дөнья күргән зур күләмле бу җыентыкка узган гасыр Казаны белән бәйләнешле җиде йөзләп чыганак тупланган. Архив киштәләреннән яки "җиде йозаклы" яшерен сейфлардан алынган бу чыганакларның күбесе беренче мәртәбә басыла һәм чал тарихлы башкалабызның монарчы билгесез вә серле сәхифәләрен саллы дәлилләр белән бөтенләй яңача яктыртып бирә. Әлеге җыентык, барыннан да бигрәк, әнә шунысы белән әһәмиятле һәм игътибарга лаеклы да!




Дөрес, күпмедер дәрәҗәдә моңа охшаш җыентыклар элекке елларда да сирәк-мирәк чыккалаган. Ләкин алар Идел кебек галәмәт киң һәм тирән теманың нинди дә булса бер тармагын гына яктырткан. Ә менә гасыр хәтле тулы бер гасырлык Казан тормышын һәм социаль-икътисади, һәм социаль-иҗтимагый, һәм мәдәни яктан зур итеп, дәрьядай киң-саллы итеп яктыртканнары монарчы булмаган. Бу—беренчесе!

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре тарафыннан әзерләнгән әлеге җыентык өч зур бүлектән тора. Аларның беренчесендә Казанның 1901—2000 еллардагы социаль-икътисади хәле хакында сөйләнә. Китерелгән чыганаклар китапта шулхәтле күп һәм кызыклы ки, аларның кайберләренә кинрәк тукталып узмау һич мөмкин түгел.

Казан губернаторы П. Полторацкийның 1900 елда әзерләнгән язма белешмәсендә бу шәһәрдә барлыгы 139 мең 839 кеше яшәве, шуларның 115895е христиан, 21448е мөселман икәнлеге әйтелә. Полицмейстер П.Панфилов тарафыннан 1904 елда тупланган мәгълүматларда тагын да төгәлрәк саннар китерелә. Бу вакытта Казанда барлыгы 198 урам , 41 тыкрык булып, аларда 84295 ир-ат, 77270 хатын-кыз яшәве, шәһәр халкының 81,65 процентын урыслар, 15,75 процентын татарлар тәшкил итүе әйтелә.

Ә 1950 елда әзерләнгән тагын бер белешмәдән укып, Казан халкының 500 мең кешегә җитүен белергә мөмкин, 1979 елга исә бу сан ике мәртәбә арта һәм башкалабыз миллион кешеле шәһәрләр сафына баса. "Правда" газетасының 17 ноябрь санында бу зур шатлык сәбәпчесенең Ирек Мостафин дигән сабый булуы, хәтта әлеге исемнең "азатлык" төшенчәсен белдергән тирән мәгънәгә ия икәнлеге дә әйтелә.

Китапның "Иҗтимагый-сәяси хәрәкәт, 1901-2000" дип аталган икенче бүлегендә гыйбрәтле дәлилләр тагын да күбәя төшкән. Менә аларның әдәбият-сәнгать дөньясына караган кайберләре.

Казан жандарм идарәсе башлыгы полковник Мочалов 1905 елның 5 гыйнварында мөселманнар арасында киң билгеле татар язучысы Гаяз Исхаковның Мәскәү һәм Воскресенск урамнары чатында "Кәрван-Сарай" исемле хәрчәүнә ачуы хакында хәбәр итә. Әлеге хәрчәүнә татарлар арасында революцион пропаганда һәм милли китаплар тарату максатын күздә тотып оештырылган икән.

"Казан көндәлеге" газетасы 1907 елның 15 феврале көнне округ судында "Азат хатын" исемле мөселман басмасы редакторы Галиәсгар Камал эше каралуы һәм, аны судка биргән сәүдәгәр Ибраһимов ризасызлыгына карамастан, редакторның аклануын хәбәр итә. Казан губернаторының яшерен донесениесеннән күренгәнчә, 1912 елның 13 ноябрендә Ф. Әмирхан бүлмәсендә кинәттән тентү ясала. Имештер, биредә Төркиядәге Кызыл Хач җәмгыяте файдасына акча җыеп ятканнар икән. Ләкин язучыны гаепләрлек бер дәлил дә табылмый. Шушындый ук нәтиҗәсез тентү Тукайның якын дусты нәшир Әхмәтгәрәй Хәсәни бүлмәсендә дә ясала.

1915 елның 17 октябренда Казан губернаторына үтә яшерен хәбәр житкерелә.

Әлеге хәбәрдә бер төркем татар язучыларының ничек итеп сугышка бармый калу чараларын эзләүләре хакында әйтелә. Мәсәлән, Гыйльметдин Шәрәф тиздән Хивага, Фатыйх Камалетдинов (Фатыйх Сәйфи) актер Кәрим Тинчурин белән башта Персиягә, аннары Әфганстанга качарга җыеналар икән...

Китапта Сөембикә манарасы очыннан күпме еллар буена татар халкын мыскыл итеп торган ике башлы бөркет билгесенең ничек алынуы турында да кызыклы мәгълүматлар бар. Бу эш болай башлана: 1917 елның 2 сентябрендә Казан мөселман хәрби комитетында Сөембикә манарасыннан ике башлы бөркет билгесен алу һәм аның урынына ярымай кую турында карар кабул ителә. Шушы карар нигезендә әлеге чараның гамәлгә ашырылуы 16 сентябрь көнне булачагы хакында Вакытлы хөкүмәтнең Казандагы губерна комиссары В. Чернышевка житкерелә.

Әлеге хәбәр "вакытлы губернатор"ны кара кайгыларга сала. Нишләргә? Казан мөселманнарын, көч куллану белән куркытып, бу артык кыю ниятләреннән тыяр иде дә—ныклы хакимият булмаган мондый болганчык көннәрдә ике башлы бөркет белән бергә үзеннең газиз башкаең да очып төшүе бар. Әгәр каршы төшмәсәң—Питер каласындагы Вакытлы хөкүмәткә нинди җавап бирерсен? Тегеләй дә болай уйлый торгач,ниһаять, хәйләкәр губернатор бүрене дә тук иткән, бәрәнне дә исән калдырган алтын урталыкка туктала. Нәтиҗәдә, әйтелгән 16 сентябрьдә Сөембикә манарасыннан ике башлы бөркет алып ташлана, ә менә аның урынына куелырга тиешле ярымайны урнаштыру беразга—илнең сәяси болганчык сулары тоныклана башлаган көннәргә хәтле кичектерелә.

Бу урында үткәннәрдән киләчәккә бер гыйбрәт булырлык нәтиҗә ясап кую кирәктер: әйе, Казан мөселман хәрби комитетында Сөембикә манарасыннан урыс империясенең символик билгесен алып ташлау кебек бик тә четерекле һәм җаваплы гамәлнең вакытын искиткеч төгәл сайлый белгәннәр. Чөнки астына су керә башлаган Вакытлы хөкүмәттә бу көннәрне империя киләчәген кайгырту уе булмый инде.

Гражданнар сугышы елларында Мирсәет Солтангалиев һәм Шамил Усманов инициативасы белән Татарстанда 1—Татбригада төзелүе һәм аның җәһәннәм тишегендәге Төркестан фронтына җибәрелеп, басмачыларга каршы көрәш дигән ялган шигарь астында үзбәк патриотларын кырып йөргәнлеге, моның исә Сталин мәкере нәтиҗәсендә үзбәк һәм татар халыклары арасына куеп калдырылган зәһәр мина булганлыгы күптән мәгълүм иде инде.

Баксаң, Идел буенда мондый Татбригаданың икенчесе дә төзелгән булган икән. Аның командиры итеп Мидхәт Борындыков билгеләнгән, ә политкомы Бәкер Белоусов булган. Бу турыда Түбән Новгородтагы Идел буе хәрби комиссариатыннан Казанга җибәрелгән телеграф хәбәрендә әйтелә.

Шунысын да әйтергә кирәктер: 1920 елның маенда Көнбатыш фронтта хәлләр мөшкелләнеп киткәч, 2—бригада составындагы өч полкның һәркайсыннан берәр рота бүлеп алына һәм алардан татар иркәле батальоны оештырыла. Бу батальон 122—армия составында Киевне поляклардан азат итүдә катнаша. Ә сентябрь аенда 2—татар бригадасы Көньяк фронтка җибәрелеп, Врангель армиясен тар-мар итешә. Бу вакыйгалар үзе дә татар бригадасының бер гади сугышчысы булган Гомәр Бәшировның "Сиваш" повестенда әйбәт яктыртыла.

1932 елгы халык хуҗалыгы планнарын тикшерүгә багышлап, шул елның мартында ТатЦИКның чираттагы сессиясе үткәрелә. Төп мәсьәлә кысаларында сессиянең көн тәртибенә дәүләти һәм кооператив сәүдә оешмаларында, трестларда, предприятиеләрдә, югары уку йортларында һәм техникумнарда татар теленнән ничек итеп кинрәк файдалану турында сөйләшү дә кертелгән була. Бәхәсләр барышында кайбер вузлардагы шовинистик очраклар ачыкланып, аларга тиешле бәя бирелә. Мәсәлән, Казан коммунистик төзелеш институты студенткасы Уманова бер чыгышында мондый фикерне әйтергә җөрьәт итә: имештер, татарлар укырга сәләтле түгел, аларны вузларга татар саны кирәк булганга гына кабул итәләр.

Ә Көнчыгыш педагогия институты галиме Горшенев хәтта "татарлар фәнни эшкә сәләтле түгел, аларны бу эшкә якын җибәрмәскә кирәк" диюгә хәтле барып җитә... Әлеге һәм бүтән вузларның партия-комсомол оешмалары тамырдан ялгыш мондый шовинистик карашларны үз вакытында фаш итәргә һәм кискен бәясен бирә белергә тиеш. Бу хакта китапта урнаштырылган ТатЦИК сессиясе материалларында әйтелә.

ВКП(б) шәһәр комитеты бюросы утырышының китапта бирелгән бер беркетмәсеннән күренгәнчә, 1947 елның 21 февралендә татар галиме Ш. Байчураны эссе табага бастырганнар. Тел галименең теле артык озын булганы өчен!

Ә Ш. Байчураны партия билетыннан колак кактырган хәл болай килеп чыга: РСФСР һәм ТАССР Верховный Советларына сайлаулар алдыннан аны агитатор итеп билгелиләр. 17 гыйнварда ул үзе беркетелгән сайлау участогына керә һәм, игътибарын Сталинның каршы стенадагы чәй эчеп торган портретына юнәлтеп, үз-үзенә нидер әйтеп куя. Шунда ук аның янына

Королев дигән озын колаклы бер бәндә килеп житә:

—Сез кем турында, иптәш?

—Менә... аның чәй эчүен күргәч, минем дә тамак кибеп киткән кебек булды бит әле.

—Сез нәрсә, иптәш, үзегезне даһи юлбашчы белән тиң куясыз әле?..

Королев бу сөйләшү турында Ш. Байчура эшләгән Фәннәр академиясе филиалының партбюро секретаре Фурасовка бер ай узгач кына әйтә. Ә соңгысы, кичекмәстән партиянең югары оешмаларына житкерәсе урынга, бу хакта Дәүләт иминлеге оешмасына хәбәр итә.

Һәм менә нәтиҗәсе: Ш. Байчура партия билетыннан, ә Фурасов партбюро секретарьлыгыннан колак кага!

1958 елның 21 маенда КПСС өлкә комитеты пленумы уздырыла. Анда "Совет Татарстаны" газетасы редакторы Г. Рябков та чыгыш ясый. Пленумда катнашучылар игътибарын ул башкалабыз Казан урамнарында күрсәтмә агитация материаллары азлыгына, ә татарча язылганнарының бөтенләй диярлек булмавына, булган очракта да ана телебездә дөрес язылмавына юнәлтә.

Бу чыгыштан соң инде ярты гасырлап вакыт узган. Ә күпләребезнең горурлыгына тия торган әлеге мәсьәләне бүген—Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә дә—уңышлы хәл ителгән дип булмый әле.

Без утызынчы елларда Казан югары уку йортларындагы шовинистик чыгышларның хәтта ТатЦИК сессияләрендә тикшерелеп, фаш ителү очракларын күреп үткән идек инде. Алтмышынчы елларда исә хәлләр кискен үзгәргән: милли мәктәпләрне ябып, милли телләрнең тамырына балта чабып, партия СССР дигән шыксыз зур империядә нибары бер интернациональ тел калдыру кебек җинаятьчел гамәлне тормышка ашыруга кучкән. Менә шушы сәясәткә яраклашырга мәҗбүр булып, хәзер Татарстан җитәкчеләре шовинистларны түгел, ә алардан да куркынычрак җирле милләтчеләрне эссе табага бастыра башлый. ТАССР Министрлар Советы каршындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисе А. Бичуринның КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Табеевка юллаган яшерен белешмәсе—моның ачык мисалы. Әлеге белешмәдә Казандагы оргсинтез заводының яшь аппаратчысы, ВЛКСМ әгъзасы, булачак илгизәр-язучы Тәүфикъ Әйдинең, имештер, илдәге милли сәясәт белән килешмәүче гамәлләре турында сүз алып барыла.

Бу гамәлләр нидән гыйбарәт булган соң?

Барыннан да бигрәк, татарларның бүгенге сәяси һәм мәдәни кысылуыннан, ягъни, милли телдә белем бирүче мәктәпләрнең күпләп ябылуыннан, татар матбугатының җитәрлек булмавы, татарча кинофильмнар төшерелмәве, радио һәм телевидениедә үз телебездәге тапшыруларның күзгә кырып салырдай азлыгы, татар симфоник оркестры оештырылмавы һәм башка күп кенә мәсьәләләрнең хәл ителмәвеннән зарланып, СССРның татарлар күпләп яши торган бүтән төбәкләренә хатлар яудыра башлавын ошатмыйлар.

Т. Әйдинең һәр адымын диярлек нык-лы күзәтү астында тоталар. 1965 елның 11 мартында Ленин исемендәге республика китапханәсендә язучы Эдуард Касыймовның "Гомер ике килми" романы буенча укучылар конференциясе уздырыла. Анда, язучының әлеге әсәрдә урыс сүзләрен артык күп куллануын тәнкыйтьләп, Т. Әйди дә чыгыш ясый. Шымчы күләгәләр: "Әһә-ә... Чыгыш ясаучы урыс сүзләрен яратмый икән!" дип шунда ук бу кәфер фикерне тиешле оешмага барып әйтәләр.

Нәтиҗәсе шул: "кырын" эшләрен тагын бераз күзәтеп йөргәч, КПССның Ленин райкомына чакыртып, Т. Әйдине бик шәпләп "мунча кертәләр". Әлеге пешекләү вакытында оргсинтез заводы вәкилләре һәм районның карт коммунистлары да катнаша.

Алтмышынчы елларда җирле милләтчеләргә каршы аеруча көчәеп киткән көрәш турында сүз чыккач, бу язмада сүз барган китапның "Мәдәният үсеше. 1901-2000" дип аталган өченче бүлегендәге тагын бер язманы телгә алып китәсе килә. Ул "Казан дәүләт университеты студентларының гыйльми эшләре турында КГБ бүлеге башлыгы Максютов тарафыннан 1960 елның 17 маенда язылган белешмә" дип атала. Үткәннәрдән бүгенгә һәм, ин мөһиме, киләчәккә тиешле гыйбрәт булып бара алганлыктан, әлегәчә яшереп саклап ган бу чыганакка киңрәк тукталып үтәргә кирәк.

"Соңгы елларны КГБда тупланган мәгълүматлардан күренгәнчә,—диелә әлеге документта,—яшь татар зыялылары арасында милләтчелек күренешләре шактый артты. Бу куркыныч чир, башлыча, Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган белгечләр арасында киң таралган (язучы Н. Фәттах, КДУның гыйльми китапханәсе директоры урынбасары Ә. Кәримуллин, КДУ укытучысы Р. Нәфыйгов, ИЯЛИ галиме Х. Курбатов һ.б.)

Бу унайдан без КДУда татар теле һәм әдәбияты белгечләрен әзерләү мәсьәләсе белән кызыксындык. Тупланган материаллардан күренгәнчә, унай яклар белән беррәттән, әлеге өлкәдә төзәтеләсе кимчелекләр дә байтак. Бигрәк тә студентларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеге мәсьәләсендә.

КДУның татар теле һәм әдәбияты бүле-

ге студентлары, беренче курслардан ук, мондый эшчәнлеккә кин тартыла башлыйлар. Алар башта теге яки бу темага фәнни докладлар, курс эшләре язалар, ә университетны тәмамлаганда, шул темаларны кинәйтеп-тирәнәйтеп, диплом яклыйлар. Болары яхшы, әлбәттә. Ләкин студентлар язган эшләрнең тематикасы заман таләпләренә җавап бирә дип һич кенә дә әйтеп булмый.

Һәм менә ни өчен?

"Студентлар башкарган күпчелек эшләрнең темасы революциягә хәтле чорга карый. Шунлыктан ул чордагы төрле реакцион һәм милләтчелек карашлары сеңдерелгән басмаларны студентларга үзләре теләгәнчә укый һәм өйрәнә алу мөмкинлеге тудырылган. Бу хәл исә әле тиешенчә белем алып өлгермәгән яшьләрнең фәнни-сәяси карашлары дөрес формалашуга тискәре йогынты ясый."

Шуны гына әйтү дә җитә: 1959 елда якланган 32 диплом эшенең 23 се революциягә кадәрге чор темасын яктырта.

Студент Ф. Миңнуллин (алдагы елларда күренекле әдәби тәнкыйтьче булып танылды – ред.), мәсәлән, "Г. Ибраһимов иҗатына Г. Нигмәти тәнкыйте" дигән теманы өйрәнгәндә революциягә кадәр басылган барлыгы 70 китап һәм журналны укып чыккан. Ә ул басмаларда буржуаз-милләтчелек карашлары хәттин ашкан.

Студент Ә. Рәшитов (бүгенге көндә танылган шагыйрь һәм публицист), "Ан" журналында эстетика мәсьәләләре" дигән темага диплом эше язганда, шундый ук эчтәлекле 40 хезмәтне өйрәнгән...

Студент Ф. Әгъзамов (танылган журналист, галим һәм тәрҗемәче) "Әдәби тәнкыйть Ф.Әмирхан турында" дигән темага диплом яклый. Аны язар алдыннан ул шулай ук революциягә кадәр басылган 40 әсәрне укып чыга. Алар арасында яшь кеше аңына тискәре йогынты ясый торган "Асылган җидәү" кебекләре дә бар.

Студент Х.Зарипов диплом эшен "Вакыт" гәзитендә Тукай иҗатына тәнкыйть" темасына язган...

1960 елда якланган дипломнарның да күпчелеге революциягә кадәрге чорга карый. Алар арасында, мәсәлән, мондый темаларга язылганнары бар:

—"Дәрдмәнд иҗаты" (студент Н.Хисамов).

—"С.Рәмиев иҗаты" (студент Ш.Садретдинов).

—"Г.Кандалый әсәрләренең лексикасы" (студент Х.Халиков).

КГБның бүлек башлыгы Максютов әфәнде әзерләгән әлеге белешмә уңаеннан шунысын да әйтеп китәсем килә: алтмышынчы еллар азагында Казан дәүләт университетының без укыган татар теле һәм әдәбияты бүлегендәге 446 нчы төркемдә дә дәүләт иминлеге сагында торучылар игътибарын җәлеп иткән бер хәл булып алган иде. Бу хакта сабакташ каләмдәшләрем Рафаил Сибат һәм Флүс Латыйфи бераз элегрәк язып чыкканнар иде инде. Сүз җаеннан файдаланып, биредә мин дә үзем белгәннәрне алар әйткәннәргә берникадәр өстәп китәргә булдым.

Көннәрдән бер көнне булачак шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов һәм минем исемгә Бакудан юлланган нииндидер ике хат килеп төште (исем-фамилияләребезне "Казан утлары" журналында нәкъ шул айларда басылган М. Мәһдиев мәкаләсеннән алганнар булса кирәк. Ул Курган өлкәсенә оештырылган фольклор экспедициясе йомгаклары турындагы бу язмасында безнең икебезне дә атап киткән иде).

Ни гаҗәп, Бакудан җибәрелгән хатларда да нәкъ Т. Әйди әйткәннәр бәян ителгән иде. "Татар яшьләренең нигә әдәби журналы юк?" дигән җөмлә турысына, артык ошатып, мин дә өндәү билгесе куйганмын булып чыкты. Ике хатның берсен, кулдан-кулга йөртеп, бүтән студентлар да укый башлаган иде, күрәсең. Берзаман аларны берәм-берәм Черек күл буендагы шомлы бинага чакыртып ала башладылар. "Куркыныч" хатны кемнең кайчан укуын энәсеннән җебенә хәтле җиткереп торганнар, күрәсең.

Ә мин чакырткannарын көтеп тормадым, тоттым да, үземә юлланган теге хатны алып, усал агайлар янына киттем. Ни гаҗәп, иелгән башны кылыч кисмәс дигәндәй, мина бер авыр сүз әйтеп бәйләнүче, янау-куркытучы булмады. Бары тик капитан погоннары таккан урта яшьләрдәге татар офицеры гына Баку хаты чйтенә мин куйган теге өндәү билгесенә килеп төртелде дә, мыек астыннан елмаяелмая, сорап куйды:

—Ә бу нәрсә, энекәш?

—Өндәү билгесе.

—Булачак филолог бит инде син. Йә, әйт әле, әлеге билге кайчан куела?

—Сокланганда, нәрсәнедер хуплаганда... —дидем мин һәм, үзем куйган капкынга үзем үк килеп кабуымны абайлап, кинәт телсез калдым.

—Менә-менә... Дөрес әйтәсең, энекәш: өндәү – хуплау билгесе! Ярый инде, бу бүлмәдә безгә Сталин чорларында очрашырга язмаган. Һич арттырып әйтүем түгел: шушы өндәү билгесе өчен генә дә синең башкаеңа, кем белә, нибары бер пуля җиткән булыр иде.

—Анысы шулай инде.

—Шулай булса, бар, энекәш—тулай торагына кайт та, якты дөньяга сине соңлабрак тапкан әниеңә рәхмәт укы!..

Тиздән Баку хатлары бөтенләй онытылды. Мин аларны ул чакта нииндидер очраклылык аркасында гына килеп чыккан күңелсезлектер дип уйлаган идем.

Әлеге хәлләрдән соң үткән кырык ел

аша күз ташлап, хәзер бөтенләй икенче нәтиҗәгә килдем: юк икән, Казан дәүләт университеты югары белемле милләтчеләр әзерләп чыгара күрмәсен дип, биредәге татар теле һәм әдәбияты бүлеген әледән-әле, планлы рәвештә жиз иләк аша үткәреп, ягъни мәсьәлән, куркытып-өркетеп торганнар! Ә, кем белә, Баку хатлары да усал агайлар тарафыннан махсус оештырылган профилактик чараларның берсе булгандыр. КГБ бүлеге башлыгы Максютов әфәнденең "Казан тарихы..."нда бирелгән яшерен белешмәсе белән танышкач, әнә шундый нәтиҗәгә киләсең.

"Мәгариф" нәшрияты чыгарган "Казан тарихы..." җыентыгында өстә телгә алынган татар яшьләренең әдәби журналына бәйләнешле тагын бер документ бар. 1978 елның 9 июнендә теркәлгән әлеге язма "Яшьләр басмаларын чыгаруны күбәйтү турында КПСС Үзәк Комитетына ТАССР Язучылар, Рәссамнар һәм Композиторлар союзлары юллаган хат" дип атала. Бу хат күптән өлгереп җиткән һәм татар җәмәгатьчелеге тарафыннан әледән-әле күтәрелә киленгән мәсьәләнең, ниһаять, Мәскәү алдында җитди итеп куелуы нәтиҗәсе булып тора. Тик, үкенеч ки, илдә кәгазь җитмәү кебек техник сәбәпләрне сынъкка сылтау итеп, татар яшьләре журналын ачуны һаман суза килделәр. Ә бу сузуның нигезендә татар яшьләренә яңа басма чыгарырга рөхсәт итсәң, СССР составындагы бүтән автономияле милләтләр дә шуны ук таләп итә башларга мөмкин дигән курку-шикләнү ята иде.

Шунысын да әйтү кирәктер: татар җәмәгатьчелеге күптән таләп итеп килгән, хәзер инде яшьләрнең яраткан басмасына әйләнгән "Идел" журналын бары тик илдә үзгәртеп кору җилләре исә башлаган сиксәненче еллар азагында гына ачарга мөмкин булды.

"Казан тарихы документларда һәм материалларда. XX гасыр" җыентыгында, күреп үткәнебезчә, мөһим дәлилле беренчел чыганаклар шулхәтле күп ки, алар белән танышып чыккач, бу көннәрдә 1000 еллыгын билгеләп үтүче чал башкалабызның узган йөздәге бер гасырлык тормышы бөтен тулылыгы белән күз алдына килеп баса. Ә бит әле аның, инде тәмам расланып җиткәнчә, 1000-1900 еллардагы вакыт аралыгын эченә алган тагын тугыз гасырлык бай үткәне бар. Кем белә, Ходай насыйп итеп, киләчәктә әле бәлки ул чорларның искиткеч кызыклы һәм беренчел чыганаклары тупланган шушындый ук калын вә саллы җыентыклар белән дә танышырга мөмкин булыр. Һәрхәлдә, күңелнең моңа бик, бик тә ышанасы килә.

Без сүз алып барган җыентык А. Герценның китапка эпиграф итеп алынган гаять тирән мәгънәле сүзләре белән ачыла. Ул болай дигән: "Казанның әһәмияте искиткеч зур. Ул — ике кыйблалы ике кыйтганың үзара очрашу һәм көрәшү урыны. Әнә шуңа күрә анда ике башлангыч — көнбатышча һәм көнчыгышча яшәү рәвеше күзгә ташлана. Казан Аурупа идеяләрен Азиягә һәм азият холкын Аурупага илтү юлындагы төп кәрван-сарай ул".

Әйе, Казанның чал тарихтагы төп урынын һәм әһәмиятен төгәл билгеләгән гаҗәеп дөрес вә хак сүзләр бу! Инде әлеге фикергә өстәп, шунысын да әйтү кирәктер: Россиянең бүгенге туграсына тагын бер кат игътибар итик әле — анда да бит, Герцен сүзләрен раслап, борынгы төрки халыкларның изге туграсы саналган ике башлы бөркет күзгә ташлана. Ул бөркетнең бер башы көнбатышка, ә икенчесе көнчыгышка карап тора. Бу очраклы хәлме? Түгел, әлбәттә!

Дөньяның кендеге элек-электән нәкъ менә Көнбатыш белән Көнчыгышның кыл уртасындагы Казан тарафларында әйләнгән. Ул бүген дә шулай. Киләчәктә дә нәкъ шулай булып калачак.

Төрки бабаларыбызның борынгы билгесен бүген үзенә дәүләт туграсы иткән Россия империясе дә моннан 450 еллап элек нәкъ менә Казан каласын яулап алудан башланып киткән бит. Аның киләчәктә чын федерациягә әйләнеп, хәзерге чикләрендәге аерым дәүләт сыйфатында яши алу яки алмау мәсьәләсе дә бүген нәкъ менә Казан тарафларында хәл итеп ятуы бик ихтимал. Тормыш та, сәясәт белгечләре дә бүген әнә шундый фаразны әйтеп чыга.

Шулай итеп, аңлашылса кирәк: бүген Казан — Россиянең генә түгел, ә бөтен җиһанның кыл уртасы, аның үзенчәлекле кендеге. Әнә шуңа күрә дөньяның олы юлындагы иң төп, иң мөһим кәрван-сарай ролен үтәүче Казаныбызның 1000 еллык бәйрәме бүген менә шулай зурлап, бөтен ил, бөтен дөнья күләмендә билгеләп үтелә дә.

Олы бәйрәмең котлы булсын, Олуг Казаным!

Синең гыйбрәтле үткәнең, ышанычлы бүгенгең һәм нурлы киләчәгеңне яктыртып, әле тагын да байрак эчтәлекле байтак китаплар язылсын!

**Равил ВӘЛИ**

*Котлыйбыз!*

# ДЕТЕКТИВ ОСТАСЫ

## МӘГЪСУМ НАСЫЙБУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

..."Без капчыкта ятмый", "Телсез шаһитлар", "Төнге ату", "Алтын алка", "Яшерен касса", "Йөрәк таш түгел"... Җитмешенче-сиксәненче елларда зур-зур тиражлар белән (20,30,50 шәр мең данә!) басылып чыккан бу китапларны укымаган татар кешесе калдымы икән? Еракеракларга чапкан поезд купеларында да, шәһәр һәм авыллар арасында җилдергән автобус салоннарында да, урманкырларда куелган палаткаларда да һәм, әлбәттә инде, өйләрдә бөтен эш-мәшәкатьне онытып та укылдылар әлеге китаплар!



Әйе, детектив әдәбиятның көче әнә шундый! Бу айда үзенең 80 яшен тутыручы язучыбыз Мәгъсум ага Насыйбуллин югарыда саналган һәм саналмаган күп санлы әсәрләре белән татар әдәбиятының детектив жанрын үстерүгә зур өлеш кертте.

Мәгъсум Нәҗип улы Насыйбуллин 1925 елның 15 октябрендә Кукмара районының Байлангар авылында туа. 1940 елда җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң ике ел Кукмара МТСында эшли, аннары башлангыч мәктәптә укыта. 1943 елда ул Армиягә алына, хәрби аэродромда хезмәт итә. Аннары кече командирлар мәктәбен тәмамлап, хәрәкәттәге Армиягә җибәрелә. Ул Көнчыгыш Пруссия өчен барган сугышларда катнаша.

1947 елда Армиядән кайткач М. Насыйбуллин Свердловск шәһәрендә икееллык кичке юридик мәктәпне, аннары юридик институтның хокук бүлеген тәмамлый һәм Свердловск өлкәсенең Кировград, Югары Тавда шәһәрләрендә прокурор ярдәмчесе, шул ук өлкәнең Серов, Богданович һәм Сажино районнарында прокурор булып эшли. Хезмәтеннән аерылмыйча укып, 1959 елда ул Свердловск педагогия институтының филология факультетын тәмамлый.

1962 — 1970 елларда М. Насыйбуллин башта Казахстанда, аннары Башкортстанда прокурор булып эшли. 1970 — 1981 елларда ул Татарстан прокуратурасында хезмәт итә.

М. Насыйбуллинның беренче язмалары матбугатта илленче елларда күренә башлый. Аның очерк һәм мәкаләләре гаделлек сагында торучы милиция, прокуратура, суд хезмәткәрләренә багышлана. Әнә шулай тәҗрибә туплый-туплый язучы әкренләп документаль прозага аяк баса.

Аның беренче китабы 1968 елда русча, ә икенчесе "Юрист язмалары" исеме белән 1970 елда Башкортстан китап нәшриятында дөнья күрә. Казанга кайткач М. Насыйбуллинның детектив әсәрләрен туплаган китаплары бер-бер артлы басыла башлый һәм алар шундук укучылар мәхәббәтен казана. Аның байтак әсәрләре республика күләмендә уздырылган конкурсларда җиңеп чыкты. Язучының китаплары шулай ук рус телендә дә басылып тора. М. Насыйбуллин—матбугат битләрендә милләт язмышы һәм милли тәрбия мәсьәләләренә багышланган күп санлы мәкаләләр авторы да.

**Тынгысыз җанлы өлкән каләмдәшебезне олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, иҗат уңышлары, озын гомер телибез!**

*Безнең календарь*

# ИСКӘ АЛЫЙК ГЫЙФФӘТ ТУТАШЛАРНЫ...

ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВАНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Сүзне шуннан башлыйм әле: житмешенче еллар башында "Нигез сагындыра" исемле шигырь язып, Аурopa, дөнья шигърияте белән мавыгып, "саташып" йөрелгәннән соң, "акылга килү"—уяну" билгесе итеп, милли җирлеккә—жирлеккә кайтуымны да белдереп, бер тәүбә китергән идем:

*Гадиерәк хәзер идеаллар да:*
*Матильдалар түгел, йә Сандлар...*
*Истә күбрәк—Сәмитова апа,*
*Мозаффариялэр, Гыйффәт туташлар...*

Ул чакта, "туташлар" дип күплектә язуым ахры бер тел чарасы гына булган: безнең шигърияттә XX гасыр башында Гыйффәтләрнең икәү булганы миңа мәгълүм түгел иде әле. Ә Гыйффәт туташ исемле шагыйрәбезне антологиядән, гасыр башы шигъриятебезгә багышланган хезмәтләрдән укып белә идем инде. Замандашларына бәйләп тә исемен мәкаләләрдә, шигырьләрдә очратып, хәтерли идем. Әйтик, Ш. Бабичнын атаклы "Китабеннас"ыннан:

*Мәшһүрә Гыйффәт, елак, шөһрәт таба һәр як белән,*
*Аһ, йөрәгем, дип елый, чиртсәң дә бер тырнак белән,—*

кебек юлларны да кабатлый идем. Әйе, Бабич белән шашып йөргән 60 елларда, шагыйрьне белгән кешеләрне эзләп, Оренбург чоры буенча шагыйрьне яхшы хәтерләүче Хәдичә апа Тарпищева—Мәхмүт Галәүнең беренче хатыны белән сөйләшеп утырганда, аның өенә нәкъ менә "Гыйффәт туташ"—Заһидә Бурнашева үзе килеп кергән иде. Танышкач, сөйләшүгә ул да кушылды; минем Тукайлы, Бабичлы, димәк үзе дә шигырьгә килгән чорга мәхәббәтемне, кызыксынуымны күреп, ярыйсы ук ачылып, сорауларыма җавапларда бирде. Озак утырмады. Аны озаткач, мин теге эпиграмманы укып, Хәдичә апаны көлдердем дә... "Бабич бик шаян-шук иде... Бик прастуй киенеп йөри иде—шалапут студент кебек,"—диде ул, аннары шагыйрьнең атаклы "Язгы жыр" шигыренең үзендә сакланган, Бабич күчереп биргән нөсхәсен—оригиналын күрсәтте...

Әмма, истәлекләрне онытып торып, шуны уйлыйк әле: нигә "елак" соң әле Бабич эпиграммасындагы Гыйффәт туташ? Ә ул вакытта—кара реакция елларында шагыйрәләрдә генә түгел, бөтен шагыйрьләрдә дә төшенкелек, пессимизм мотивлары күп! Тукаебызда да шулай. Петербургка баргач, "Нур" газетасы идарәсендә шундый шигырьләрне укыгач, ул аларны басарга тәкъдим итә. Сәбәбе: безнең бүгенге шушы хәлебез матбугатта чагылып, күренеп калсын, ди ул. Тарих өчен!

Ә шагыйрәләр турында сөйләгәндә моның икенче ягын да уйлыйбыз: ул—хатын-кызларыбызның гасыр башында да әле үзгәрмәгән авыр хәле, изелүләре, хөрлеккә омтылулары... 1907 ел азакларында "Әльислах" газетасында Маһруй Мозаффариянең "Мәшһүр хатыннарымыз" исемле, аларның ирләр белән тигезлеген яклаган, даулаган *("сездә шагыйрь булса—бездә шагыйрә бар... Мөселманда булмас, бәлки—башкаларда "бог"ка каршы "богиня" бар..." кебек юлларын хәтерлик!)* шигыре басылып чыга. Аны укыгач, кызу темпераментлы Сәгыйт Рәмиев редакциягә килеп, Тукайга: "Син үзең язгансыңдыр әле аны?" ди, аннан инде ышангач, шатланып, рухланып, "Юк, үлмим, торам әле" исемле мәкаләсен язып бастыра. Ягъни матбугат галәменә хатын-кызлар, шагыйрәләр килүенә сөенечен уртаклашып. Бу—гүзәл женеснең ижат чәчәкләрен котлап, шатлык бүлешү—бүгенге көннәргә кадәр килгән бер мирас традиция бугай...

Әйе, нәкъ менә шуннан соң Мозаффариялэр, Хәдичә Сөнгатьзадә (Шаммасова) Заһирә Байчурина, Фәхрелбанат Сөләймания, Зәйнәп Сәгыйдә (Бакирова), тагын

бер гыйффәтле күнел—Сания Гыйффәт (З. Кадыйри хатыны, соныннан Г. Исхакыйның мәсләктәше булып, мөһаҗирлектә үлә) һ. б. исемнәре бөтен татар галәменә калкып чыга. *(Бүген дә алар—төрле-төрле, кызыклы, талантлы шагыйрәләребез бар; яшьләрдән—күбрәк тә килә бугай алар хәзерге шигырьгә. Бусы—аерым тема.)* 1914 елда исә алар сафына әлеге Гыйффәт туташ тәхәллүсле—чын исеме Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева—шагыйрә дә килеп кушыла... Ул 1895 елның 19 октябрендә хәзерге Рязань өлкәсенә кергән Әҗе авылында сәүдәгәр гаиләсендә туа; абыйстайдан сабак укып башлаган кыз күрше авылда русча да укый, белемле, аңлы яшьләр сафына килүен белдереп, шигырьләрен, мәкаләләрен бастыра башлый. *(Г. Исхакый житәкләгән "Ил", соңрак "Сүз" газеталары, "Аң" журналы битләрендә).* Бу—үтә диндар, кадим кешеләр булган әти-әнисенә ошамый, алар кызларын мондый эштән сүрелдерергә теләп, өйдә ябып тоталар... Нәтиҗәдә ул, качып, Мәскәүгә китеп, аерым яши башлый.

Аны яклап, хуплап, матбугатта күп мәкаләләр чыга.

1915—1917 елларда яшь шагыйрәнең "Гыйффәт туташ шигырьләре" исемле өч китабы басыла: аларның үзәге, җаны—нәкъ менә шул ирекккә, рухи азатлыкка омтылган яшь татар кызы халәте, аның газаплы сагышлы уйлары, һәм, әлбәттә инде, мәхәббәте, күз яшьләре... Менә ул Бабич язган "елак"лык тарихы! Бабич дигәннән, Г. Тукай, С. Рәмиев кебек остазлары мәктәбен узган Гыйффәт туташта үз замандашларының эзләнүләре—шул ук Ш. Бабич, Г. Харис, З. Ярмәки һ. б. белән уртак темалар, сурәтләр, шигъри алым-чаралар юк түгел. Барсын да бергә җыеп, чагыштырып укыганда бик кызыклы шигъри чор булуына ышанасың. 2004 елда "Мәгариф" нәшриятында басылган "Татар шигърияте. XX гасыр башы" исемле, З. Рәмиев төзеп чыгарган бай антологияне укыгач, бу ышанычым тагын да ныгый төште. Анда Гыйффәт туташ иҗатына да шактый зур урын бирелгән—үзенчәлекле лирикасына да, Пушкиннан тәрҗемәләренә дә һ. б. Менә бер шигыреннән юллар:

*Әй өмит күгемдәге ай, ник йөзең күрсәтмисең?*
*Яшеренәсең һәрвакыт—ник нурларың тибрәтмисең?*
*Бер генә ач йөзләреңне, ялтырат тормыш юлын,*
*Кил, чыгар золмәт юлыннан, суз мөкатдәс ак кулың...*

Шагыйрә, үзе инанганча, тормышының ак көннәре ана 1917 елда килә шикелле. Ул шул елда партиягә керә, чын мәгънәсендә хатын-кыз азатлыгы өчен көрәш юлына баса: Урта Азиягә китеп, Сәмәрканд шәһәрендә өлкә газетасында, Төркестан компартиясе Үзәк Комитетында хатын-кызлар белән эшләү бүлегендә хезмәт итә. Мәскәүдә Коминтернның Икенче конгрессында, Көнчыгыш хатын-кызларының I конференциясендә катнаша (1920), Россия Компартиясенең Үзәк комитетында инструктор була (1921—1923); аннары янә Урта Азиядә—Төрекмәнстанда, Кыргызстанда партия, совет учреждениеләрендә эшли, җирле хатын-кызлардан милли кадрлар әзерли; "Почет билгесе" ордены белән бүләкләнә. 1952 елда исә пенсиягә чыгып, Казанга кайта.

Егерменче еллар башында хикәяләре, шигырьләре Казанда татар, рус телләрендә нәшер ителсә, 1971 елда "Татар хатын-кызлары тарихыннан" исемле публицистик китабы дөнья күрә. Вафаты—1977 елда...

Шагыйрәнең тормышы һәм иҗат юлы турында матбугатта төрле елларда М. Гайнуллин, Л. Ихсанова, А. Хәсәнова һ. б. мәкаләләре басылып чыкты. Әмма безнеңчә, Гыйффәт туташ—Заһидә Бурнашева турында, аның кебек үк "халыклар бәхете өчен" көрәшеп үткән каршылыклы, ялгыз гомер ияләре Абруй Сәйфи, Гөлчирә Гафурова, Зәйнәп Бәшировалар язмышы турында киләчәктә китаплар да язылыр әле. Хәер, Зәйнәп Бәшированың бер юбилее унае белән журналыбызда халык шагыйре Равил Фәйзуллинның якташы турында ачынып, уйланып язылган мәкаләсе басылган иде.

Әйе, уйландырырлык нәрсәләр бар безнең бу гыйбрәтле язмышларда!

Бәхетле булдыгызмы сез, әй, гыйффәтле, пакь җанлы туташларыбыз?

**Рәдиф ГАТАШ**

## «Казан утлары» архивыннан



*Татар Пен-үзәкнең бер җыелышы "Казан утлары" редакциясендә узды. Утырышта катнашучылардан бер төркем. Сулдан уңга, беренче рәттә: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рафаэль Мостафин, Миркасыйм Госманов, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин; икенче рәттә: Харрас Әюпов, Зөлфәт, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Мансуров, Нур Әхмәдиев, Флүс Латыйфи, Мөдәррис Вәлиев, Әхәт Мушинский, Тәлгат Бариев, Газинур Морат. 2003 ел. Казан.*



*Гомерен татар халык иҗатын өйрәнүгә багышлаган фольклорчы галим Хәмит Ярми (1904-1981). 1965 елда алынган фоторәсем. Мамадыш районы, Олыяз авылы.*



*Музыкаль гаилә. Композитор Луиза Хәйретдинова әтисе Әхмәт Хәйретдинов белән. 70 нче еллар. Казан*



*1993 елны Сабада Башкортстанның Яңавыл районы әдәбият һәм сәнгать көннәре үткән иде. Бу рәсем шул көннәр истәлеге. Уңнан сулга—галим-язучы Азат Әхмәдуллин, Нурихан Фәттах, Тәлгат Нәҗмиев.*



*Язучы Идрис Туктар (1896-1982). 1975 елда алынган фотосурәт.*



*Язучы Рауль Мирхәйдәров Венециядә, Йосиф Бродский кабере янында. Италия. 2005 ел.*

# КАБАТЛАНМАС БӨЕК БӘЙРӘМ

## ТАТАРСТАН—ДУСЛЫК СИМВОЛЫ

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВНЕҢ КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ 1000 ЕЛЛЫГЫ ҺӘМ РЕСПУБЛИКА КӨНЕ УҢАЕННАН КОТЛАВЫ

Кадерле ватандашлар!

Бүген—гасырлар тарихында истәлекле көн. 15 ел элек, 1990 елның 30 августында, Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителде. Шул вакыттан башлап, ел саен Республика көнен билгеләп үтү матур гадәткә әйләнде. Ә быел без башкалабызның 1000 еллык юбилеен да берьюлы, зурлап бәйрәм итәбез.

Ел буена без дөньяның төрле җирләреннән кадерле кунаклар кабул иттек. Шушы көннәрдә Казанга В. Путин, Бәйсез Дәүләтләр Берләмлеге илләренең президентлары һәм Россиянең бөтен губернаторлары килеп китте. Безгә карата ихтирамнары өчен без аларның һәммәсенә, аеруча Россия Федерациясе Президентына рәхмәтлебез. Барыгыз да беләсез: ул Казан шәһәренең 1000 еллыгын үткәрү буенча комиссияне үзе җитәкләде.

Дөньяның төрле почмакларында террорчылык баш калкыткан бу заманда бездә милләтләргә, диннәргә, гомумән, кешеләргә тигез караш, сабыр мөнәсәбәт яши. Татарстан үзара килешү, дуслык-татулык символы булып тора. Бу—бәяләп бетергесез тәҗрибә һәм зур хәзинә. Без мона хезмәттә—тырышлык, тормышта—зирәклек, сәясәттә—саклык, шәхси мөнәсәбәтләрдә эчкерсезлек нәтиҗәсендә ирештек. Без моны булдыра алабыз, дидек һәм, чынлап та, ниятләгән эшләребезне эзлекле рәвештә тормышка ашырабыз.

Безнең башкалабыз Казанның тарихы искиткеч бай һәм гыйбрәтле. Кайчандыр Казан Болгар дәүләтенең һәм Алтын Урданың сәүдә үзәге булган, аннан соң Казан ханлыгының мәркәзенә әйләнгән. Россия империясендә ул—зур губерна үзәге. Казанны үзе килеп күргәч, Екатерина II болай дигән: "Бу—Россиядә, Мәскәүдән кала, һичшиксез, беренче шәһәр... Казанның зур патшалык башкаласы икәнлеге һәр яктан күренеп тора". Әлеге сүзләр Казанга карата ихтирамны белдерә, аның ил тарихындагы ролен югары бәяли.

Соңгы елларда Татарстанның абруе чагыштыргысыз дәрәҗәдә үсте. Без бүген ныклы ышаныч белән, Казан—Ауразия мәркәзләренең берсе, дип әйтә алабыз.

Без шәһәребез тарихы белән горурланабыз, бирегә бөтен дөньяга танылган бөек шәхесләр яшәгән һәм эшләгән. Мөхәммәдъяр һәм Державин, Лобачевский һәм Бутлеров, Тукай һәм Такташ, Камай, Арбузовлар, Шаляпин, София Гобәйдуллина, Салих Сәйдәшев, Сергей Аксаков, Лев Толстой, Ульянов-Ленин, аталы-уллы Туполевлар, Сергей Королев, Рудольф Нуриев кебек атаклы исемнәр безнең өчен бик кадерле. Алар аша Казан шәһәренең даны бөтен дөньяга таралды, бу—үзе бер дәрәҗә.

Бүгенге көндә без барыбыз да—илдәге тирән үзгәрешләрнең шаһитләре. Тормыш үзебезнең күз алдында үзгәреп бара. Иң мөһиме: республика башкаласында да, Татарстанда да иҗади хезмәт рухы колач җәйгән. Без инде Россия Федерациясе күләмендә күп юнәлешләрдә унай үрнәк булып өлгердек. Шул ук вакытта эшлисе эшләребез, хәл итәсе мәсьәләләребез дә аз түгел. Милләтара татулык, аңлашу, дуслык булганда, алга куйган максатларыбызга ирешүдә минем шигем юк. Безнең уртак бурычыбыз—җәмгыятьне үзгәртеп кору чорында Россиядә демократик федератив дәүләт төзү.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай язганча:

*"Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?*
*Без туган бер җепкә бергә теркәлеп".*
*"Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;*
*Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез гыйззе вә җәл".*

Татарстан тарихында төрле вакыйгалар булды, катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә сабырлык, ярдәм һәм теләктәшлек күрсәткәнегез өчен барыгызга да олы рәхмәтемне белдерәм. Меңьеллык юбилей, без теләгәнчә, Казанда яшәүчеләрнең һәммәсенә бәйрәм булып барып иреште. Чөнки халыкка кирәкле күп социаль-спорт

корылмалары, торак йортлар, юллар, күперләр төзелде, шәһәребез күзгә күренеп матурлана һәм янара. Бу бәйрәмгә татарстанлыларның һәрберсе үз өлешен кертте, дип саныйм. Зур рәхмәт барыгызга да, хөрмәтле ватандашлар! Сезгә тынычлык һәм иминлек телим.

Бәйрәмегез котлы булсын!

### МЕҢЬЕЛЛЫК ТАНТАНАЛАРЫ

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында сәнгать осталарының Казанның 1000 еллыгына багышланган гала-концерты булды. Аны БДБ илләре җитәкчеләре һәм РФ Дәүләт Советы әгъзалары тамаша кылды. Россия Президенты В. Путин һәм Татарстан Президенты М. Шәймиев бәйрәм кичәсенең мактаулы кунаклары булды.

Тантанала Россия Федерациясе Президенты В. Путин сәламләү сүзе белән чыкты. Ул бердәм Россияне формалаштыруда Казанның чын мәгънәсендә кабатланмас тарихи ролен билгеләп үтте. "Без Советлар Союзы таркалуы нәтиҗәсендә килеп чыккан хәвефле үзәктән качу тенденцияләрен җиңеп чыгуга ирештек. Федераль үзәк һәм федерация субъектлары арасындагы мөнәсәбәтләрне урнаштыру процессы Россиянең күпмилләтле халкы бердәмлегенең тарихи ныклыгын тагын бер кат раслады",—диде В. Путин һәм бу яктан Татарстан җитәкчелегенең алдынгы ролен һәм Президент М. Шәймиевнең зирәк сәясәт алып баруын билгеләп узды.

В. Путин халыкның тормышын яхшырту, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү җәһәтеннән шәһәрдә башкарылган эшләрдән канәгать калуын белдерде. Президент М. Шәймиев татарстанлылар исеменнән кунакларга—Россия Федерациясе Президенты В. Путинга, БДБ дәүләтләре җитәкчеләренә, аларның вәкилләренә, Россия төбәкләре җитәкчеләренә Казан шәһәренең юбилей көннәрендә бу борынгы җиргә килүләре өчен рәхмәт белдерде.

Тантаналы җыелышта БДБ дәүләтләре президентлары исеменнән Казакъстан Президенты Н. Назарбаев чыгыш ясады.

### КАЗАНДА ПРЕЗИДЕНТЛАР ҖЫЕНЫ

Казанда Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә керүче илләр башлыкларының Советы утырышы әлеге Бердәмлек алдында торган мәсьәләләргә ачыклык кертте. Иң беренче чиратта, илләр арасындагы хезмәттәшлекнең гамәли нәтиҗәлелеген күтәрү һәм шуңа ирешү юлында БДБ органнарын камилләштерү зарур, диелде саммитта.

РФ Дәүләт Советы утырышыннан соң Президент В. Путин катнашында Казан ратушасында Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге саммиты булды. Башта БДБ илләре башлыклары катнашында гына узган сөйләшү сонрак киңәйтелгән утырышка барып тоташты.

Казанга БДБ составына керүче унбер илнең дә башлыклары килде. Бердәмлек бирелә үзенең алдагы чорга яна планнарын кабул итте. Аерым алганда, "Бердәмлек органнарын камилләштерү һәм реформалаштыру турында"гы документ кабул ителде. Сонрак Таҗикстан Президенты И. Рахмонов, Казакъстан Президенты Н. Назарбаев, Әзәрбайҗан Президенты И. Алиев, Украина Президенты В. Ющенко, Грузия Президенты М. Саакашвили, Молдова Президенты В. Воронин, Үзбәкстан Президенты И. Кәримов, Әрмәнстан Президенты Р. Кочарян, Беларусь Президенты А. Лукашенко, Кыргызстан Президенты К. Бакыев һәм БДБ илләре делегацияләре катнашында узган матбугат очрашуында РФ Президенты В. Путин, БДБ органнарын камилләштерү—югары дәрәҗәдә каралырга тиешле мәсьәлә, диде.

Көн тәртибендәге мәсьәләләр шактый иде. Беренчедән, террорчылыкка каршы көрәштә килешеп эшләү юлларын хәл итәсе бар. Икенчедән, хәрби өлкәдә килешүләр кабул итеп, чик буе сәясәтен дә тикшерү бурычы тора. Саммит алдыннан кайбер сәясәтчеләр БДБнең таркалу алдында булуын, хәтта Украина белән Грузиянең әлеге оешмага альтернатив вариант тәкъдим итәргә ниятләвен әйткән иде. Ләкин В. Путин, Бердәмлекнең һәр әгъзасы әлеге берләшмәбезне саклап калырга тели, диде. Унбиш еллык тарихы булган Бердәмлекнең төп эш алымнары бүгенге чор таләпләренә җитәрлек дәрәҗәдә җавап бирмәвен күз алдында тотсаң, алга таба Бердәмлекнең структур үзгәрешләргә дучар буласына гаҗәпләнергә кирәкми.

Саммитта законсыз миграциягә каршы көрәш буенча 2006-2008 елларга исәпләнгән, террорчылыкка каршы көрәштә 2005-2007 елларда хезмәттәшлекне күз алдында тоткан программалар хуплау тапты. БДБ илләренең киләсе саммиты исә Минскида узарга тиеш. Ә 2006 ел Бердәмлек илләрендә БДБ елы булып тарихка кереп калачак.

В. Путин үз чыгышында Казанның меңьеллык юбилее БДБ илләренең хезмәттәшлеген көчәйтүдә, алар арасында гуманитар элемтәне ныгытуда зур әһәмиятен искәртеп үтте. "Бирелә гомер-гомергә төрле милләт һәм дин кешеләре яшәде, алар һәрвакыт күршеләренең рухи байлыкларына, телләренә хөрмәт белән карады",—диде ул.

### ОЛУГ ВАКЫЙГАЛАР СӘХИФӘСЕ

***

Казанның 1000 еллыгы уңаеннан башкалабызда "Бөтендөнья татар конгрессы" иҗтимагый берләшмәләре халыкара берлегенең тантаналы җыелышы узды. Анда

Россиянең 61 төбәгеннән—639, 26 чит илдән—30, Татарстаныбыз районнарыннан 215 милләттәшебез килгән иде. "Пирамида" мәдәни күңел ачу үзәгендә үткән әлеге җыенда Президент М. Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, ТЮРКСОЙ халыкара оешма генераль директоры П. Бюльбюль оглы һ. б. катнашты.

—Хөрмәтле милләттәшләр! Безнең бүгенге бәйрәмебез зур тарихи әһәмияткә ия,—диде М. Шәймиев. —Шушы бәйрәмгә бердәм булып, күтәренке күңел, якты йөз белән килеп, бер-берегезне сәламләгәнегез өчен бик зур рәхмәт сезгә.

Илбашы татар халкының барысын да үзе булдырып яши белү сыйфатына сокланып сөйләде, киләчәктә дә тырыш һәм бердәм булырга өндәде.

Тантаналы җыелышта катнашучылар алдында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, Россия Мөфтиләр шурасы рәистәше Р. Гайнетдин, язучылар Т. Миннуллин, Ф. Бәйрәмова һ. б. чыгыш ясады.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров барыбызны да борчыган, милләт өчен мөһим булган кайбер проблемаларга кагылып эчтәлекле чыгыш ясады.

***

Казанда, ниһаять, метро ачылды! Аның шулай чагыштырмача кыска вакыт эчендә (төзелеш 1997 елның августында башланды) сафка басачагына ышанучылар аз иде. Казанның 1000 еллык юбилеен бәйрәм итү атнасында җир асты юлын күрергә метрога төшкән РФ Президенты В. Путин үзе дә соклануын яшермәде, "Әмәт" станциясендә метро төзүчеләр белән очрашканда: "Рәхмәт сезгә! Җиңүегез белән котлыйм! Булдыргансыз!"—диде.

Метроны В. Путин белән бергә Президентыбыз М. Шәймиев, Казакъстан Президенты Н. Назарбаев, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, Россия транспорт министры И. Левитин, Россия Эчке эшләр министры Р. Нургалиев, Россия финанс министры И. Кудрин, РФ Президентының вәкаләтле вәкиле С. Кириенко һ. б. карады.

Рәсми делегация үзенең сәфәрен "Кремль" станциясеннән башлады. В. Путин метроның эшләү тәртибе, поездларның йөрү ешлыгы, иминлек системалары белән кызыксынды. Метро әлегә биш станциядән тора. Җир асты юлының гомуми озынлыгы 8,60 километр тәшкил итә. "Кремль", "Әмәт", "Сукно бистәсе" һәм "Таулар" тукталышларын нибары 12 минут эчендә узарга мөмкин. Станцияләрнең һәркайсы заманча итеп, исеменә туры китереп бизәлгән. Әйтик, "Г. Тукай" станциясендә шагыйрь әсәрләрен файдаланып, мозаика белән эшләнгән 22 панно бар. "Әмәт" станциясендә исә җир өстендәге матур манзара белән сокланырга мөмкин. Метроның әлеге беренче тармагын 2013 елда төзеп бетерү планлаштырыла. Ул Авиатөзелеш районын Танкодром, Таулар, Азино бистәләре белән тоташтырачак. Казан метросы исә киләчәктә өч тармактан торырга, аларның гомуми озынлыгы 55 километр булырга тиеш.

***

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры янындагы мәйданда Президент Минтимер Шәймиев Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен быелгы өч лауреатка тапшырды.

Билгеле булганча, быелгы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә замандашлары һәм Татарстанның әдәбият-сәнгать әһелләре портретлары өчен Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, РФ һәм ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы, Б. Урманче исемендәге бүләк иясе Зөфәр Гыймаев лаек булган иде. Шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, А. Алиш исемендәге бүләк иясе Рөстәм Мингалимовка бу зур бүләк "Дәрт чүлмәге" исемле шигырьләр җыентыгы өчен бирелде. Әлеге бүләкне шагыйрьнең хәләл җефете кабул итеп алды. Лауреатларның өченчесе—Россиянең һәм Татарстанның Композиторлар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Д. Шостакович исемендәге бүләк иясе Шамил Шәрифуллин. Аңа бу зур бүләк "Мөнәҗәтләр", "Авыл көйләре" хор концертлары өчен бирелде.

Тантанада РФ Дәүләт Думасы Рәисе Б. Грызлов, Төркия Дәүләт министры Бәшир Аталай, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Әзәрбайҗан мәдәният министры П. Бюльбюль оглы, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Р. Гайнетдин һәм башкалар катнашты.

***

Тантанада катнашучылар алдында танылган шагыйрьләр дә чыгыш ясады. Тукай һәйкәле янына һәм Камал театры мәйданына җыелган тамашачыларны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов сәламләде. Аннары бер-бер артлы каләм әһелләре сүз алды. Алар арасында республикабызның күренекле шагыйрьләре—Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миннуллин һәм башкалар белән беррәттән Чуашстан, Удмуртия, Мари Иле, Түбән Новгород язучылар оешмалары җитәкчеләре Валерий Тургай, Егор Загребин, Василий Крылов, Валерий Шамшурин, "Наш современник" журналының баш мөхәррире Станислав Куняев һ. б. каләм осталары бар иде.

***

Бауман урамындагы "Йолдызлар аллеясы"на танылган опера җырчысы, татар опера сәнгате үсешенә үзеннән зур өлеш керткән артист Мөнирә Булатовага һәм бүгенге эстраданың күренекле вәкиле җырчы Салават Фәтхетдиновка "йолдызлар" ачтылар.

Әлеге аллея бездә 2002 елда ачылган иде. Ул вакытта татар мәшһүр җырчыларыбыз Илһам Шакиров һәм Әлфия Афзаловага "йолдызлар" куелды. 2004 елда аларга танылган опера җырчысы Хәйдәр Бигичев йолдызы да өстәлгән иде.

***

Республика көнендә бәйрәм тантаналары яна төзелгән халыкара ат спорты комплексында да узды. Аны исә бер көн элек кенә БДБ илләренен Казан саммитында һәм РФ Дәүләт Советы утырышында катнашкан РФ Президенты В. Путин һәм ТР Президенты М. Шәймиев, БДБ илләре башлыклары, Россия төбәкләре җитәкчеләре белән бергәләп тантаналы төстә ачканнар иде...

Бәйрәм сәхнәләштерелгән тамаша белән ачылды. Анда халкыбызның үткәне—бабаларыбыз атта чапкан далалар да, риваятьләр дә, инде бүгенге ирешкәннәребез дә чагылыш тапкан иде. Бәйрәмгә республика районнары җитәкчеләре дә яхшы кәеф белән килгән. Республика кырларының һәр гектарыннан уртача 30 центнер уныш җыеп алынган. Уңышны иң күп җыеп алган район башлыклары олуг кунакларны хөрмәтләп быелгы игеннән пешерелгән икмәк каравайлары алып килгәннәр иде.

"Татарстан кырларында әлегә мондый игеннен үстерелгәне юк иде. Бу үзгәртеп кору елларында мөмкин булды. Татарстан җире эшли. Бу шулай булырга тиеш тә, чөнки ул кешегә Аллаһы тарафыннан бирелгән иң кыйммәтле әйбер",—диде М. Шәймиев. Илбашы йөгереш юлларында ат бәйгеләре кызган арада Россия Президенты призына ярышта беренче булып килгән Нурлат чабышкысы Ламборгны халыкка күрсәтте.

Ә бу бәйгеләрдә—ТР Министрлар Кабинеты призына уздырылганында Нурлат районыннан Ш. Яһүдиннын Реалистик исемле, Казан шәһәренен халыкара ат спорты комплексы призына ярышта "Татнефть" ачык акционерлар җәмгыятенен Америго исемле атлары финиш сызыгын беренче булып үтте.

***

Бәйрәмнен кульминацион ноктасы Үзәк стадионда булды. Юбилей финишын "Мәңгелек Казан" дип аталган театральләштерелгән тамаша һәм бәйрәм фейерверкы тәмамлады. Казанлыларны, кунакларны Президентыбыз М. Шәймиев һәм Россия Дәүләт Думасы Рәисе, "Бердәм Россия" сәяси партиясе җитәкчесе Б. Грызлов котлады. Шулай ук Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков та үзенен изге теләкләрен җиткерде.

—Быел Республика көне Казанның меңьеллык юбилеена туры килде,—диде Илбашы. —Шәһәр бәйрәмен үткәрү республикабыз кысаларында гына түгел, ә ил һәм дөнья күләмендә үтте. Телэгән очракта без бик күп эшләр эшли алабыз икән. Без бәйрәмне тиешле дәрәҗәдә үткәрдек дип саныйм.

Б. Грызлов та Татарстан Президентының теләкләренә кушылды. Кремльдә булып археологлар табылдыклары белән танышканнан сон, ул үзендә туган фикерләрен казанлыларга да җиткерде.

Казанның туган көнендә стадион "Миллениум" корабын хәтерләтте. Стадиондагы тамаша Казанның барлыкка килгән чорыннан алып бүгенге көнгә кадәрге тарихны гәүдәләндерде. Тамашачылар экраннан борынгы Казанның бүген нинди үсеш чоры кичерүе белән дә таныштылар. Шунда ук бөтендөньяга мәгълүм эстрада җырчылары чыгыш ясады.

***

Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Татарстан Язучылар берлегенә дә мәртәбәле кунаклар килде. 28 август көнне Язучылар йортында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов Хакасия Язучылар берлеге рәисе, күренекле балалар язучысы Галина Кужекова һәм матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге мөдире, шагыйрь Юрий Забелин белән очрашты. Әңгәмә барышында үзара әдәби бәйләнешларны ныгыту, һәр ике якны борчыган мәсьәләләр хакында фикер алышу булды.

Башкалабыз юбилее кунаклары буларак чакырылган Россия Язучылар берлеге рәистәше, "Наш современник" журналының баш мөхәррире, шагыйрь һәм публицист Станислав Куняев, Удмуртия Язучылар берлеге рәисе драматург Егор Загребин, Түбән Новгород Язучылар оешмасы җитәкчесе, прозаик һәм шагыйрь Валерий Шамшурин (ул безнен якташыбыз, Әгерҗедә туып-үскән), Чуашстан Профессиональ язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Валерий Тургай, Марий Иле Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Василий Крылов ике көн буе Казан белән танышып, шәһәрдәге үзгәрешләргә таң калып йөрделәр. Татарстан Милли музее генераль директоры Геннадий Муханов шәхсән үзе кунакларны Кол Шәриф мәчете, Благовещение һәм Богоявление чиркәүләре белән таныштырды, "Казан Кремле" музейтыюлыгындагы яңалыклар хакында сөйләде. Шулай ук Татарстан Милли музеенда, Казан ратушасында булу, "Казан" мил-

ли-мәдәни үзәгендә барган тамашада катнашу кунакларда зур тәэсир калдырды.

30 августта исә Г. Тукай һәйкәле һәм Г. Камал театры янындагы мәйданда Шигырь бәйрәме булды. Кунакларыбыз да анда бик теләп катнашты, ин изге теләкләрен тамашачыларга җиткерде.

Шул ук көнне кунаклар Аккош күлендәге Язучылар бакчасына сәяхәт кылдылар. Аларны үзенең дача йортында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин кабул итте. Бу очрашуны башка төбәкләрдә яшәп иҗат итүче төрле милләт әдипләренең дуслык очрашуы дип тә атап булыр иде. Әлеге мәҗлестә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, күренекле драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин, халык шагыйрьләре Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, шагыйрь Гәрәй Рәхим, язучылар Зиннур Хөснияр, Факил Сафин, Данил Салихов, Шаһинур Мостафин, Рауль Мирхәйдәров, Мөдәррис Вәлиев катнашты. Очрашу барышында әдәбиятләр дуслыгы, илкөн кичергән вакыйгаларга нисбәттә халыкның рухын саклыктыруда әдипләр алдында торган җаваплылык һәм бурычлар хакында эчкерсез сөйләшү булды. Кунаклар Казанның 1000 еллыгы һәм Татарстанның суверенитеты турында Декларация игълан ителүгә 15 ел тулуга багышланган чараларда катнашудан алган тәэсирләрен уртаклаштылар. Республикабыз Президенты М. Шәймиевкә, дәүләт һәм хөкүмәт җитәкчеләренә рәхмәт сүзләрен белдерделәр, киләчәктә дә Татарстан халкына имин тормыш, алгарышлы үсештә уңышлар теләделәр.

Сөйләшүне Равил Фәйзуллин алып барды һәм татар әдәбиятындагы яңалыклар, үсеш-үзгәрешләр хакында тәфсилле аңлатмалар бирде. Үзара аңлашу рухында үткән бу очрашу әдәбиятлар арасында салынган дуслык күперен ныгытуда кирәкле бер гамәл булды.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Мәгълүм булганча, 1944 елның 25 августында Германиянең Плетцензее төрмәсендә халкыбызның каһарман уллары—унбер милләттәшебезнең гомере фаҗигале төстә өзелә. Шушы җәһәттән байтак еллар инде меньяшәр Казаныбызның 1 Май мәйданында патриот шагыйрь Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләр барельефлары алдында хәтер җыены үткәрелә.

Быелгы искә алу мәрәсиме театральләштерелгән моңлы тамаша рәвешендә оештырылган иде. Ул "Торыгыз, Мусалар" исемле җыр белән башланып китте. Аннары М. Җәлилнең мәгълүм "Җырларым" шигыре яңгырады, гильотинада башлары киселгән җәлилчеләрнең исемнәре аталды. Һәр каһарманны игълан иткән саен шагыйрьләребез Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Мөдәррис Әгъләм, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Харрас Әюп, Мөхәммәт Мирза, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла үзләренең шигырьләрен сөйләде...

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үз чыгышында җәлилчеләрнең әлеге тиңсез батырлыкка рухи яктан әзер булулары, шушы фидакарьлекләре белән халкыбызны бөтен дөньяга танытулары, аларның мәдәниятебез һәм ватанпәрвәрлек тәрбиясе өчен мәңгелек мирас калдырулары турында искәртте.

Әдәби-музыкаль хәтер мәрәсимендә җырчылар Рафаэль Сәхабиев, Георгий Ибушев, Татарстан дәүләт кыллы квартеты, "Айгөл" балалар хоры, яшь башкаручы Бәйбулат Батулла һ. б.лар чыгыш ясады. Алып баручылар вазыйфасын Зөһрә Шакирҗан белән Фәнис Җиһанша башкарды.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеш керткәне, дәүләт хакимияте органнарында күп еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен язучы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары **Миңнуллин Туфан Габдулла улы** "Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен" ордены белән бүләкләнде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты. **С. Исхаков** *фоторәсеме.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы һәм актер **Хәлим Җәлә**л.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Фәйзелхак Ислаев. **Батырша восстаниесе.** 1755 ел: Тарихи очерк.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—127 б. Тиражы—2000 данә.




Тарих фәннәре докторы Фәйзелхак Ислаевның бу монографиясе 1755 елда булган халык күтәрелеше—Батырша восстаниесенә багышланган. Китапта Россия дәүләтенең дини сәясәте һәм аны тормышка ашыру, татар һәм башка халыкларны көчләп чукындыру, мөселманнарның ислам өчен рухи, икътисади, хокукый эзәрлекләүләргә каршы көрәше тасвирлана. Архив документларына таянып, восстание тарихы беренче мәртәбә җентекләп тикшерелә, күтәрелештә актив катнашкан каһарманнарның фаҗигале язмышлары ачыклана.

Хезмәт—ислам һәм татар тарихы белән кызыксынган киң даирә укучыларга адресланган.

Китапның фәнни редакторы—академик Индус Таһиров.

Сәгыйть Сүнчәләй. **Әсәрләр һәм хатлар.**—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—367 б. Тиражы—1000 данә.



Бу китап шагыйрь, тәрҗемәче, драматург Сәгыйть Сүнчәләй иҗатын чагыштырмача тулы күрсәткән басма. Китапка әдипнең 1909-1927 еллар эчендә язылган 300гә якын шигыре, ике пьесасы, хикәя, мәкалә һәм истәлекләре, көндәлеге һәм 70ләп хаты кергән. Әлеге хезмәт Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар һәм текстология бүлеге тарафыннан әзерләнгән. Төзүчесе, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче, кереш мәкалә авторы—филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев. Китап ахырында урнаштырылган "Поэт-лирик Сагит Сунчелей" исемле рус телендәге мәкаләнең авторы—филология фәннәре кандидаты Рәисә Мусабекова. Басма егерменче гасыр башы әдәби мирасын халыкка кайтаруда тагын бер уңышлы адым сыйфатында тәкъдир ителүгә лаек.

Индекс 73210



Хәлим Җәләл

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)